
ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

12.2011





**Сибгат Хәким**
**(1911—1986 )**

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2011

**12**

**(1070)**

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
**«ТАТМЕДИА»**
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—562-10-62.
Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.
Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр ........ 5
Сәгыйть ЛАШМАНЧЫ. Алман көчтәнәче. *Роман-элегия* ........ 10
Рәшит БӘШӘР. Бер җыр йөри күңелем түрендә... *Шигырьләр* ........ 112
Рушания АРСЛАНОВА. Бик сагынып искә төшерермен... *Шигырьләр* ........ 141

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Шул булды эш... *Драма* ........ 116

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР**

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Җырлап яши Мөхәммәтҗан. *Сатирик кыйсса* ........ 144
Фидаил МӘҖИТОВ. Замана чибәркәенә. *Шигырь* ........ 151
Люция ӘБЛИЕВА. Кырмыскалар йорт салалар... *Шигырьләр* ........ 152

**ХӘТЕР**

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Якты шәхес, олы иҗат *(Кави Нәҗминең тууына 110 ел)* ........ 156
Рафаэль ХӘКИМ. «Төшләргә кереп гел йөдәтә...» *(Сибгат Хәкимнең тууына 100 ел)* ........ 162
Сибгат Хәким турында замандашлары ........ 169
Гәрәй РӘХИМ. «Туры карап күзегезгә...» *(Зәки Нуриның тууына 90 ел)* ........ 171
Зәки НУРИ. Ышану. *Шигырьләр* ........ 172

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 174

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Марат ЗАКИР. Игелек иясе *(Фәиз Зөлкарнәйнең тууына 60 ел)* ........ 178
Ю. Әминовның тууына 90 ел ........ 177

Рабит БАТУЛЛА. Язучы сәфәрдән кайтты ........ 181

**РӘСЕМ ҺӘМ ИСЕМ**

Рәфикъ ЮНЫС. Ник елыйсың, Такташ? ........ 182

Котлыйбыз! *(Әхәт Сафиуллинга 75 яшь)* ........ 176
«Казан утлары» архивыннан ........ 154
2011 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге ........ 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман-элегия С. ЛАШМАНЧИ «Гостинец из Германии»;
стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Р. БАШАРА, Р. АРСЛАНОВОЙ, З. НУРИ.
«Драматургия»: драма Р. ЗАЙДУЛЛЫ «Иссякла сила и сломан меч...».
«Сенной базар»: Конкурс сатирических произведений. А. АХМЕТГАЛИЕВА. «Живет он припеваючи»; стихи Ф. МАЗИТОВА, Л. АБЛИЕВОЙ.
«Память»: статьи Ф. ГАЛИМУЛЛИНА, Р. ХАКИМА, Г. РАХИМА, посвященные 110-летию К. Наджми, 100-летию С. Хакима, 90-летию З. Нури.
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Наши юбиляры»: статья М. ЗАКИРА, посвященная 60-летию Ф. ЗУЛКАРНАЯ.
Р. БАТУЛЛА. «Конгресс литературных журналов».
Р. ЮНУСОВ. «Почему ты плачешь, Такташ?»
Из фотоархива журнала.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2011 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зима»; писатель и переводчик Наиль ИШМУХАМЕТОВ.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel-elegy by S. LASHMANCHI «Fairing of Germany»;
poems by R. FAYZULLIN, R. BASHAR, R. ARSLANOVA, Z. NURI.
«Dramatic art»: drama by R. ZAYDULLA «Dried up power and broken sword ...».
«Hay market»: Competition of satires. A. AHMETGALIEVA. «He lives happily ever after»; poetry by F. MAZITOV, L. ABLIEVA.
«Memory»: articles by F. GALIMULLIN, R. HAKIM, G. RAHIM dedicated to 110th anniversary of K. Nadjmi, 100th anniversary of S. Hakim, 90th anniversary of Z. Nuri.
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages».
«Our heroes of day»: article by M. ZAKIR dedicated to 60th anniversary of F. ZULKARNAY.
R. BATULLA. «Congress of literary journals».
R. YUNUSOV. «Why are you crying, Taktash?»
From photo archive of magazine.
Bibliography of works published in 2011.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Winter», writer and translator Nail ISHMUHAMETOV.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.12.2011, график буенча 01.12.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–1859. Тираж 4022.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.



Равил
Фәйзуллин

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Җәлил һәйкәле

**Бу һәйкәлне Шагыйрь үзе койды:
каны-җаны белән түләде.
Бу һәйкәлне Тарих үзе куйды:
тураюыбызны теләде.**

**Ил-җир өчен шәһит киткәннәрдән
чәчәкләргә күчкән кан монда.
Кем символы булса пьедесталда,
шул халыкның рухы хан монда.**

**Бу биеклек өчен яу-алышта
Казансуга күпме кан аккан...
Дошман җиңгәч: «Бу җир минеке!»—дип,
алтын хачлы казыклар каккан.**

**Ә хәзергә безнең һәйкәл тора.
Чит кавемнәр күреп соклансын!
Хәтер булып, үлемсезлек хисе
яңа буыннарда саклансын.**

**Шушы җиргә рухи терәк эзләп,
күпләр әле, күпләр киләчәкләр.
Күзләрендә булыр өмет нуры
кулларында булыр чәчәкләр.**

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943)–*Татарстанның халык шагыйре; алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Пароход бәете

Чыгардым мин бу бәетне,
тыңлаучысы кем булыр?
Аңлаучылар—җаны көйгән
тол яки ятим булыр.

Ике мең дә унбер елның
унынчы июлендә,
дөньяны тетрәткән хәл
булды Татар Илендә.

Унынчы июль—кем анасыз,
кем баласыз калган көн.
Яңа тарих битләрендә
кара исем алган көн.

Һәлакәтләр, фаҗигаләр
чыгып тора һәр илдә.
Әмма мондый да фаҗига
булмаган ди Иделдә.

Ярымватык пароходка
утыртып яшен-картын,
җибәргәннәр «ял итәргә»,
каерып билет хакын.

Акчарлаклар озата барган
бу табут-пароходны.
Эшкуар дигән козгыннар
ярда саный доходны.

Пароходмы, теплоходмы
корабмы ул—барыбер...
Каюта бүлмәләрендә
киселде күпме гомер!

«Без утырган пароходның
исемнәре дә төрле.
«Украина»[1]—төпкә тартты,
«Булгария»—үтерде...

Бер минуттан ни буласын
белмибез—Ходай ирке.
Суда батканнарның саны
йөз дә егерме ике.

Пароход йотылган җирдә
дулкыннар давыллады.
Зиратлары тарттымы әллә
су баскан авылларның?

Җирне җуеп, диңгез ясап,
ник буганнар Иделне?
Безнең хакта хәбәр булгач,
кайгы басты илемне.

Соң сәгатьтә дулкын шашты,
котырынып җил исте.
Кешеләрнең комсызлыгы
безнең гомерне кисте.

Кайсы ачык, кайсы ябык
каютэ тәрәзәләре.
Язган безгә су төбендә
мәет дәрәҗәләре...

Батканда да уйнадылар
музыка салонында.
...Бу минутта әнкәйләрнең
ни булды икән уенда?!

Без яткан комлы ләхеткә
ай нуры да үтә алмый.
Бу хәсрәтне дулкын түгел,
ил иңе дә күтәрми.

Туу—үлем башы диләр,
һәркем белә үләсен.
Әмма мондый да үлемне
дошманың да күрмәсен.

Каһәр төшкән бу дәрьяны
кара болыт каплаган.
Сәяхәткә чыкканнардан
сирәк калды батмаган.

Кемдер әҗәле җиткәндә
бер кашык суга мохтаҗ.
Тәмуг—диңгездә икән ул,
дәрья хәтле су йоткач.

Ун көн безне җыйнадылар
егерме метр төптән.
Җаннарыбыз күккә ашты,
судан чыкты бары тән.

Безне әниләр бу дөньяга
бәхеткә дип тапканнар.
Водолазлар күтәрделәр
бәйләп юан арканнар.

---

[1] Теплоход озак еллар "Украина" исемен йөрткән, соңгы елда гына "Булгария" дип атала башлаган.

**Чыгарганда безнең йөзләр**
**танымаслык булганнар.**
**Бу хәсрәткә ничек түзәр,**
**энкәй-эткәй, туганнар?**

**Бу сынауга, и Ходаем,**
**нигә безне сайладың?**
**...Күпләр озакка оныталмас**
**шушы Сөйки[2] ярларын.**

**Кышлар килгәч, дулкын түгел,**
**бу урында боз ятыр.**
**Бәлки, безнең бу фаҗига**
**Илне бераз айнытыр?**

**Һәлакәткә сәбәпчеләр,**
**ихтимал, җавап тотар...**
**Иң зур җәза: якыннарың**
**зур су күргәч, ут йоту...**

**Без батмадык, без йотылдык**
**дәрьялар упкынында.**
**Һәммәбезне яд итегез**
**догалар укыганда.**

**Биргән хәер, сәдакагыз**
**барсы савапка булсын.**
**...Илендә булмаган тәртип**
**ничек корабта булсын?!**

**Еракгагы пароходлар**
**күренә ак төсләрдә.**
**Безне хәзер күрә алырсыз**
**инде бары төшләрдә...**

**Пароходлар озатканда**
**дога кылып калыгыз.**
**Үлем хәле искә төшкәч,**
**безне искә алыгыз.**

## Халәт

**Була вакыт:**
**ачынып,**
**арганчы елыйсың...**

**Килә вакыт:**
**яшь бетә,**
**елый да алмыйсың.**

**Җитә вакыт:**
**тиледәй көләсең!**
**Чарасыз...**

***

**Гөнаһларым**
**биек тау кадәр.**

**Йөрим шул тау итәгендә**
**тынгысыз бер кырмыскадай.**

**Бер көн шул тау ишелеп,**
**мине сытып китәр шикелле.**

**Бусы—бер хәл!**
**(Мин ул нәрсә?).**

**...Империя җимерелеп (яки ныгып),**
**үзебездәй халыклар белән**
**хәрабәләр астында калсак?..**

---

[2] Сөйки—һәлакәт булган урынга иң якын урнашкан авылның исеме (Кама Тамагы районы).

## Шундый эшләр...

*«Воруют-с...»*
Н.Карамзин

**Ил нигезе корылганга**
**урлашуга—**
**байлыкның да бәрәкәте**
**юк ул шуңа.**

**Акча яки алтын урлау—**
**аңлашыла.**
**Җанны урлап сатмакчылар...**
**әрнү—шуңа!**

**Корт урынына үрчеп тора**
**поп та полиция!**
**Һәммәсе дә үзләренчә**
**халык сөя!**

**Әй, күбәйде хокукларны**
**саклаучылар!**
**Күпләр качу ягын эзли**
**«яклаучы»дан.**

**Калач урлап тотылганнар—**
**зинданнарда.**
**Миллиардлар урлаганнар—**
**йөзә данда.**

**Урлап сатып җибәрәләр**
**җанашын да.**
**Күпме гөнаһ чыга икән**
**җан башына?**

**Мондый хәлдә кем ышансын**
**хакимнәргә.**
**...Аллаһ үзе ярдәм кылсын**
**ятимнәргә.**

***

*Поскребешь русского—*
*выскребешь татарина.*
(Әйтем)

**Нишләптер бик килә кемнең**
**үз туганын егасы...**
**Уйлап чыгара мәкердән**
**БДИ[3] дигән ЕГЭсын—**
**...Менә шул була инде ул**
**Империя игосы!**

***

*М.*

**Яшьлек илләреннән**
**илче булдың.**

**Бәхет катларына**
**димче булдың.**

**Авыр хәлләремдә**
**имче булдың.**

**...Ә хәзер соң үзем**
**«Кем»че булдым?**

***

**Балачагым болыннары**
**язын тагын яшәрде.**

**Теләгән белән яшәлмәде,**
**язган белән яшәлде.**

[3] БДИ—бердәм дәүләт имтиханы, ЕГЭ—единый государственный экзамен.

...Карлыгачым, сөртеп китче
керфектәге яшьләрне!..

## Дүртьюллыклар

***

Зур кайгылар, афәт–һәлакәтләр
кешеләрне берләштерә.
...Шул чакта да ятим малны
кайберәүләр үзләштерә.

***

Мәхәббәттә хәер сорашмыйлар.
Горурларга ялыну килешми.
...Диңгезләрне атлап чыга алсак та,
кичә алмыйбыз кайчак инешне.

## Гыйбрәт

Сәддам Хөсәеннәр, Каддафиләр[4]
Соңгы юлга ничек юлланды!
Янә «Король Лир»лар искә төшә.
Беркем белә алмый финалны.

***

Хурлык атавын күтәрү
зурлык билгесе түгел!

...Бер бисмилла әйткән өчен
ике тапкыр... төртенү!

## Көнләшү

Төшләремдә минем тибрәнәсең
офыктагы рәшәләр кебек?
...Таң алдыннан тәрәзәңә чиртеп,
кемнәреңдер дәшәләр кебек.

***

Булды заманнар:
уйнадык, көлдек!
Яшь, таза чакны
мәңге дип белдек.

Күнеккәч кенә
якты кояшка,
әйләнеп куйды
гомер—баешка...

Картлык ягы да
үзенчә кызык.
Ходай Тәгалә
куйганчы сызык...

[4] Сәддам Хөсәен, Моамар Каддафи – озак еллар Гыйрак һәм Ливия илләренең юлбашчылары булып торган шәхесләр.



Сәгыйть Лашманчы

# АЛМАН КҮЧТӘНӘЧЕ

РОМАН-ЭЛЕГИЯ

## I бүлек

—Әй, Илаһым Кадыйр, килә бит, килә...—дип пышылдады Сара карчык. Хәлсез, кайнар иреннәре әвәләгән сүзләрдән аның зиһене ачылып китте. Соңгы көннәрдә ачы сагышка чумып йөрүенең чын сәбәбен кырыс сүз белән әйтеп, атап бирә алуыннан тетрәнеп куйды. Синнән генә калмаган, күпме сузсаң да, Алла кушып, бер каршыңа килә шул ул... Чалгысын иңенә асканмы—баш очында селтәнерме ул шуның белән, яисә шыр сөякчел куллары белән бугазыңнан кысып алырмы, әҗәл дигәнең барыбер алдыңа килеп, җаныңны алмый калмый. Яшәгәндә берәүләр солтан, икенчеләре олтан булсалар да, үлем дигән ачы суттан һәркемгә дә өлеш тигез чыга... И Ходайның бирмеше! И адәм акылы ирешмәслек мәгыйшәт! Алдында торган гаҗизлеккә карап нинди сүз әйтәсең, нинди теләкләр телисең? Җиңел үлем бир, Аллаһым, дип ялварудан, шул хакта догалар укудан башка тагын нинди сүзе булырга мөмкин адәмнең...

Һай, җебесә дә җебер икән кеше әҗәл җиле каршында! Әле бит атнаун көн чамасы элек кенә Сара карчык үз мәгыйшәтендә чәмләнеп дөнья көткән затлардан иде. Дөрес, тар инде, артык тыйнак инде аның мәгыйшәте. Хәер, җитмеш кунып килгән корткадан тагын ни көтәсең? Әмма барыбер кешене гамьнәргә салып, аякта тотып килгән чак, яшәү бит әле бу. Ул таң белән торып кәҗәсен сава. Сакалбаен ипи катылары белән сыйлап, сөйләнә-сөйләнә мамыгын тигәнәктән арындыра. Сарык, яркаларына да сыйдан өлеш чыгара һәм барысын үзенчә карап, күздән кичереп, көтүгә озата. Бертуктамый үзенә ияреп чапкан тавык-чебиләргә дә җимнәр сибә хуҗабикә. Чирәмле йортында кабаланып, бер-берсен төртешә-төртешә бөртек чүпләгән озын торыклы эре чуаркайлар Сара карчыкның аерым игътибарында. Авылга килгән инкубатор машинасыннан унбиш чебеш сатып алган иде. Ходайның рәхмәте, барысы да тавык затыннан булып чыкты. Кул назына атлыгып торалар. Сара карчык чүгәләп, берәрсенең йомшак кына аркасын сыпырса, чабышып киләләр дә аның кулы

---

Сәгыйдулла ХАФИЗОВ (тәхәллүсе – Сәгыйть Лашманчы) (1945) – *язучы һәм әдәби тәнкыйтьче; филология фәннәре докторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Җ. Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты. Уфада яши.*

кагылганны, сыйпаганны көтәләр. Ни хикмәттер, карчыкның бирчәйгән кулларыннан назланган чуаркайлар ярып килгән канатларын җилпиләр, үзләренчә киерелеп, кагынып куялар...

Карчык әлеге эшләр белән йорт-курасында мәшәкатьләнгәч, өенә кереп самавырын куя. Ул кайнап чыкканчы дип түшәктә яткан ире Хабул янына килә:

—Хабул... Хабул димен, өенңдәме син?

«Өенңдәме син?» дип эндәшүе юкка түгел. Картын паралич сукканга менә өченче җәй үтеп бара инде—аяксыз калды. Әүвәлге мәлләрдә бик каты ыңгырашкалап, үзен-үзе белештерми түшәктә бәргәләнгән иде. Ходайның рәхмәте, соңгы вакытларда ничектер тынычланып калды. Күбрәк йоклап уздыра. Әле менә Сара эндәшкәч, Хабулның күз кабаклары тартышып куйды, аңа тоныкк карашлы конгырт күзләре төбәлде.

—Ә?—диде ул, ниһаять, өн чыгарып.

—Астың корымы?

Карт чак башын кагып куйды. Урыны коры, таза димәк. Монысы да Сара өчен зур сөенеч. Югыйсә, баштарак авыру астындагы җәймәләрне алыштырып, тәнен юып бик изаланган иде бит. Тора-бара әмәлен тапты үзе. Келәттәге иске-москы тутырылган сандыкта әйбер эзләп казына иде, кулына ирләр йодрыгы чамасындагы жиз кыңгырау килеп эләкте. Сабыйларча мавыгып төрле яктан күзәтте, шалтыратты. Зең... зең... зең! Тавышы бәллүрнекедәй саф, яңгыравык, ачык. Башта Сара карчык кыңгырауны истәлек дип сөенде. Хабуллар йортына килен итеп төшергәндә, аны әтисе сөлгеләр белән бизәлгән ат дугасына үзе бәйләгән иде бит! Хәер, бер генә дә түгел, икәү иде, парлы иде кыңгырау. Ат тояклары тавышына, чана табаннарының зыңлавына кушылып яңгыраган әлеге кыңгыраулар чыны әле һаман колагында тора:

—Зең, зең—килен төшә, килен! Йортка ямь төшә, сөю төшә—зең, зең...

Мир өстендә йөреп, байтак киленнәрне кияү йортларына төшергәч, кайсыдыр бите юмаган нәрсә кыңгырауның берсен йомды, ә икенчесен Сара үзе ил-көннән яшерде. Шуннан бирле онытылып сандыкта яткан икән ул...

Кортка кыңгырауны янә селеккән иде, көмеш чыңнары зиһенен кымшатып үтте: «Моны Хабул кулына тоттырырга кирәк. Хаҗәте булса, чылтыратсын!» Сара карчык, кош тоткан сыман сөенеп, иренең баш очына килде.

—Менә, Хабул, йомышың төшсә, шулай шалтыратырсың, яме?

Хабулның чырае сытылды:

—Н... ни эш...шләргә?

—Йомышың булса, шалтырат, димен. Аңлыйсыңмы? Урыныңны пычратма!

Хабулның йөзеннән кызыллык йөгереп узды. Әллә көлде, әллә рәнҗеде—белмәссең... Тик акылы ул дәрәҗәдә үк чуалмаган икән. Кысталса, караватының башына бәйләнгән кыңгырауга үрелде, Сара карчык янына килеп басканчы селкеп торды шуны.

—Зең, зең—ашыгыч ярдәм кирәк!

Сара карчык Хабулның түшәк-мендәрен рәтләде, йомшак чүпрәкне җылымса суга манчып иренең битен сыпырып чыкты, кулларын юды. Хәзер инде картына чәй эчерергә мөмкин...

Ниһаять, үзенең дә кипкән иреннәренә, сусаган тамагына хуш исле, сөтле чәй тияр мәл житә. Чеметеп кабарга бал, яисә йомшак кәнфите булса, чәй эчү кәефен арттыра, бәдәненә дәрман өсти.

Аннары намаз. Ходайдан үзенә, ире Хабулга исәнлек, иминлек сорап ялварулар... Намаздан соң Сара карчыкны бакча эшләре көтә. И, мондагы мәшәкатьләрне тавык та чүпләп бетерәсе түгел! Тик, шөкер, үсәсе барыбер үсеп, җимешен биреп тора. Суганы да шалкан кебек күкрәк җәя. Түтәлләрдә тәгәрәшеп яткан яшькелт кыярлары, кызарып килүче помидорлары күзне иркәли. Бакча эшләре белән ихлас мавыгып, төш килеп җиткәнен дә тоймый кала Сара карчык. Җир җимешләре белән иренә, үзенә тәгам әзерли. Суганлы, борычлы яшелчә шулпасын Хабул да яратып чөмерә. Табак-савытны юып, чистартып куйгач, башны мендәргә төртсәң, кич тә җитеп куя. Сара карчык кулына ипи тотып кәҗәсен, сарык, яркаларын каршылый. Беркавым шулар белән әвәрә килә: сөтен сава, өс-башларын тазарта...

Кичке эшләр, мәшәкатьләр тезмәсендә янә күңеле тарткан бер юанычы бар. Каршы күршеләре Гапсаттарның иркен эскәмиясенә кунаклап, күршеләре белән, ахирәтләр белән сөйләшә, төрледән-төрле хәбәрләргә, хәл-әхвәлләргә ирешә бу. Кунак ашы—кара-каршы дигәндәй, сорасалар, Сара карчык та шунда үз күңелен, эчен бушата... Капка төбендәге күңелле җыен әле һаман гөрләп кала, әмма корткабыз ай яктысыннан хасил булган шәүләсе белән җитәкләшеп, инеш ягыннан килгән бакалар тавышына колак салып, өенә ашыга. Хабул кыңгыравын чылтыратып ятмасын тагын... Карты янына килеп, хәл-әхвәлен белешә, аның йомыш-гозерләрен үти дә, догаларын укый-укый йомшак түшәгендә йокыга чума торган иде Сара карчык...

Урыс атнасы таңында Сара карчык бик ямьсез төшләр күреп, бастырылып уянды. Ләхәүлә! Җен-шайтан кагыла түгелме соң? Тик өенендә дә хәле шәптән түгел икән. Башы авырта, тәне дә биниһая каты сызлый. Дарулар кабыннан баш төймәсе алып, су белән йотарга җыенган иде, тамагының бик каты шешкәнен чамалады. Хәер, беренче тапкыр гына түгел, тамак хастасы даим-даим кәефне кыра инде. Хәленә төшенгәч, элеккечә үзе җәен җыйган чәчәк-үләннәрдән чәй әзерләде. Кайнар, парлы сыекча тамагын иркенәйтте, авырту-сызлау да кинәт басыла төшкән кебек тоелды. Чир, минем башыма кунма, кун казык башына, дип пышылдады Сара карчык һәм көндәлек эшләренә керешеп китте...

Тик Ходай багышлый, бәндә сагышлый икән... Кичен тамак хастасы янә көчәеп китте. Ә төнен исә авырту-сызланулардан күз дә йомалмады кортка. Сулышы буылып, хәтта ятып тора алмаслык хәлгә килде ул. Йа, Алла, нинди яман зәхмәт соң бу? Грипп-мазар микәнни, дип уйлады Сара карчык һәм пунктка барырга, Зәйнәп духтырга күренергә кирәк дигән уйга килде.

Көләч йөзле, купшы бәдәнле, сөйкемле Зәйнәп Сара кортканы гадәтенчә шаяртып каршылады:

—Әйдүк, Сараттәй... Бәй, таякка таянгансың түгелме? Таякны Хабул абзыйдан прокатка алдыңмы? Берәүләр прокатка машина ала. Икенчесе бала арбасы. Син инде таякка калдыңмы, Сараттәй?!

—Әйтмә, Зәйнәп кызым. Менәтрәк тамак күзне ачтырмый. Баш казасы...

Зәйнәп духтыр Сара карчыкның авыз, тамак тирәсен бик озак күзәтте. Лампа куеп та, лупа тотып та карады. Ә аннары эскәк кебек озын саплы җиһаз белән шештә казынып, бәләкәй пыяла кисәгенә берничә тамчы лайла да тамызды.

—Сараттәй... Ни бит әле, тамагың бик әйбәт түгел. Салкын тигәнгә генә охшамаган шеш бу. Ныклап карарга кирәк!.. Менә анализ алдым. Аксуга озатырбыз. Берничә көннән җавап килер. Аксуга барып, операциягә ятарга туры килмәгәе Сараттәй...

—Һе, шулай укмы?—дип артык гаҗәпләнде Сара карчык.

—Әйе, Сараттәй, начар хәбәргә дә әзер булып торырга кирәк. Ходай

саклanганны саклармын дигән бит!

Сара карчык беркавым хәрәкәтсез калып урындыкта утырды. Күрәмсен, ул табибның әлеге шөбһәле сүзләрен үз хәленә каратып, нидер үлчи, исәп тота иде.

—Күпме ятармын соң, кызым, Аксуда?

—Операция ясалса, ярты айлап булыр инде, Сараттәй...

Карчыкның йөзенә сыкрау галәмәте бөркелде.

—И, Зәйнәп кызым, ярты ай дисең. Ай-һай! Түшәктәге картымны кем кулына калдырам инде мин?

Кортка авыр гына урыныннан кузгалды, диванлагы мамык шәлен иненә ябынды, таягын кулына алды һәм үзен сүзсез генә күзәтеп торган Зәйнәпкә карап тыныч кына үз сүзен әйтте:

—Яшем житмешкә якынлаша. Ходай ни язса, шул булыр инде, кызым...

—Туктале, бик борчылма, Сараттәй. Анализ нәтижәләрен көтик, аннан сөйләшербез,—диде Зәйнәп духтыр. Һәм «менә монысын көнгә өч тапкыр эчәрсең, монысын тамагың бик әрни башлагач йотарсың», дип күрсәтә-күрсәтә дарулар тоттырып карчыкны өенә озатты.

Чирлим дип урын өстендә ятарлык әмәле бармы соң Сара карчыкның?! Кәжәсен савасы, сарык, яркаларын карыйсы, көтүгә озатасы, каршылыйсы бар. Иртә-кич бусага төбенә өелешеп тавык, чебешләре көтә. Әнә гел-гел Хабул кыңгыравын шалтыратып тора. Чирли бу дип тормыйлар, һәркайсын ашатырга-эчертергә, тәрбияләргә кирәк хужабикәгә. Ни хикмәт, Зәйнәп духтырның дарулары да авыруга имләү бирде, кортканы һаман аяк өстендә тотты. Ә вакыт дигәнең, синең сызлануларга карамый, һаман үз жаена тәгәрәп ята икән. Өченче көн, иртән малларын көтүгә озатып, самавырына гына тотынган иде, ишек шакып Зәйнәп духтыр килеп керде. Эш кешесе шул, ашыга да булса кирәк, тәкәллеф саклап тормады:

—Сараттәй, сине утырмага озатырга дип килдем. Әйдә, жыен!

Почмактагы кортка «лып» итеп артына утыра язды. Дөресен әйткәндә, ул үз хәлен һич кенә дә начарга юрарга жыенмаган иде. Чынлап та, нишләп ябышсын аңа нинди дер яман чир. Ходай каршында гына түгел, адәмнәр алдында да бер хөсетлеге юк сыман. Эш башында утырган яисә адәм башына басып йөргән нинди дер күрекле зат та түгел. Гап-гади жан иясе. Кемнеңдер каргышы, бәддогасы төшәр дип шикләнергә урын юк, димәк... Менә сина кучтәнәч! Исәпкә бар, санга юк дип йөргән кешене зурлау!

—Сараттәй, ник эндәшмисең?—дип Зәйнәп өйгә узды, карчык янәшәсенә үк килеп басты.—Сине мактарга кирәк, Сараттәй. Бик вакытлы килдең. Чиренәле яңа башлана. Операциягә өмет зур. Терелерсең. Никадәр тизрәк барсак, шулкадәр яхшырак булыр. Тик дүрт-биш меңләп акча кирәк булыр инде, Сараттәй. Хәзер дәвалану түләүле бит...

—Акча гына табылыр ла ул, Зәйнәп кызым. Пенсияләр килеп тора бит. Кәфенлеккә, кабер садакаларына жыйганы да байтак кына,—дип ниһаять фикер чуалчыгын бер агымга салып тавыш бирде Сара карчык.—Тик әйттем бит инде, Зәйнәп кызым, Хабулымны кем кулына калдырам инде? Үзем китеп, ирем белән берәр хәл булса, кеше күзенә ничек күренермен мин? Юк, ташлый алмыйм түшәктәге чирлене. Ир бит ул, хәләлем бит!

—Һи, юкка хафаланасың, Сараттәй! Мин сөйләштем инде. Иреңне Аксудагы картлар йортына урнаштырып торырбыз. Анда ул син аякка басканчы торыр да, янә алып кайтырбыз,—диде Зәйнәп.

—Һе! Алып калырлар дисеңме?—диде кортка чынлап торып аптырап.
—Тик минем Хабулым барырмы соң Аксуга? Барса, бер хәл...

—Ник бармасын, Сараттәй,—диде Зәйнәп һәм баягы кызулыгы белән

өй хуҗасының ятагы янына килеп, тавышын тагын да күтәрә төшеп әйтеп салды:

—Хабулла абзый, Аксуга картлар йортына кунакка барасыңмы? Анда дәва яхшы. Матур әбиләр күп...

Хабулның күзләре ачык иде. Өйдәге тамашаны күреп, хәлне беркадәр аңлап ятуы да хактыр мөгаен. Ләкин ул үзенә кагылышлысын өр-яңадан башлады:

—К...ка-ая бар-рырга?

—Аксуга, картлар йортына, Хабулла абзый...

Хабул беркавым төбәп Зәйнәп духтырга карап торды. Көрән күзләрендә ниндидер саран, зәгыйфь, әмма очкынлы чаткылар биешә башлады. Ул да булмый, аларга акрынлап яшьләр тулышты, менә алар күздән ташып бит буенча тәгәрәштеләр, мендәргә тамдылар. Хабул уң кулын күтәрде дә, әле бер күзен, әле икенчесен каплап, балаларча сулкылдап еларга кереште. Эчтән, тирәннән бәреп чыккан тыелгысыз ихлас елау иде бу.

—Сар-ра мин-нән й-йөз чө-чө-ер-рәме? Карарга ч-чир-канамы?

Иренең елавын тетрәнеп карап торган Сара карчык әлеге сүзләрне ишеткәч, күзләрен каплап почмак ягына елышты. Ул да такмаклый-такмаклый елый башлады:

—И, җаным! Сара миннән йөз чөерә диме? Сара мине карарга чирканамы диме? И, Ходаем, нишләп ташлыйм ди мин Хабулымны!

Шулай беравык яшен түккәч, Сара карчык яулык очы белән күзләрен сөртә-сөртә Зәйнәп духтыр янәшәсенә килеп басты:

—Инде, кызым, вакланмыйк! Үлем каршында да кеше булып калыйм. Бармам инде Аксуга. Минем хакта кайгыртуларың өчен мең рәхмәт сиңа, Зәйнәп кызым!

—Хәлең бик җитди бит, Сараттәй. Карышып, Нуриәсма апа хәленә каласың бит!—диде Зәйнәп сагышлы карашын авыруга төбәп.

Нуриәсма—каршы күршедәге Гапсаттарның хәләл җефете иде. Чиксез уңган иде, чая иде. Пенсия яшенә җитсә дә, фермада яшь хатыннар белән ярышып сыер сауды. Сатар өчен дип, бакча-бакча бәрәңге үстерде. Нәкъ бәрәңгеләр утырткан мәшәкатьле бер мәлдә Нуриәсманың аскы ирене чабырып чыкты. Ирен чабыру—аяк-кулны кычыткан чагу белән бер. Нуриәсма да ярасына май сөртеп байтак вакыт бер пошынусыз йөргән иде. Сара карчык күршесенең иренендә чиләнеп, кан саркып торган яраны күреп үзе дә әйтте: «Хәерлегә түгел бу, Нуриәсма, Зәйнәп духтырга күрен!»—диде. Инде шул вакытта ук хәле мөшкел булгандыр Гапсаттар хатынының, тик табибка барырга гына вакыт тапмаган шул... Хәер, атна-ун көннән соң Сара карчыкка үзе килеп зарланды Нуриәсма: «Ирене—ирен... Бөтен тәнемне чуан басты бит, Сараттәй. Нинди им табыйм икән?»

Нәрсә әйтәсең үз сәламәтлегенә үзе төкергән кешегә? Нуриәсма үз белдеге белән мунчада кайнар миңлек белән тәнен пешекләгәч, һушы китеп егылган.

Зәйнәп духтыр тик шунда гына авыруга тап була. Иртәгәсен, ике дә сөйләтмичә, Гапсаттарны машинасы белән Аксуга куа. Тик Гапсаттар Нуриәсманы ничек утыртып китсә, шулай өенә алып та кайта. «Рак дигәннәр, соң дигәннәр...» Нуриәсма ике атна чамасы сызланып урын өстендә ятты да теге дөньяга китеп барды шул...

Авыл табибәсенең Нуриәсма апа хәленә каласың бит, дигәне әнә шул куркыныч хаста белән искәртә инде ул. Әлеге афәттән Сара карчык кош булып, канатларын бар көчкә җилпеп качар иде дә бит... Әмма теле башканы тәкрарлый шул:

—Үз хәлемне аңлыйм инде, Зәйнәп сеңлем. Тик күрәсең бит... Язмыш,

Ходай, шулай кушадыр инде. Гаепләмә, кызым!

Зәйнәп духтыр дәшмәде. Күрәсең, ул, ниһаять, Сара карчыкның холкын, тормыш хәлләрен бөтен җитдилеге белән аңлады. Операция ясату—кешенең үз ихтыярында. Теләми икән, мылтык терәп хирург өстәленә яткыра алмыйсың... Ул сумкасын алып, шыпырт кына өйдән чыкты. Бераздан урамда, йорт каршында торган машинаның яман фырылдап кузгалуы колакка чалынды...

Сара карчык кош булып очып чыгар хәлгә җиткән йөрәгенә тоеп Хабул ятагына килде. Кулы белән иренең чал башына, төкле аякләренә кагылды. Күзләр белән күзләр очрашып алды.

—И, җаным, нишләп синнән йөз чөерим инде мин. Хәләлем бит син... Тик минем хәзергә үз хәлем мөшкел бит, Хабул. Чирлим мин. Аңлыйсыңмы шуны? Хабул башын какты:

—Сар-ра! Алманнан к-кайтт-кан куыкны чыг-гар! Ик-кес-сен дә. Бер-се сиңа, бер-се миңа... Аңладыңмы?

Иренең әлеге сүзләре Сара карчыкның янә күңелен айкап ташлады. Бу ике куык Хабулның әсирлектән алып кайткан күчтәнәчләре... Егерме ел элек ир шуны таптырып җан талашты. «Китер, кабам да, вәссәлам!» дип үзе дә актармаган урын калдырмады. Ә кеше башына җитәргә сәләтле куркыныч куыкларны Хабул сугыштан кайтып Сара кулына ничек тоттырган булса, шулай келәтнең бүрәнә куышында төргән килеш ята бирделәр. Ике куык—ике гомергә әҗәл... Ә нәрсә? Чынлап та котылу әмәле түгелме соң бу?

Сара карчыкның тәненнән җинел елдырам йөгереп узды. Аны алда яткан куркыныч, шомлы диварны үтеп чыгу, яисә адашкач, ышанычлы сукмакка төшү кебек юанычлы бер хис биләп алды. Ә хатынына төбәлгән Хабул, әйтерсең, аның эчке уйларын укып бара:

—К-кайчан?

—Атнакич, Хабул! Аңладыңмы?

—Аң-н-лыйм, хатын!

Атнакичкә әле тагын туп-тулы дүрт көн бар иде...

### II бүлек

Авыл җан исәбе белән түгел, сау капкалы нигезләр саны һәм керер кыр-капка белән чыгар кыр-капка арасының озынлыгына карап санлана. Киресенчә булса, коры яланга күп катлы иләмсез зур бер йорт утыртып та, авыл ясарлар иде югыйсә. Түреш исә—бик чәчелеп утырган борынгыча озын сала. Нәкъ шуңа зур авыллар исәбенә керә ул.

Хабулларның йорты авылның таң ягы читендә, аулак бер почмакта утыра. Бәрәңге бакчаларының аръягы хәтта яшел битләүгә үк барып тоташкан. Иренмичә шул чирәмле, чалулы битләүгә барып чыксаң, аякларың үзләреннән-үзләре сине калкулыкка әйди. Биек кенә үзе, ешрак атласаң, хәтта йөрәгең сикеренә башлый. Ә сыртына менеп басып башыңны күтәрсәң... Йа Хода, менә кайда икән ул гүзәл тамаша!

Күңелеңне галәмәт ерак, зур кинлек, иркенлек биләп ала. Иген кырлары да, чәчәкле болын, тугайлар да, киртләч-киртләч тезелгән яшькелт, күксел урманнар, туйралыклар да бар анда. Ә янәшәңдә, синең аяк астыңа ук сарылып диярлек шактый мул сулы, йөгерек Түреш ага. Тыңлыйм дисәң, аның әрәмәсендә төрледән-төрле кошлар сайрый, чыпчык, саесканы чыр-чу килә. Тотыйм дисәң, суында учак ягып аш куярлык балыклары сикерешә... Валлаһи, ачкычсыз, түләүсез керә торган бер җәннәт почмагы инде бу!

Сара карчык таягы белән җитәкләшеп авырлык белән, тыннары кысыла-кысыла булса да, әлеге сайранга күтәрелде. Әйтми булмый, эче пошкан мәлләрдә ул монда еш чыкты. Малларын карап, кояш батып, ай калыккан

матур кичләрдә Хабул белән дә бәрәнге үсентеләрен карап, киртә-кура төзеклеген күзәтеп, монда мөнгәләделәр. Жәйдә кайткан кунак-тумачаларны да әлеге хозур урынга алып чыгып, учак ягып чәй кайнаталар, табын коралар иде. Хабул гармунын уйный, берәрсе кушылып җыр башлый иде...

Зәңгәрсу томанлы, тымызык август иртәсе. Хәер, тегеннән-моннан ерткаланып, томан пәрдәсе инде таралып килә. Ара-тирә исеп куйган йомшак, дымлы җил эше бу. Салкынча һава дулкыннары карчыкка да бәрелеп, тамак кайнарлыгын баса, тән-бәдәненә җиңеллек бөрки.. «Ис әле син, җилкәй, ныграк ис!—дип пышылдады Сара карчык. Минем күңелемне дә җиллэт әле, җил! Серләремә кагыл, хәсрәтемне тыңла, сагышларымны тарат әле син. Кешеләргә сөйли, хәтта ахирәтләремә әйтә алмаганны, түкми-чәчми сиңа җиткерергә җыенам бит мин...»

Сара карчык чыннан да зур сүзгә керешергә торган кеше сыман тамагын кырды. Сызланудан куырылып куйды, күзенә яшь бөркелде. Бераздан әрнү акрынлап басылды. Күңеленә янә тезелешеп уйлары кайтты. «Әй, кыйбла җиле, мин сине таныйм бит. Син җиргә ләйсән яңгырлар белән чәчәкле, ямьле язлар китерәсең. Сиңа ияреп туган якларына очар кошлар кайта. Жәйге челләдә, бөтен чәчкән, утырткан ризык дымга көеп яткан бер вакытта күкрәтеп китергән шифалы явымнарың белән җиргә тернәкләнә, имләнә бирәсең син, кыйбла җиле. Дөрес, кырку да син, каудар да син кайчакта. Өермәләр, давыллар булып та күтәреләсең, адәмнәр күңеленә шом, куркулар да саласың син. Әмма болардан башка безнең мәгыйшәт тә, алмашыну, михнәтләрдән рәхәткә күчү буламыни?.. Аллаһыма мең шөкер, мин синең гарасатларыңны да, рәхим-шәфкатьләреңне дә тигез тоеп яшәдем. Барысы өчен рәхмәт сиңа кодрәтле җил!

Тик мин сиңа рәхмәт әйтер өчен генә тауга менмәдем, син җилкәй белән саубуллашырга дип килдем. Хушлашу дигән нәрсә синең өчен яттыр, мөгаен, җилкәй. Бу хисне аңлап та бетмисеңдер. Тик Ходай адәмнәргә туу, яшәү бәхетен биргән кебек, дөнья белән хушлашу сагышын да салган шул. Син, җилкәй, үзең әлмисактан бирле яшәү җегәре, вакыт юлдашы булып киләсең. Ә кешеләрнең гомере, ай-һай, чикле шул... Соң син үзең үк минем нарасый чакны хәтерлисеңдер. Аз гына төртсәң дә, авып китәргә торган бер бәбкә шае идем ласа. Буй тартып, яшьлек канатларында талпынуларым да исеңдәдер. Сиңа ияреп, әллә кайларга, гүзәл дөньяларга очып китәргә торган дәртле чак иде бу. Ир хатыны булып, ат кебек басылып тормыш арбасын сөйрәүләремә, шулай ук шаһитсың бит син. Минем яшәгән гомер синең өчен, җил, бакыйлыктагы берничә кәррә талпыну кебек кенәдер. Ә мин шул арада чал чәчле, өшәнгән һәм таякка таянган бер карчыкка әверелеп каршыңда басып торам. Туным, тәнем тузган, тик җанда яшәргә нәфсе бар әле. Әй, җилкәй, яшәүдән кем генә туя икән соң?..

Әмма нәфесе-нәфес, акыл җанымны тынычлыкта калдырамы соң? Тәндә дәрман беткәч, чирләрдән сыкрап яшәүнең кызыгы бармы, дип үзеңнән еш сорыйсың. Яшәү дигән бөек сөенечне һаман тулы татып буламы бу чакта? Юк бит! Тән-җан сыкравы сиңа дөньяга рәхмәтләр әйтеп, инде китәргә вакыт икәнен искәртә, җилкәй. Алда синең назларыңда башкалар рәхәтләнсен, синең белән бүтәннәр серләшсен, кыйбла җиле! Көнләшәм мин, урынымны бирү авыр миңа, әмма безнең яшәү кануны шундый кырыс шул...

Киткәндә дә адәм башы җиңел генә араланмый, котылмый, җилкәй. Беләсеңме син, ахирәткә кичеп Ходай каршына басасы адәм җан сафлыгы, гыйффәтлеге турында уйлый. Тормыш үткәндә гамәл дәфтәренә гөнаһлар теркәлмәгәнме? Языклары бармы? Боларны кайгы, сагышлары белән яшәгәндә түләп бетергәнме ул? Дөньялыкныкы тик дөньялыкта каламы?

Яшермим, бу уйлар мине дә шөбһәле итә, куркыта. Иң курыкканым—ирем Хабул белән берләшеп яшәүдән ваз кичү. Үз-үзебезгә кул салу, әҗәл чакыру... И, Ходаем, әйтү дә куркыныч. Бу бит, мөгаен, зур гөнаһтыр... Тыелган гамәлдер... Кеше булган кеше алай эшләмидер. Тик башкача булмый бит, җилкәй. Мин хасталанып, әҗәл каршында торам. Ә Хабулым яшәп калса, ни хәл булыр? Түшәккә кадакланган зәгыйфь ирне кем тәрбияләр? Кем аны ашатыр-эчертер? Кем аның астын алыштырыр, тазартыр? Үзем исән булсам, Хабулның үлем куыкларына бер хаҗәт булмас иде дә бит. Гаҗизлек, чарасызлык безне шул юлга этәрә шул, җилкәй...

Әйт син, дөньялыктагы дөньялыкта калсын өченниләр кылырга, кайсы кодрәтле догаларны укырга икән миңа, әй, мәңге бакый кыйбла җиле?!»

Тауга басып җилгә шулай үзенең кайгы-сагышларын түккән Сара карчык борынгы таш балбалны хәтерләтте.

## III бүлек

Кеше туа, аякка баса, балигълык яшенә дә җитеп килә. Тик буй тартса да, асылын ачмаган әле ул. Һаман да канат яра алмаган төксе бәбкә кебек... Аның исем-шәрифләре дә тирә-юньдәгеләрнең исен китерми. Холык-фигыленнән дә халык бер фәһем алмаган әле. Кыскасы, исәпкә бар, санга юк. Әвәләнелмәгән әле кеше! Моның өчен әлеге дә баягы кыйбла тарафларыннан кискен җил исеп кую, язмыш сәхифәсен кузгатучы, битне ачучы бер көч кирәк.

Күпләребезгә кагылышлы бу гадәти хәлне искә алсак, Сара Кыям кызының тәрҗемәи хәлен 1935 елдан башларга кирәк. Бу елда аның тормышында ике зур вакыйга булды. Май аенда, шомыртлар чәчәк атып, бәрәңгеләр утыртып яткан мәлдә ул Казаннан китапханәчеләр курсын тәмамлап кайтты. Бу ят һөнәргә аны колхоз идарәсенең карары белән укырга җибәргәннәр иде. «Клуб салабыз, китапханә эшен белгән кеше кирәк», дип эзләнә башлагач, артель бригадиры Кыям кызына тукталдылар. Былтыр, унынчыны тәмамлаган Сараның үзенең дә «Кая барыйм?» дип аптыраган чагы иде. Берсүзсез килеште.

Дөрестән дә, авыл уртасында өр-яңа клуб кукыраеп утыра. Аның янында китапханә ачылачак. Нарат сагызы, буяу исе аңкытып торган, кояш нурлары белән тулган иркен залга Сара, оҗмах бусагасын атлаган кебек, чиксез сөенеп керде. Ул бит, әле унсигезенче яшенә яна аяк атлаган кыз, менә шушы мәгърифәт учагының мөдире булачак!

Авыл башлыгы Минач, әлеге клубны үзе юллап корган кеше, хезмәткә тәгаенләр алдыннан Сара белән, өстәленә таянып, бик җитди сөйләште:

—Курсларны бик яхшы билгеләргә тәмамлагансың. Өстәвенә, грамота да биреп җибәргәннәр икән үзеңә, Әбүталипова. Һәйбәт! Инде Түреш халкын сәяси агарту фронтында җиң сызганып эшкә керешерсен дип ышанабыз. Хезмәтең бик революционный әһәмияткә ия бит, Әбүталипова. Укытучыларың да моны гел искәрткәннәрдер. Мин дә кабатлыйм...—Хром итек, галифе чалбар, күн тужурка кигән зәңгәр күзле сөйкемле ир уртасы, эчке киеренкелек тоеп бугай, урындыгыннан торды, йөренеп алды.— Сеңлем, син бик яшь әле, шуңа искәртәм. Бу эштә суллык чалуланулары да, мораль тугарылу да булырга тиеш түгел. Син бүгеннән Түрештәге идеология работникларының берсе. Совет власте вәкиле. Партия сүзен тыңлап, коммунистик мораль белән яшәү сиңа да закон булып торачак!

Дөрестән дә, Минач абыйсының сәяси шалтыравыклы байтак сүзләрен кыз училищеда да еш ишетте. Аларны гел тукып тордылар. Ә менә рәиснең кызны Түрешнең күз өстендә каш булып торган кешеләр рәтенә куюы колакка да, аңга да яңалык булып чалынды. Дөрес, моны ишетү,

бер яктан, бик сәер иде. Урта буйлы, сипкелле коңгырт күзле һәм шул күзләре белән дөньяга ихласлык, мөлаемлык нурларын сипкән гап-гади кызкай өчен артык зур дәрәҗә түгелме бу? Икенче яктан, күңелле дә булды Сарага Минач абыйсының әлеге сүзләрен тыңлау. Яхшыга тиңләүне кем яратмас?

Түреш халкы каршында бер карыш югарыга күтәрелгәненә горурланып, чынлап та, җиң сызганып эшкә кереште Сара. Иң әүвәл колхозның агач осталары Хәмәтгата һәм Мөхәммәтзариф агаларыннан китаплар өчен киштә, шүрлек, тезмәләр ясатып алды. Уку залы өчен озын-озын өстәлләрне, урындыкларны да тиз ара әлеге осталар эшләп бирде. Хәмәтгата абзыйсы һаман төртмәле:

—Сара сеңел, туеңа өстәл-мазар әзер инде. Эш кияүгә генә терәлеп кала бугай.

Җиһазларны ул үз зәвыгы белән урнаштырып, дивар-почмакларны кызыл комач, плакатлар, рәсем-сурәтләр белән бизәде. Кулыннан лозунг язу, рәссамлык осталыгы да килә иде аның, беркемгә ялынычы төшмәде. Китапханә эче, сәнгатьчә бизәге, тәртибе белән күңелне канәгатьләндергәнче, Сара кулыннан каләм-караны, буяуларны төшермәде.

Хәзер инде эш китапларга, гәзит-журналларга килеп терәлде. Авыл Советына төрле-төрле вакытлы басмалар, гәзит-журналлар килеп тора икән. Тик болар төрле җирдә таралып, өелеп яткан булган. Кыз җыештыручы Мәһрүзә апасы белән ярты көн буена шуларны китапханәгә ташыгач, барысын тәртипкә салып төпләргә кереште... Хәзер газета-журналларны хат ташучы Факиһа китапханәгә кертә, Сара кулына тапшыра башлады.

Ә китап турында уйлап, кыз төннәрен саташа. Тегеннән-моннан җыйганы дивардагы киштәләрне тутырырга да җитмәде. Идәндәге шүрлек, тезмәләр әлегә бөтенләй шыр калды. Нишләргә? Кыз, Минач абыйсына кереп китап кытлыгы хакында ихлас зарлангач, тегесе тарантасына утыртып аны Аксуга алып китте. Юкка гына комиссар киеменә төренеп йөрми, сүзенә колак салалар икән Түреш рәисенең. Берничә кабинет бусагасын таптагач, ул китапханә мөдиренең кулына кибеттән, базардан китап алу өчен рөхсәт кәгазен тоттырды. Шул көндә үк алар Түрешкә тарантас тутырып китап кайтардылар. Озакламый Сараның соравы буенча почта аша Казаннан да зур бер кап китаплар килеп төште...

Нәкъ ике айлап вакыт үткәч, ямьле июль кичендә, китапханәне ачу кичәсен үткәрделәр. Бер үк вакытта клуб туе да булды бу. Чөнки үз вакытында ишек ачу тантанасы үткәрелмәгән булган икән. Түреш халкы өчен чын-чынлап мәдәният бәйрәме ясалды. Докладлы да үткәрелде, концерты да куелды. Сараның Һади Такташ поэмасы—«Мәхәббәт тәүбәсе»н яттан сөйләгән чагында байтагы кулъяулыгын чыгарып күз яшьләрен сөрткәләп утырды...

Яңа китапханә гөрләп эшли башлады. Урак өсте булса да, кичләрен аның залы гәзит-журналлар кыштырдатучы, китап алыштыручы егетләр, кыз-кыркын белән тулды...

Шулай итеп, утыз бишенче елда Сара тормышында булган беренче зур вакыйга кызның Түрештә китапханәче булып эшләп китүеннән гыйбарәт иде.

Һай, оныта язганмын бит, клуб тантанасыннан соң атна чамасы вакыт узгач, Аксуда чыга торган «Азат хәят» район гәзитендә «Түрештә—кызыл китапханә» исемле шактый зур мәкалә дөнья күрде. Аны үзхәбәрче Мансаф Хәкимов язып, әлеге авылда культура фронтындагы гүзәл уңышлар тасвирланган, китапханәче яшь комсомолка Сара Әбуталипованың эш тәҗрибәсенә карата аерым мактау сүзләре әйтелгән иде...

## IV бүлек

Анын тормышына кагылышлы икенче вакыйга шактый катлаулы һәм ул кызнын үзе өчен, беренче карашка, бөтенләй ят, хәтта чит тоелган кешеләр белән үрелгән иде. Әйтик, Саранын җиде ятып бер төшенә кермәгән Кифая улы Хабулга кияүгә чыгасын кем юраган...

Әлеге елда, югарыдагы карар нигезендә, районның барлык авыл хуҗалыгы җитәкчеләре белән беррәттән, Түреш авылы башлыкларына да Тамбов өлкәсенә барып урман кисү, агач әзерләү планы йөкләнде. Кышын Түрештән озатылган беренче урман кисүчеләр төркеме бик әйбәт эшләп кайтты. Мыштым Гайнулла кебек кесә тутырып акча алып кайтучылар байтак булган. Әлеге мыштым иркәй Аксудагы кооператив кибетенә барып, велосипед сатып ала, шул «шайтан тәгәрмәче» белән кеше теленә керә. Керми ни, җәяүле интегеп Түрешкә ике-өч сәгать кайтасы араны бу тәгәрмәчләре өстенә атланып егерме биш минут эчендә җилдергән бит! Шулай итеп, авыл ирләре арасында велосипед җене кузгалды. Лашман тартырга теләүчеләр артты.

Әлеге мыштым Гайнулла хатыны теге яки бу сәбәп табып өстенә акырына башласа, хәзер тегенең авызын шыплап томалап куя икән: «Мөсәббиха, ташлыйм мин сине. Тамбовка китәм. Анда хеть рабучийга пачут, акча!»

Янә бездәге ир-ат теленә гыйбарә өстәлде: «Мөсәббиха, ташлыйм мин сине, Тамбовка китәм!»

Яшерен-батырын түгел, салам түбәле тәбәнәк өйләр, ызбалар янәшәсендә патша сарае сымак кукраеп утырган Түреш клубы шул Тамбов урманынын юмарт бүләге бит. Сон каян килсен безнең усак, юкә, каен белән тулган урманнарга мәһабәт, зифа, хуш исле нарат гөрәшләре? Тимер юл станцасы Түрешкә утыз җиде чакрым гына. Тамбовтагы леспромхоз хуҗалары белән сөйләшеп, монда бер вагон агач китерү колхоз өчен әлләни кыенлык тудырмады.

Октябрь бәйрәмнәре үтеп, кыр эшләре бөтенләй түгәрәкләнеп куйгач, Тамбовка янә иллеләп кешедән торган урман кисүчеләр төркемен озаттылар. Боларга башлык булып коммунист Кифая Галиәсгарова билгеләнгән иде. Әмма бер айлап вакыт узды микән, Тамбовтан авыл Советына чыбык суктылар. Трубканың бу башында Минач сөйләшә. Теге яктан килгән сүзләрнең барысы да халыкка мәгълүм булмады. Әмма нәтиҗәсе тетрәндергеч иде—Кифаяны агач басып үтергән...

Минач бу хәлдән нык дулкынланып Совет утырышын җыйды. Чынлап та, анын зәңгәр күзләре жетеләнеп киткән, ихлас сагышка чумган иде. Сүзен дә үрә катып башлады:

—Авылдашлар, безгә тирән кайгы килде. Тамбовтагы бик җитди хезмәт фронтында без коммунистик партия әгъзасы Кифая Галиәсгарованы югалттык. Бер-ике минутка торып басып, матәм кайгысын белдерик, иптәшләр!

Утырышта, Минач тәкъдиме белән мәрхүмәне күмү буенча комиссия төзелде. Сара да аңа әгъза итеп беркетелде. Һәркемгә анык йомышлар кушылды.

Кифаянын гәүдәсен станцадан район хәрби комиссариаты машинасында ике көннән соң, төш алдыннан кайтардылар. Ара-тирә кырпак кар төшкәләп, салкын җил исеп торган көн булса да, мәрхүмә йортына байтак халык җыелган иде. Туган-тумача, күрше-күлән мәетне йола кушканча кадерләргә, кәфенләп күмәргә әзерләнде. Тик авыл Советы каршына килеп туктаган «полуторка» бераздан яман үкереп турыдан-туры зират тарафына юл тотты. Ә инде машина каберстан капкасы төбенә килеп туктап, әрҗәсеннән кызыл табут төшерелгәч, кабер әзерләп яткан ир-ат «аһ» итте:

«Кифаяны ящикка тыгып күмәргә җыеналар микәнни? Фәрештәләр янына ничек керер?..»

Зират янәшәсендә хәрәкәт, ыгы-зыгы башланып китте. Зур төркем булып мәктәп укучылары килеп төште. Кифаялар капкасы тирәсенә җыелган халыкны да монда әйдәделәр. Кешеләр һаман килә тора, ә Сараның колагына янәшәдәге апа, абыстайларның чыш-пыш килеп сөйләшүләре ишетелә: «Ходай каргады микәнни?.. Аның ире дә бик ямьсез китеп барды бит... Балалары хәзер нишләр инде?..»

Кифая мәрхүмә—Сара өчен бикле сандык. Аның йорты Кыямныкыннан ерак. Зур авылдагылар читтә очрашсалар, бер-берсен танымаска да мөмкиннәр әле. Кая ул белү? Аннары Кифая апасының яше ничаклы да, Сараныкы күпме? Яшь арасы—хәл-әхвәл арасы, читләшү чарасы бит.

Шулай да кыз әти-әнисенең аулак бер сөйләшеннән бу хатынга бәйле зур фаҗигане хәтерли. Аның ире Габбас кышын басуга китеп үз-үзен суйган... Кырда, болында, бигрәк тә эңгер-меңгердә ялгыз калса, Сараны өркү басты. Каршына муеныннан кан агып торган, пычак тоткан куркыныч ир килеп чыгар төсле...

Ә моннан алданрак бер Сабан туенда үзе кебек кыз-кыркыннар белән тотынышып әйлән-бәйлән әйләнгәндә, Сара очкынлы коба күзле, туткыллы йөзле һәм кыска чәчле башына беретка элгән чая бер хатынның уртага чыгып биюенә таң калган иде.

Эха-а!
Дым-дым рита,
Дым-дым рита,
Рита, рита

Ритая... дип такмак әйтеп, ят куплетлар җырлап, очынып-очынып биегән иде ул. Ә аннары тирләгән битен яулыгы белән җилгәрә-җилгәрә кычкырды:

—Менә шундый, факстротка биергә кирәк, яшьләр! Ә сез «Әпипә»гә тыпырдашып ятасыз...

—Кем бу?—дип сорады Сара.

—Хабул дигән малайны беләсеңме? Шуның әнисе Кифая апа бу. Читтә күп йөргән,—дигәннәре хәтерендә калды кызның.

Җәсады кабер янәшәсендә торган кеше хакында шулардан артыгына Сараның хәбәр-фәһеме җитмәде. Хәер, мәрхәмә турында гайбәтләр тупларга җыенмады да ул. Тизрәк комиссия әгъзалары җыелыша башлаган урынга, табут янына атлады.

Ниһаять, капкачы ачык, әмма йөзе ябулы мәрхүмә яткан кызыл комачлы тартма янына Минач һәм тагын өч-дүрт башлык килеп бастылар. Рәис бүреген салды да, көчле бәрхет тавыш белән сүз башлады:

—Авылдашлар, иптәшләр, көрәштәшләр! Революция, бәхетле тормыш өчен башларын салган кызыл солдатлар белән без фронтта залплар биреп хушлаштык. Тик хәзер безнең кулларда мылтыклар юк. Без хәзер инде башка фронтта. Социализм, коммунизм төзү фронтында. Шулай булса да корбаннар бирүдән туктамыйбыз. Чөнки иптәш Сталин әйткәнчә, социализм өчен көрәш көчәйгән саен, сыйнфый дошманнар һөҗүме арта, мәкерләнә бара ул.

Иптәшләр, без революцион лидерларыбызның берсе Сергей Миронович Кировның үтерелүен ишетеп тетрәнгән идек. Менә тагын яңа кайгы. Көрәштәшебез коммунист Кифая Галиәсгарова хезмәт фронтында һәлак булды. Бу һич тә очраклы, гадәти үлем түгел. Кифая беренчеләрдән булып колхозга керде. Күмәк тормыш активисты булып танылды. Халык бәхете өчен аны күралмаучылар да күп булды. Аның сыйнфый дошманнары бар.

Әйткәнемчә, бу дошман мәкерле. Ул безне ачлык белән куркыта, почмактан ата, өскә агач аудара...

Тик без курыкмыйбыз, юлдан да чигенмибез, иптәшләр! Чөнки без күп, без дөрес юлда! Һәм безнең эшләрне яңа буын дәвам итәчәгенә дә шик тотмыйбыз. Тыныч йокла, көрәштәшебез һәм дустыбыз Кифая Нуриман кызы Галиәсгарова!

Янындагы кәрзиннән Минач берничә кызыл, купшы канәфер чәчәге алды һәм аны табуттагы гәүдә өстенә салды. Төркем өстендә тынлык хөкем сөрде. Һәм шул тынлыкта әле тегендә, әле монда сулкылдап елау да ишетелде.

Миначтан соң да матәм сүзләрен әйтүчеләр байтак булды. Ике пионер мәрхүмә каршында салют биреп, Ленин, Сталин юлын дәвам итәчәкләрен вәгъдә иткәч, табут капкачын ябып куйдылар. Минач янәшәсендәге ирләр табутны кулларына алып зират капкасын үтте, кабергә юнәлде. Хатын-кызларның барысы да киртәнең аръягында калдылар. Шәригать бу женеснең зират туфрагына аяк басуын тыя...

Сара моннан да барысын күреп, ишетеп тора. Кабер тирәсендә көтмәгәндә нииндидер тавыш, чуалыш башланды. Кулларын бутап, ярсып кычкырып рәис каршысына баскан киң җилкәле таза, гайрәтле бер ир күз уңына менде: «Кифаяның туганы... Рзай чекист... Чиләбедән кайткан...» диештеләр хатыннар. Әлеге ирнең тавышы монда да килеп ирешә:

—Нишләп гроб белән күмәсең? Туганнарыннан сорадыңмы? Кем йоланы бозарга кушты сиңа?

Авыл башлыгы үзенә карата мондый әрсезлек, дорфалыкны көтмәгән иде. Шулай да җиңел генә хәлне үзенчә борып алырга теләде:

—Кит юлдан!

—Нишләп китим. Кифая минем бертуганым. Җирләргә хакым бар... Ә менә син үзең аңа кем буласың?—диде Рзай үҗәтлеген, гайрәтен үстерә барып.

—Отчет бирергә кем син миңа?—дип рәис тә ир каршында күкрәген кабартты.

—Шул, шул, кеше каршында отчет тотмыйсың син. Гел үзенчә! Фронт, көрәш, корбан... Революция дип аң чуалткан аскет! Ә Кифая сеңел ничек үлгән? Яисә кем үтергән? Бу турыда эш кузгатырмын. Тик хәзер үк ачык: өч балалы хатынны урман кисәргә озатуыгыз өчен башыгыздан сыйпамаслар сезнең. Лашман тартырга ир-ат беткәнме? Моны судка бирергә кирәк!.. Моралең хакында шунда тагын берничә сүз әйтермен. Советка таянып, мир үгезе булып йөрисең бит син, азгын!

—Нәрсә лыгырдыйсың син, контра, сволоч!—дип ярсып кычкырды рәис Минач.

—Белгәнемне лыгырдыйм. Син авылда гарем тотып, каста ясап ятасың. Мин кем, имеш? Совет гражданины мин! Кирәк булса, кемлегемне тиешле урыннарда да ачып күрсәтермен мин сиңа.

—Күрсәт!

Күкрәкне күкрәккә терәп баскан, нәфрәттән ярсыган ике ир низагы тагын нинди рәвешләр алган булыр иде, янәшәләренә сабыр гына авыл мулласы Шакир карт килеп басты:

—Оланнар, икегез дә могтәбәр кешеләр. Зират өстендә тавышланмагыз. Рзай сүзе дөрес. Туганнар хакы хак! Мәрхүмәне ящик белән күмегез, дип васыять калдырмагандыр бит, Минач энем? Шул бармы-юкмы? Булмаса, бу—мөселман зираты. Ата-баба, шәригать йоласын бозмыйбыз, оланнар! Ә Кифая мәрхүмә, коммун кеше, исән чакта: «Мине гробта күмегез!» дисә, ул чагында мәетне алып китегез, башка җиргә күмегез, Минач энем,—диде мөтәвәлли.

Минач рәис озын гәүдәле, какча карт каршында сүзсез калды. Бары тик зәһәрләнеп яңакларын уйнаткалап торды ул. Бераздан аның сул кулы кесәсенә үрелде, «Казбек» пачкасын тартып чыгарды һәм тәмәкесенә ут кабызу нияте белән ул зират киртәсенә таба юнәлде. Комиссия әгъзалары, табут күтәргән ир-егетләр көтүчесез маллар кебек, аптырашып җирдәге кызыл тартмадан читкә елыша, төрле тарафка авыша башладылар...

Мәрхүмәне җирләүне Шакир мулла тулысынча үз кулына алды. Кифая Нуриман кызы Галиәсгарова, коммунист булса да, ислам шәригатенең мөһим кануннарына туры китереп, Җир-ана куенына тапшырылды.

## V бүлек

Җир өсте бер агарып, бер каралып, лычма юешләнеп, сазланып байтак вакыт төсләр алмаштырып торгач, ниһаять кыр, урманнар, елга-күлләр, тыкрык-урамнар, түбәләр өстенә дә ныклап ак кар яу. Аяк асты катты, атлаулар җиңеләйде. Үткән фасыл белән бәйләнешле кичерешләр, күңелне тырнаган уйлар да ак җәймә астында калган сыман булдылар.

Сараның китапханәдәге эшләре күңелле генә бер көйгә тәгәри. Китаплар санын һаман арттыра тора, укучылар саны ишәя. Бигрәк тә мәктәп балалары күбәйде. Болар белән аралашу, сөйләшү аеруча кызык. Мавыгып укыган әсәрләрнең эчтәлеген сөйлиләр, геройларга үз бәяләрен бирәләр. Иң мөһиме, китапта язылганнарга ихлас ышаналар болар.

Кызның эш даирәсе дә киңәя, төрләнә бара. Әле колхозның сарыклар фермасына юлын ешайткан чагы. Партия кушкан эш дип Минач абыйсы аны монда агитатор итеп беркетте. Хәзер ул терлекчеләр өендә Кызыл почмак оештыра, сарык карауччы апалар белән үзе әзерләнеп килгән темаларга әңгәмәләр үткәрә. Һәр сөйләгәненне сеңдереп баралармы, Сара моны ачык әйтә алмый. Тик халык, барыбер, сүзенне үзенчә бора шул. Ә болай хайваннар арасында кайнашып йомылган кешенең үзенә юнәлгән сүзне ихтирам белән тыңлавы хак. Адәмне санлау дип тә кабул итәләр булса кирәк. Инде сүзеңне бетереп, эш сораулар бирүгә, үзара сөйләшүләргә китсә, капчык тутырып китәрлек кызык-мызыклар килеп чыга. Үткәндә өлкә газитендәге «Агитатор блокнотына» дигән сәхифәдән Америка негрларының кызганыч хәле турында зур гына язманы укыган иде Сара. Борыны янәшәсендә зур гына миң асраган Фәһимә апасы сорап куймасынмы:

—Сара сеңлем, ул негр дигән халык, абау ямьсез икән. Кинода күреп тә кот очты. Соң шуларны берәр сабын яисә мазь белән агартып булмыймы? Алар мунча да кермиләр ди бит. Яннары исле ди. Амриктә аларның мунчалары юк ди. Пешекләп мунча кертеп тә, каралыкларын бетереп булмас иде микәнни шуларның?

Һәр сүзне көлкегә борырга торган юантык Гайнигөлем рәхәтләнеп бот чапты:

—Һай, Фәһимә, кеше көлдермә! Негр бит ул туганда ук төннән кара булып туа. Мунча кертеп, карасын юарга җыендыңмыни?

Фәһимәнең исе китмәде:

—Һе, туганда безнең балалар да кысла кебек кып-кызыл була. Тора-бара юып агартасың бит!

Сүзгә бик белдекле кыяфәттә сул күзенә ак төшкән Гыйльмияза килеп кушылды:

—Болай бит ул, Фәһимә ахирәт. Казыңа дегет сөрткәннәре булмадымы синең? Ә минем бер елны бер оя казымны дегеткә буядылар. Әй тырыштым, әй тырыштым, юк! Сабын белән юсаң да, пешекләсәң дә бетми. Негр тәнендә дә шундый бетми торган дегет кебек нәрсә бар инде ул. Ходай

сөртеп куйган да, шул һаман бетмичә килә булыр...

Күп тыңлап, аз сөйли торган бик җыйнак гәүдәле Һәдия түти боларны тыңлап торды-торды да, Сарага юнәлтебрәк әйтеп куйды:

—Син, сеңлем, безгә карап аптырама инде. Сарык карап, үзебез дә сарыкка әйләнмибез микән без? Мына, рәхмәт үзенә, гәҗит, китап сүзләрен сөйләп азмы-күпме агартасың. Без инде, барыбер, томана. Уку дигән бәхет эләкмәде. Ә яшьләр хакында кайгыртуыңны күреп халык шатлана. Синең белән, кызым, әби-сәбиләр дә кызыксына башлады бит...

Һәдия түти үзалдына елмаеп куйды һәм кулы белән ахирәтләренә ишарәләде:

—Тыңлагыз әле, бер кызык хәл сөйлим сезгә. Минем күрше—Бибиниса астай бит. Шактый чукрак бу. Шуның унынчыда укыган төпчек кызы мәктәптән кайта да бәрәңгесен ашап, чәен эчкәч бик ашыгып чыгып китә башлаган. Үзе әйтә икән: «Әни, югалтма, мин бибиләтикәгә китәм». Бер китә бу, ике китә, өч китә. Үзе һаман әйтә: «Әни, югалтма, мин бибиләтикәгә китәм».

Дүртенче кат ишеккә тотынгач, Бибиниса баласына әйтә икән: «Кызым, син Бибилатифа янына китәсең дә китәсең. Ә үзең шул кызны нишләп бер дә өебезгә чакырмыйсың соң? Утырмага килсен. Мин дә күрер идем, белер идем, кем кызы ул Бибилатифа? Алып кил!»

Менә шулай, кызым, син Бибилатифаны күп йортларда искә төшереп, күрергә зарыгып торалар бездә»,—дип мәзәген очлап куйды Һәдия түти. «Дөрес, дөрес!» дип җөпләделәр калганнары.

Хезмәт кешеләре белән очрашу, аз булса да аларның уй-фикер дөньяларын кинәйтү дәрте кызның үзенә дә файдалы. Кызыклы әңгәмәләр корыйм, кешеләргә файдалы сүзләр сөйлим, дип ул мавыгып гәзит-журналлар укый, язып ала, уйлана...

Көз фасылында Сараның аеруча зур эшләреннән берсе китап укучылар конференциясен оештыру булды. Әбүнәчеләрнең сәләтен, көчен, ә үзенең мөмкинлекләрен күрү өчен әүвәл ул Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» повестена тотынды. Була! Тик әсәр хакында җитди һәм кызыклы сөйләшү килеп чыксын өчен китапханәченең үзенә алдан зур гына оештыру эшләре алып барырга, залны җәлеп итәрлек сораулар куя белергә генә кирәк икән!

Яшьләрне дә, олыларны да дулкынландыра торган берәр әсәр табарга кирәк иде. Һәм тапты бит Сара. Нәкъ көзен Түрешкә Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте килеп ирешә. Бу язучыны белә, әсәрләрен ярата иде Сара. Китапны да өмет белән кулына алды кыз. Һәм берничә көн бар дөньясын онытып тик әлеге повесть белән яшәде. Әсәр искиткеч көчле! Геройлар барысы да янәшәңдә тора кебек. Алар гаҗәп тормышчаннар. Болар белән хәтта сөйләшеп була сыман... Мондагы Галия—соңгы еллардагы татар әдәбиятында иҗат ителгән иң көчле образларның берсе.

Әдәбиятка таянып, халыкны замана тормышы һәм хатын-кыз яшәеше хакында уйландыру өчен моннан да яхшырак әсәр табып булмас, дип фикерләде Сара. Ул ашкынып конференциягә әзерлек эшләрен башлап җибәрде.

Шөкер, «Тапшырылмаган хатлар» китабы зур тираж белән басылган. Китапханәгә дә мул гына өлеш чыкты. Ун данә! Югыйсә, байтак басмалардан авылга ике-өч китап кына җибәрелә иде. Хәзер инде боларны тиз арада халыктан укытып алу чарасын күрергә кирәк. Сара Гадел Кутуй китабының бер данәсен Минач абыйсына кертеп бирергә генә җыенган иде, әллә күрәзәлеге бар, китапханәгә ут элдергән мәлдә үзе килеп керде.

Дөресрәге, башта шкаф ышыгында торып, эшләре белән мәшгуль чагында, кыз рәиснең бәрхет тавышын гына ишетте:

—Китап хуҗабикәсенә сәлам!

Ә яктыга чыгып керүчегә күз салгач, рәис янәшәсендә ул урта буйлы, сөйкемле туткыл йөзле егет затын да шәйләп алды. Мәрхүмә Кифая апа малае, дип уйлап өлгерде кыз. Моның да коба күзләре очкынлы, карашы кискен икән...

—Менә таныш бул, Сара. Бу—Хабул, гармунда шәп уйный. Кичә-фәлән ясасаң, егет әзер, шулаймы, Хабул?

—Шулай!—дип баш селекте егет.

Кыз тагын игътибар итте, Хабул карга канаты кебек кара бөдрә чәчле икән. Шул пумала башын бора-бора күзләрен китап шкафлары, шүрлекләр буйлап йөгертеп алды.

—Китапларың күп икән,—дип ихлас гаҗәпләнде ул.—Каян җыеп бетердең үзләрен? Боларның барысын да укып, белеп бетереп тә буламы?

—Безнең Сара китапларны су кебек эчә ул,—дип кызның аркасыннан җиңелчә какты Минач абыйсы.

—Әйдә, Хабул, рәхим ит! Кунак итәргә чәй-шикәрем югын юк. Менә гәзит-журналлар укырга була,—диде Сара һәм Минач абыйсы белән булачак конференция, уйлаган ниятләре хакында җитди сөйләшүгә керешеп китте.

Башта рәис, аннары хушлашып Хабул чыгып киткәч, кыз уйлап куйды: «Әйбәт кеше дә инде бу Минач абый. Гел ярдәм кулын сузып тора. Гармунчысы ярыйсы күренә. Үзешчәннәр төркеменә катнашып китсә яхшы булыр иде дә бит».

Кызлар юктан да егет-җилән белән кызыксынучан була. Хабул исә, юньләп бер генә күзгә чалынса да, гармунчы, егет заты буларак Сараның күңелен кытыклап куйды. Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, дигәндәй, моңа җае да чыгып тора бит. Авылның Хабуллар яшәгән очыннан китапханәгә Сәкинә атлы кыз бик еш йөри. Борча кебек тере, сүзгә, фикергә гаҗәп үткер Сәкинәне күзаллап куйгач, Сара телен шартлатып алды. Бәрәч! Бу беркөнне сарыклар фермасында көлеп телгә алынган Чукрак Бибиниса апа кызы түгелме соң?

—Сәкинә,—дип сүз башлады китапханәче алдына мөлаем кыз килеп баскач.—Син үзең Бибилатифа янына бик еш барасың. Нишләп аны үзенә чакырмыйсың?

Тегесе беравык күзләрен түгәрәкләндереп бик җитди кыяфәттә торган Сара апасына карап торды. Аннары ике кулы белән дә кисәк йөзен каплады, кычкырып көлеп җибәрде:

—Сара апа, дөрес шул бу! Әни: «Ник Бибиләтифаны үзебезгә чакырмыйсың?» ди. Моны каян ишеттегез соң?.. Барсагыз, бүген үк өйгә чакырам...

Сәкинә укыган китабын тапшырды, шүрлекләрдә капшанып, үзе теләгән китапны сайлады. Менә ул инде китәргә дә җыена.

—Сәкинә сеңлем, сезнең күрше Хабул гармунда уйный диләр. Чакырсам, килер микән? Кичә ясарга планлап тора идем...—диде Сара ваемсыз күренергә тырышып.

—И, Сара апа... Ай-һай...—дип ихлас суzды кыз.—Бигрәк йомык, сәхнә һәвәсеннән ерак бит ул! Тыкрыкка да, кереп чакырсак кына чыга. Уйнаса, гармунны әйбәт уйный инде үзе... Кайгысы зур бит аның, Сара апа! Әнисенең кырыгын үткәргәндә дә күзеннән яшьләрен тыя алмаган... Туганнарын карау мәшәкате дә өстендә. Җитмәсә сеңлесе дә гарип... Авыр инде мескенгә!

Теле бик кычытса да, артык сорау бирүдән Сара тыелды. Сәкинә сөйләгән Хабулны күзалларга сораганы бик житкән иде. Күп белсәң тиз картаерсың, дип үз-үзен үчекләп, кыз эш мәшәкатьләренә бирелде.

Хәер, бу яктан һич тә куркасы юк. Сара үз асылын яхшы анлый. Ул чынлап та эш кешесе. Егет кайгысы—кештәктә. Казанда укыганда Гутман исемле бик өлкән яшьтәге бер доцент психологиядән лекцияләр сөйләде. Залга татар, урыс төркемнәреннән алтмышлап кеше жыелды. Тик шунын дәресендә чебен очкан тавыш булмый. Холык-фигыль асылы буенча кешеләрне өч типка аерырга кирәк, дип берчак сүз башлады Давид Самойлович.

Беренчесе—халыкка юнәлеш.

Икенчесе—үз-үзенә юнәлеш.

Өченчесе—эшкә юнәлеш.

—Давид Самойлович,—дип алдагы партадан сүз кыстырды Гайнан. Бу—татар төркемендәге өч егетнең берсе. Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый калмаган сыман, кеше сөйләгәндә берәр нәрсә әйтеп тыгылмый калмаган адәм.—Бу юнәлешләрдән безнең өчен нинди нәтижә чыгарасыз инде сез?

Давид Самойлович сүзен бүлдергәнгә һич ачуланмый. Киресенчә, рәхмәт әйтә һәм янә ихлас сөйләп китә:

—Хөрмәтлем, әлеге юнәлеш типларын белү, тирә-юнебездәге кешеләр асылын аңлау, хәтта күрү бит ул. Менә халыкка юнәлгән типны алыйк. Сез үзегез дә халык белән бик аралашкан, төркем эчендә кайнаган бик жегәрле кешеләрне беләсез. Боларның асылында житәкче заты, башлык ята бит. Алар халык алдына күтәрелеп, үзләрен лидер, узаман итеп расларга омтылалар. Баш игәнне, мактаганны көтәләр. Кеше буйсындырудан тәм, ләззәт табалар алар. Мир каршында, тормыш сәхнәсендә герой булып уйнау боларның бөтен яшәү максатын тәшкил итә...

Ә үз-үзенә юнәлгән тип вәкилләре—әйтелгәннәрнең бөтенләй киресе. Мондый типка халык та, тормыш та кирәкми. Тик үз-үзен һәм шәхси рәхәтен кайгыртып яши ул. Бармагы һәрчак үзенә кәкре була аның. Акча жыя, байлык ярата. Билгеле инде, мондый юлда угрылыктан, алдау-хәйләдән дә тайчынмый эгоист адәм...

Игътибар итегез, үз-үзенә юнәлгән адәм тибы—донжуаннар, эчкечеләр, сәяси шарлатаннар чыганагы да ул. Яшермим, тормышыбыз өчен бик куркыныч тип бу. Бездәге бик күп бәлаләр, фажигаләр, артталык һәм хәерчелек шуннан килеп чыга. Ә инде матур маскага төренеп өскә үрләгәннәре—ил, халык фажигасен ясый...

Лектор эчке уйлар, хисләр киеренкелеген басар өчен бераз сүзсез калып, йөренеп ала, башын күтәреп, тынгысыз карашын аудитория өстендә йөртә.

—Мин беләм,—дип сүзен дәвам итте Давид Самойлович.—Сезнең бик күбегез—чын эш кешеләре. Ягъни хезмәткә юнәлгән тип вәкилләре. Болар өчен эш—кәләш тә, калач та була. Шатлыгы да, кайгысы да шул—эш. Эш дип хәтта йокысын, ашау-эчүен дә оныта кеше. Холкы нәкъ шулай корылганга әлеге типтан бишьеллык ударниклары, стахановчылар килеп чыга. Рекордлар куючы хезмәт батырлары туа. Бездәге уңышлар, индустрия, фән, культура өлкәсендәге жиңүләр—хезмәткә юнәлгән кеше тибы казанышлары алар...

Менә шулай, хөрмәтлеләрем, алдыгызда башланмаган зур тормыш. Иптәшләр, дуслар табасыгыз бар. Өйләнер, кияүгә чыгучыларыгыз да булыр. Сайлаганда Давид абыегыз әйткәннәрне онытмассыз,—дип әлеге темага сүзен йомгаклап куйды лектор.

Галим чынлап та дөрес искәрткән. Эше төшкән яисә аралашкан байтак

затлар хакында уйланып кала Сара: Кем бу? Кайсы юнәлеш тибы? Тик менә зирәк лектор кебек анык нәтиҗә ясавы гына кыен кызга. Күзәтү осталыгы җитми күрәмсең үзенә...

Хәер, Сара дигән туташ хакында шикләнәсе юк инде. Эш каршында башын игән... Үз-үзенә юнәлешле зат булса, әллә кайчан берәр егет кисәге белән йөреп ятыр иде. Исем өчен булса да берәрсен ияртер иде. Югыйсә, адәм хуры бит! Дуадак каз сыман һаман ялгыз... Әле бер көн хәтта әнисе сорый: «Кызым, төннәрен бик соңлап кайтасың. Озатып куючың бармы ул?»

Сара бик кырку итеп җавап бирде бирүен: «Мин үзем дә курыкмыйм. Нигә миңа озатучы?» Әмма тора-бара уйлана калды. Әнисе йөргән егете булмавына пошынып ята түгелме соң?

Тик әнисе түгел, иң якын ахирәтләре дә белми калды. Мыек төрткән елгыр бер зат өчен ут йоткан чаклары булды инде кызның...

Унынчы сыйныфны тәмамлап килгән көннәре иде Сараның. Төш тирәсендә икенче сменага чамалап мәктәп сукмагыннан атлаган чагы бу. Май кояшы, бөреләнгән таллар хозурлыгына куанып барганда, каршысына әкияттәге принц сыман зифа буйлы көләч йөзле матрос килеп чыкмасынмы?!. Тып итеп каршына басты, үткәрми. Үзеннән хушбуй исе, тагын башка нindидер ят исләр бөркелә. Бәлки диңгез исе булгандыр бу...

—Кем кызы син?

—Әни миңа таныш булмаган кеше белән сөйләшмәскә кушты...

—Син бит хәзер зур инде, буең да зифа күренә. Иреннәрең дә тулышкан.

—Буем үссә дә, акылым үсмәгән әле. Мин әнкәй сүзеннән чыкмыйм.

—Алайса әнкәннең исемен әйт!

—Әниемнең исемен әйтергә минем әтием бар. Аңардан сорарсың.

—Һе, туташ, сез әйтмисез икән, без ялынмыйбыз,—диде егет һәм кулын бескозыркасы янына ялт итеп күтәреп китеп тә барды.—Честь имею!

Шаярып әйткән сүзләре белән бергә егет елгыр карашын кыз күңеленә чәнчеп калдырды. Яшькелт, каймалы күзләрдән атылган әлеге караш Сараның тынычлыгын җуйды. Йөрәгендә әллә нинди ят хисләр тыпырчынды аның.

Матрос Фоат исемле иде. Берничә мөрит ияртеп, узгынчы юлчы кебек, Саралар тыкрыгына да килеп чыккалады. Теге кызга текәлде, бу кызны күзләде. Хәтта бер тапкыр егет Сараны чакырып, «дүртле» дә биеп алды. Өметләнде Кыям кызы... Җилкәсенә кулын салса, кыз аны тибәрмәс иде. Озатам дисә, кыз каршы килмәс иде... Әмма, әллә Фоат юньләп кызны күрмәде, әллә кыз каш сикертә белмәде, аралар бәйләнмәде шул... «Асылы үзенә юнәлгән кеше тибына ошаган. Алдыннан арты хәерлерәк», дип суына төшкәч, нәтиҗә чыгарды кыз.

Бер авызы пешкәч, Сараның кысыр хисләр белән үзен җәфалыйсы, тынычлыгын җуясы да килмәде: «Насыйп яр табылыр әле. Хәләле, ризык кебек, теш ярып керер әле ул...»

## VI бүлек

Сәкинә зирәк кыз булса да, күршесен бик белеп бетерми икән. Сара чакыргач, «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча үткәрелгән китап укучылар конференциясендә катнашты бит Хабул. Әлеге тамаша нәкъ менә Хабулның җинел, дәртле һәм бик заманча көйгә гармунда уйнавы белән башланып китте. Гармунчы янәшәсенә баскан ике егет һәм ике кыз көйне матур сүзләр белән беркетеп җырлап җибәрделәр:

Син дә жырла батыр егет,
Син дә жырла матур кыз!
Матур булсын, матур булсын
Матур булсын бу тормыш!

Әйтми булмый, Хабул сөйкемле иде. Ялтыраган күн итеге, күтәртмә якалы кара күлмәге, шул күлмәк өстеннән буылган киң каешы һәм аеруча маңгаена төшкән бөдрәләре, очкынлы карашы, тыйнак елмаюы белән ул бик килешле күренде. Авыл егете, авыл кызының нииндидер һөнәр белән сәхнәгә күтәрелүе һәрчак куандыра. Әртистләрнең күмәк жыры залдагыларга кәеф кертте, элек күпләрнең колакларына да юньләп чалынмаган нииндидер кәнфирәнсәнең матур үтәчәгенә өмет уятты.

Көй, жыр белән әйтелгән бисмилладан Сара оста файдаланды.

—Авылдашлар,—диде ул сәхнәгә килеп чыгып.—Тормышыбыз матур булсын өчен көрәштә матур әдәбият та үзеннән зур өлеш кертә. Язучылар, шагыйрьләребез безнең әхлак, рух үсеше өчен кайгыртып матур-матур әсәрләр язалар. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» исемле китабы хакында күмәкләп фикер алышу безне моңа ышандырыр дип ышанам. Шулай итеп, әйдәгез, вәгъдә ителгән сөйләшүне башлап жибәрик!

Кайбер активистлар каршы килгән булса да, Сара конференцияне клуб залында үткәрергә карар итеп дөрес эшләгән. Халык күп. Мәктәп укытучылары, авыл житәкчеләре, шул исәптән Миначра рәис тә килгән.

Әүвәл, шактый ук дулкынланып китапханәче әсәр авторы Гадел Кутуй турында мәгълүмат бирде. Кайда туган, әти-әнисе кем булган, ничек үскән—шулар турында сөйләде. Яшермәде, язучы булып формалашканда чит элементлар коткысына бирелеп түбән идеяле әсәрләр язуын да әйтте.

Ай
маена—
май маена.
Майдан—
Майга—
Май!
Майга ура!
Ура майга!
Тайга—
тай! тезмәсен укыгач, халык шаркылдап көлде: «Вәйт, такмак чыгарган!.. Үзе язганны үзе аңладымы икән соң бу Кутуй? Татарга тылмач кирәкми дисәгез дә, монда тылмач кирәк бит, иптәшләр!»

—Бөек борылыш елларындагы социалистик жиңүләр, партия тәрбиясе йогынтысында Кутуй чит элементлар белән арасын өзә. Ул социалистик реализм белән коралланып инде югары идеяле әсәрләр яза башлый!—дип сөйләп халыкны тынычландырды Сара.

Моннан соң сүз «Тапшырылмаган хатлар» китабына күчеп, сәхнәгә берәм-берәм алдан сөйләшеп әзерләнгән кешеләр чыкты. Әсәрнең эчтәлеге, Галия, Искәндәр, Вәли кебек төп геройларның холык, сыйфатлары турындагы чыгышларны да халык җанланып, ихластан тыңлады.

Инде хәзер жаен табып, укучыларның фикерләрен бәрелештерергә, әсәр хакында бәхәс кузгатырга кирәк иде. Әмма Сара дирижерлык итәргә өлгермәде, алдагы рәттә утырган мәһабәт гәүдәле Шәрифулла карт күтәрелде. Бу—колхоз активисты, һәр эштә үз сүзен әйтергә ашыга.

«Оланнар, бу Гадел Кутуй дигән иптәш безгә бик яхшы үрнәк биргән бит,—диде ул.—Безнең Түреш авылына да Галия кебек бик оста табиб кирәк. Монау бит суга баткан кызны терелткән, рак дип куркып, тере мәет

булган картны дәвалый. Ә бездә нәрсә? Чирле кеше тизрәк имчегә йөгерә. Мулладан өшкертә. Ә болар терелтәме? Юк! Үзләре әҗәл, дәҗҗал ласа! Минач энем, сиңа әйтәм, безнең авылга да әнә шул Галия кебек укыган, гыйлем алган табиб табарга кирәк!»

Зал гөж килде: «Дөрес, Шәрифулла абзый, дөрес!» дип аяк тибүчеләр дә табылды.

—Туктагыз әле!—дип икенче очтан өлкән яшьтәге бер хатын күтәрелде. Кем бу? Сара белми, әмма ул тавышларны җиңеп, залга аваз салды.—Безнең Түрешкә Әдрәстәге кебек яхшы пункт та кирәк, агай-эне! Үткән җәй күзгә дару салдырдым. Түбәдән янгыр үтә. Идән өсте чиләк, табак белән тулган. Үзегез беләсез, безнең пункт—кулак Гарифулла өе. Хуҗасы булмагач, түбәсе дә тишек...

Минач энем, сәвит властена инде ничә ел! Түрешкә дә адәм рәтле пункт корырга кирәк! Халык бу хатынны да хуплап гөжләргә, тавышланырга тотынды. «Беттем!» дип башын тотты Сара. Ул һич тә мондый борылышны көтмәгән иде. Җилкәсенә кагылу тоеп, борылса, янәшәсенә Сәкинә килеп баскан икән.

—Сара апа, сүз алыйммы?

—Нәрсә сөйләрсең соң?

—Галиягә кагылышлы үз уйларым бар.

Сара анык сүз әйтмәде, кызны җитәкләде дә сәхнәгә таба этәрде.

Сәкинә кыю гына сәхнә түренә чыгып басты. Кычкыру түгел, хәтта эндәшмәде дә ул. Каршыларында басып торган ак алъяпкычлы сөйкемле кызкайны күзәтеп, кешеләр акрын гына тына башладылар. Менә зал бөтенләй оеды.

—Авылдашлар, абыйлар, апалар,—дип башлады Сәкинә сүзен.—Түрешкә доктор да, дәвалау пункты да кирәк. Тик без хәзер китап хакында сөйләшүне максат итеп куйдык бит әле. Укыганнарыгыз таныш, укымаганнарыгыз ишетте, Гадел Кутуй китабында кызыклы геройлар бар. Тик безгә яхшырак күзалларга кирәк. Галия кем? Искәндәр нинди ир? Вәли хакында без нәрсәләр уйлыйбыз? Кешеләр холкы, әхлагы турында уйлану бәхеткә ирешү юлларын ачыклау бит ул, авылдашлар. Әллә сез үзегезгә бәхет теләмисезме?

Залдан эндәшүче кеше булмады. Күрәсең, йомырканың тавыкны өйрәтүе кебек, әле яңа гына кеше арасына кереп бара торган бер чәчбинең сүзләренә дикъкать итәрлек этәргеч өлгермәгән иде. Шулай да теге почмактан, бу почмактан пышылдашкан тавышлар ишетелгәләде: «Теге Бибиләтифа янына йөри торган кызмы бу?.. Яшь булса да, кыю... Укыган кеше чукынган кеше шул...»

Сәкинәнең кыңгырау чынын хәтерләткән яңгыравыклы тавышы янә җай гына янәшәдәге чишмә төсле булып акты:

—Мин үзем Галиягә ифрат сокланам. Әтисе көтүче булган, гомере сарыклар арасында үткән. Ә ул—мәшһүр доктор. Яна тормышта яши дип кенә китереп бирмәгәннәр бит ана бәхетне. Бәхеткә ирешим дисән, Галия кебек, гел яктыга үрләргә, тырышып укырга, белем алырга кирәк шул!

Шулай да Галия тулы бәхетле кешеме? Мин озак уйландым. Тик ничек уйласам да, аны тулы бәхет иясе дип исәпли алмадым. Чөнки Галия эшендә, кешеләр алдында абруйлы күренсә дә, үз өендә, гаиләсендә ямь тапмый. Искәндәр белән Галия икесе дә бик матур, укымышлы кешеләр булсалар да, түгәрәк тормышлы ир һәм хатын була алмыйлар. Ә үз өендә иминлек, бәрәкәт тапмаса, кешене бәхетле дип әйтеп буламыни?

Мин әнидән дә, күршеләрдән дә еш ишетәм, гаилә учагы хатын-кыз кулында ул. Искәндәрне бик ошатып кавышкач, Галиягә утны гел өстәп

торырга иде. Дөньяда яратканыңны табу бер генә була бит. Мәхәббәтләрен яшәтү өчен көрәшергә кирәк иде Галиягә! Ә ул теге яки бу сәбәпләр табып, иренә салкыная, хәтта аның белән чын-чынлап сөйләшми дә. Искәндәр белән гаилә дәфтәре, көндәлекләр аша гына аралашырга тели ул. Ә ир аларны укымый да...

Мин бит әле Галияне иреннән суыткан төп сәбәпне әйтми торам. Хатын булгач, ул фәлсәфәгә бирелә. Янәсе женесләр арасында табигый сайланыш, ягъни тышкы матурлыкка бирелеп яр сайлау мөһим түгел, ярны идея сайланышы, сәяси, сыйнфый карашлар бердәмлегеннән чыгып яратырга кирәк! Ә Искәндәр иске карашлы кеше, мөэзин малае бит! Галиягә пар түгел ул. Галиягә Вәли пар! Бу фәлсәфә чын мәхәббәтне үтерә... Моны мин Галиянең беренче зур хатасы дим...

Сәкинә тыштан тыныч күренсә, шома сөйләсә дә, эчтән шактый ук дулкынлана, хәтта шүрли иде. Беренче тапкыр шундый зур залда, өлкәннәр каршында нотык тота бит! Кирәксез табып, сүземне бүләрләр, шаулый башларлар дип тә курыкты. Ә болай сүз бирсәләр дип, әйтәсе фикерләрен кат-кат шомарткан иде югыйсә. Кыз беркавым сүзсез калып, янә хәтерендә аларны тәртипкә китерде, жепкә салды.

—Сенлем, икенчесен дә тизрәк әйт инде, онытып куйма!—дип сабырсызланып әйтте иренә сыенып утырган яшь хатын.

—Мин генә түгел, әсәрне укыган һәр кеше белеп тора. Искәндәр гаилә жылысын, хатынының яратуын тели,—дип элеккечә рухланып дәвам итте Сәкинә. Үзен иркәләп эшкә озатуын, сөенеп каршылавын, тәмле ашлар пешереп сыйлавын да теләгәндер ул. Минем әни гел әйтеп тора, ир-ат бала кебек бит ул, гел кадерләгәнне көтеп тора, ди.

Ә Галиянең күңеле өйдә дә түгел, ирендә дә түгел. Ул жәмәгать эшләренә чумган. Хатын-кыз ике көймәнең койрыгын тота алмый. Мин бу сорауга жавапны үзем укыган башка әсәрләрдән дә чыгып бирер идем. Бу сорауга жавап үзебезнең авыл тормышында да бар. Ике көймә койрыгын тоту теләге хатын-кызны фажигагә китерә... Кемгәдер авыр тоелыр, әмма бер жыенгач, уемны әйтәм. Кифая апа өч баласын калдырып, әллә каягы Тамбовка урман кисәргә китмәсә, мөгаен, үзе дә исән, гаиләсе дә имин булыр иде...

Сәкинә, жилкәсеннән авыр йөкне алып ташлаган сыман, очынып сәхнә артына йөгерде. Ә аның соңгы сүзләре, кырмыска оясына ташланган таяк сыман, залда көчәя барган гөжләү, ыгы-зыгы куптарды.

Халык мыжгый торсын, ә без күз уңында Сәкинә булган чакта, алгарак китеп булса да, искәртик әле. Әлеге Түреш халкы алдындагы гажәеп нотыгы белән бу кыз үзен кеше итеп раслады, асылын ачты бит! Югыйсә, әле ул кичә генә адәмнәр күзенә гел канат ярмаган төксе бәбкә кебек күренгән иде. Бүген исә асылын ачкан кеше ул. Кешенең дә нинди асылы булып житеште бит Түреш кызы Сәкинә! Сара ике дистә еллап гомер узгач, аның белән янә күреште. Бу вакытта ул инде китапханәче түгел, гомумән беркем дә түгел, ә ижтимагый эшләрдән читләшеп яшәп яткан гап-гади авыл хатыны иде. Кулына Хабулның эш бияләйләрен киеп, каз-үрдәккә бирер өчен кычыткан, әрекмән, суган кыякларын тапап тора иде, капкаларыннан шәһәрчә зәвык белән киенгән матур гына бер яшь хатын килеп керде. Кем булыр соң бу? Йөзендә ниндидер таныш чалымнар да бар сыман...

—Сара апа, әллә танымыйсызмы? Бу мин, Сәкинә бит... Бибиләтифа янына килүем ласа!

—Сәкинә!—Хатын бияләйләрен ташлады, колачын жәеп кунакка каршы юнәлде, кочаклашып күрештеләр.—Менә син нинди! Сөбханалла, нинди күркәмсең!

Хужабикә Сәкинәне өйгә чакырды. Чәйнегенә су салып кайнату хәстәрен

күрде, табын жыя башлады. Һаман күрешү сөенеченнән дулкынланып бер-берсенә сораулар бирделәр, тегесен-монысын хәтерләп алдылар. Кунак лимон, әфлисун, затлы кәнфит, чәй кебек күчтәнәчләрен өстәлгә чыгарып салды. Күчтәнәче күчтәнәч, анысы өчен рәхмәт, тик Сарага Сәкинәнең эш, яшәү хәлләрен белү кыйммәтрәк иде.

Түреш кызы Фәннәр академиясендә, Мәскәүдә эшләп ята икән. Психология фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешкән. Гыйльми китаплар яза. Фәндә үз мәсләге бар, ишле санда шәкертләрен дә булдырган икән... Чукрак Бибиниса кызы Сәкинәгә хәзер баш күтәреп, үрелеп кенә карарга туры килә. Үссә дә үсә икән кеше! Бу инде алты айлык курсларны бетереп китапханәдә утыру гына түгел... Асылы белән хезмәткә юнәлгән соклангыч кеше Сәкинә!

—Йә соң, гаилә хәлләреңне дә сөйлә!—диде Сара.

—Мин үземне фәнгә багышладым инде Сара апа. Кияүгә чыкмадым,—дип беркадәр уңайсызланыбрак җавап бирде Сәкинә.—Тик минем өчен борчылма, варисым бар. Балалар йортыннан алып ир бала тәрбияләдем. Үз балам кебек дияр идем, табып карамагач, әйтү кыен. Ифрат яратам үзен. Кеше булып килә инде, Ходайга шөкер!

—Ике көймә койрыгын тотмыйм диден инде, алайса,—диде Сара Сәкинәнең клубтагы нотыгына төрттереп.

—Әйе, Сара апа,—дип җөпләде кунак бик җитди төстә—иргә чыгып, гаилә корсам, мин фәндә үземне раслый алмас идем шул... Фән, гыйлем бит ул, Сара апа, холыксыз ирдән дә болайрак. Җаның, тәнең белән бирелгәнне ярата. Инде янәшәндә тагын ир, балалар торса?.. Юк, мин ике ир белән торган хатын мәгыйшәтен күзаллый алмыйм.

Сара апа! Менә үзебез дә сизми иң кирәкле сүзләргә килеп чыкканбыз. Яшьлектә салынган уйларга кайттык. Шулар өчен мин бит сиңа рәхмәт әйтергә дип килдем. Китапларың өчен, киңәш-табышларың өчен рәхмәт! Син миңа курыкмыйча зур дөньяга чыгарга көч бирдең, канат куйдың. Укытучыларымнан да кадерлерәк кеше бит син миңа, Сара апа!

Кунакның яшьле күзләрен сөрткәләп әйткәннәре бик нык хәтеренә сеңде.

## VII бүлек

Сәкинә сәхнәдән йөгереп диярлек чаршау артына кереп югалгач та, гөжләп торган халык каршысына мәктәпнең татар теле, әдәбияты укытучысы Нәгыймә Харисовна күтәрелде. Кыска чәчле башына зәңгәр беретка элгән урта яшьләрдәге кырыс йөзле хатын бу.

—Син, Шаһназарова, һаман китапта язылмаган сүзләр сөйлисең, һаман заманга ярашмаган фикерләр чәчәсең!—дип халыкка карап түгел, ә Сәкинә югалган якка юнәлеп бармак янады ул.—Шунын өстенә Кифая Галиәсгарова кебек хөрмәтле кешенең, коммунистның истәлеген хурлыйсың... Ә синең «Тапшырылмаган хатлар» китабына бәйле сүзләрен тоташ хата, «икеле» генә түгел, «берле» куярлык сина. Бәхетне ялгыз яулап булмый. Күмәк көч белән, сыйныф белән яулыйлар аны, Шахназарова. Кеше үз иминлеге өчен түгел, халык мәнфәгатьләре өчен яшәргә тиеш! Кирәксә, хәтта гомерен дә бирергә тиеш. Иптәшләр, сездә хата фикерләр калмасын. Галия һәрьяктан дөрес образ! Кифая коммунистның тормыш адымнарыннан ялгышлар табу шулай ук хата!

—Туктагыз әле!—дип залның уң канатыннан, пункт юклыкка зарланган өлкән яшьтәге хатын янә урыныннан күтәрелде.—Нәгыймә Харисовна, сез әлеге күренекле сүзләрегезне мәктәптә, укучыларыгыз алдында сөйләрсез. «Берле»ләрегез белән дә мәктәптә куркытырсыз. Ә монда ил-көнгә якынрак

килеп, турысын әйтик әле. Менә мин үзем—мәрхүмә Кифаяның ун күршесе. Тамбовка урман кисәргә язылганын ишеткәч тә, сорадым: «Кифая, ул өч баланны кемгә калдырасын сон?»—дидем. Әйткәнне яратмады бу. «Минем Хабулым бар, карар!»—диде. Хабул—житкән бала, әйе, сүз юк, акыллы бала. Тик ир-ат женесеннән бит ул. Хабулга карарга гарип кызы калды Кифаяның. Гаурәтенә кагылырга, күлмәк-ыштанын алыштырырга кирәк. Ир бала бу эштән тайчынмасмыни? Менә шуны уйлый белмәде Кифая. Мин дә барысын ташлап Тамбовка китәр идем. Бергә эшләү, күмәк ашау-эчү нинди кыен эштә дә кызык ул. Гулять итәргә дә җай табыла... Тик китә алмыйм шул мин үзем—гаилә тота!

Хабулны телгә алгач, әйтсәм әйтим. Сенелен карауга була мәктәпкә дә жибәрмәделәр үзен. Жиде сыйныф белем белән калды, бахыр. Хәзер ятимнәр белән интегә инде... Ә бездә гаилә йөгеннән котылырга торган ирдәүкә хатыннар байтак. Минем андыйларга әйтәсе сүзем шул. Башта балаларынны булдыра алганчы күтәр, кеше ит! Иренне яхшылап тәрбиялә! Аннары инде комун бул, мир эшенә чык!

Ә Сәкинә сенелгә бармак янамагыз, Нәгыймә Харисовна! Ул да минем күрше, яхшы беләм. Кифая мәрхүмә хакында аның сүзләре ифрат дөрес! Мондый комуннарны үрнәк итеп куймагыз безгә...

—Синең сүзләр дә дөрес, Фәһимә апа!.. Дөрес сөйлисең!—дип берничә кеше залдан кычкырды. Тагын гөжләү китте, аяк тибүчеләр табылды. Нәгыймә Харисовна бу аяк тибүләрдән, үзенә юнәлтелгән ямьсез сүзләрдән шүрләп сәхнәдән шылды.

Бу арада Сара залга үтеп, сәхнәгә табан олы яшьтәге, ак чәчле, күзлекле кешене житәкләде. Халык шаулашудан арына барып, сабыр гына картның мөнбәргә күтәрелүен күзәтте.

—Мин үзем дә мөгаллим, исемем дә Мөгаллим. Картмын инде, оланнар! Китап хакында сөйләшү була дигәч, килмәүне гөнаһка санадым. Китап—изге әйбер!—диде ул шактый гына көр тавыш белән.—Тик әдәбият сөеп гомерем үтсә дә, китап шул кадәр гауга чыгарыр дип уйламаган идем. Мин инде җир бүлешкәнне дә күргән, авылга староста сайлаганда да катнашкан кеше. Валлаһи, бу кадәр дә тавыш чыкмый иде мир жыеннарында. Сөбханалла, китапның кешеләргә тәэсире арта бара. Пәйгамбәрләр юкка китап язмаган шул.

Сара сенел үтенгәч, Гадел Кутуй китабын укыдым мин. Өслүбе яхшы. Адәм жинел укый. Галия дә чын сәвит баласы булып баса. Аның хакында сез күп сүләдегез. Тик мин уйлыйм, бу сәясәт белән нык сугарылган шәүлә. Гадел Кутуй үзенчә, сәвитчә исәп тота, ә халыкның үз аршыны бар бит, оланнар. Бәхәс шуна. Сәясәт сеңгән китапның гомере кыска булмагае...

Мөгаллим карт тынын алмаштырды, күзлеген салып аны кулъяулыгы белән чистартып торды. Янә киде дә сөйләвен дәвам итте:

—Яшь кызны Шаһназар нәселеннән дидегез, бугай. Сәкинәме? Шул бик акыллы сүз әйтә бит, оланнар. Хатын-кыз гаилә учагын тота, ди. Хатын-кыз ике көймә койрыгын тота алмый ди... Урамга, мир каршына чыкканчы, баласын, ирен карасын дип, сүзен көчәйтүчеләр дә табылды. Монда борынгы хакыйкать күрәм, оланнар. Ата-баба да еш искә алды аны.

Мин әле Шаһназар дигәч, Бибиниса киленне искә төшердем. Аның атасы Гыйрфан безгә хәлфә булды. Җәдитчә укытты. Һай, гыйлемле кеше иде! Шулай әлеге Сәкинә бала Шаһназарларның варисы булып чыга бит. Тамыры булмаса, оясында акыллы сүзләр ишетмәсә, каян килсен бала авызына хикмәтле кәлимә?!

Җепне өзмәскә, тамырларны сакларга кирәк, оланнар! Шунсыз халык көчле, рухлы була алмый. Тик арагызда бәхетне, мәхәббәтне, гаиләне

заманача, сәясәткә карап аеручылар бар. Болар өчен корбан сораучылар да булды. Тик үлгәч, дөнья бәхете сиңа эләгәме соң? Ә исәннәр кеше корбаны белән яуланган бәхетнең кадерен беләмени? Шуңа күрә үләргә һич ашыкмагыз оланнар! Кеше тугач, матур яшәргә тиеш.

Аннары тагын шуны әйтим, Нәгыймә бәхетне сыйныф белән, күмәкләп яуларга кирәк, ди. Шулай итәсе иде дә бит, бәхет көтү булып йөрми шул. Күпләр аңардан өлешсез кала, димәк. Шуңа бәхет кошын һәркем ялгызы тотарга ымсына. Шулай итми дә булмый. Иң олы бәхет—мәхәббәт белән яшәү. Мәхәббәтсез, сөюсез яшәү—яшәү түгел инде. Пәйгамбәрләр китабында да мәхәббәт бик макталган. Йосыф—Зөләйха кебек бер-берегезгә гомерлек гашыйк саклап керсез, хыянәтсез, яшәгез, оланнар. Гадел Кутуй белән килешмәгән урыным шунда минем, оланнар, гаеп итмәгез...

Халык шаулатып кул чапты. Берничә җинел сөякле егет Мөгаллим картның аркасыннан сөя-сөя җитәкләп урынына алып китте. Залда сөенечле, җиңел кыйбла җилләре исеп киткәндәй булды. «Инде, Ходаем, азагына кадәр шул халәтне саклыйсы иде! дип уйлап куйды Сара.—Тик ничек итеп? Ничек гаугалашмыйча, акыллы гына ябып куярга хәзер тамашаны?»

Кинәт башына килгән уйдан кызның күзләре очкынланды һәм сөенеп, елмаеп сәхнәгә омтылды:

—Хөрмәтле авылдашлар! Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәре буенча бик җанлы барган әңгәмәбез инде азагына якынлаша. Мин аны йомгаклап куяр өчен авыл Сәвите рәисе һәм партия ячейкасы секретаре Минач Гайфетдиновка сүз бирәм. Рәхим итегез, Минач абый!

Алдагы рәтләрдә куштан-актив төркеме белән бергә утырган Минач дертләп китте. Аерым чыгышларны тыңлап, күптән инде хаким ирнең яңаклары уйнаклый башлаган иде. Сүзне ул китапханәче үтенмәсә дә, әйтәчәк иде, әлбәттә. Ничек кенә әйтергә җыенып торды әле ул! Тик коммунистлар башлыгы белән халык арасында бер аермалык булды. Кешеләр сөйләп, үзара бәхәс корып яисә төрлечә кычкырып хуплап яисә кире кагып, һич югы аяк тибеп утырганда, бу барысын эченә җыйды. Аеруча саруын кайнаткан—борын асты да кипмәгән Сәкинә булды. Динче, кадимче коткысын тарата бит бу кыз. Кулак җырын җырлый. Валлаһи, сәвит мәктәбендә укый димәссең. Директорлары Ришат Гәрәевич, укытучылары тарафына юнәлтеп: «Кем тәрбияли бу йөгәнсез баланы?» дип усал итеп сорарга теле кычытты аның.

Дөнья болгатырга оста Фәрхуригә да тозлап-борычлап кисәтү ташларга җыенды рәис: «Телең белән тегермән тартма, басуга чыгып, эш башкар, Сәйфетдинова! Югыйсә, сепараторыңнан файдаланып кешедән каймак җыясың, симерәсең син».

Тамашадагы чатаклыклар өчен китапханәчене дә пешекләргә кирәк, дип уйлады Минач. Ни уйлап сәхнәгә борынгы мәдрәсә мөгаллимен менгезә ул? Кая авыл ударниклары? Сәвитчә яшәү ысулын яклаган активка ник сүз бирелмәде?

Минач үзе дә ачык авыз, сәяси томана инде... Сара китап укучылар конференциясен уздырырга рөхсәт сорап кергәч, план-фәләнен дә сорап тормады бит. «Үткәр!» диде. Ул гомумән, әкият-хикәят тарафына кызык-мызык чыгару диебрәк кенә карый иде. Ә баксаң, дошманың белән мылтык атышу, юк, алай гына түгел, дөньялыкны дер селкетеп бомба шартлату сыман куркыныч бер фронт икән ласа бу нәфис әдәбият дөньясы! На чеку торырга иде дә бит, җебегән булгач, эченә җыясын шул. Хәер, эчкә кергән барыбер бер чыга ул. Минач та үзе белеп, форсатын табып, вакытын чамалап чыгарыр әле. Үзләренә таш атканнардан шартлатып бер үчен алыр әле ул...

Мөридләренең чыш-пышларына колак салгалап, янак итләре сикерешкән Минач рәисне тагын бер нәрсә тынычландырды. Түреш китапханәсенең мөдире Әбүталипованың конференция үткәрүен белеп, әлеге дә баягы һәркая борын тыккан «Азат хәят» хәбәрчесе Мансаф Хакимов һәм район мәдәният бүлегеннән тагын кемдер Түрешкә килергә җыенганнар иде. Ярый әле, үзләрендә ниндидер җитди сәбәп чыгып, болар авылга килә алмадылар. Югыйсә, язып чыгып, райком бюросына куеп, авылында кулак идеологиясен таратучылар үрчетәсең син, дип урыныннан очырачаклар иде бит...

—Минач абый, халык көтә бит...—дигән Сара тавышына рәис айнып китте: «Йомгакларга икән йомгакларга... Беренче тапкыр гына түгел, сүзендә гауга, тавышка янә дә урын калдырмыйсың. Һәр тарафка ярашлы, гомум сүзләр табасың. Көйлисең, чөйлисең... Эшне оештырган кешегә дә рәхмәт әйтергә онытмыйсың. Иң мөһиме: азактан түбәне очлап куярлык чакыру, лозунглар таба белергә кирәк!»

Ун-унбиш адымлык сәхнәгә чыгу юлында Минач кул астында эшләүче Сараның бүгенге зирәклегенә, тапкырлыгына үзенчә бәя бирергә дә өлгерде: «Кара син аны, кеше кулы белән утлы күмерне тота белә бит бу! Юкка гына китап мәгарәсендә ятмыйдыр шул».

...Кичәдән соң яшьләр уен корып җибәрделәр. Сәлим белән Хабул гармунда парлашып та, чиратлашып та уйнаган көйләргә «уникеле», «дүртле» дә биеделәр. «Капка»га да тезелделәр, «крест» та типтерделәр.

Сара өчен бу көндәге яңалыкның тагын зурысы—Хабулның үзен озатып куюы булды. Шикләнергә урын юк, юл унаена карап очраклы парлашу, сөйләшеп ара кыскарту гына түгел бу. Егет кызның янәшәсендә атлап, үзара тегесен-монысын кабаланып сөйләшеп, азак аңа хәерле төн теләп капка төбенә кадәр озаткан икән, димәк, аның нияте җитди...

Калганнары кышкы җепшек кичтә икәү әвәләп тау башыннан шудырткан кар йомгагы кебек тиз тәгәрәде. Яңа ел кичендә Сара Хабулга кияүгә чыкты. Язмышындагы кискен борылышны кыз үзе дә абайламыйча калды. Ник болай ашыкты? Авыл белән бергә тикшергән әдәби герой Галия кебек көчле, тәвәккәл зат булып күренәсе килдеме аның? Әллә киресенчә, гаилә учагы тергезеп, ирне бәхетле итә алган тугры хатын итеп расларга теләдеме үзен Сара. Хәзер моны ачык әйтә алмый. Тик Гадел Кутуй китабы кызны, оста димче кебек, гаилә кору турында җитди уйлатты, ашыктырды.

Бәлки Сараның Хабулга чыгуында Минач абыйсының да йогынтысы булгандыр? Агач астында калып үлгән коммунист Кифаяның улына бик кызганып карады, тормышын көйләүдә аңа ярдәм итәргә теләде бугай ул. Егет кызның үзенә тәкъдим ясарга батырчылык итәр идеме икән? Ай-һай, юаш егеттән булырмы бу? Минач рәис кызның кылларын башлап үзе тартты бит... «Идеяви сайланыш дип баш ватасы түгел. Хабул—безнең кеше. Коммунист баласы. Гаилә кыенлыкларын бергә-бергә күтәрергә өйрәнергә кирәк безгә. Интектермик егетне. Ошатсаң, чык үзенә!»

Әтисе Кыям Хабул белән туганлашуга һич каршы булмады. «Ат белән любой эшне башкара. Салам-печәнен дә ташый. Урманнан бүрәнә дә кайтара. Мондый ир белән яңа йорт кору да авыр булмас. Булдыклы ир-ат җирдә аунап ятмый. Теләгең булса, чык!»

Хәер, җиде үлчәп, бер кисә торган Кыям бригадир авыл башлыклары белән арасын бозып, кызына, башкача сүз әйтә алыр идеме икән? Аның каравы, әнисе Зәмзәмия Хабулны кияү итеп күрү түгел, хәтта исемен дә ишетергә теләмәде. «Юк, Сара... Юк, кыз, акылың булса, нигезләреңә аяк басасы булма! Туең турында ишетергә дә теләмим, азгын ана баласы бит ул»,—дип күтәрелеп бәрелде ана. Аннары башын бәйләп, ыңгырашып түшәккә үк ауды ул.

Менә шунда Минач рәис яшьләр язмышын бөтенләй үз кулына алды. Тирә-якта инде гадәткә керә башлаган хәл. Клубта комсомол туе ясап өйләнеште Хабул белән Сара. 1935 елның соңгы йолдызлы киче Түреш халкы өчен бәйрәмгә әйләнде.

Сый-хөрмәттән өстәлләр сыгылды. Хәмернең агы, кызылы да, көмешкәсе дә чишмә булып акты. Ә кияү белән кәләшкә яуган тәбрикләүләр, теләкләр, күктәге йолдызлар кебек, сансыз-хисапсыз иде.

## VIII бүлек

Алман күчтәнәчен кабарга ниятләгән атнакичкә тагын ике көн калды... Хабулның хәле ничеклеген бер, Аллаһ кына беләдер, ыңгырашмый-нитми, элеккечә түшәгенә кадакланган килеш ята бирде. Бер карасаң, күзе йомык, йөзе тыныч аның. Янә баксаң, күзләрен түшәмгә төбәгән. Үпкәләгән бала төсле... Иртәдән бирле шалтыратмый да... Ә Сараның үз хәле, ай-һай, мөшкел. Онытылып ризык капсаң, үңәчнең сызлавына чама юк, сыгылып ук төшәсең. Күңелен болгатып башы авырта, тәне сызлый. Ятсаң, чир тагын да көчәя сыман. Сулыш та тәмам буылып китә. Шуңа ыңгырашып булса да, аяк өстендә йөрүең хәерлерәк...

Менә ул кәҗәсен савып, малларын көтүгә озатты. Тавык-чебешләренә җим сипте. Бакчага чыгып, помидор-суганын җыясы иде дә бит, дәрманы юк шул. Төнлә яуган яңгырдан соң җир дә бик чыланган. Өйдә ниндидер шөгыль тапсаң гына... Хабулга бирәр затлы аш әзерләргәме икән әллә? И Ходаем, аның да ризыгы киселеп бара түгелме соң? Соңгы ашлары, тәгамнәре бит!

Карчык, күңеле йомшарып, иренең нинди ризыклар яратуын барлады. Эремчек пәрәмәчен яратты. Төче коймак дип үлде. Әче камырдан пешерелгәнен күпме генә майлама, ничек кенә баллама, барыбер яратмады. Ә... Хабулның иң яраткан ашы бәлеш иде бит! Берәр бәйрәм көтелсә, яисә кунак табыны турында сүз чыкса, «Бәл-леш!» дияр иде. Мичтән генә чыккан, тәмле исләр тараткан бәлешне өстәл уртасына утыртып, сызыклы өрә сибә-сибә кысташкалап ашау өчен җанын фида кыларга әзер иде инде хәләле...

—Бәлеш пешерим!—дип пышылдады Сара.—Ризык әрәм булыр, дип куркасы түгел. Гапсаттарга кертермен. Нуриәсма китеп барганнан бирле каты-котыга кучте... Әминә карчыкка да өлеш чыгарырмын. Бездән хәер булыр!

Сара карчык бисмилласын әйтеп, тәвәккәлләп эшкә керешә. Аллага шөкер, уйлаганын гамәлгә ашыру өчен кул астында барысы да бар. Инде миченә ут үрләтсә дә була. Бәлеш дигәч, кортка әрдәнәдән юкә пүләннәрен сайлап кергән иде. Төрткән уты тирәсенә җайлап кына шуларны тезә башлады. Утын гына дисәләр дә, һәр агач пүләненең үз яну рәвеше бар шул. Усак пыскып, миченне генә түгел, өеңне дә ыс, төтен белән тутыра. Нарат, киресенчә, дулый, шарт-шорт килә, тирә-юньгә чаткы чәчә. Имәннең януы тыныч тынычлыкка, тик бар җегәре күмергә күчә аның. Кирпечләрне һич тә тигез кыздырмый ул. Бәлешең күмер урынына эләксә, Ходай язмасын, көеп, янып китәргә дә мөмкин көткән ризык.

Юкә исә тыныч яна, бөтен мичне купшы, озын телле, карасу очлы ялкын белән тутыра. Мичнең һәр тарафын тигез итеп ялый, шәп кыздыра ул. Ичмасам, кызык өчен, яисә хуҗабикәгә үч итеп, коймак, кабартма өстенә бер чаткы ыргытмый. Хәер, юкәдән чаткы түгел, күмер дә калмый. Бөтен җегәре ялкынга күчә аның...

Мичкә карап уйланып торган Сара дертләп куйды: «Ходаем, бездән дә, шулай күңел өчен, бер истәлек әсәре калмас микәнни? Күршеләр белән дә

бәхилләшми китеп барырбызмы?

Ут ялкыны әкренләп пүләннәргә үрләде, берәм-берәм аларны ялап, кочып алды, зурайды, көчәйде. Юллыкка моржага үрләп сулышын кинәйтә, гүли һәм терелүенә янә сөенеп жыр суза башлады ул.

—Ялкын, ялкын, ныграк үрлә!—дип пышылдады Сара карчык.—Үз жырынны көчлерәк гүләт, безнең өйгә жылынны, яменне бир, жан күшектергән салкыннан арала әле безне. Синең кулда мондый могжиза бар бит, учак-ут! Хәтерлисеңме, зыкы кышкы суыкта күшегеп эштән кайтам. Өй дә суынган, тын буйлары парлана, шыксыз, гөлләрем боек. Мин ашыгып мичкә киләм, куз табып алам, ут тернәкләндерәм. Менә ялкын бии башлый. Иелә, сыгыла, үзенчә тыпырдый, сикеренә ул. Ут биләмәсен һаман кинәйтә бара, өскә дә үрли. Инде аның тавышы да ачыла. Үз көен табып, гүләргә, жырларга керешә ул... Бу, мөгаен, борынгы аучыларның сунарга чыгар алдыннан башкара торган йола биюләре кебек, утның да гап-гади яшәп китү рәвешедер. Әмма адәм өчен могжизалы тамаша бу. Ут кабызу, ут үрләтү һәрчак сөенеч. Ут кешегә туклык, жылы, яктылык, ямь алып килә бит.

Минем учак-ут жегәре белән казанда аш кайный, самавыр жырлый. Өйгә тәмле ис тарала, жылыдан гөлләргә ямь кайта. Жанындагы сөенечне арттырып, ирем ишектән үк кычкыра: «Әй, тамакны кычыта... Нәрсә пешердең, Сарабикә?» Ул ара балам мәктәптән кайтып керә: «Әни, безнең өйдә ничек жылы!»

Боларның барысы өчен дә олы рәхмәт сиңа, учак-ут! Хатын булган кешегә сиңа табыну фарыз шул. Синнән башка нинди яшәү, тормыш итү булырга мөмкин? Әмма ничек кенә зурласам да, миңа синең белән хушлашырга вакыт житте, учак-ут... Син үзең нишә тапкыр сүнәсең, сүреләсең, тик кузың калгач, янә кабынасың. Ә бәндә бер сүнсә, кабат кабынмый шул. Миңа да сүнәргә, синең белән мәңгегә хушлашырга туры килә, минем шәфкатьле учак-утым.

Әй, мәрхәмәтле учак-ут, хушлашканчы әйтче миңа. Син бакыйлыкның ялгыз, бердәнбер утымы? Юкка сорамыйм, адәм синнән китеп, тәмуг утларына төшүдән яман курка. Ышанасым килми, шәфкать иясе белән көйдерүче бер үк асылдан булмас. Житмәсә, икенче, башка дөнья уты бит ул... Белсәң, сөйлә миңа, учак-ут, тәмугның чынлап та жиде коесы бармы? Алардагы утлар берсеннән-берсе зәһәррәкме? Су сорасаң, зобанилар, чынлап та, эчләренне көйдереп алырдай утлы касә сузалармы?..

Ник Сара карчык жәһәннәм газаплары турында сораша, тәмуг уты каршында калтырый, дип аптырыйсыңмы, учак-ут? Әй, гөнаһлы дөньяда яшәп, тәмугтан кем курыкмый соң. Алдында чара, әмәл калмаса, языклы гамәлдән кем котыла? И, Ходаем, үзең ярлыка, тәмуг утларында янарга язма!

Ә вөждан уты сиңа кемдер, кардәшме, читме дигәндәй, миңа таныш, учак-ут. Аның хакында синнән төпченергә дә кирәкми миңа. Ялкынында житәрлек яндым, көйдем инде мин. Гөнаһларым өчен тулысынча түләдем кебек инде, уткай... Яшәү—жәһәннәм коесына ук төшеп көйрәү булмаса да, барыбер яну инде ул. Тик синең эчеңдәге пүләннәр сыман һәркем үзенчә дөрли-көйри, учак-ут...

## IX бүлек

—Әйдә, килен, төкле аягың белән!—дигән сүзгә ияреп бусага аша атлап ызба эченә үткәч, иң элек Сара күзенә ташланганы өйдәге фәкыйрьлек, шыксызлык булды. Тәрәзәләр ялангач, стеналар шыр иде. Өй түрендә зур сәке, аның өстенә түшәк, юрган, мендәрләр өелгән. Челтәр-япма астында

булмагач, һәркайсы үзенчә акаешкан, чекерәйгән... Өй уртасындагы озынча өстәлне берничә яктан тупас такталы эскәмияләр уратып алган. «Нәкъ колхоз идарәсендәге кебек, тәмәке төтене белән ыслану гына житми үзләренә», дигән әче уй узды килен башыннан.

Күрми булмый, киң такталы идән-сайгаклар, сарысы чыкканчы юылганнар юылуын, тик өсләрендә күнел өчен палас, жәймә әсәре күренмәде. Мич алды, аш-су әзерләү почмагы гадәттә такта белән бүленгән була. Тик Хабул ызбасы мондый бүлмәдән дә мәхрүм иде. Шуңа күрә савыт-саба, чиләк, чуен, ухват ише жиһазлар чәчелгән хәлдә күзгә кадалып торалар...

Саранын Түрештә байтак кына кешеләргә кергәне булды, тик берсендә дә мондый чекерәеп торган ярлылыкны шәйләмәде ул. Ә үзе үскән йорт эче хужаларнын, бай булмаса да, шактый житеш мәгыйшәттә яшәвен әйтеп тора иде. Кисәк әнисенең кара янып: «Атлап басасы булма!» дигән янавын хәтерләп, йөрәге сыкрап, сызлап куйды килен буласы кызның. Ходаем, монда ничек яшәргә, көн итәргә булыр икән?!»

Янәшәсендәге Хабул кәләшнең кичерешләрен тойды, гаепле, төшенке тавыш белән:

—Сара, борчылма! Исән булсак, барысын жайларбыз әле...—диде.

«Хет әйтә белде»,—дип уйлап бераз тынычланды яшь килен. Һәм шул көндә үк жинен сызганып Хабул өен ипләргә керешә: «Куышка ия буласын килсә, аны үзең теләгәнчә үзгәрт, үз зәвыгыңны сал, килен!»

Бабасы—Кыям бригадир—кушканны тынлап, ир кеше иртән үк эшкә китте. Сыерлар өчен ерак Чукай чалуыннан ике рәт печән кайтарды. Кичен арып, туңып өенә кайтса, күзләренә ышанмый торды. Өй ожмахка әйләнгән ләбаса: тәрәзәләрдә челтәр, пәрдәләр эленеп тора, кашагалар карашларны иркәли. Сәке өстенә авыл остасы суккан, бизәкле зур палас жәелгән. Паласларның кер күтәрерлек тынычрак төсләре берничә тасма булып идән өслегендә дә сузылып ята. Өстәл дә купшы кунак кызы сымак, матур шакмаклы, йомшак ашьяулыкка төренгән. Ни гажәп, авыр эскәмияләр юкка чыгып, өйдә жинел юкә урындыкдар пәйда булган. Каян алган соң Сара боларны?

Мич алды биләмәсе һәм аш-су пешерү урыны да тигез тартылган чаршау аркасында серле бер почмакка әйләнгән. Хужабикә, учак-ут патшалыгы бу... Билләһи, үз капкаларын ачып керүен искәрмәсә, Хабул чит кеше өенә кердем мәллә дип, чыгып та китәр иде...

—Йә, жаным, булганмы?—дип почмактан, кәжәнкә ягыннан кулларын сөртә-сөртә елмаеп ире каршына чыгып басты Сара.

—Сорыйсың тагы... Ничек боларның барысына да кулың житеште, Сара?—диде Хабул һаман да аптырап.

—Менә Фәрһат булышты,—дип яшь хатын сәкедә утырган кара тутлы малайга ишарәләде. Жингәсенең мактавыннан эреп, Фәрһат матур итеп елмаеп куйды. Урындыкта утырса да, гәүдәсе, башы туктаусыз чайкалып торган Әлифә дә, шатлык белән балкып, тегендә-монда төртеп Хабул абыйсына ниндидер сүзләр кычкырды.

—Матур шул, матур, Әлифә!—дип аны жөпләде абый кеше.

—Әлифә дә булышты бит. Чаршау төбен тотып торды,—дип Фәрһат тә сүз кыстырды.

Моны ишетеп кыз тагын жанланды. Алпан-тилпән мич катындагы чаршау янәшәсенә атлап, Хабулга ниндидер сүзләр бытылдады...

Туганнар үзара жинел аңлашалар ла ул. Тик менә Сара бу кыз белән нишләр? Сүзләрен, ымнарын аңларга тырышу түгел, йөзенә туры карарга да курка бит. Кеше түгел, әкияттән килгән ниндидер ят зат, өрәк кебек.

Урман пәрием͏е, су иясеме шунда. Әллә төнлә атларның ялларын үрә торган йорт иясенә тартыммы?.. Хабул йортына аяк басканда, Сараны өйдәге фәкыйрьлек өркеткән иде. Әй, исән кеше малы юкка кайгырамыни? Мал бүген бар, иртәгә юк ул. Тулы бер дәүләт иясе булган патша, хаким дә, үлсә, коры кул белән торып кала. Ә инде сина язганы булса, эзләмәсән дә, хәләл мал теш ертып керә бит. Менә Ходай бәндәгә гариплек язмасын. Олы шүрләү, курку шулдыр! Өлешенә каһәрле язмыш төшеп, ник тууына үкенергә генә каладыр ул...

Шул Әлифә өрәге аркасында бит, яшь ир белән яшь хатын арасында әллә нинди тузга язмаслык мәрәкәләр булып алды. Урынны кемгә ничек һәм кая салырга дип аптырады Сара.

—Фәрһат, кая ятасың?

Малай ике дә уйламый, җавабы әзер:

—Мич башына, апа-җинги!

Чынлап та, мич башы җылы, иркен, малайның буен сыйдырырлык. Җинги кеше анa йомшак, иркен түшәк әзерләп бирә.

Әлифә белән нишләргә? «Кая ятасың?» дип кызның үзеннән сорап булмый. Хабулга эндәшә Сара. Ир кеше башын кашып тора:

—Соң сәкегә, почмак кырына сал!

Сара түрдәге сәкегә—үзләренә һәм Әлифәгә—урын җәя. Сәке кин, зур анысы, теләгәндә уртага тагын берничә кеше сыйдырырга була. Тик Әлифә белән янәшәлек тыныч йоклар өчен түгел икән. Кыз төне буе угаланып, аяк-кулларын бәреп, ыңгырашып, хәтта котны алырлык дәрәҗәдә кычкырып чыга.

Хабулның боларга исе китми бугай, Сараны кайнар итеп коча, назлы итеп сыйпый, үбеп-үбеп ала. Әмма хатынының шикләнүдән тәне каткан: «Җаным, йокламый бит... Бераз сабыр ит!»

Хабул кисәк урыныннан тора, почмак тарафына юнәлә, кисмәктән су алып эчә. Янә килеп ята.

Тик бу арада Әлифә тагын бәргәләнеп ала. Авыз эченнән бытылдап куя. Үзен сумы, әллә утмы арасында калган кеше кебек сизгән Сара нишләргә дә белми...

Берничә көн шулай кабатланды. Өченче көнне инде Хабул үзе түзмәде. Иртәдән үк ихатадан балта алып кереп, күз ачып йомганчы зур сәкене ботарлап ташлады. Ә кичен атлы чанага салып, колхоз мастерскоеннан юкә кровать кайтарып куйды ул.

Баш-башлары матур рәшәткәле, иплe ак сынлы ятакка түшәк җәйгәндә Сара астыртын көлеп, әйтеп куйды:

—Әллә кайчан кирәк иде!

Икәүләшеп кирәк чакта караватны чыбылдык эченә яшерерлек җай да әтмәлләп куйдылар. Хәзер Сара Әлифәгә урынны кин сандык өстенә җәя. Әмма берничә рәт кызны түшәкләре янында күреп, коты очты җинги кешенен.

—Куккам, куккам!—диде Әлифә калтыранып.

Тавышка Хабул да уянып китте:

—Курыкма, сенел... Әйдә үзем саклап торам,—диде ул һәм Әлифәне житәкләп урынына яткырды, янәшәсендә саклап торды.

Табын кору, ашау-эчү тирәсендә дә савыт-саба шалтырап куйгалады. Хабул туганнары белән бер коштабактан ашарга гадәтләнгән иде. Тәүге көннәрдә яшь килен дә бу тәртипне бозарга җөрьәт итмәде. Уртак табакта бәрәңге, ботка булса, түзәрлек әле. Әлифә, чайкалдырса да, ризыклы кашыкны авыз шәрифләренә китереп житкерә. Ә шулпа булса, җилдә чайкалган көймә сыман, калтырап торган кашыктан тик тамчылар гына

кала. Аның каравы кыз алдына шулпа күле җәелә. Коеныргa чыпчык-мазар тотып җибәр!

Үз өйләрендә аш-су тирәсендә чисталыкны, ашау әдәбен сакларга өйрәнгән кызның җирәнүенә дә чама юк. Әлифәнең ашавын күзәтеп, хәтта бер-ике рәт табынын да ташлап китте ул. Күңеле кисәк самовар кебек кайнап ташты: «Нәрсә инде бу! Үз табыныма үзем хуҗа булмаска. Кем соң мин, бер стрәпкәме әллә?»

Сара үзе дә сизмәде, теленә әнисенең сүзе килеп кергән икән. Әтисе Кыям белән чәкәләшкәндә, Зәмзәмия шул гыйбарә белән бәрә иде! «Нәрсә, мин сиңа стрәпкәме?» Димәк, кызга да ирдән үзенекен ала белергә кирәк!

Хабул белән дә сөйләшеп тормады, үзенчә эшләде яшь хуҗабикә. Итле өйрәне өстәлгә гадәтенчә коштабак белән дә китереп утыртты. Тәлинкәгә салып та чыгарды һәм аны Әлифә алдына этәреп куйды.

—Сеңлем, менә бу савыттан аша, яме!

Әлифә җингәчәсенең сүзләренә аз гына да игътибар итмичә, тәлинкәсе аша табакка үрелүен белде. Менә кашыгын чумырып өйрә күтәрергә җыена ул. Сара үз кашыгы белән кызныкына китереп сукты:

—Әлифә, савытыңнан аша!

Тик ни гаҗәп, кыз кылтайса-былтайса да кашыгын табак өстендә тотуын дәвам итте, бер бу тамашаны күзәтеп торган Хабулга, бер җиңгәсенә караш атты һәм авыз эченнән бытылдап, кычкырып елап җибәрде:

—Сау-ут тәмсез... Табак тәмне! Хабу... Хабу!

Ниһаять ир кешенең дә түземлеге бетте. Ул кашыгын өстәлгә бәреп, урыныннан сикереп торды һәм Сарага кычкырды:

—Бездән җирәнәсеңме?

Кычкырып калса гына бер хәл. Табак аша үрелеп Әлифәнең тәлинкәсен эләктерде, селтәнеп кәҗәнкәгә томырды. Тәненә әллә кайнар аш, әллә тәлинкә үзе эләкте, әче итеп песи чинап җибәрде, кайнарлык белән мич башына томырылды ул.

—Ярар, үзегезчә ашагыз. Туганнар табагына мин башка тыгылмыйм,— диде Сара һәм идәндәге ашка басмаска тырышып, почмакка кереп китте. Мәче кебек аңа да кеше күзеннән качарлык аулак урын кирәк иде. Әллә кайнарлык белән бөтенләй чыгып ук китәргәме икән? Чынлап та, нәрсә дип хәерче, гарип-горәбә арасында интегә әле ул. Ни хакына кешелеген җуя?!

Сара почмактан чыгып, сәке астына үрелде, чемоданын тартып алды һәм кулына эләккән бер кием-салымны аның эченә томыра башлады.

—Нишлисең?—диде Хабул аптырап.

—Китәм!—дип кисте Сара.

Өстәлнең бер читендә баядан бирле тавыш-ызгышны сагышланып күзәткән Фәрһат кинәт кычкырып елап, җиңгәсенең кулларына ябышты:

—Җинги, китмә! Синсез нишләрбез?

Үсмер ир баланың ихлас елап кулларына ябышуы Сараны айнытып җибәрде. Китүен китәр, ә аннары кеше күзенә ничек чалынып ул? Китап дөньясы, геройларның әхлак сыйфатлары хакында авылдашлары белән башын югары тотыпниләр сөйләшә алыр китапханәче? Юк, ул бит, чынлап та, Минач абыйсы әйтмешли, ин элек сәвит вәкиле. Нинди генә хәлгә төшмәсен, түзәргә кирәк!

Сара яшеренеп кенә күз яшьләрен сөртеп алды, Фәрһатнең яратып башыннан сыйпады:

—Ярар, каенем, елама! Китмим.

Ул чемоданын янәдән сәке астына яшерде һәм мунчала алып идәнне юарга керешге. Белмәгән икән, Хабулның бәгыре таш сыман каты булып чыкты. Әлифә белән кара-каршы утырып, уртак табактан тәмле өйрәне

чөмереп бетерә яздылар. Ә аннары ир кеше йортны, мал-туарны карыйм, дип киенеп чыгып китте. Хатын ана әллә бар, әллә юк...

Тик икенче көнне кич, токмач ашар алдыннан, Әлифә алдына куяр өчен тәлинкә сорап алды ул. Бәләкәч чүмеч белән үзе аш салды һәм кыстап сенлесен сыйларга керешге:

—Тәлинкә ничек тәти, күрәсенме? Әнә чәчкәләре! Ә ашы... Аһ тәмле, кап әле тагын... Менә шулай. Тәлинкәдә аш тәмле була шул. Гел шулай ашарсың яме, Әлифә иркәм! Ә хәзер әппәр әйт инде.

Тора-бара зур коштабакның кирәге дә калмады. Һәрберсе матур чәчәкләр, татлы җимешләр белән бизәлгән тәлинкәләрдән ашау әмәленә күчте. Шулай, тарткалашулар белән булса да, кәләш белән бергә Хабул өенә яна гадәт, әдәпләр керде.

### X бүлек

Фәрхури түтидән дә шәфкатьлерәк тагын берәр кеше бар микән дөнья йөзендә? Сон, ялыну түгел, әйтмисең дә, хәтта. Ым да салмыйсың. Ә ул мунчасын ягып уздыра, томалый да гөлдерәп килеп керә:

—Сара килен, әзерлә Әлифәне, парлап алыймчы үзен!

—И, Фәрхуриттәй, ничек кенә рәхмәтләр әйтеп бетерим икән үзенә?— дип ихлас сөенә Сара. Сөенмичә, өстеннән гарип кызны юындыру, күлмәк-ыштанын алмаштыру мәшәкате төшә бит.

Гәп, сөйләш яраткан ачык йөзле хатын үзенчә сибелә:

—И, Сара килен, кешегә савап-гамәл кирәк бит ул. Әнә теге көнне авылыбыз башлыгы Минач әйтмәдемени: «Фәрхури сепаратың белән кешедән каймак җыясың». Моны ишетеп гамәл фәрештәсе мина гөнаһ язса, аны берәр савап белән капларга кирәк бит! Тәмугка керәселәр килми, кызым, җәннәт ишекләрен ачтырасы иде Ходайдан. Калхузда трудден эшләгән кебек, яшәгәндә савап-гамәл җыярга, кызым, савап-гамәл кирәк!

«Фәрури әби»сенең үзен мунчага дәшүен белеп, Сарадан бигрәк Әлифә шатлана. Авызын ерып, ниләрдер быгылдый, суда уйнар, «чәп-чәп» кертер өчен курчакларын, уенчыкларын җыя башлый. Мунча керү бу кыз өчен чынлап та бер бәйрәм күрәмсен. Чәчләре купшыланып, тәне парланып, сафланып чыккач та, курчаклары белән һаман да мунча керү турында сөйләшә, алар белән гәп кора ул...

Берчәкны почмакта аш-су белән мәшгуль хәлдә, хуҗабикә ирексездән Әлифәнең быгылдавына колак салды. Житмәсә мич белән чаршау арасындагы ярыктан кыз үзе дә ачык күренеп тора. Җыйнаграк каз оясы чаклы кәрзин «бирнә»сеннән байтак нәрсә бушаткан. И, нәрсә генә юк монда! Төрле кисәктәге, әллә нинди бизәктәге ситса, сатин, бәрхет корамалар, чәй кургашы, кәнфит кәгазьләре, фарфор чичикайлар, бушаган кәтүкләр, төсле карандаш кисәкләре, алкалар, балдаклар, талир тәнкәләр—барысы да бар. Кызның күнелен аеруча җәлеп иткәне— курчаклар, билгеле. Әнкәсе ясап, тегеп биргәнме, әллә башка кулдан мирас булып күчкәннәрме—болар ифрат күп иде. Алъяпкычлы, калфаклы кыз да, җиләнле егет тә, шәлле әби дә, тәлпәкле бабай да бар Әлифәнең курчаклар төркемендә...

—Бар, Фәррат, Фәрури әби дәш,—дип кайсыдыр курчагына йомыш куша кыз.—Фәрури әби, әйт, кил-лен төш-шә, әйт!

Әлифә үз тирәсенә җайлап кына «егетләр», «кызлар», «әби», «бабайлар»ны тезә. Кулына ак алъяпкычлы, калфаклы, ин күрекле курчакны ала:

—Мыни кил-лен. Кил-лен матур. Исмен әйтме? Исме Сар-ра! Әдә, кил-лен Сар-ра. Мендәр бас! Төкле ай-як бул, кил-лен!

Саранын күнеле кисәк кенә айкалып куйды. «Барысын белеп, барысын күнеленә сендереп бара икән ласа бу бала!»

Әлифә шактый гына вакыт тынып торды. Кыз, күрәмсең, курчаклары белән яна тамаша корырга әзерләнде. Чынлап та шулай икән. Әлифәнең кулында җиләнле, бик күркәм, «егет» заты пәйда булды. Кыз, песи кочкан кебек, аны күкрәгенә кысып торды. Шатланып елмайды һәм янә бытылдарга керешге:

—Җег-гет! Матурмы? Матур җег-гет! Кемгә була җег-гет? Әйт, Хабу! Хабу әйтә, матур җег-гет Әлифә иркәмә!

Кыз әлеге уены белән Сараның һушын алды. Гарип дисәң дә, үз дөньясын коруда тирә-юньдәгеләрдән һич калышырга җыенмый икән ул... Әмма беркөн Әлифәнең сандык-сәхнәдә корган тамашасы хуҗабикәнең җен ачуларын кузгатты. Кызның ялгызын калдырып, агитаторлык шөгыле белән киткән иде. Кайтса, идәндә яткан чемоданын, төрле якка ташланган эчке кием-салымын күреп артына утыра язды. Әлифә зур кара гаилә кайчысы белән анын челтәрле, затлы эчке күлмәген тапап ята...

—Нишлисең син?

Әлифә кисәк айкалып-алгысып китте, кулыннан кайчысы төште:

—Күл... Күл-мәк тег-гә!

Йөрәге тырсылдаса да, ул кызның еларга җитешкән кыяфәтен күреп тыелып калды. Кулыннан күлмәген дә тартып алмады, инде эшкә ярамаслык хәлдә иде ул. «Киссә, киссен, көя!» Чемоданын җыештырып карават астына шудырды да, мич алдына килеп утырды Сара.

Кече мичкә, казан астына ут элдереп җибәрде. Йөрәге янганчы, ичмасам, утын янсын!.. Әй, күңелгә бер ялкын капса, аны тыеп буламыни? «Ходай, тагын күпме җәзаларсың икән мине бу имгәк белән? Тагын нинди җәфалар, нинди казалар күрергә яздың соң син миңа? Йорт та корырсың, кием-салымыңны да рәтләрсең, кешеләрчә яшәп тә китәрбез. Тик һаман да бу албасты өстә торса, дөньяның ни яме бар соң миңа... Әй, Ходаем, нинди гөнаһларым өчен газаплыйсың мине шулай?»

Сара үзенең эчке тавышына колак салып, аптырап та китте. Моңа кадәр нинди генә авырлык, кыенлыклар, җәбер күрсә дә, Алла затына болай ялвармый иде ул. Кичә китапханәгә почта аша Казаннан бер кап китап килеп төште. Арада Мөхәммәдьяр исемле борынгы шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» исемле китабы аеруча җәлеп итте аны. Безгә тәрҗемәсе «Егетләр бүләге» мәгънәсендә икән. Егет бүләге юк-бар нәрсә булмас, белим әле, дип укырга тотынган иде, китап белән бөтенләй сихерләнде. Әй, борынгылар мәгънә белеп яшәргә ымсынганнар шул. Ходайны зурлаганнар, Ходай сүзен тотканнар. Алла әмерен җирдәге иң хак канун дип ышанганнар. Шул хакта нинди генә кыйссалар юк мәҗмугада. Сараны аеруча бер хикмәт дулкынландырды. Шәһәр хакиме йолдыз багучылар белән очрашкач, гүзәл кыз баланы коткарырга алына. Моның ләүхелмәхфүзендә язылган икән: «Ундүрт яшенә житкәч, бүре ашар». Хаким әмере белән таш бина салына. Киек-җәнлек түгел, җил дә үтмәслек кальга була бу. Гүзәл кыз бала шунда яши башлый. Әмма хаким башына кетелмәгән уй төшә: «Ялгызына моңсудыр бит...» Өйдәш ясап, янына кол кызны кертәләр. Ә ул сорый: «И, гүзәл кыз, ник таш диварда ялгызың хәят кичерәсең? Гүзәл кыз үзенә язылганын моңсуланып сөйләгәч, кол кыз үзен-үзе белештермичә, Аллага эндәшә: «И, Ходай, бәне бүре итсәң, ни булгай!»

Кол кыз шундук явыз соры бүрегә әверелә һәм күз ачып йомганчы гүзәл кызны ботарлап та ташлый...

Унбишенче яшь китте, шаять исән гомер кичерер, дип ишекне ачсалар, ишектән халык каршына коточкыч усал бүре ыргылып чыга...

Хаким шул минутта ук ялгышын аңлап сәҗдәгә егыла: «Кичерә күр, Мәүләм!»

Учак утына караган хәлдә, Сара янә поэмадагы куркыныч өзекне хәтерләде. Теленә ирексездән утлы уйлар йөгерде. «И, Ходай, бәне бу имгәктән коткарсаң ни булгай!»

Һәм шуның артыннан ук чаршау ярыгыннан бик куркынып, тетрәнеп Әлифәгә күз атты. Тик Әлифә үз өстендә уйнаган яшен утларын абайламый, аларны бар дип тә белми, курчаклары белән уйный, ихлас бытылдый иде...

Икенче көнне хуҗабикә иртүк Хабулны колхоз эшенә озатты, Фәрһатны әзерләшеп укуга җибәрде. Инде үзенә дә озак юанырга кирәкми, авыл Сәвите җыелышы ачылган мәлгә барып өлгерергә кирәк иде. Әмма үч иткән сымак, миче һәмишә узмый тора. Инде чуены белән куеп китәр өчен борчак ашын да әзерләде, күмерләрне җыярга ымсынып кучаркасына да тотынгалап карады, тик имән кисәүләре әле һаман, аждаһа сыман, зәңгәрсу кызыл ялкын бөркеп тора иде.

Чаршау ярыгы аша үрелеп стена сәгатенә күз салса, йөрәге җу итте Сараның. Аның киенеп, йөгереп барып җитәрлек кенә вакыты калган иде... Хатынны нинди дер ят ашкыну биләп алды. Тиз генә утлы кузларны кече мичкә тартты, казанга чиләге белән суны томырды һәм чуенны ухват белән кайнар мич эченә озатып, томалап та куйды... Сандык өстендә утырып калган Әлифәгә карап уйларга да вакыты калмады Сараның, кәнсәләргә чапты.

Түреш авылы халкының көнкүреш мәсьәләләрен караган җыелыш чамадан тыш гаугалы булды. Депутатлар, алдан сөйләшеп куйган төсле, бер-бер артлы күтәрелеп, Минач рәиснең начар эшләвен күрсәттеләр. Дәвалау пункты төзүгә смета төзелмәгән, районның төзелешләр планына кертелмәгән. Фельдшерлыкка килергә белгеч кеше бар, әмма монда яшәр өчен фатир юк икән. Кооператив кибетчесе Хөснетдин эчү белән шөгыльләнә, халыкны алдый, товар кайтармый, диючеләр дә булды. Авылда налог җыю эше дә ифрат начар куелган...

Район вәкиле Бәширов әлеге аһ-зарларны тыңлап торды-торды да түзмәде, кызарынган-бүртенгән Минач каршысына басып турыдан ярды:

—Сез, Гайфетдинов, клуб, китапханә кордыгыз да, хәзер дан-шөһрәт сәндерәсенә менеп йокыга чумгансыз. Сез бит, беләсезме, бу хөрәсәнлегегез белән Совет властен халык күз алдында юкка чыгарасыз. Мин бу хәлне районыбыз башлыкларына җиткерермен!

Минач рәиснең зәңгәр күзләрен бу кадәр сагышлы, куркулы кыяфәттә күргәне булмаган иде әле Сараның... Җыен тәэссоратларына чумган хәлдә үз өенең ишеген ачса, хатын күзләренә ышанмыйча катып калды. Әлифә сандык өстендә дүрт санын дүрт якка ташлап җансыз, хәрәкәтсез ята иде.

—Әлифә!—дип кычкырды Сара һәм чусинкәсен дә салмыйча кыз янына томырылды. Аның карашын Әлифәнең йөзе тартып алды. Әлек һәрчак кылтаеп, чалшаеп торган йөзенә ул текәлергә курка иде. Хәзер бит-йөз катып калган. Сараның күзләре аңсыздан таш чырайны капшап чыкты... Ак, озын муен, төз аяк, шома яңаклар... кыйгач кашлар, төптән курпыдай дулкынлы чәчләре... Болар сылу кыз галәмәтләре ласа! Ә югарыга, түшәмгә текәлгән зәңгәр күзләр, сагышлы караш Сараның җанын айкады: «Әҗәлең булып чыктыммыни, балакай?» Бер үк вакытта сәер уй кисеп үтте аны. Кемне хәтерләтә Әлифә күзләре? Әле генә бу күзләрне ул башка кешедә күрде түгелме?..

Үлем каршында коты алынып, ис-акылын җыя алмаган Сара бу узгынчы

сорауга ярты елдан соң җавап табар. Өй чормасына менеп, иске-москыны җыештырырга керешкән иде, кулына капчык эченә тыгылган ридикюль килеп эләкте. Ачып карады. Өй хуҗасы Кифая Галиәсгарова исеменә караган төрле-төрле документлар, рәсми кәгазьләр, фотосурәтләр күзенә чалынды. Хатлар төргәге килеп чыкты. Кызыксынып бер саргылт конвертны ачты Сара. Матур сырлап язылган хат килеп чыкты.

«Исәнме Кифая!

Вербовка белән авылдан китеп, Чиләбедәге трактор заводына эшкә керешүеңне хуплыйм. Даже шәп бу! Әлегә җир казып фундамент салучы гына булсаң да, алда укырсың, һөнәр алырсың, дип ышанам. Киләчәккә фундамент булыр бу! Үзеңне яхшы яктан күрсәт. Активлар сафында бул! Бу—партиягә керү өчен бик кирәк. Партиягә басмый торып карьера ясап булмый. Шуны бел!

Минем әле һаман Оренбург далаларында хезмәт итеп ятыш. Тауларга, урман, чокырга таралып качкан Дутов бандасын дөмектереп киләбез. Татар-башкорт батальонын басмачыларга каршы ташларга торалар дигән сүзләр дә йөри. Китсәк, анда байтак вакыт үтәр әле. Ә мин, Кифая, сине бик сагындым. Һәрчак уйларымда син торасың. Үткәндәге бәхетле көннәребезне сагынам. Кара, син дә мине онытма!

Хуш сөеклем! Миначың».

Сара башка хатларны ачып, актарып тормады. Берсе дә, аңа бик зур сер ачты, шул да җиткән. Кифая белән Минач яшьлекләрендә бер-берсен сөешкән, яратып йөргән ярлар булганнар икән. Тик аларның кавышуына нindидер киртәләр сәбәп булган күрәмсен... Сара утлы күмерләрне чиләккә сыпырып төшергән сыман, хатларны ридикюльга салды. Хатлар өеменнән аерылып, аяк очына бер кәгазь кисәге очып төште. Күтәрде, язуга карады: «Кифая иртәгә Аксуга барам. Тарантаста ялгызым. Әгәр көненне минем белән үткәрергә теләсәң, иртәнге 8гә кыр-капка янына чык!

Минач».

Йөреп кенә калмаганнар, ил-күздән качып очрашулар, сөешү-якынлыклар кылу да булган инде болай кәгазьләр язышкач... Ә гарип кыз Әлифә гөнаһлы мәхәббәт җимеше булып чыкса, ни гаҗәп? Югыйсә каян килсеннәр Әлифәгә Минач күзләре? Без дигәнен капчыкта ятмый шул, кайчан да бер тишеп чыга. Кифаяның ире мескен Габбас та үз-үзенә юктан гына кул салмаган инде болай булгач... Фаҗигага китергән мәхәббәт инде бу. Азгын мәхәббәт... Намуслы ир моңа бармас... Нинди кеше соң бу Минач абый? Чынлап та, эшкә, халыкка юнәлгән затмы бу? Әллә матур, купшы сүзләр япмасына төренеп, иң элек үз-үзен кайгырткан адәмме бу? Кешеләр башыннан йөргән замана афәтеме?

...Хуҗабикә күзләрен Әлифәнең җансыз бәдәненә күчереп, кисәк айнып китте. Ничек үлгән? Мич исе тиде микәнни? Әй, ашыкты шул... Инде Хабулга ни әйтер, кешеләргә нәрсә дияр? Сара елап җибәрде һәм үз-үзенә дә хисап тотмастан Фәрхури апасына йөгерде. Күршесе җиңнәрен терсәккә кадәр сызганып камыр басып ята иде.

—Фәрхури апа, Әлифә үлгән!

Әмма ни гаҗәп, хәбәр хатынны артык каушатмады. Кулларын сөртә-сөртә ул эшеннән араланды, өстенә чөйдәге сырманы алып элде дә Сараны үзе җитәкләп өенә юл тотты. Монда кергәч, ул мәет алдына килеп басты һәм тәүге эше итеп, аның ачык күзләрен япты.

—Котылган бичаракаем. Урыны җәннәттә булсын!

Ул өйдә нindидер ят ис сизде, күрәмсең. Ишекне тупсасына кадәр киереп ачты, сөлге алып ашыгып һаваны җилләтте дә, көл кебек агарынган Сарага пышылдады:

—Шым бул! Кешегә ашыгып юк-барны сөйләмә. Өстенә бүре генә китерерсең. Духтырга ил кизүе диярбез. Аллага шөкер, тәнендә күгәргән, каралган урын юк. Куркасы түгел. Ә Хабулга кирәкле сүзне табып үзем әйтермен. Сабыр бул, кызым, Ходай багышлый, бәндә сагышлый. Берни эшләп булмый. Алла каршында саф бул, кызым!—диде.

Бу арада мәктәптән Фәрһат кайтып керде. Ул күршеләрне чакырды. Кайсыдыр чанага басып, ат куып дәвалау пунктына чапты. Каршы күрше Гапсаттар Хабулны алып кайтырга фермага китте. Шулай итеп, мәетне карау, кадерләү һәм җыештыруга бәйле әрнүле дә, гадәти дә эшләр тезмәсе башланып китте.

## XI бүлек

Сара үз гомерендә байтак үлем-китем күрде. Күңелне айкаган авыр монзар инде бу! Кемнендер җеназасында катнашып, бу хәятнең фанилыгына уфырып куясың. Икенчесенең дөньяны ташлавына ихлас әрнисең, саф яшьләрең тәгәри. Үлде, дип әйтсәләр дә, өченчесенең һәлакәтенә күңелең ышанмый тора. Моны акылга сыймас гайре табигый бер хәл итеп күрәсең, бәгырең ката, елый да алмыйсың... Сараның хәтерендә тетрәндерерлек тагын бер матәм кичерешләре яши...

1948 елның җир җиләкләре пешеп яткан кояшлы, эссе мәле иде. Үз тирәләрендәге өч-дүрт хатын белән, Сара да малае Җәмилне ияртеп, Чукай чалуына юнәлде. Болын үзәнлекләрендәге куе үлән, чәчәк арасында җиләк әле өлгермәгән, яшькелт иде. Битләүгә, тау калкулыкларына сибелделәр. Йөгерек Җәмил әле моннан, әле тегеннән әнисенә кычкыра:

—Әни, уйдык монда. Галәмәт күп!

—Күп булса, җый!—ди ана кеше һәм малайга бәләкәй буяулы чиләк суза. Җәмил сузылып ятып, астын күзләп эре, сусыл кызыл гарәбәләрне җыя башлый. Тәмлекәчне ара-тирә авыз шәрифләренә дә озатып куя ул. Сара бу табигать җимешенә хәйран калу белән бергә, яшәү хозурлыгына сөенә. Чынлап та, тирә-юньне илаһи матурлык баскан бит. Җир әллә нинди төсләр белән балкый, баллы исләр бөркетә. Кайдандыр күке аваз сала, шәүлегән сызгыра. Кыз чакырган егет диярсең... И, дөнья, әлеге гүзәл мизгелләрне күрү өчен адәм баласы әллә нинди авырлык, михнәтләр кичерергә әзер шул ул!..

Сара кулындагы дәү тырыс җиләк белән тулып килә. Җәмил дә шактый талчыкты, инде кайту ягына борылу турында уйлар чак җиткән иде. Тик авызлары тәмле азыкка тигән маллар кебек, хатыннар җиләк нәфесеннән араланырга ашыкмадылар. Ә Сара аларны ташлап китәргә яхшысынмады. Бу арада күзгә күренеп һава үзгәрде. Өермәләр кузгатып җил исте. Кыйбла тарафыннан авыр, кара-кучкыл болытлар килеп чыкты. Ерактагы урман өстендә ара-тирә ялтыраган яшен утлары гарасатның тиз ара монда килеп житәчәгенә дә шик-шөбһә калдырмады. Кайдандыр ышыкланыр урын табарга, давылны исән-имин үткәреп җибәрү әмәлен табарга кирәк иде. Сара Җәмилне җитәкләп, калкулыктагы туйралык, агачлар тарафына юнәлде.

Куе ябалдашлы имән төбендә ышык, тыныч иде. Ана белән ул шуна килеп сыендылар.

Кеше баш өстендә яшен уйнаса, яисә янәшәсенә берәр афәт якынлашса, Аллаһ турында ныграк уйлаучан була. Сара да Җәмилне үз янәшәсенә тартып ләхәүләсен укый башлады. Үзендә җан тынычсызлыгын тойды хатын. Менә ничәнче тапкыр инде аның каршысына зәңгәр күзле кыз бала өрәге килеп баса. Кайчандыр аның карашы түшәмгә төбәлгән кебек иде. Ә хәзер сагыш бөркелгән күзләр Сарага юнәлә сыман... «Син миннән жирәндең, минем үлемемне теләдең... Гөнаһлы син, Сар-ра!» дия кебек бу өрәк.

Әйе, үз вакытында күршеләре аны гайбәттән, яман сүздән, җәзадан аралап

калды. Рәхмәт бу шәфкатьле, изге күнелле Фәрхури түтигә! Тик ул да «Аллаһ каршында сафлык кирәк!» дигән сүзләре белән Сара күнелендә һаман пыскыган күз калдырды бит. Чынлап та, Ходай алдында сафмы ул? Әлифәгә кул тидермәде, сүзе белән җанын кыйнамады. Ис белән гомерен кисүе дә хаталык аркасында булды бит. Явыз ният тотмады ласа! Димәк, үзен Аллаһ каршында гөнаһлы итеп санамаска да мөмкин ул... Әмма күнелендә янә бер тавыш сүз ала. Ә син, Сара, савап эшләү турында уйландыңмы? Гарип балага шәфкатьле тәрбия күрсәтеп, син бит савап җыя ала идең. Җыймадың, тик үзең турында кайгырдың. Аллаһ кушкан гамәл синең өчен канун булмаган, димәк... Аннан соң, Сара, хәтерлә әле: «И, Ходай, бәне бу имгәктән коткарсаң ни булгай!» дип Аллаһка ялваручы кеше син түгел идемени? Гөнаһ языклы гамәлдән генә түгел, ә кара догадан, явыз теләктән дә туа ул. Юк шул, Сара, Ходай каршында гөнаһлы син, икеләтә гөнаһлы! Вөҗдан утыннан котылу юк сиңа, Сара...

Ниһаять, баш өстендә чын гарасат купты. Күк күкрәп яшен яшьни. Җирне сыкратып, ниндидер гөжләү чыгарып, давыл дулкыннары шуыша. Менә эре-эре салкын тамчылар да тамарга керешге.

—Курыкма, улым, хәзер үтәр!

Кинәт аяктан егарлык булып янә җил бәрде. Аткан таш булып Җәмилнең түбәтәе очты. Малай аны тотарга теләде булса кирәк, артыннан ташланды.

—Җәмил!

Шул мизгелдә үк Сараның күз алдында ут камчысы уйнап алды. Колак тондыргыч шартлау яңгырады һәм өстенә нәрсәдер ишелеп төшкән кебек булды...

Һушыңа килеп, дөньяга кайтудан да авыррак халәт юк. Теге якта ниндидер оеткыч иминлек бар, тәнең, җаның илаһи тынычлыкта изри. Син теләгән хәят бу! Кемнәрдер сиңа сөеп карыйлар, ягымлы сүзләр эндәшәләр. Тагын, тагын дәвам итсен иде бу рәхәтлек! Ләкин синең теләгенә каршы килеп, гәүдәңне каядыр өстериләр! Кирәкми! Ачуың килеп, күзләреңне ачасың, исеңә бәрәм-бәрәм үз чынлыгың, үткәндәге тойгыларың, авыртуларың, сызлауларың кайта. Күңелең укшый, болганып китә...

Сара, күзләрен ачып, караватт каршында урындыкта утырган Хабулга байтак вакыт текәлеп торды. Иренең йөз-бит торышы гадәттән тыш борчылу кыяфәттә иде. Кырынмаган, күзләре кызарган. Бер дә ашыгып сүзгә үрелми үзе.

—Хабул!—диде ниһаять Сара.—Җәмил кайда?

Хабул дәшмәде.

—Улыбыз кайда?—диде янә хатын шактый ук дулкынлана төшеп.

—Мин солдат булган кеше, Сара. Сугыш, кан күргән кеше. Урап тормыйм. Башыңның бәйләнгән икәнен беләсеңме? Сиңа агач суккан. Яраң бар... Ә Җәмил юк инде. Юк улыбыз, Сара!—һәм Хабул тыела алмыйча кычкырып елап җибәрде.

—Ничек юк?—диде Сара кисәк калкынып.

—Шулай юк!—Хабул кинәт үкереп сүгенеп җибәрде, кулын калтыратып хатынның борын төбенә китереп терәде.—Син тиле бәрән орлыгы ашаган нәрсә... Әллә бу башыңда тавык миеме синең? Ник хатыннар таудагы имән астына менмәгән? Бер син, дурак, үрләгәнсең шунда. Харап иттең малаемны!—Һәм ир баягыдан да катырак кычкырып елый башлады.—Әй, улым, балакаем...

Сараның аңы яктырып китте. Күз алдына Җәмил белән имән төбендә басып торулары, яшенләп күк күкрәү мизгеле килеп басты. Каядыр ымсынган малайны ут, ялкын чорнап алгандай булды. Әйтерсең, анадан читләшкәнне көтеп, сагалап кына торган ут. Колак төбендә янә күк шартлады... «Әй,

Ходаем, жинелрәк башка үлем тапмадыңмы!? Утка ялвардың, уттан ал, диденме? Гөнаһың өчен түлә, диденме?»

Ут эчендә малай түгел, ана үзе яна сыман. Эчтән өтә, куыра... Менә авызы тәмам кипте... Эх, ничек котылырга бу гарасаттан?

Сараны янә ут, давыл дулкыны таптап үтте. Әмма гарасат җегәре дә чикле. Күпме тәгәрәргә була? Ниһаять, тирә-як тынып ук калды.

—Хабул, Җәмил хәзер кайда соң?

—Кабердә.

—Кайчан күмдегез?

—Кичә өйләдән соң.

—Ә мин күпме ятам соң?

—Тәүлек булды.

Хабул өйдән чыгып китте. Тәрәзәдән кояш нурлары бөтенләй сүрелеп, томаланып килә иде. Күрәмсең, көтү кергәндер, маллар да кайткандыр. Сыерны сава алыр микән соң Хабул? Хәер, хуҗабикәсез чакларда күрше Фәрхуриттәй сава иде бит...

Сара башындагы яраның тибеп сыкравына оеп байтак ятты. Кинәт эңгер-меңгерле өй тынлыгында хатын ап-ачык булып Җәмилнең «Әни!» дип аваз салуын ишетте. Әйе, әйе, бу Җәмил тавышы, аны бутау, саташтыру мөмкин түгел, Сара кинәт мендәреннән күтәрелде:

—Әү, улым, Җәмил!

Тыңлап торды. Ләкин җавап булмады. Сара тәмам тынычлыгын җуеп караватыннан күтәрелде, аягына басты. Башы әйләнә-әйләнүен, ләкин, түзәрлек. Ул өстенә күлмәген табып киде, аягына чүәкләр элде дә йорт алдына чыкты. Хабул үрдәкләр ашатып йөри иде.

—Хабул, яныма кил, утыр әле!

Ир карышусыз гына бусага йөзлегенә килеп кунаклады.

—Сүгенсәң сүген, җаным, минем Җәмилне күрәсем килә, кочасым килә. Янына барыйк әле. Үлмәгән ул. Безне көтә ул. Каберенә барыйк!

Ир кеше тәмам аптырап шактый вакыт хатынына карап торды. Күрәмсең, ул бу сүзләргә нинди җавап кайтарырга да белмәде. Эченнән исәрләнмәгәнме икән бу дип тә шикләнгәндер әле.

—Хабул, ул үлмәгән бит! Минем кебек аңын гына җуйган. Яшен сугып мәрткә киткәнне җиргә күмеп терелтәләр бит, Хабул җаным, малаебыз миңа «Әни!» дип кычкырды бит. Күнелем тоя. Исән ул!

Хабул кисәк Сараның йөзенә иелеп бакты:

—Тавышын ишеттем, дисеңме?

—Әйе, җаным!

—Син ишетерсең лә ул!—дип янә өметсезләнеп, сүрелеп кулын селекте ата кеше.—Аны бит кинәт кенә кабергә тыкмадык инде. Төрлесе карады. Картлар белә бит инде...

—Духтырга, Нәсибә Мәхмүтовнага күрсәттегезме соң?

—Нәсибә Мәхмүтовна Аксуга киткән булган шул. Санитаркасы «Картлар карагач, күмегез инде», диде.

—Болай булгач, исән ул, исән!—дип кычкырды Сара.—Һушсыз булгач, мине дә кабергә илтеп тыгасыгыз калган.

Ир мәетне җирләүгә бәйле ашыгычлыкны, үзенең гаҗизлеген, кайгыдан миңгерәүләнгәнен хәтерләп кинәт шикләнеп тә куйды. Үлеп кабердә терелгәннәр хакында байтак сөйлиләр сөйләвен. Чәчләрне үрә торгызган сөйләмнәр дә бар. Чынлап та хорафат картларга ышанып, мәрткә киткәнне күмеп куймаганмы ул? Нәсибә духтыр караган булса, бер хәл. Кырку Шәрифулла карт аңга килергә дә ирек бирмәде: «Иртән җан бирсә, кич мәетне җирләү фарыз. Юкса бозыла»,—диде. Мөтәвәлли сүзен аяк астына салып булмый шул.

Хабул мингерәүләнгән кеше кебек башын тотып бусага тирәли әйләнгәләргә кереште: «Барсаң да—исәрлек. Кабер ачу—качып хатын кочу түгел. Хәтәррәк язык. Ходай язганга каршы килә бит. Картлар да баштан сыйпамас. Бармасаң да, гомерлек үкенеч булыр. Тегене-моны ишетсәң, гел үзеңнекен хәтерләрсең... Хатын хакын хакламау да бит бу...» Һәм Хабул тәвәккәлләп карар кабул иткәндә генә була торган хәрәкәтен ясады. Аяк тибеп, уң кулы белән һава ярып төшерде, хатынына кычкырды:

—Әй, ни булса шул булыр. Ачам каберне. Улыңны кочасың килсә, әйдә. Түлке карадан киен, өрәкләр дип белмәсеннәр безне.

Бәхеткә, төн караңгы иде. Ара-тирә яңгыр да тамгалый. Хабул Сараны зират киртәсе ышыгында калдырды да, зур шахта көрәген җир янәшәсендә тотып, иелеп эчкә юнәлде. Менә каралып торган таныш кабер, үзе куйган таш... Ир бисмилласын эш арасында гына әвәләде дә, ашыгып туфракны тирә-юньгә таратырга кереште: «Әй, Ходаем, могҗизаңны күрсәт! Бәндәңнең өметен кисмә, бер Аллаһ!»

Көчле, ашкынулы ир кулындагы зур көрәк тиз арада йомшак, тере туфракны да өскә атты. Менә ләхет такталары да күренде. Монда инде Сараның ярдәме кирәк иде. Кайсысындыр өскә күтәрергә, кайберләреннән баскыч корырга кирәк булыр. Барыбер дә хатынның янәшәдә булуы хәерле хәзер...

—Сара!—дип эндәште Хабул.

Һәр шылт иткәнгә колак салып, сагаеп торган хатын авазны ишетеп, килеп тә җитте:

—Әү, Хабул!

—Мә, шул тактаны күтәр!

Хабул ләхетне буеннан-буена ачмады. Тик кыйбла ягыннан тактаны күтәреп эчкә тыгылды. Йөрәге тырсылдап типте, теле туктаусыз Аллаһка ялварды: «И, Ходаем, Мәүләм, Кадыйрем... Улымны исән ит!»

Менә кулы кәфенгә орынды. Менә Җәмилнең башы... Җылы бит! Валлаһи, җылы! Хабул үзен-үзе белештермичә үрелеп улының күкрәгеннән, кулларын капшарга кереште. Әйе, җылы бит... үлсә, мәет булса, салкын булыр иде кана!.. Хабул янә бер талпыну белән үз ягыннан ләхет такталарын күтәреп туфракны этте, эчкә киңрәк юл ачты. Хәзер инде сак кына Җәмилне тартып алырга да була. Әйе, гәүдә чынлап та тере, сыгылмалы иде. Менә бала бөтенләй ата кулында, аның кочагында. «Җәмил, Җәмилкәем минем... Инде һушыңа кил, улым!»

—Сара,—дип әллә нинди ят, гомер булмаган сөенечле тавыш белән кычкырды ата кеше.—Сара, Җәмил исән бит!

—Бир тизрәк, бир улымны!

Хабул үзе корган такта-басмаларга басып Җәмилне өскә күтәрде. Өстән аны Сараның куллары эләктереп алдылар:

—Улым, Җәмилем!

Һәм ананы да, ирне дә зәгыйфь тавыш тетрәндерде:

—Әни, су!

Хабул җанлы гәүдәне ашыгып пинҗәгенә төрде һәм аны кочагына салып турыдан бәрәңге бакчалары буйлап, авыл духтырына, Нәсибә йортына сыптырды. Сара башы сызлауга карамастан, кош кебек канатланып, ире, баласы артыннан очты. Еракта, Чукай чалуы ягында, караңгы офыкны аллатып-кызартып кигәвен яшене яшьни иде...

## XII бүлек

Атнакичкә тагын бер генә көн калып бара... Болай да җыйнак гәүдәле Сара карчык, чир талкуыннан, авыр, төшенке уйлар хастасыннан тагын да бөреште, хәлсезләнде. Йортка да ул хәзер таягы белән җитәкләшеп кенә

чыга башлады. Шулай да түшәккә егылмаска тырыша. Бер ятса, тора алмас сыман...

Менә янә эш чыгып тора. Чишмәдән су алып кайтырга кирәк. Югыйсә иртәнге чәйгә житми су. Сара карчык ишегалдына сөялгән көянтәсен кулына алды, иңенә куйды да, чиләкләрен асып чишмәгә юнәлде. Таягын да онытмады: «Әйдә, гаса—таяк», әйдә! Чишмәгә барып, су алып кайтыш мина».

Чишмә юлының як-ягын йомшак яшькелт-кара каз үләне басса да, аяк асты такыр, ипле. Бу очтан байтак хатын-кыз йөри суга. Аш-суны һәр йортта әлеге чишмә зәмзәменнән әзерлиләр. Менә таякка таянып, авыз эченнән ләхәүләсен укып Сара карчык әлеге сукмактан теркелди... Үзүзеңнән кычкырып көләрсең бит, билләһи!

Кәләш чагындагы Сарага менә шул шәүләгә төртеп күрсәтсәң, алдагы булмышың бу, дисәң, ышанып иде микән? Юк, дошманына ук әйләнер иден. Гәүдәсен, билен уйнаткалап, жиргә аягын да тидерми очкан көянтәле асыл зат өчен бу иң зур хурлау ук булыр иде. Айдагы көянтәсен аскан Зөһрә сыман гомер бакый яшь, таза, матур булып чишмә юлын таптарсың кебек бит ул...

Ташлы тәлпәк тау төбеннән агып чыккан чишмә әллә ни зур түгел. Гапсаттарга рәхмәт, иманнан бура куйды. Көмеш су кисмәктәге кебек кынысыннан тулып тора. Чиләгеңне чумыр да, тутырып ал. Чишмәнең төбе дә айкалмый-чайкалмый, һәрчак суы саф... Чумырып чиләк тутыру Сарага кирәкми анысы. Яртысы кулыннан килсә дә бик житкән...

Менә Сара бисмилласын әйтеп чишмәгә иелде. Көзгедәй тыныч, сабыр су өслегендә йөзе чагылып китте. Ак яулык астыннан бөркелеп чыккан чал чәчләр... Ак, мәрмәр йөз, сагышлы күзләр... Йа, Хода, нинди илаһи мизгел бу! Син, Чишмә, мине шулай хәтерләп кал, яме? Исеңдә калдыр да, гомер буе рухымны яшәт, йөгерек су. Синең бит жуелмас хәтерен бар. Челтерчелтер килеп, көмеш тавышың белән кешеләргә минем турыда да хәбәр сөйлә. Сезгә кадәр Сара дигән зат бар иде, яшәүгә гашыйк иде, диген. Яшел чирәм, сайрар кош, агар су аның күнел яме булды. Гел кояшка зарыкты, айны юксынды, язлар-жәйләр яратты диген. Тик нишләптер яшәү рәвеше генә зарлы, моңлы булды шул Сараның дип әйтергә дә онытма син, Чишмә! Хәер, әйтмә моны! Бу дөньядан кемнең соң зарсыз, моңсыз, үкенүләрсез киткәне бар! Кешеләргә минем хакта гел матур, ямьле хатирәләр генә сөйлә син, Чишмәкәй. Авырларын, моңсуларын оныт! Хәер, минем яшәү рәвешем синең белән һәрчак матур булып үрелеп барды бит, йөгерек су. Боларны хәтерләсәк, көнозын бергә утырып сөйләшсәк тә, сүзебез бетәрлек түгел ласа.

И, эштән сусап кайтып, гөжләп жырлап утырган самавыр каршында гаиләң белән утырып чәй эчү вакытларын ничек онытасың? «Йомшак су, йөгерек су, син мине чиста ю!» дип такмаклап сабый коендырулар истән жуелырлыкмыни? Үзең яккан кайнар мунчада иреннең кайнар, хуш исле, парлы миндек белән рәхәтлектән эһелдәп чабынуын күрү—хатын жаны өчен бәйрәм бит ул, су ахирәт!

Ә синең ләйсән яңгырлары булып жиргә иңүең кешеләр күңеленә нинди олы сөенечләр китерә, йөгерек су, брамат су! Тымызык, жылы май башы бу. Син йомшак тамчыларың белән кардан, салкыннан күшеккән чирәм, үләннәрнең битләрен юасың, агач, куак кәүсәләрен коендырасың, бөреләрне сыйпап үтәсең, жирне сафландырасың, күпертәсең. Синең рухың, сутың, кәүсәр су булып бар тереклекне уятып, жанландырып жибәрә. Жиргә янә шатлыклы, сөенечле яшәү гаме кайта.

Син бит сафлык, керсезлек сакчысы да—су! Бит-йөздәге каралыкларны

гына түгел, мәгыйшәттәге пычракларны да юасың син. Сафлык, аклыкта сине кешеләр үзләренә үрнәк итеп куялар. Жаннарын тапамаска тырышалар бит. Шул асылың белән дә керсез жаннарны гомер бакый сөендерәсен бит син. Боларның барысы өчен дә чиксез рәхмәт сиңа су-Ана! Әй, мин сиңа һаман серләремне сөйләр идем, үзеннең челтерәвеңне тыңлар идем. Тик китәр вакытым житте шул, Чишмәкәй. Синең белән бөтенләйгә, мәңгегә хушлашыр көнем, сәгатем житеп килә бит минем. Әмма гозеремне онытма, Чишмә. Жырыңа кушып сурәтемне, рухымны яшәт син. Мин синең хәтереңдә калыймчы! Су хәтере—мәңгелек. Су хәтере—жан ахирәте бит, Чишмәкәй...

Су юлыннан көянтәле, таяклы Сара карчык кайтып килә. Ярый әле сукмак буш... Эңгер төшмәс борын калыккан айдан Зөһрә кыз гына берара гажәпләнеп көянтәдәш женесенә күз салып торды. Ярый әле, Жирдә калмадым, күккә аштым, дип сөенде бугай...

## XIII бүлек

1945 елның 27 сентябрендә, атнакич, Түреш авыл Советы рәисе Сара Кыям кызын Аксуга район партия комитетына чакыртып алдылар. Телефонограммага идеология секретаре Мөхлисов кул куйган иде. Сараның күз алдына туп кебек тәгәрәп торган елгыр, карсак ир килеп басты. Ул, алтынсу кысалы күзлеген төзәтеп куеп, бераз чекерәеп, хатынга текәлде. Аннары, гадәтенчә, ирониялє елмайды: «Мине алдый алмассыз!..»

Баш идеолог иртәгә бернинди киңәшмә-фәлән оештырмый икән. Димәк, ниндидер аерым сөйләшү көтелә... Бу хәл рәисне тәмам пошаманга салды: «Мөхлисов нинди вәгазь укырга жыена икән аңа? Нәрсә хакында икән секретарьның жомга вәгазе...»

Сәфәргә Сара авыл Советы йомышчысы, чукрак Зиннур карт белән иртүк чыкты. Аксуга юл—ындыр әйләнү генә түгел, олы мәшәкать. Тик тарантас ипле, жайлы, тәртә арасындагы юртак күк «Бөртек» яшь, дәртле, кичәге күңел юшкыны да таралган—сәфәрченең хәтта күңеле күтәрелеп китте. Кузлага менеп кунаклаган Зиннур карт тарантас жаена чайкала-чайкала авыз эченнән ниндидер озын көй суза. Чын ямщик диярсең! Сара шул хакта картка сүз кушарга омтылган иде, тегесе артка борылып, сәләмә кашлары арасыннан коңгырт күзләрен чекерәйтте:

—Нинди яшник, Сара сеңлем?

—Ни... Базага сугылып, берәр ящик сабын алып кайтырга онытмыйк, Зиннур абзый,—дип көлүен көчкә тыйды Сара. Чукрак картны бимазаламавың яхшырак шул...

—Була ул!—кучер күндәмләнеп баш какты һәм янә үзенчә моңлана башлады.

Әбиләр чуагының тансык жылысын сипкән кояш нурлары, көзге кырбасулар яме, урман бизәкләре белән хозурланып бара торгач, Сара үзе дә сизмәстән, уйларга чумды. Көзнең нәкъ шундый хозур мәлендә сельсовет рәисе булып эшкә керешкән иде бит ул. Ничә ел булган инде? Бишме? Юк, дүрт кенә икән бит. Минач абыйсының тәкъдимен башта бер уен-шаярту итеп кенә санаган иде: «Сельсовет башлыгымы? Һи, китегез инде, Минач абый, булмаганны, кеше көлдереп...»

Тик Минач рәис, һәрвакыттагыча эшне үзенчә, кырку тотты.

—Иптәшләр!—диде ул Түреш авылы Советы сессиясенә жыелган депутатлар, авыл активы каршына чыгып баскач.—Сугыш барыбызның да яшәү планнарына кискен үзгәрешләр кертә. Мин—запастагы красноком, үзем теләп фронтка язылдым. Дары иснәгән кешеләргә кытлык чак. Азмыкүпме оештыру куәтем дә бар. Фронтта файдам күбрәк булыр. Китәм... Шул

унайдан сезнең алда бер мәсьәлә калка: бу урынга кемне куярга?

Көтелмәгән хәбәрдән аптырашка калып, гөжләшә башлаган кешеләр каршында Минач йөренеп алды. Йөзендә гамь, ниндидер хисап галәмәте... Рәис янә өстәл артына килеп басты һәм баягы эшлекле тавышы белән дәвам итте:

—Рәис постына мин депутат Сара Галиәсгарова кандидатурасын тәкъдим итәр идем. Миңа аны сезгә таныштырга кирәкми. Китапханәче. Түрештәге избач районга үрнәк. Бездәге бер мәдәни чара да Сарадан башка үтми. Идеологик яктан чарланган. Грамоталы. Арабыздагы депутатларның иң яше ул. Әмма җаваплылыкны күпләребездән ныграк тоя. Белдегез, сайлаучылар наказын үтәп, Түреш елгасы аркылы менә дигән күпер салдыртты. Тагы да планнары бар аның. Кыскасы шул, җәмәгать, Галиәсгарованы рәис итеп сайласак, хата булмас!

Зал тагын гөжләргә керешге. «Хатын-кыз бит... Яшь әле... Камчы тота белми!» кебек сүз-гыйбарәләр дә колакка чалынды. Әмма ни гаҗәп, торып сүз алучылар Сара хакында тик яхшы сүзләр генә сөйли башлады. Шулай йомгак тәгәрәп тә китте...

Артык хисләнгән хатын шул кичтә үк кулына түгәрәк мөһер белән шкаф сыман зур яшькелт сейф ачкычын тоттыруларын да абайламый калды... Сөендеме бу үрләтүгә, әллә суынгач, көендеме Сара—анык кына төшенмәде. Тик күргәннәре, Аллага шөкер, бисмилла әйтми тотынса да, туярлык булды. Эт—эткә, эт—койрыкка, дигәндәй, нинди генә йомышлар кушмадылар кәнсәләр башлыгына. Халыкка шундый-шундый налоглар салып, фәлән вакытка шул суммада акча җыярга... Фәлән кадәр йорт башлыгын заемнарга яздыртырга... Фронт ихтыяҗы өчен авыл буенча фәлән центнер бәрәңге киптереп куярга...

Солдатлар өчен шул кадәр пар бияләй бәйләп озатырга... Урман кисү өчен шул чаклы кеше җыярга... Һәркөн диярлек өстенә явып торган эреле-ваклы әмерләр фронттагыларның баш очында шартлаган туплардан кай ягы белән ким? Билләһи, ир-ат булса, ачлыктан, ялангачлыктан җәфа чиккән кеше зарын ишетмәс өчен Сара үзе дә Минач кебек сугышка китеп котылуны артыграк күрер иде. Ялгыз башың, бер тамагың дигәндәй...

Әй, монысы да аптыраганнан гына әйтелгән сүзләр инде. Сугыш үзе моннан ерак булса да, кызарып кояш батканда, шәфәкъ алсулыгы җәелгәндә, ут таулары атылган җәһәннәм төсле тоелып, йөрәккә шом сала. Шул тарафларга карарга куркыта. Көн-төн тынмаган гарасат утында кешеләр кырыла бит... Сугышка киткән кеше үлеме, фаҗигаләрнең иң зурысы, иң әчесе булып, монда да килеп ирешә. Һәлак булган кеше—туганың, карендәшең дә түгел. Тик сиңа төбәп каткан йөзе, көләч күзе белән генә истә калган ул... Ни үкенеч, менә шул адәм хәзер хәятта юк инде. Гарасат уты аны да яндырган, көйдергән...

Ай саен Түрешкә килеп торган похоронкалар Сараның бәгырен авыр әрнешләр белән телгәләде. Даим-даим алар үз ире Хабулны да искә төшереп торды. «Хәбәрсез югалды» штампы белән кырык өченче ел азагында килгән язу Сарада әле һаман да иренең исәнлегенә карата өмет яшәтеп килде. Пыскып кына торса да, өмет өмет инде, күңелдән китмәде. Инде сугыш бетеп, авылга үз аяклары белән кайтып килүче фронтовикларны ешрак күргән саен, Сара үз ирен дә исән-имин каршыларга җыена башлады. «И Ходаем, күрешү сәгатьләрен насыйп ит!»—дип эчтән генә ихлас теләкләргә чумды.

Түреш мөсафирлары Аксуга килеп кергәндә казна, кәнсәләр хезмәткәрләре эшкә керешкән иде инде. «Бөркет» райүзәкнең таш урамына басып шак-шок килә башлагач, Сара тарантасны туктатты да, Зиннур

картны фатирга озатып, райком бинасына юнәлде. Юл уңаенда өс-башын каккалады, төзәтенде. Лозунглар, кызыл комачлар белән бизәлгән ике катлы таш бинага якынлашкан саен эченә янә пошаман йөгерде: «Мөхлисовның нинди сүзе бар икән соң? Нишләп җомга вәгазе укырга булган ул сиңа, Түреш бичәсенә?»

Ниһаять, Галиәсгарова Мөхлисовның кабинет ишеген ачты:

—Рим Идеятеч, мөмкинме, чакырткансыз икән...

Бусагадан атлап үтүгә, ялгызы өстәл артында бик бирелеп язып утыручы кешедән бигрәк, Сараның күзләре дивардагы зур, мәһабәт Сталин сурәтенә төште. Юлбашчының баштан-аяк тасвирланган сынын күргәне юк иде әле, әсәрләнүе дә шуннан килеп чыкты. Ил башы аксыл-яшькелт постаудан тегелгән френч кигән. Ялтырап торган хром итектән. Мәгърур чырай... Шул ук вакытта сиңа текәлгән күзләрендә сорау да бар сыман: «Ни йомыш?..» Ишек ягыннан караганда, Сталин итекләре астында утырган сыман булып күренүче Мөхлисов, ниһаять, башын күтәрде, туткыл йөзенә елмаю җәелде.

—Ә, иптәш Галиәсгарова! Көтәбез, көтәбез! Урыс әйтмешли, легки на помине.—Мөхлисов Сарага каршы атлады, килешле генә култыклап алып килеп, өстәле каршысыннан урын тәкъдим итте.—Менә исемлек төзеп ятыш. Иптәш Сталинның тыл ударникларын бүләкләү турында указы килде бит. Шуңа ярашып райком җитәкчелеге сезне дә «Фидакарь хезмәт өчен» медаленә тәкъдим итә, иптәш Галиәсгарова!—Мөхлисов урынына кереп утырды. Сараның тыйнак елмаюына каршы кулын әртистләрчә селтәп куйды:—Юк, юк, иптәш Галиәсгарова, сез бүләккә лаек! Түреш авыл Советы райком күрсәтмәләрен һәрчак төгәл үтәп барды. Үз постыгызда коммунистик фидакарьлек күрсәттегез сез. Партия үз членнарын күрә, күтәрә белергә тиеш! Бу турыда бәхәс ачмыйбыз, иптәш председатель.

Һәм, чынлап та, сүзне беткәнгә санап, Мөхлисов йодрыгы белән өстәлгә сугып куйды. Шул кыланышы белән секретарь Сараның да эч хәвефләрен койды: «Курыкканга куш... Сине медальгә тәкъдим итәргә җыеналар ласа!»

—Рәхмәт, Рим Идеятеч, шулай зурлавыгызга!

—Иптәш Галиәсгарова,—диде Мөхлисов хатынның әлеге рәхмәтен абайламаган кеше сыман.—Тормыш шундый нәрсә инде ул. Рәхмәте дә, каһәре дә янәшә. Төрлечә сыный ул кешене. Партиягә таянган кеше генә рухы белән көчле була, иптәш Галиәсгарова... Һәм Мөхлисов кабаланып күзлеген төзәтте, урыныннан торды.—Ни өчен бу сүзләрне сезгә сөйлим дисезме? Ныклыкка чакыру бу. Сезнең ирегез Хабул исән һәм ул...

Сара ток суккан кебек урындыгыннан сикереп торды, йөзе кисәк шатлык белән балкыды:

—Хабул исән, дисезме? Чынлапмы, Рим Идеятеч? Нинди сөенеч!

—Сезнең урында сөенергә ашыкмас идем, Галиәсгарова. Ирегез пленда булган бит. Илгә хыянәт иткән...

Әлеге шомлы сүзләрдән соң кабинет хуҗасы Түреш рәисенең сыгылып төшүен көткән иде. Әмма яшь хатын сөенүен белде, биегән кебек, идәндә таптанды:

—Хабул исән, исән! Үлмәгән дидем бит... Менә дөрескә чыкты.

Сараның шатлыктан урамга, кояш яктысына йөгереп чыгасы, очраган берсе белән сөенечен бүлешәсе килеп китте. Хәтта ишек катына атлау нияте белән сумкасына үрелгән иде ул, тик Мөхлисов өлгеррәк булып чыкты:

—Туктагыз, иптәш Галиәсгарова, безнең сүзебез бетмәде бит әле.

Идеология секретаре яшь хатынның кыланышларына читсенеп карады: «Яшь шул әле, нинди хәлгә тарыганын белми, бахыр...» Түреш рәисен

чакыртыр алдыннан Мөхлисов аның «Дело»сын җентекләп карап чыкты. Хәер, нәрсәсен тикшерәсең, коры папка... Бер битлек биографиясе ята да, китапханәче булып эшләү, авыл Советы рәисе булып тәгаенләүгә бәйле гадәти рәсми кәгазьләр, документлар бар. Шунысы кызык: революция ясалган елда, унҗидедә туган икән... Сәвит баласы, дип тел шартлатты Мөхлисов. Кара нәселдән. Кулак, мулла-мәзин нәселеннән яисә милләтче дип дәгъва тотарлык бернәрсәсе дә юк. Куркытылмаган кош әле бу... Югыйсә, иренең хәлен ишетеп, телдән язар иде.

—Рим Идеятеч, зинһар әйтегез әле, хәзер кайда соң ул? Ни хәлдә?—дип, уйга калган секретарьга сораулы карашын юнәлтте хатын.

—Военкомга килгән мәгълүматлар буенча, ирегез фильтрация лагеренда, особистлар кулында. Хыянәтен тикшерәләр,—диде Мөхлисов салкын гына.

Сара тәшвишкә төшмәде төшүен. Шулай да халыкта ишетелгән сүзләр аңында янарып, йөзенә күләгә салды: «Әсирне кешегә санамыйлар... Пленный булгач, Сталин үз малаеннан баш тарткан, ди... Пленга төшкәнче, үлүең артык...» Болар аның үз иренә дә кагылыр микәнни? Шулай да шикләре якты хисләрен томаламаган икән әле.

—Соң, Рим Идиятеч, төрмәгә япмаганнар, Себергә озатмаганнар... Тикшерерләр дә кайтарырлар. Бер Хабул башына гына төшкән хурлык түгел бит. Рим Идеятеч, сез мине алай ук куркытмагыз инде?!

—Сара Кыямовна, хөрмәтлем, сез үзегезне гавам, гади халык белән янәшә куймагыз. Сез—коммунист. Власть вәкиле. Җитәкче! Мин бит «ирегез исән» дип сездән сөенче алыр өчен чакыртмадым. Сиңа иреңә карата мөнәсәбәтне ачыкларга кирәк. Аңлыйсынмы?

—Рим Идеятеч, ир—ир инде ул! Аңа нинди мөнәсәбәт тотыйм тагын? Кайтуын көтәм,—диде Сара, эчкерсез көлемсерәп.

Секретарь елмаюны күреп гарьләнде. Йөзенә кинәт усаллык галәмәте бәреп чыкты.

—Сез мине алдый алмассыз, Галиәсгарова! Алла диванасы булып кыланмагыз. Сезне, бәлки, хыянәтче ир канәгатьләндерер дә. Баш-аяк, куллар исән... Көтеп алырсыз, пычрак җанына күз дә йомарсыз. Тик райком, халык бар бит әле. Коммунист вөҗданы бар. Ил саткан кеше белән бер түбә астында яшәп, сез кешегә нинди үрнәк бирәсез? Әхлагын җуйган кеше ничек җитәкче булып кала... Кайда аның абруе? Иптәш Сталин безнең барыбыздан мораль сафлык, сыйнфый уяулык таләп итә. Кыскасы, райком сезнең алда мәсьәлә куя, Галиәсгарова: йә ирегездән баш тарту, аерылу хакында рәсми сүз таратасыз. Гәзиттә, җыелышта, мәсәлән... Йә рәислектән китәсез, үзегез теләп, гариза язып...

Түреш рәисенең йөзендә каһкаһәле елмаю уйнап алды:

—Сез бит әле генә миңа медаль бирергә җыенган идегез, иптәш Мөхлисов. Инде урынны бушатырга да кушасызмы?

—Без сездән, коммунист буларак, мораль югарылыкта торуыгызны көтәбез.

—Димәк, партия өчен минем иремнән баш тартуым кирәк. Шулаймы, Рим Идеятеч?

—Райком җитәкчелеге сезнең кебек работникларның кадерен белә, Сара иптәш. Җаваплы постта калуыгыз дөрес булыр иде. Яхшылап уйлагыз!

—Уйланырсың, кодагый,—дип сузды хатын. Идеология секретаре Мөхлисов каршына барып басуны, хәтәр мәсьәлә кузгалуны уйлап юкка хафаланмаган икән шул ул. Бу кабинетка кереп чыгуны, әлеге карсак Мөхлисов белән очрашуны сират күперен кичеп чыгуга тиңләүчеләр дә күп булды. Кешенеке кештәктә иде... Менә әлеге алтын кысалы күзлек

иясе Сараның үзен инде урталайга яра. Йә ир, йә җаваплы пост, имеш... Кайсын сайлыйсың, Сара, йә уйла!

Хатынның күз алдына Хабул килеп басты. Йөзен төк баскан, өшәнгән, киеме өтәләнгән. Күзләрен күтәреп карарга базмый, сүз дә әйтми. Тик кайчагында үпкәләшкән кебек, яңакларын уйнатып, җиргә текәлеп тора... Хас та ярамаган гамәл кылган бала! «Кит янымнан, Хабул. Үзең пычрангансың, инде мине дә пычратма дияргәме?»

Ирдән ваз кичсәң дә, ул бит барыбер Түрешкә кайтыр. Биштәр аскан кешене күреп, Җәмил «Әти!» дип ашкынып, каршысына йөгерер. «Уйла, Сара, уйла! Малаеңа ни әйтерсең? «Улым, тукта! Атаң түгел бу. Әсир, илен саткан кеше!» диярсенме? Малаеңны шулай ата канатыннан мәхрүм итәрсеңме, Сара?»

Түрәлектә калыйм, дип әсир иргә капка бикләсә дә, урамда калмас, берәр толга йортка керер Хабул. Дүрт саны да төгәл булса, әсир ни дә, герой ни—барыбер түгелме иргә тилмергән бичә-чәчәгә?.. Карар, назлар, аякка бастырыр ул ил хурлаган ирне. Берәр чак парлашып урамнан да үтәр. Һәм шунда ниләр кичерерсең, Сара? Уйла, уйла! Ир бирмәк—җан бирмәк, дип сыкраучыларның берсе нәкъ син үзең булмассыңмы?

Сараның күз алдыннан тагын Түрештәге авыл Советы кәнсәләре кыелап узды. «Кызым, гозерем бар сиңа!»—дип кемдер аваз сала, имеш. Кешеләр белән эшләү, ил, халык эше белән йөрү дә аның канына сеңгән. Инде авырлыкларны үттем, эшкә өйрәндем, дигәч кенә урынны ташлау да ахмаклык булыр шул. Уйла, Сара, уйла! Бу хакта да уйла. Халык каршында дәрәҗәң бер төшсә, янә күтәрелә алырсыңмы икән?

«Әллә соң Беренченең үзенә керимме, яклавын сорыйммы?» дигән уй да йөгереп үтте Түреш рәисе зиһененнән. Өмет хисләренә чорналып, күз алдына Кашшаф Газиевич басты. Олпатлы, сабыр, кешегә илтифатлы бу җитәкчедә гаделлек дигән нәрсә бар инде барын. Тик бигрәк авыр сөякле шул... «Нәрсә бар анда сезнең, Галиәсгарова?» дияр инде. Тыңлар да: «Ай-һай, хәтәр мәсьәлә икән шул. Тик мин нәрсә эшли алам? Мин Алламы? Райком бар бит безнең. Бюро бар. Ирең хакында ямьсез фикер сине пычрата икән, мин ничек сине аннан аралап калыйм?»—дип әйтәчәк Кашшаф Газиевич. Мондый ваемсыз, сабыр тонны җыелыш, киңәшмәләрдә байтак тыңлады инде Сара...

—Йә, нинди фикергә киләсез, коммунист Галиәсгарова?—дигән тавыштан Сара сискәнеп китте.—Карар кабул итү шулай бик кыен икән, булмаса, кайтып уйлагыз. Дүшәмбе шалтыратырсыз.

—Миңа кәгазь, каләм бирегез!

Сара аңа күтәрелеп карамыйча гына үзенә таба шудырылган ручканы, кәгазьне алды да житез, калтыравык кул белән түбәндәгеләрне сызгалады: «Мин иремне медальгә һәм постка алмаштырмыйм. Урынымнан бушатыгыз». Имзасын куйганда Сараның күзләреннән яшь сытылып чыкты, кәгазь битенә тамды. Әйтерсең, язганына мөһер сугу булды бу.

Аннан соң Сара кинәт кенә урыныннан торды, һаман да күтәрелеп карамыйча, кәгазьне Мөхлисовка томырып, ишеккә юнәлде. «Бу да кемнеңдер ире бит, җирәнгеч нәрсә... Хәшәрәтнең үзеннән ваз кичсәләр, дөрес гамәл булыр иде шәт»,—дип уйлады.

Менә шулай Сара Кыям кызы идеология секретаре Мөхлисов кабинетына Түреш авыл Советының абруйлы рәисе сыйфатында керсә, аннан чыкканда гап-гади авыл хатынына әйләнеп калды. Сталин итекләре астында утырган алтын кысалы күзлек иясе аның ярты ягын умырып, өзеп алып калды.

Каядыр сурәт эченәме, әллә рәсем артынамы яшеренгән иблискә туклану өчен кирәк булгандыр инде бу. Борынгылар белеп әйткән шул: «Сын-сурәт

ясама, олан! Ул синнән җан, кан сорар...»

Җинеләеп калган Сара кояшлы урамга чыккач, барыбер сөенеп кычкырды: «Хабул исән! Исән җанкисәк!»

## XIV бүлек

—Галиасгаров, допроска!

Менә ничәнче кат Хабул «Смерш» тикшерүчесе капитан Сидоров каршына килеп баса. Чигәләренә җинелчә чал йөгерә башлаган зәңгәр күзле, кырыс чырайлы ир тоткынга бер генә күз сирпеп алды да, папкада бутануын дәвам итте. Әһә, теләгәнен тапты бугай, кәгазьне кулына алып, җентекләп укый башлады.

—Өлкән сержант Галиаскеров, янә бер кат ачыклыйк әле. Син БМ-13 реактив миномет частенә ничек эләктен?

Тикшерүче Хабулның фамилиясен теш арасыннан сыгып чыгарып, урысчалатып әйтә иде: «Галиаскеров!»

—Иптәш капитан, бу турында аңлатмамда яздым,—диде сораулардан тинтерәгән Хабул сүлпән, төшенке генә.—Мин 215нче махсус авиаполкта техник идем. 1942 елның май башларында приказ белән аннан киттем. Дүртме-бишме тәүлектән соң тиешле урынга, Мәләкәскә килеп җиттем. Монда минем белән биографиям хакында сөйләштеләр, катюша расчетына шофер итеп беркеттеләр. Шул!

—Ә син үзегезнең яңа назначениегез хакында уйландыгызмы? Кем һәм нишләп сине чакырган?

—Билгеле, аптырадым. Тик Мәләкәскә килгәч, подразделение командиры Минач Гайфетдинов миңа аңлатты. Катюша өчен бик ышанычлы кешеләр кирәк икән. Командирларга үзләре якыннан белгән солдатларны җыю бурычы йөкләтелгән. Бу корал бик каты сер астында бит, беләсез. Гайфетдинов мин авылдашы булгач, шикләнмәгән инде, чакырган.

—Гайфетдинов нинди званиедә иде?

—Сезнеке кебек, капитан...

—Авылыгыз Түрешме? Анда кем булды ул?

—Сельсовет председателе.

—Шоферлыкка кайчан, кайда укыдың?

—Утыз тугызның февраль-апрель айларында, райүзәктә, Аксуда.

—Кем укытты?

—Военкомат.

—Армиягә кайчан алдылар?

—Утыз тугызның октябрендә.

—Алай...—дип сузды тикшерүче, беравык җитди төстә Хабулга карап торды.

Алты-җиде ел буена йортын, хатынын, бала-чагасын күрмәгән ирне кызгануы булдымы бу, әллә бирелмәгән берәр соравы калмыймы икән, дип уйлануы булдымы—тоткын төшенә алмады. Хәер, әсиргә карата шикләре алдарак тора икән шул:

—Туган якка отпуск бирмәделәрме?

—Юк, андый бәхет эләкмәде шул.

Сидоров ирнең нечкә хисләренә килеп кагылды. Күз алдыннан газиз авыл сурәтләре—су буйлары, печән чапкан болыннар, иген исләре аңкыткан басулар шәйләнеп узды. Бакча артларындагы калкулыкка күтәрелеп, тере кыйбла җиленә йөз-бит куйганы, сокланып тирә-юньне тамаша кылулары искә төште...

—Хатының кем, нинди эштә, Галиаскеров?

—Председатель... Сельсовет председателе.

—Алай...—дип янә гаҗәпләнә ымын чыгарды тикшерүче.—Берегез Ватан дип җан ата, икенчегез Ватанны сата. Сидоров авызына «Казбек» папиросын алып капты һәм төтен пыскыта-пыскыта идән буйлап йөреп алды. Шулай аяк язулардан соң гадәттә тоткынганиндидер яңа гаеп ташлана. Тон да, сүзләр дә кискен үзгәреп китә. Атакага ташланучы солдат сыман капитан да тәвәккәл кыяфәт ала. Хәзер дә шулай булды.

—Син, Галиаскеров,—диде «Смерш» тикшерүчесе кинәт Хабул каршысына килеп басып,—үзеңнән ниндидер простак ясама. Күз бума. Син—хыянәтче бит!.. 1943 елның 15 сентябрендә Гайфетдинов төркеме катюшалар залпы белән баш-аяк юкка чыга. Үзләре «Огонь на себя!» сорыйлар. Ә син шунда бер ялгызың исән калгансың. Ничек котылдың димим, ничек качтың дип сорыйм. Залптан качып котылырга гына була. Йә, ничек качтың, сөйлә Галиаскеров?

—Мин качмадым, приказ үтәдем!—дип ярсып урыныннан күтәрелде тоткын.

—Кем приказы?

—Политрук Гайфетдинов әмере. Мин йөрткән 513нче катюша корылмасын шартлатып булмады. Заряд эшләмәде. Гайфетдиновка рапорт ясадым.

—Һаман Гайфетдинов? Ә ни өчен Гайфетдинов әле? Подразделение командиры Соколов булган бит!

—Әйе, Соколов. Тик безнең биш расчетлык аерым төркемгә политрук Гайфетдинов командалык итте. Үзегез дә әйттегез бит. Гайфетдинов төркеме, дидегез. Безгә аерым задание бирелгән иде. Аны үтәп, чолганышта калдык.

—Ярар, монысы дөреслеккә туры килә. Шуннан нәрсә?

—Немецлар кулына төшермәс өчен катюшалар берәм-берәм шартлатылды. Ә 513нче—юк! Шартламады. Шуннан соң Гайфетдинов аны суга батырырга боерды.

—Суга батырырга? Монысы нинди мәрәкә тагын?

—Әйе, янәшәдә генә Днепр култыгы бар иде. Гайфетдинов кушканча, катюшаны шул култык суына батырдым.

—Алдыйсың Галиаскеров!

—Ышану-ышанмау—сезнең эш. Тик мин әмер үтәдем. Кабинада фляжка ятар. Эчендә командир язган кәгазь булыр: «Мин, катюшалар подразделениесе политругы Минач Гайфетдинов, 513нче расчетны конспирация максатында сержант Галиаскеровка суга батырырга приказ бирәм. 1943 ел, 15 сентябрь».

Капитан Сидоров үзалдына зәһәр елмаеп башын чайкап торды. Аннары ярсып идәнгә төкерде:

—Син нәрсә, Галиаскеров, алдашып үзегезнең Хуҗа Насретдиннан да уздырмакчы буласыңмы? Хуҗа кеше көлдерер өчен ялганлый, ә син үз тиреңне коткару өчен тырышасың бит, дезертир!

—Алдамыйм мин!

—Ялган, хәйләгә чумгач, син безгә машинаңны батырган Днепр култыгын да күрсәт, алайса. Ничек табарга аны? Әйт!

—Эзләсәң, табып булыр. Тик богауда торып, сезгә ул култыкны күрсәтә алмам шул.

—Безне кибәннән энә эзләтергә телисеңме? Һаман эз бутыйсың, хыянәтче!—диде Сидоров һәм папкасын шапылдатып ябып, тоткынга кул селтәде.—Бар, бүгенгә сүз тәмам!

Немец фашистларына әсирлеккә эләккән совет солдатларының күп санлы төркеме Польшаның Едлино тимер юл станциясендә урнашкан

иде. Әлеге фильтрацияләү пункты дип йөртелгән җирдә сугыш елларында әсирләр лагере булган икән. Электр токлы чәнечкеле чыбыклар белән кат-кат уратып алынган ихатадагы бараклар исәбенә бармак бөгеп кенә чыгармын димә. Бомба, снаряд чокырлары күренмәсә дә, сугыш җиле моннан да кубарылып узган икән. Читтәге баракларның түбәләре янган, бик күп тәрәзәләрдә пыяла юк, кайбер рамнар фанера, картон, чүпрәк белән томаланган. Урта баракларның берсендәге такта сәкегә бөгәрләнеп ятып Хабул җан асрый.

Җәй үтеп, көз салкын сулыш өрә башлагач, барак тагын да шыксызлана төште. Төннәрен аеруча салкын була башлады. Йокы юк, калтырата. Кием-салымның тәмам рәте киткән шул. Чалбарның тез башлары тишек. Гимнастеркасы эт талаган кебек, тәмам теткәләнгән хәлдә. Чүл дәрвише диярсең. Сәләмәдә нинди тән җылысы торсын? Хәер, җанда гамь әсәре калмаса, тән хәстәре каламы соң?

Хабул гына түгел, монда барысы да төксе, караңгы чырайлы. Этап белән кораллы конвой астында һәркөн хәрби әсирләр китерәләр. Көн дә төркем-төркем оештырып, биштәрле ирләрне станциягә озата торалар. Янәшәңдә бүген берсе, иртәгә икенчесе, йөзләре дә истә калмый. Монда күршең үзе башлап сүз катмаса, берсе дә ана төбәп сорау бирми... Һәркемнең эчкә яшерелгән үз гаебе, салкын тирләргә батырып, үз акылына гына килгән тәүбәсе бар. Сорауларны да кешеләрнең һәркайсына аерым һәм төбәп бирәләр монда. Җаваплар да һәркемнеке үзенчә... Мөгаен, бирелдәге затларны эчкә, бик тирәнгә яшеренгән бер өмет кенә берләштерәдер. Папкалы, шәфкатьсез, зәңгәр чалбарлы, бер иштәге особистларның мәкерле сорауларыннан ничек исән-имин котылырга да, паеклы биштәренне асып туган төяк, газиз йорт, кадерле гаилә тарафларына юл, сәфәр башларга...

Кемгәдер бу, иртәгәсен чыгасы кояш кебек бик ачык, якын өметтер. Әмма өлкән сержант Хабул Галиәсгаров аннан күптән язды. Һәр көн тикшерүче каршысына килеп басса, яңа шик, яңа сораулар туа тора. Өскә ташланган гаепләр дә зурая тора... Сәкегә кайтып егыласың да, янә үз җаныңны үзең үк кимерә башлыйсың. Йә дөньяны, кешеләрне каргарга керешәсең. Бу хәлдә адәм дигән затта нинди яшәү гаме калсын?

Берләнбер көнне бакча карачкысы кыяфәтендәге Хабулга лагерь коменданты урынбасары игътибар итте. Майор мылтыклы ике солдат ияртеп бараклагыларны барлый иде. Сәке нумерына күз текәп карады да, кулындагы журналга иелә төшеп: «Өлкән сержант Хабибулла Галиәсгәров»,—дип саф татарча кычкырды ул.

Хабул сискәнеп ятагыннан кузгалды, авыру кеше сыман сыкрап аягына басты:

—Мин!—дип үзе дә белештермичә татарча җавап кайтарды солдат.

Мөлаем түгәрәк йөзле, балкып торган коңгырт күзле майор шактый сәерсенеп Хабулны күзәтте дә, якынрак килә төшеп әйтеп куйды:

—Әзи, исемең белән безнең кавем кешесе булсаң да, төк, ялларың белән попка тартасың бит. Ай Аллаһ, нишләп бу хәлләргә төштең?

«Әзи» дип үртәп әйтә билгеле. Майор шаян, көлкегә тартылучан кеше күрәмсең... Чөнки бу, Хабулга караганда, үзе байтак өлкән, абзый кеше. Шуңа күрә тоткын Хабул да әфисәргә «әзи» дип эндәште:

—Әй әзи, чукынырга гына калды инде... Наган булса, әллә кайчан чигәгә терәр идем...

—Йә, йә!—дип кисәк каршысындагы ирнең сүзен өзде майор.—Сугыш беткәч, Аллаһы теләсә, инде яшибез дигәч кенә нинди самострел ул? Дөньялыкта нинди генә хәлләр булмас, күтәрә белергә кирәк!—Һәм берникадәр Хабулга ихлас карап торганнан соң, эшлекле тон белән әйтеп

куйды.—Дүртенче баракта база-склад. «Интендант Загитов» ишеген тап. Кием-салымыңны рәтләрмен, кил!

Әстерхан татары Давыт Заһитов чынлап та Хабул өчен Хозыр Ильяс сыман изге зат булды. Гәүдәсенә чамалап киштәдән җылы күлмәк-ыштан тапты. Өр-яңа гимнастерка, чалбар бирде. Итекне дә җәлләмәде, әфисәрләр кия торганын, китереп тоттырды. Заһитов кушканча, мунча кереп, кырынып алгач, Хабул бөтенләй кешегә үк охшап китте. Гәүдәсенә җылы, сихәт кайтты аның. Ә иң мөһиме, майор зур дәрәҗәле әфисәр булса да, кешелекле, дустанә мөнәсәбәте, юату сүзләре белән күңелдәге юшкыннарны юып төшерде. Югыйсә тоткынга тирә-юньдәге кешеләрнең барысы да, Сидоров кебек, аңа җирәнеп, чирканып карыйдыр кебек иде. Уйлаганнары дөрес булса, бер хәл. Тик нахак бәла тагалар бит! «Смерш» тикшерүчесенең аеруча Хабулны «качкын» дип атавы чыгырыннан чыгарды. Ничек гаеп өя әле? Синең иптәшләрең залп утыннан баш-аяк юкка чыга. Ә син берүзең исән калгансың дип бәйләнәме? Әйт, ничек качып котылдың диме?

Чынлап та, егетләр белән янып күмергә әйләнсәң, бер дәгъвасы булмас иде Сидоровның. Ә мәхшәрдән исән чыккач, мәсьәлә калка. Ни өчен Хабул тере калган? Ник үлмәгән ул? Җинә килгәч, сугышта кан койганга төкереп карап, җанын, тәнен мәсхәрәләү дә берни тормый, күрәсең...

Хабул сәкегә чалкан яткан килеш, Сидоров күңелен кузгаткан хатирәләргә бирелде, үткән көннәрен күз алдына бастырды.

## XV бүлек

Ефрейтор Хабул Галиәсгаров Ленинград төбәгендә вакытлыча дислокацияләнгән авиаполкны калдырып, Мәләкәскә юл тотканда сәер бер хис кичерде. Поездга урнашып бомба, снаряд чокырлары белән теткәләнгән кырлар, мичләре генә утырып, баганалар тырпаеп калган авыллар, яртылаш җимерелгән кала, касабалар аша үткәндә нинди хис булырга мөмкин? Билгеле инде, сугыш гарасатына көенә, җимереклеккә ачыну, һәлакәтләр өчен әрнү... Әмма төтен ялларын бөркеп туктаусыз чапкан паровоз, поезд тәгәрмәчләре өстендәге вакыт икенче тәүлекне тутыргач, күзләрне тигез басу-болыннар, яшькелт киемле төз урманнар биләде. Хәтфә диңгез булып җәйрәгән арыш яланнарын күреп, Хабулның күңеленә ачык кына атап булмаган нindидер дәрт, ашкыну инде. Поезддан сикереп төшәсе, баш калкытып килүче арыш үсентесен иснисе, җиргә ятып, барысын онытып, тургай җырларын тыңлыйсы килде аның.

Хәзер станцияләрдә дә бертөрле, соры киемле солдатлар, гаскәриләр урынына төрлечә киенгән, бит, сыннары чуар халык төркеме кайный. Вокзалларда урыс һәм башка кавем сөйләшләре белән бергә, ара-тирә татар сүзләре дә ишетелгәләп китә. Юлда һаман ешрак күзгә чалынып үткән мәчет манаралары, бизәкле тәрәзә йөзлекләре, төзек киртә-куралар белән ямьләнгән җыйнак, сөйкемле ызбалар Хабул мосафирга «Без—татар авыллары!» дип еракtan ук кычкырып, сәламләп тордылар.

«Яшел алан» дип бик төгәл аталган станцада Хабул поездын алмаштырды. Кузгалып китәргә бер сәгатьләп вакыты бар иде әле, перронга чыкты. Каршыдагы эшелонда кемнәрнедер озаталар булса кирәк. Китүчеләре никрутлар бугай. Күзгә әледән-әле кырылган башлар, кыбырсык яшь йөзләр чалына. Шулай шул, әнә теге, паровозлы башта, оркестр яңгыратып «Славянка» көен уйный башлады. Бу якта тальян гармун телгә килде. Кемнәрдер аңа кушылып җыр да сузып җибәрделәр... Тик Хабул колагы белән генә түгел, үзалдына биешкән бармаклары белән дә сизеп, тоеп тора, көй-җыр рәхәтләнеп талпынып күтәрелеп китә алмый. Хас та канатлары каерылган киек коштай, кагына-җилпенә, тик очып китәлми.

Хабул тынычсызланып, эче пошып, үзе дә сизмичә төркем ягына атлады. Озын буйлы, сыек гәүдәле яшүсмер, чынлап та тальянның бакаларын бармаклар белән тоеп түгел, ә күзләре белән капшап уйный иде... «Өйрәнчек! Уйнау түгел, гармунны гына газаплау инде бу».

—Энекәш, бир әле!—диде Хабул аның каршысына басып.

—Мә!—диде тегесе һәм секундлар эчендә тальян ефрейтор кулына күчте. Күкрәгенә үрләгән сабыйны сыйпаган сыман, Хабул уң кулын клавишалар буйлап йөгертеп узды. «Әйдә жаный, сиптер!» һәм киерелеп күрекне тартып җибәрде ул. Шаулатып, бөтен шартын китереп башта көйне уйнады, аннары үзе үк җырлап та җибәрде Хабул.

Йөгердем житәлмадым,
Сикердем читәннәрен.
Ни булды икән телләремә,
Сау бул, дип әйтәлмадым...

Гармунчыга елыша төшеп, җырны иркен яңгыравык тавышлы сипкелле кыз күтәреп алды. Аңа ак күлмәкле ахирәте кушылды. Янә таякка таянган бер ир көйгә ныклы, ышанычлы төсмер өстәде... Шулай җыр көчәеп, канат ярып төркем өстеннән канатланып очты, күнелләргә бәреп керде, тел белән әйтеп булмаган хисләрне моң аркылы ярып салды.

Хабул һәм әлеге җырчылар «триосы» кайнарлык белән тагын берничә көй башкардылар.

Солдат мылтык аткан чакта
Дары исе тарала,
Ходай сабырлыклар бирсен
Сугыштагы балага...

Җырны тыңлап, күзләреннән яшь сөртүчеләр дә күренде. Ул арада эшелон буйлап «По вагонам!» дигән әмер яңгырады. Тамбурга күтәрелүләр, куллар биреп саубуллашулар башланды. Кемнәрдер: «Рәхмәт, солдат!.. Күнелне эреттең... Улым, Ходай гомерләр бирсен үзеңә»,—дип яратып, сөеп Хабулның да аркасына кагылып киттеләр. Ә теге ак күлмәкле сипкелле кыз, күз уңыннан язып торгач, яшьле күзләрен йодрыгы белән сөртә-сөртә янә ефрейтор алдына килеп басты:

—Абый җаным, сугыш бик куркынычмы? Киткәннәр үләме, исән калмыймы инде?

—Мин фронттан киләм, сенлем. Сугыштан. Күрәсең бит, исәнмен әле. Егетең дә кайтыр, елама!—дип җавап кайтарды Хабул.

—Егетем түгел, абыем китте!—дип ашыгып сүзне төзәтте сипкелле кызыкай...

—Абыеңа герой булып кайтырга язсын, матур кәләш табып куй.

—Рәхмәт, абый җаным!

Үз вагонына утырып, байтак юл киткәч тә, Хабул перрондагы хисләр тәэсирендә булды. Аяклар белән генә түгел, колачлап бетмәслек Русия җирендә татар да нык тамыр җәйгән икән. Бу хәттә без дә әзле, тәэсирле икәнбез. Шул газиз Ватанны саклыйм дип, яуга чыккан солдат үз җиремне, үз халкымны Гитлер явыннан коткарам дип кан коя икән бит... Шул юл хисләре ирнең рухына ныклык, төзеклек өстәде, алдагы көннәренә яктылык иңдерде.

Хәрби мосафир Мәләкәскә кояш калыккан бер мәлдә килеп төште. Ул вокзал каршындагы комендатурага кереп, килүе хакында мондагы дежур

әфисәргә рапорт биреп, документларын күрсәткәндә кемдер җиңеннән тартты. Башын кыйшайтып караса, янәшәсенә ниндидер капитан баскан икән. Озынча какча йөзе, зәңгәр күзләре яшерен мутлык белән тулы. Биткә елмаю җәелергә тора. Хабул аптырап та калды. Кем булыр соң бу?

—Нихәл, энекәш! Танымыйсыңмыни?—диде капитан татарчалап.

—Минач абый, синме бу?!—дип сөенеп кычкырды Хабул.

—Күрешмәгәнгә биш былтыр!—Минач туганнарча ике кулы белән дә авылдашының иңнәренә кагылды, аннары кочаклап та алды.—Йомышлы кешеләр булып киттек шул, Хабул. Язмышлар йөртә...

—Сине шинельдә күрермен дип һич тә уйламадым, Минач абый...

Авылдашларның очрашуы һич тә очраклы булмады. Әлеге капитан, Минач Гайфетдинов, ефрейтор Галиәсгаровны Мәләкәстә махсус каршылаучы кеше булып чыкты. Комендатурада рәсми эшләрен бетергәч, Хабулны хәрби шәһәрчеккә алып киттеләр. Юлда Минач Хабулның колагына иелә төшеп сөйли барды:

—Инде, энем, синнән секрет-мекрет юк. Элек авиатор булсаң, хәзер син ракетчик булырсың. Техник яктан нык әзерлеклесең... Бик яшерен корал белән сугышка керергә торабыз. Катюша! Ишеткәнең юкмы? Расчетта синең конкрет вазыйфаң шоферлык булыр...

Ниһаять, Хабул үзе белән булган бөтен мәрәкәнең чын сәбәбенә төшенде. Аны яңа коралга җәлеп итәргә телиләр икән. Һәм бу авылдашы капитан Минач Гайфетдинов тәкъдименә корылган булып чыкты: «Белгән, сыналган кешеләрне генә җыярга тырышалар монда, энем. Мин сиңа туганга ышанган кебек ышанам».

Төрле кабинет-бүлмәләрдә биографиягә, шөгыльгә, нәселгә бәйле иркле сөйләшүләрдә дә коммунист Кифая Галиәсгарова улына ниндидер дәгъва белдерүчеләр табылмады бугай, берничә көннән ефрейтор Хабул Галиәсгаров ставка карамагындагы махсус дивизионда артиллерист-ракетчик булып расланды.

Штаб мәйданчыгы каршында фронтның төрле төбәкләреннән китерелгән, дары иснәгән солдатлар, кече командирлар сафлар булып тезелгәч, политрук Гайфетдиновның дулкынланулы сүзләре яңгырады. Зур эшкә тотыныр алдыннан әйтелә торган бисмилла сыман булды бу.

—Ракетчиклар! Немец илбасарлары Мәскәү янындагы сугышларда сыртларын сындырдылар. Ләкин Сталинград, Ленинград кебек асыл шәһәрләр, бик күп калалар, авыллар язмышы һаман куркыныч астында. Дошман яраланган ерткыч кебек, көчле каршылык күрсәтә. Менә шундый хәтәр вакытта ил безнең кулга дәһшәтле корал-катюшалар бирде. Иптәш Сталин җитәкчелеге астында эшләнгән һәм дөньяда тиңе булмаган корал белән без дошманны һәлак итәчәкбез. Бу—безнең һәркайсыбызны горурландыра торган миссия, иптәшләр!

Ракетчиклар! Көчле корал көчле ирләр кулында булырга тиеш. Сез—совет халкының алдынгы, намуслы һәм патриотик хисле вәкилләре. Катюшаларда сугышырга ризалык биреп, сез барыгыз да моны тагын бер кат расладыгыз. Ышанмыйм, антыбызга тугъры калып, безгә кан коярга, хәтта Ватан өчен гомер бирергә дә туры килер. Тик шуны белегез, бөркетләр, без ил, тарих каршында батыр ирләр булып калачакбыз. Бөек Ватан сугышы елъязмасында безнең исемнәр алтын хәрефләр белән язылыр!

Хәрби сафлар сүз белән тәэсирләнгән. Йөзләр житди, күзләр ымсынулы...

Шәп сөйли, көчле сөйли, дип эчтән Минач абыйсына чиксез сокланды Хабул, урысчасы да бик шәп икән! Яшьлегендә, гражданнар сугышында айкалганда теле чарланып калгандыр инде. Югыйсә Түрештә калгач,

Хабулнын урысчасы әлләни мактанырлык түгел шул...

Хәер, сүз көче тел чайкаудан гына торса, подразделение командиры капитан Соколов тагын да канатлырак сүзләр сөйләргә тиеш иде. Урыс бит, сүз эзләп кесәгә керәсе түгел! Әмма Аполлон кыяфәтле яшь ир сафлар каршысына килеп чыккач, һәрберсенә дустанә, тыныч караш ташлап үтте дә, гадәти тонда сөйләп китте:

—БМ-13 корылмасы—хәрби техниканың соңгы казанышы. Бу реактив миномет чыннан да ин дәһшәтле «Сугыш Алласы». Тик аны «катюша» дип атыйбыз. Һәм катюша да катюша, дип авыз суын корытабыз. Мәхәббәт иясе, күрәсең. Күрмәдегезме әле үзен? Һай, чибәр! Ул тавыш, ул гөрләү, ул йөрәкләрне айкап ташлау! Шул мәхәббәтле зат белән сугышу үзе бер азарт, егетләр! Чын ирләр уены бу.

Сафлар буйлап тыенкы көлү, йөткерү, ымлыклар дулкыны тәгәрәп узды.

—Смирно!—диде Соколов кинәт кырысланган тавыш белән һәм ракетчикларны марш бастырып ангарга, катюша белән тәүге күрешүгә алып китте.

Озын кара япманы күтәреп шудыргач, курсантлар алдында «Студебеккер» автомашинасы пәйда булды. Әрҗәсе урынына тимердән әтмәлләгән ниндидер корылма куелган, шуннан авышкан казыкларга тартым тимер борыслар тырпаеп тора... Хабулның аптыраганы шул булды: кайда соң бу катюша дигәннәренең көпшәсе? Көпшә, торба булмагач, снарядны, тупны атып буламы? Дәһшәтле «Сугыш Алласын» күрермен дигәч, ул гаубицаларга, дингез пушкаларына тартым биниһая озын, саллы, зур авызлы торба турында уйлап алган иде. Менә сиңа әкәмәт! Көпшәсез дә пушка булыр икән?

Ракетчикларның тегесе болай, монысы тегеләй аптырашып, БМ-13 корылмасын урап алдылар, жентекләп, иелеп-сыгылып күзәтергә, капшарга тотындылар. Үзара сөйләшү китте...

Мәләкәс Хабул күнеленә катлаулы коралны үзләштерү, зиһен туплау, кул күнекмәләренә ия булу белән бергә, Минач абыйсының тәмле чәйләре белән дә хәтеренә кереп калды. «Ефрейтор Галиасгаров, минем сезгә бер соравым бар. Замполит бүлмәсенә рәхим итегез!» дип кешеләр каршында чакырып ала да, үзе белән ияртеп китә ул. Жыйнак кына кабинетка кереп, өс-башын салгач, Минач политруктан бер әсәр калмый. Ул Хабулга карата һәрчак жылы, кайгыртучан мөнәсәбәт күрсәткән абзый кешегә әйләнә дә куя. Өстәлнең бер почмагыннан кәгазь, китап, газитләрне читкә этеп тастымал жәеп куя да, табын көйли. Ә үзе эш арасында жай гына туктаусыз сөйләнә:

—Хат алып торасыңмы? Ә үзең яздыңмы соң? Син, Хабул энем, хатыңда мондагы хәлләр хакында ләм-мим, авызыңа су кап! Мин дә син, Мөхәммәт Әмин генә белә... Берниндн ишарә дә, киная дә ясый күрмә. Без жиде кат күзәтү астында бит. Аңладыңмы?

—Хатларны да ачып тикшерәләрмени, Минач абый?

Минач кунагына шелтәле караш ата:

—Өстеңә бүре китерәсең килмәсә, әйткәнне тыңла. Гомумән, монда итәк-жиңеңне бик жыеп йөр, Хабул энем. Кеше белән юк-бар темага кермә, бушны сөйләмә һәм лыгырдавыкны үзең дә тыңлама син. Әмерне тыңла, кушканны житкереп үтә! Менә шунда син герой булырсың...

Ниһаять, Минач политрук нәсыйхәтләрдән арына. «Йәле, чәйдән житешик!» дип хуш исле, парлы һинд чәен кружкаларга агыза. Тәм-томны Хабул алдынарак этеп куя: «Әйдә, сыйлан әле!»

Кабинет хужасы өстәленнән папирос алып кабыза, төтен суыргалап тын

гына Хабулның чәйләвен күзәтә һәм хушкүңелләнеп янә сүз ката:

—Хабул, армиягә китәр алдыннан гына малаеңны күрдем бит мин. Анасы белән картәтәсенә китеп бара иде. Үсеп килә, аягына баскан инде. Бик сөйкемле, тере бала... Күтәреп сөйгән идем, ятсынмый. Әйтәсе юк, бик матур малаең үсеп килә, Хабул!

Ир ашавыннан туктый, тамагына төелгән кебек тора.

—Исеме ничек әле?

—Җәмил...

—Ярар, Хабул, бирешмә! Алла теләсә, исән-сау кайтып, гаиләне кочарбыз әле без. Нишлисең, түзәргә кирәк, ил белән бит. Башка төшкәнне ирләрчә күтәрә белү кирәк, энем...

Үзен дә, кешене дә юату өчен әйтә инде моны Минач абыйсы... Мәләкәсне хәтерләп фильтрацияләү лагере сәкесендә яткан ирнең зиһенен кинәт бер уй кисеп үтте. Политрук Минач Гайфетдинов аны авиаполктан чакыртып алмаса, Хабул тоткын хәлендә «Смерш» кешеләре каршында басып торыр иде микән? Әрсез кырмавык кебек булып «качкын... хыянәтче»... сүзләре ябешер иде микән аңа?

Уйлавын уйлады, икенче тарафтан килеп, аларны шундук күңеленнән дә куды: «Йа Ходай, язмышыңа үпкә тотып, хәтта ник туганыңа үкенеп торсаң, кешеләр хакында ниләр генә уйламассың...»

## XVI бүлек

Катюшалар белән сугышка кайчан керде соң әле алар? Хәер, календарьда адашасы түгел икән. 1942 елның 22 июнендә булды бу. Гитлерның сугыш башлавына нәкъ бер ел тулган көн иде. Фашистка сабак укыттылар. Монда Хабул күргәннәр баланның да баласына сөйләрлек бер кыйсса инде...

Төнлә, үтә нык яшеренеп хәрәкәт итүче катюшалар, ниһаять, таң алдыннан Пронино шәһәре янына килеп туктады. Ракетчикларга дошманның бик хәтәр «Әле баш» дивизиясен тоткарлау, шәһәрне камалыштан коткарып калу бурычы куелган иде. Яңа плацдармга күчкәч, иң элек реактив минометларны кая урнаштыру хәстәрен күрү кирәк. Подразделение командиры Егор Соколов, политрук Минач Гайфетдинов планшетларын асып полк штабына юнәлде. Ә Хабуллар, мөмкинлектән файдаланып, черем итеп алу җаен кайгырта калды.

Көтелгән кунакларны штабта офицерлар төркеме каршылады. Озак юанмыйча, өстәлгә бик зур фронт картасын җәеп салдылар.

—Йә, иптәшләр, катюшаларны кая урнаштырабыз?

Капитан Соколовның әлеге соравына штаб начальнигы подполковник Евсуков ике сөйләргә урын калдырмаслык катгыйлык белән:

—Кая булсын, артиллериянең урыны биеклектә!—диде. Һәм картада шартлы билге чекерәеп торган җиргә таяк белән төртте.—Менә монда бик җайлы тау битләве бар. 15-20 чакрымга кадәр тирә-юнь уч төбендәге кебек күренеп тора...

—Ә сез үзегез күргәч, сезне дә шәйләрләр димисезме?—дип кисәк сорау куйды Соколов. Залп биргәч тә, мессерларның үзебезне үтүкләп куюын теләмәсәгез, безгә берәр чокыр, иңкүлек күрсәтегез сез. Аннан торып та, кирәкле ноктага бәрә алабыз бит без...

—Сукыр килешме? Ай-һай, зерә биеклектән баш тартасыз, капитан,—диде сүзе аста калуга кәефе киткән штаб начальнигы.—Гомер-бакый тупчылар югарыдан позиция алырга тырышканнар. Яхшы позиция—җинә!

—Минем сүземә ышанмасагыз, иптәш подполковник, үзегез сайлаган тау башына пушка карачкылары тезегез соң. Күрербез, кем хаклы булыр?

Әйткәнемчә, безгә дошман абайламаслык урын күрсәтегез. Стратегик корал өчен мин җавап бирәм бит.

Капитан Соколовның әлеге катгый сүзләреннән һәм ныклы тотышыннан штабтагылар катюшаның яңа корал булу белән бергә, хәрбиләргә дә сугыш тактикасын кору, позиция сайлау, маневр ясау тирәсендә янача таләпләр куюын аңлап алдылар. Һәрхәлдә ракетчиклар белән бәхәсне дәвам итү урынсыз иде. Соколов теләгенә буйсынып, һөҗүм итү планы әзерләнә башлады.

Катюшаларны урман авызыннан башлап шәһәр ягына сузылган озын инкүлеккә урнаштырырга булдылар. Ә менә күзәтчене тау башына мендерергә карар кылынды. «Күз» ракетчикларга юнәлеш-ориентир биреп тору өчен кирәк иде.

—Фрицның танклары күпме?—дип сорады Соколов план-бланшны тагын да ныграк ачыклауга исәп тотып.

—Безнең мәгълүматлар буенча йөз иллеләп. «Тигр»лар,—диде разведка начальнигы Шаумян.

—Алар кайда дислокацияләнгән?

Шаумян картада билгеләнгән урманга күрсәтте:

—Чәчелгәннәр, гөмбәләр диярсең. Һәркайсын шәпләп яшергәннәр. Атаканы үз планнарына карап ясарга җыеналар бугай. Ояларыннан чыкмыйлар, йөз яшеррәләр.

—Маневр ясасак, чыгарлар!—дип сүзгә кушылды политрук Минач Гайфетдинов—Тик тычканга сыр ыргыткан кебек, хәйлә корырга кирәк.

Һәм политрук үз ниятен бәян итте:

—Артиллерия залпы белән дошман оборонасын теткәч тә, немецка ым бирергә кирәк. Янәсе, артподготовка бетте, хәзер пехота атакага күтәрелә... Дошман оборонасы дәшмәсә, немец танкларны чыгармый булмас, чыгарыр. Һәм менә шунда пехотаны яткырабыз да, катюшалар белән «Тигр»ларны яндырабыз...

—Шәп идея бит бу, иптәшләр! Иң мөһиме—солдатларны саклыйбыз,—дип пехота башлыгы полковник Заманов кайнарланып Гайфетдиновны куәтләде.

Тагын да ачыклаулар, өстәүләр булды. Ахыр чиктә һөҗүм планы барысының да күңеленә ятты.

Командирлар штабтан кайтуга, Хабуллар эшкә керешә. Машиналарны куаклы, туйралыклы инкүлеккә төшереп, сугышчан әзерлеккә тезделәр. «Шәмнәрне шәмдәлләргә» дә кертеп утырттылар. Монысы—Хабулларның расчет командиры Букштейн гыйбарәсе. Яшь лейтенант мыек астыннан гына көлеп, тел-лөгать дөньясын гел үзенчә сукалый. Әйтәсе юк, башлы егет. Сугышка институттан алганнар үзен. Ә болай әйтелгән шөгыль шәмдәлләр тирәсендә кайнашу гына түгел анысы. Хабул беренче күргәндә катюшаның көпшәсе кая дип аптыраган иде. Бу бөтенләй көпшәсез, торбасыз булып чыкты. Букштейн әйткәнчә, чынлап та шәмгә тартым, кеше буйлык озын реактив фугас снарядны тырпаеп торган рельс-борысларга беркетеп куялар икән. Икәвең арыш капчыгы авырлыгындагы снарядны лямкага эләктереп рельс буенча өскә шудыра, ә өченчең аны артыннан этә-төртә күзәтә: «шәм» тиешле урынга утырдымы-юкмы? Бу эшне башкарганда гел әмер явып тора. «Күтәр!.. Төшер! Булды, утырды, үз урынына ятты»... Шәм кую, имеш... Тапкан бу студент сүз! Хабул моны үзе ЗИС әрҗәсенә бүрәнә төяү сыман мәшәкатьле, авыр эш итеп саный. Тиргә чумасың, ачыгасың, сусыйсың берничә потлы фугас снарядларын борыслар арасына тезгәнче.

Инде көтүләр... Атака көтү—түшәгеңә ятып бичәңне көтеп алу түгел ул. Төрлесен уйлыйсың. Башка ниләр генә килми. Колакларың шылт иткәнне

дә ишетергә әзер тора. Күзең чекерәеп, тирә-юньне барлый. Бу җир алай-болай, әйтемдәгечә, синең саламны алдан ук җәеп куярга ымсынган урының түгелме?

Фронт сызыгында әлегә тынлык. Тик ара-тирә мина шартлап куя. Кеше эләктеме, әллә берәр киек-җәнлек бастымы үзенә? Янә тынлыкны бозып ялгыз мылтык атыла. Снайпер кеше аулый бугай... Колак гаме тагын гөнаһсыз, риясыз кош-корт чыр-чуына, сайравына чума.

Кояш инде кул яссуы күтәрелде. Сәгать тә, ниһаять, алтынчыга китте. Күзәтче кеше радиотехник старшина Чанборисов командирлар белән рациясен бер дулкынга көйләде дә, аксыл томан эченнән чак-чак шәйләнгән тау тарафына юнәлде.

Иңкүлектә акрынлап томан эреде. Биеклек ачык булып шәйләнгәч тә, политрук Минач рациясеннән Чанборисовның татарчалап әйткән сүзләре ишетелде: «Килеп кунакладым. Күл өсте яхшы күренә»... Бу тарафтан Минач җавап юллый: «Аңладым. Безнең кармаклар әзер».

Болар шулай, фрицлардан сер яшерү өчен, ана телләрендә сөйләшергә сүз куешканнар икән. Бик яхшы! Немец безнең телне каян белсен, ничек төшенсен? Гитлер татарны Русиядәге бер кыргый азиат итеп кенә саный, ди бит. Әйдә, ләгънәт фашистка безнең туган тел дә орсын әле!

Көткән минутлар бөтенләй якынлашып килә. Катюша командирлары наушниклы шлемнарын киде. Пульт такталарына төзәүчеләрнең куллары ятты. Букштейн наушнигы аша командир Соколовның конкрет әмерләре ишетелеп торды. Ул исә үз чиратында төзәүче Андреевка командалар бирде. Һәм, ниһаять, рация аша кискен боерык яңгырады: «Җырла!»

Кинәт иңкүлектә нинди дер ят, куркыныч җанварлар үкергән сыман булды. Утлы эзләр сузып һавага ракеталар күтәрелде. Алар һаман да көчәя барган гүләү, иңрәү авазлары чыгарып дошман окоплары, блиндажлар, дзотлар тарафына очты. Күпме секундлар узгандыр, күкне көчле шартлау гөрелтесе биләп алды. Немецлар яткан җирдән нәҗәгай балкышына охшаш ут дивары күтәрелде...

Рация аша Чанборисов әсәрләнеп кычкырды:

—Анакай, мәхшәр... Гарасат... Мондыйны бер дә күргән юк иде!.. Алло, Алло! Җәен барысын йота, шәп!—Бер минуттан инде күзәтченең әмере ишетелде:—Ярар, кармагынны акрынлап сулга күчерә башла!

Минач, янәшәсендәге капитан Соколовка борылып, әмерне үз телләренә күчерә:

—Снарядлар ноктага ята. Инде ориентерны сул тарафка күчерергә кирәк!

Ул ара Чанборисов янә тавыш бирә:

—Кармакны көнбатышка таба биш адым ыргыт әле! Чуртан күзәтелә.

Политрук үз шәрехләвен ясый:

—Ату дистанциясеннән ярты чакрымлап көнбатышта дзот урнашкан.

Соколов шундук үзе расчет командирына әмерен ясый: «Бездә шундый-шундый сәгать, фәлән минут... Җырла!»

—Булды! Чуртан капты!—дип сөенә күзәтче.

Команда пункты шул рәвешчә эшләп, дошман оборонасы, ныгытмалары һәм күзәтче юнәлткән төрле хәрби объектлар өстенә туктаусыз фугас снарядлар явып торды. Жиде-сигез чакрым ераклыкта өзлексез ут баганалары биеште, җир янды. Бу күрелмәгән мәхшәрдән кемнендер исән калуына да ышану кыен иде. Тере калса да, акылыннан шашар бу тәмугта адәм заты...

Ә катюшалар һөҗүме һаман дәвам итте. Букштейн, капитан Соколов белән кыска-кыска фразалар алышкач, Хабулларга үз командасын бирә:

—Шәмдәлләргә шәмнәр тезегез!

Теге очтагылар туктаусыз ата тора, ә Хабуллар тирләп-пешеп үз катюшаларын кора: «Күтәрә төш!.. Утырды, урынына төшеп сыланды... Әйдә, яңасын шудыртыгыз!»

Күпме вакыт үткәндер, Алла белсен, Букштейн әйткәнчә, шәмнәр шәмдәлләргә менеп тә утырды.

Рация аша «балыкчылар» янә хәбәрләшеп ала.

—Баскан урыныңнан кармагыңны камышлыкка табан алты метрлап ыргыт әле. Бака бар бугай...—ди Чанборисов.

Бу инде катюшалар командирына алты чакрымдагы урман авызында дошман артиллериясе тора дигән ым бирә. Менә Букштейн наушнигында Соколов тагын телгә килә, үзләренең телендә ориентирны ачыклый һәм «җырла» дип боера командир.

Ниһаять «балык аулау»ның азагы җитте.

—Кармакларыңны җый да төш! Карчыгалар очып килер,—дип әмер җибәрде политрук Гайфетдинов. Кинәт тирә-юнь тып-тын булып калды. Шундый тын, хәтта колакларга сәер, ят, шомлы ул. Куллар, аяклар да кинәт богауланып, тышауланып калды сыман... Ярый әле рацияләр буенча командирның кырыс әмере кешеләргә янә җан кертеп җибәрде:

—Катюшаларны япмалар белән капларга! Барыгызга да маскировкалар астына яшеренергә!

Бик вакытлы башкарылды бу эш. Һавада ниндидер тоныкһәм өзлексез гүләү ишетелә башлады. Һаман шом салып үсте, көчәйде ул. Һәм фрицлар оборонасы ягыннан, урман өстеннән, самолетлар тезмәсе килеп чыкты. Хабул боларны шундук таныды: «Фокке-фульфлар. Пушкалары бик хәтәр боларның»...

Дошман карчыгалары кунарга урын тапмаган кошлар сыман, фронт сызыгы өстендә әйләнгәләделәр дә, таралышып безнең яктагы урман рәтен, каршыдагы тауны утка тотарга, бомбалар ташларга тотындылар. Штаб начальнигы Евсуковны кызыктырган битләү аеруча нык теткәләнде. Монда, Соколов сүзен тыңлап, туп, машина карачкылары тезгәннәр иде. Алар минут эчендә барысы да таш, балчык белән аралашып һавага очты.

Авиация һөҗүме унбиш минутлап дәвам итте. Ходайның рәхмәте, Хабуллар яткан иңкүлеккә берәр бомба төшеп ярылсачы! Чөнки иңкүлек, туйралык берсен дә кызыксындырмады бугай.

Килешенгәнчә, совет пехотачылары һөҗүмне башлап җибәрде. Шул арада катюшаларны өч төркемгә аерып, оборона сызыгына каратып урнаштырдылар. Безнең як дулкынланып көтте: фриц танкларын чыгарырмы? Солдатлар сафы «Ура!» кычкырып, бердәм ташкын булып, дошман оборонасын яулап килә. Менә берничә рота немецлар кулы астындагы кырга да аяк басты инде.

—Чыктылар!—дип шатланып команда пунктына хәбәр бирде Чанборисов. Алла белсен, «үткен күз» кая менеп кунаклагандыр. Әмма хәзер инде гади күзгә дә яхшы күренә. Танклар ташбакалар кебек, шуышып урманнан чыгалар. Тегеннән-моннан ут бөркелә—пушкаларыннан аталар, пулеметлардан сиптереп безнең гаскәрләргә каршы юнәләләр. Күпләр, куркынычлар!

Шулвакыт тезмәләр буенча команда яңгырады: «Тукта, ят!» Һәм солдатлар җиргә елышуга, туры наводка белән катюшалар залп бирде. Һавада янә ниндидер ят, куркыныч җанварлар үкергән сыман булды. Танкларны берәм-берәм ялкын урап алды, һавага ут, төтен баганалары күтәрелде, вырлап тимер кисәкләре очты...

Бу көндә, Гитлер безгә сугыш башлаган 22 июньдә, совет гаскәрләре

Пронино шәһәре янындагы дошман оборонасын өзеп, фрицларны 35 чакрым ераклыкка кудылар. Нәкъ шул көндә капитан Соколов җитәкчелегендәге ракетчиклар тәүге сугыш чирканчыгы алып фронт геройларына әйләнделәр.

Көчле корал көчле ирләр кулында булса, әллә нинди куркыныч дошман да калтырап төшә икән... Минач абый хак әйткән шул, дип сәкесендә яткан килеш уйлап куйды Хабул.

## XVII бүлек

Ул иртән аякланып, ашханә сыман җирдә үзенә тиешлесен капкалап кайткан гына иде, дневальный кычкырды:

—Галиасгаров, допроска!

Юлында майор Заһитов очрады. Обоз каршылау, товар урнаштыру мәшәкатьләре белән йөрүе.

—Нәрсә, энем, тагын свиданиеме? Сак белән Сок булдыгыз инде. Һаман серләшергә зарыгасыз бугай.

Эш кәгазьләре тотып, көлемсерәп үткән әфисәргә Хабул ни әйтергә дә белмәде, эчтәге ачыргалануын сиздереп кулын гына селекте. Тик Давыт абзасы төшенкелекне өнәмәде:

—Михнәт чикмичә, рәхәткә тарымассыз, дигән пәйгамбәребез. Түз!

Нинди җиңел уйлы кеше бу, дип гаҗәпләнде Хабул. Мәңге картаймас... Шулай да капитан Сидоров каршына тоткын үзендә ниндидер күңел ныклыгы тоеп басты.

—Йә, Галиаскеров, бүген нәрсә сайрарсыз?—тикшерүче гадәтенчә Хабулга күз сирпеде дә папка ачып кәгазьләрендә казынды. Тагын дәвам итте:

—Өрә белмәгән эт бүре китерер, ди татар. Тик нигәдер, Галиаскеров, бу акыл сиңа барып ирешмәгән... Менә кичә син миңа катюшаны суга батырдым, диден. Ә бит Ставканың приказ, инструкцияләрендә кат-кат искәртелә.—Сидоров, папкасында яткан кәгазьне кулына алып, тоткын алдында селекте.—Менә өзек китерәм. «...БМ-13 корылмасына кагылышлы һәр мәгълүмат хәрби сер булып калырга тиеш. Аның дошман кулына эләгү куркынычы туса, ул, кичекмәстән, шартлатыла...» Ә сез нишлисез? Хәрби сер булырга тиешле объектны елгага, суга ыргытасыз. Димәк, бу приказны үтәмәү. Башбаштаклык. Моның өчен сиңа төрмә генә аз, Галиаскеров. Сине стенага терәргә кирәк!

—Сезнең ихтыярда. Тик мин үз командирымның приказын үтәдем.

—Приказ, имеш! Ә катюшаны батырган су чыпчык тезеннән булса... Дошман килә дә каптыра. Моннан да ахмаграк сер сату булырга мөмкинме? Сиңа бит «Сугыш Алласын» тапшырганнар, Галиаскеров. Хәрби вазыйфаңа төкереп караган өчен, җавап тотарсын әле син!

—Төнлә без култыкка су керергә бардык. Тирән иде. Батармы, батмасмы дигән шиккә урын булмады. Суга батыру да кызык өчен эшләнмәде бит. Шартлаткыч зарарланган. Катюшаны ташлап калдырып булмый. Командир боерыгы булгач, машинаны кабыздым да, полоса буйлап елгага элдерттем, иптәш капитан. Шулай, сез әйткән «Сугыш Алласын» фриц кулына эләгүдән саклап калдык...

Хабулның ихластан әйтелгән сүзләре, күзләренә бәреп чыккан чын сыкрау чаткылары тикшерүчегә йогынты ясады бугай. Сүзсез генә «Казбек» кабызды, итекләрен шыгырдатып идән буйлап йөрергә кереште.

Тынлык Хабулның уйларын үзе белән җитәкләде. Күз алдына янә утлы-өермәле сугыш кыры килеп басты, колагында җанны тетрәтүче шартлаулар яңгырады. Урман тезмәсенә яшеренгән ракетчикларда шик калмады. Аларны

десантчы немец солдатлары аулыйлар... инде чолгап ук киләләр иде. Хәл мөшкел, боеприпаслар бетеп бара, сак өчен билгеләнгән взвод кырылды диярлек. Инде дошман угыннан берәм-берәм ракетчиклар егыла. Кем кем, әмма Букштейн пулядан киселер дип уйларга да базмаган иде Хабул. Бик яшь тә, чиксез зыялы да егет бит. Яшәргә дә яшәргә иде әле ана... Аннары судан коры чыга торган гадәте дә бар... Тик машина кабинасын кабаланып ачып, инструментлар әрҗәсеннән нидер эзләп торган лейтенант күз алдында дерт итеп китте, жиргә сыгылып төште. Ул сыкрап елмайган сыман, сусыл коңгырт күзләрен Хабулга текәп торды да, сүнеп барган двигатель сыман: «Вот и все... Глиа...аскаров...» сүзләрен әвәләде...

Нәкъ шул тетрәнүле мизгелдә Минач машиналарны шартлатырга әмер бирде. Әмма бикфорд шнуры чыжлап янып барса да, Хабул катюшасы шартламады. Дарыга шайтан төкергәнме, әллә запал бозыкмы сон? Лейтенант бәлки машинадагы бу көйсезлекне чамалап инструмент эзләгәндер дә...

—Бар, энем, машинанны кабыз да, полоса буйлап елгага сыптыр. Суга батыр моны?—диде Минач абыйсы тыныч, әмма тәвәккәл бер ният белән.

—Минач абый!—диде Хабул чиксез куркынып.—Мин сездән аерылмыйм. Ни күрсәк, бергә күрик инде...

—Монда беребез әлә дә бик житкән, энем. Бәлки исән калырсың. Биш минуттан Соколов залп тотачак. Көл дә калмас. Бар, ку!

Минач Гайфетдинов баш өстендә зилзилә уйнаса да, төрлесен уйлап алган, күрәсең. Ул пунктуаль, дисциплиналы һәм намуслы әфисәр, ставка приказ-әмерләрен, инструкцияләрне истә тотса да, авылдашының язмышын күнеленә якынрак алган булган бит... Хабул Минач абыйсының үзен кысып кочаклавын, яшьләнгән җете зәңгәр күзләре белән үзенә төбәлеп каравын, «Кайтсаң, минекеләргә сәламемне ирештер!» дигән кайнар сүзләрен берәр вакыт оныта алыр микән?

Хабул ыжгыр машинасы белән яр буена да барып житмәгән иде әле, жанын таныш жанвар үкерүе куырып алды. Аның әле яңарак кына кузгалып киткән урынын кинәт ут өермәләре чорнады, шартлаулардан Жир ыңгырашты. Йә Хода! Катюшалардан атылган фугас снарядлары ялкыны үзебезнекен, дошманныкын тикшереп тормыйча, газиз адәмнәрне күз алдында яндыра, көйдерә, теткәли...

—Хуш, Минач абый! Хушыгыз, егетләр!

—Өлкән сержант Галиаскеров!—Капитан Сидоровның үзенә төбәлеп торган карашы Хабулны янә кырыс тоткынлык дөньясына кайтарды.—Син катюшаннын чумган урынын хәтерлисеңме? Берәр географик пунктны яисә ландшафтны атап әйтә аласыңмы мина?

—Без һәрчак төнлә йөрдек бит. Командирлар да сер саклап безгә карталарын күрсәтеп бармадылар... Шулай да юлда «Дубец валы» дип күрсәтелгән авылмы, касабамы очравын әйтә алам. Кыйшайган бер баганада шундый язу күзгә чалынды...

—«Дубец валы»... Ярар, тикшерербез... Тикшерәбез, тикшерәбез, Галиаскеров! Син пленда ялчылык иткән немец бюргеры белән дә кызыксынырбыз. Исеме ничек әле?

—Кемнең?

—Син ялчылык иткән немец бюргеры, дидем бит!

—Карл фон Ницше.

—Аллаңа ялвар, Галиаскеров, әгәр дә сөйләгәннәрең, әйткәннәрең расланса, ярлыкауга өмет итә аласың. Алдашасың икән, үзенә үпкәлә! Бар, бүгенгә житәр.

Карл фон Ницше... Хабулның күз алдына төз буйлы, кырыс чырайлы, затлы күзлекле хәрби адәм килеп басты. Борын астында тыйнак кына «Аля Гитлер!» мыегы да бар моның. Перчаткалы куллар уйнатканда резин таяк әллә итек кунычларын сыйпап, әллә синең сыртыңа килеп төшәр. Әй, Алла, бу фрицка бәйле хәтерләүләр дә төне буе сине керфек тә какмаслык пошыну, сызлануларга сала бит. Хабулның миңгерәп немецларга әсир төшүе генә житмәде, әлеге бюргер—әфисәргә коллыкка элэгү өчен дә җавап бирергә кирәк. Бер салса, өсти-өя генә икән бит Ходай яраткан бәндәсе башына!

...Кырык өчнең ноябреме, декабре булдымы икән, әсирләр барагында башына фәс кигән, куе кара мыеклы, җәйпәк битле, юантык бер ир пәйда булды. Ул базарда мал сайлаган кеше сыман, күзе төшкән бер әсир каршына килде. Буй-сынын тикшерде, авызын ачтырып теш казналарына күз салды. «Фәс» моның белән генә чикләнмичә, кулындагы лупа белән әсирнең баш, чәчләрен, ялангач аркасын, хәтта ыштан эчләрен дә тикшерде. Бөҗәк-фәлән эзлиме? Күпләрне хайвани курку биләп алды, йөз-битләрен яшерделәр. Бу адәм әсирләр өстендә берәр тәҗрибә кылырга җыена микәнни?

Ул Хабул каршына да килеп җитте. Ирексездән күзләр очрашты.

—Син бит төрки угланы?—диде ул табак битенә елмаю саркытып.

—Мин татармын!—дип җавап кайтарды Хабул.

—Татар—төрки кавеме, углан...—Һәм әрсез адәм һич тартынмыйча, баш-аяк Хабулны да күзәтергә, капшарга кереште. Сөннәтенә дә оялмыйча күз салды. Бу гамәлне башкаргач, ул үзен озатып йөргән унтер-әфисәргә немецча берничә сүз әйтте. Тоткынны шундук җитәкләп бaрактан алып чыгып та киттеләр. «Бетте баш!»дип уйлап куйды Хабул. Хәер, бүре кебек этләр өсләтүдән кот чыгып, бетле баракта җан асраганчы, берәр үзгәрешкә сусау омтылышы да көчле иде. Ходай әллә ялваруын ишеттеме, ябык машинада ярты көн чамасы юл үтеп,ниндидер хутор кебек яланлы җиргә килеп төштеләр... Төрек Йосыф Әкрам унлап әсирне Карл фон Ницше утарына ялчылык итәргә алып кайткан икән!

Управляющий Йосыф боларны һаман үз кулында тотып, мунча аша үткәрде, дезинфекцияләде, кием-салымнарын алмаштырды да, иркен, җылы бер бүлмәгә урнаштыргач, нотык тотты:

—Төрки угланнар, мөселманнар! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Рәсүлуллаһ безгә бер-беребезне туганнар итеп күреп, ярдәм кулы сузып яшәргә өндәгән. Мин сезне Алман морзасы Карл Ницше җәнапләренең утарына эшкә алып кайтып, шул васыятьне башкарам дип уйлыйм. Сездән дә шуны өмет итәм, дин кардәшләр. Без һәммәбез дә бит Мөхәммәд өммәтеннән, мөселманнар без...

Хабулның үз телендә күптән инде әлегедәй төзек мәкамле сүз ишеткәне юк иде. Кыям бабасында кияү булып коръән ашында яисә ураза, корбан бәйрәмнәре табынында Шакир мулла авызыннан шундыйрак вәкарьле сөйләм тыңлады ул. Тик илдән чыгып киткәч, ләхәүләләр, вәләкуәтләр акрынлап онытылды, боларны искә төшерүчеләр дә очрамады. Һәм Хабул да ахыр чиктә әлеге көйле ләгать тик борынгы Түреш өчен, шундагы мәчет картлары, намаздагы карчыклар өчен генә хас сүз дип ышанды. Инде менә күрмәсәң күр, Шакир мулла кебек килешле вәгазь, нәсыйхәт укучылар бар икән ласа! Тегендә-монда түгел, ә сугыш, гарасат чыккан урында, кансыз Гитлерның ил-йортында сөйлиләр бит Аллаһка кагылышлы мәкамәле сүзләрне... Хабул гына түгел, башка солдат әсирләр дә бу хәлгә бик сәерсенгәннәр бугай. Мөселманча итагатьлелек тә күрсәтүләр, шылт иткән тавыш юк, сүзгә оеганнар.

—Аллаһы Тәгалә барчабызны үзенчә сыный. Яраткан бәндәләренә язган авырлыклар аеруча ишле ди Изге китап. Түзәргә кирәк, оланнар,

сабырлыклар кылу кирәк. Сынаган бәндәсен Ходай Тәгалә ахыр чиктә барыбер бәхетле итә, оҗмахка юл ача. Күнелләребез өметтән язмасын! Әлеге дөнья кыямәт мәхшәре булып утта кайнаган бер чакта Карл барон утарында Аллаһны уйлап вә Аллаһ кушканча яшәсәгез, иншалла, тәнегез дә төзек, җаныгыз да имин булыр, кардәшләр!

Йосыф Әкрам дисбеле кулларын күкрәгендә кушырып, дикъкать белән әсирләргә карап торды. Тегеләр сүзне беткәнгә санап булса кирәк, йөткеренә, урындыклар шыгырдата башлагач, ул янә җанланыбрак сүзгә кереште.

—Оланнар, Карл фон Ницше сезнең хезмәтегезгә зар-интизар, эшчегә мохтаҗ дисезме? Ю-у-к! Ялчы белән Европа тулы. Ул үз йортында кяферләрне түгел, сезне, төрки угланнарын күрергә теләде. Ник дисезме? Төркине барон бөек Чыңгыз токымы итеп соклана. Оланнар, хәмер эчмисез, тәтен тартмыйсыз, зина кылмыйсыз сез. Олыны олы, кечене кече итә төрки кавем. Менә шуңа Карл әфәнде төркиләрне ярата. Яратып кына калмый, аларга матур хәят тә юрый. Иншаллаһ, сез үзегез дә моңа ышанырсыз, кардәшләр. Изгелеккә изгелек белән җавап бирик, оланнар!

Хабулга бу көн бер төш булып тоелды. Моннан соң да әле байтак вакыт үзгәрешкә күнегә алмады ул. Һәр көн хайван урынына кыйналып-сугылып, ачка киселеп җан асра да, кәтмәгәндә сиңа җылы ятак, якты чырай, такта чәй дигәндәй... Көненне юанып үткәрергә эше дә бар бит аның. Үткән көннәрең белән чагыштырганда, чынлап та оҗмах бит бу!

### XVIII бүлек

Тәне сихәтләнүгә юанып, барон утарында байтак вакыт гамьсез яшәде Хабул. Җан кыйнамас өчен, кеше белән дә юньләп аралашмады хәтта. Адәмнән күнеле тәмам бизгән иде аның. Хәер, як-ягына киртә тотуның да хаҗәте юк. Әсирләрнең һәркайсына аерым эш йөкләнгән. Берсе сыер сава, икенчесе дуңгызлар карый. Өченчесенә кош-корт кетәге тапшырылган. Дүртенчесе йорт җыештыра. Казакъмы, үзбәкме үзе, озын буйлы, моңлы җырлы Хөрмәт иртүк торып тегермәнгә чыгып китә дә, онга буялып кичен генә кайта. Чечен кешесе карсак Шамил кухняга эшкә йөри. Кичен төргәк күтәреп кайткач, аның янына агай-эне җыела. Сөяк, сынык-санык белән тамак ялгыйлар, як-якка каранып, шыпырт кына нидер сөйләшәләр дә. Аерым сүзләре Хабул колагына да килеп ирешә, аңлый да кебек, тик барыбер чит кавем лөгате акылга ирешми кала. Хәер, озак өелешеп торалмыйлар, каядыр йортта Йосыф идарәченең үгет-нәсыйхәтле тавышы ишетелә, яисә юан гәүдәсен үрдәк кебек чайкалдырып кара йөзле, үткер күзле хәләл җефете Һашия килеп керә—шундук өркетелгән киекләр сыман, үз ятакларына шылалар болар.

Хабул үзе атлар карый. Баһбайлар арасында кайнаша башлагач, ул яшьлегенә кайткан кебек булды. Түрештә атлы эштә йөрде бит. Җирән кашканы җигеп ашлык, печән, салам ташыды. Кеше белән кеше аерылган кебек, атлар арасында да җир-күк арасы булыр икән! Карл барон айгырларын колхозның бөкшәйгән, үшән атлары белән тиңләп буламы соң?! Боларның алларыннан хуш исле печән, солы өзелми. Ә бер көнне кеше ышанмаслык хәлгә тап булды Хабул. Хуҗаның яраткан чаптары «Пегас» өч яшен тутырган икән. Мундирында генерал погоннары яткан Карл үзе килеп торт белән сыйлады шуны. Атка да торт пешерә икән бу халык! Ә сөлектәй кара айгыр—иркәнең иркәсе. Кура җиләгедәй бөрчекле иреннәрен маһир кыймылдатып, кулдан торт кисәкләрен дә берәм-берәм ялмап куйды. Рәхмәт әйткән сыман, тавышны күкрәк төбеннән чыгарып кешни дә белде. Инде барон йөгән кидереп, үзе артыннан әйдәгән иде,

айгыр атламый, тик биеп тора... Берсе җайдак, икенчесе юртак булып әллә кай җирләрне урап кайттылар болар.

Баронның «Пегас» кебек нәселле юртаклары ике дистәләп. Йосыф эшкә күндергәндә еш-еш кереп, Хабулны искәртеп торды:

—Берүк боларга кул күтәрмә, сукма, олан! Адәм акыллары бар бу хайваннарда. Хуҗа да үз балалары кебек күреп, кадерләп, назлап кына тора. Кул озайтканыңны күрсә, Аллаң сакласын, бәладән башаяк!

—Йосыф бәк, баронга нигә шул чаклы юртак?—дип аптырап сорады Хабул.

—Әй, олан, әйтмәдеммени? Болар бит ат белән мәшһәр нәсел. Айгырлары Европа аукционнарына куела... И күрсәң син, яз житсә, монда җыелган кунакның исәбе юк. Атлар белән сәйләнгә чыгалар, атларда ауга китүләр. Ат чабышы—үзе бер бәйрәм. Сәясмән дә—монда, эшкуар да—монда, хаким дә безгә килә. Ул утырмадагы ханымнарны күрсәң... Былбыллар кебек чөкердәшәләр! Хушбуйлары әллә каян аңкый. Безнең Карл галиҗәнаплары юк-бар кеше түгел бит. Гауляйтер!—дип аулакта ачылып китте управляющий.

—Гауляйтер? Анысы кем, Йосыф бәк?

—Аз белсәң, күп яшәрсең, олан. Тик сүз чыккач, монысын гына әйтим инде. Сезнең мәмләкәттәге бер кыйтгага хаким кеше ул. Идел-Урал йорты, диләр бугай. Шуңа башлык—гауляйтер... Һитлер Карл галиҗәнапларын үзе димләгән ди бит!

Йосыф Әкрамның әлеге сүзләрен ишеткәч, артына утыра язды Хабул. Тузга язмаган үзгәрешләр булды микәнни шулай сугыш кырында?.. Аның туган-үскән җирләре дә немец итеге астында калды микәнни? Инде анда немецтан хаким-башлыклар да куйганнармы?.. Ярый әле, тел бистәсе үзе дә аңлашмыйча, кол ирне берникадәр тынычландырырлык сүз өстәде:

—Сугыш чыкканчы ук корган ниятләрендә гауляйтер иде инде Карл әфәнде. Хәзер ничә еллап сәфәргә әзерләнә. Үзенә тугры вассаллар җыя. Иншалла, күңеленә ятса, сине дә читкә какмас. Булдыклы кешене таный, гауляйтер! Иҗтиһадлы бул, олан!

Моннан да көлкелерәк фаҗига табылыр микән? Немецны «Сугыш Алласы» уты белән кыйраткан Хабул хәзер аңа колга әверелеп, өенендә ята. Нәсел атларын карый. Шнель, шнель, Хабул, тизрәк кыймылда! Гауляйтер юртакларын ныграк назла, ялларын шәбрәк тара. Корсак хакын шулай вөҗдан сату исәбенә түлә син. Бәлки хуҗага ошасаң, Йосыф сыман управляющий да ясап куяр әле үзеңне.

Хабул дәрвиш сыман үз-үзен бик еш кыйнаса да, барон йортында тормыш һаман бер эздән ага бирде. Әсирләр сыер саудылар, дуңгыз симерттеләр, йорт-кура җыештырдылар, тегермән тарттылар... Хабул үзе атларын карады. Әмма март башында, тамчылар тамып, кояшка рәхәтләнеп арка куйган бер мәлдә, өсләреннән котырынып җил-давыл, һәлакәт узды боларның.

Иртән, әле аякланып кына килүләре иде, дисбесен тотып, үтә борчулы Йосыф Әкрам килеп керде:

—Ләхәүлә, ләхәүлә, кардәшләр! Йортка кайгы төште. Яу кырында Карл әфәндeнең улы һәлак булган. Матәм! Берүк тәртипле күренегез, күзгә-башка бик чалынмагыз. Ходай күрсәтмәсен, бәлагә тарымагыз, мөселман мәет чыккан җирдә үзен ничек тотарга беләдер? Ләхәүлә, ләхәүлә!

Машиналарга утырып та, атлы таратайкалар белән дә, җәяү дә боларга байтак кеше килде. Керә тордылар, чыгып үз тарафларына юллана бардылар. Байтак хәрби ир баскыч инсәләренә тезелеп Карл фон Ницше белән сөйләшә-сөйләшә төрепкә кабызды, сигара тартты. Әмма һәркайсының йөзе караңгы, күзләре боек иде. Күрәсең, немец угланны югалту җиңелдән

булмагандыр. Яу кырында кеше гомере өзелүгә әрнү—дошман өчен дә, үз арандагы кешеләргә дә бер үк төрле кайгы сөременә уралу икән ул. Мондый матәмнен милләте, чин-дәрәҗәсе булмый икән шул, дип боегып уйлап куйды Хабул. Хат-хәбәре булмагач, үлгәндер, дип Түрештә дә анын өчен яшь түккәннәрдер инде, Ходаем...

Матәм сагышыннан талчыгып, барон йорты бәлки изрәүгә дә талган булыр иде. Кичен сон гына, көндәгедән зур-зур каплар күтәреп, кухнядан чечен Шамил кайтты. Агай-эне шатланышып, гөрләп гадәтенчә калдык-постыкка ябышты. Идәнгә түгәрәкләнеп утырып, капларны бер кулдан икенчесенә төртеп йөртә, һәркайсы нәфесенә ятканын сайлап алып согына башладылар болар. Сүз, гәп тагын да көчәя төште. Искәртергә Йосыф Әкрәм дә, хатыны Һашия дә күренми, хөррият!

Тик көтмәгәндә ишек ачылды һәм... Фрау Һильда килеп керде. Хуҗабикә кара күлмәктән, яулыктан... Кергәч тә, бер мәл бик аптырап кушылмаган мәҗлес ясаучыларга текәлеп торды, ә аннары калтырана барып, әче, черелдәвек тавыш белән «Русиш-Швайн!» дип кычкырды. Ул әсирләр өстенә карчыга кебек җилләнеп очып килеп, кулларындагы ризыкларны бәреп төшерергә, капларны типкәләргә кереште. «Швайн!» дип янә яман кычкырды ул һәм Шамилнең янагына сукты. Аннары ничек керсә, шулай тиз генә югалды озын буйлы, матәм киемле фрау Һильда. Әйтерсең лә, хас та яшен ташы булды бу...

Ә шартлавын озак көтәргә туры килмәде. Бәреп, шап итеп ачылган ишектән башта ыргылып ике зур бурзай килеп керде, аннары утка чагылып, күзлек пыялалары ялтырады. Болар җан өшеткеч ниндидер ят ерткыч күзләренә дә тартым иде... Юк, кеше икән, чөнки әсирләрнең бәгырен куыра торган «фас!» командасын бирде бу... Этләр бүлмәдәге кешеләргә ташландылар, аяклардан, куллардан, муеннардан каптырдылар, котырынып тәннәрне умырдылар. Җан өшеткеч акыру-бакыру китте. Әмма кинәт адәм илерүләрен томалап, кызганыч итеп эт чинап җибәрде. Тешләрен ыржайтып Хабул өстенә сикерергә җыенган бурзай моны сизеп катып калды, шундук җыерылып чинаучы ягына ыргытылды. Күзләрен монын артыннан йөгерткән Хабул шунда гына хәлгә төшенә алды. Озын, кин түшле Хөрмәт имән табурет белән эткә сылаган икән. Башына эләккән күрәсең—әллә һушын җуйган, әллә үлем белән үк тартыша—чиный-чиный идәндә бәргәләнә куркыныч җанвар. Ә Хөрмәт инде янә, яннан селтәнеп, үзенә таба ыргыган бурзайга сугарга җыена. Акырып, шашып үз телендә ямьсез сүгенә, күзләре кара күмер булып яна Хөрмәтнең...

Әмма бүлмәдәгеләрне янә бер аваз—наган шартлавы сискәндерде. Хөрмәт кулындагы табурет, ычкынып, үз юнәлеше белән очты. Җилкәсенә сикергән эт белән бергә Хөрмәт тә гөрселдәп идәнгә ауды. Шундук гәүдәсе астыннан кан бөркеп чыкты...

Әсирләрнең һәркайсы төрле якка таралышты, посты. Идән уртасында наганын күтәреп Карл барон тик үзе торып калды. Ул шартларга торган граната сыман баскан урынында бөтерелә, күзлеге аша зәһәр чәчә һәм әле тегесенә, әле монысына наганын төзи. Кем башына житәр тагын бу газраил? Ходайның рәхмәте, нәкъ шул чакта ачык ишектән алпан-тилпән килеп өстенә ят күлмәк-ыштан элгән Йосыф Әкрам килеп керде:

—Туктагыз, Карл әфәнде! Зинһар атмагыз. Кеше жанын кыймагыз, тынычланыгыз, Карл галиҗәнаплары!—дип кычкырып, ике кулын кушырып, намазга чүнкәйгәндәй Бароннын аякларына егылды. Фәсле башын, җилкәләрен калтыратып әле һаман инәлде карт:

—Сез бит шәфкатьле, мәрхәмәтле җан. Ходай хакына, пәйгамбәр хакына! Үтенәм, кан коймагыз, Карл барон!

Ниһаять, хужа наганын төшерде, коралны кобурасына тыкты. Һаман да Хөрмәт өстендә ырылдап яткан этне үзенә чакырып алды һәм барысын да янә сискәндереп төркичә сүз катты ул:

—Юкка, заяга хак гамәлдән аердыгыз бән катыйльне, Йосыф бәк... Көчеккә тормас адәмнәр болар!

Карл фон Ницше шуннан соң башын элеккечә, һавалы тотып ишеккә юнәлде. «Төркинең телен белсә дә, ир-атларын эткә дә тинли алмаган адәмнән нинди гауляйтер чыгар иде икән?» дип нәфрәтләнеп төкереп куйды Хабул. Башка әсирләрнең күз карашларында да зәһәр чаткылар ялтырый иде.

Тынлыкны ватып, Йосыф идарәче кол солдатларны иң зәһәр сүзләр белән әрләргә керешер, оялтыр, хурлар дип көттеләр. Хакы бар. Барон утарына аларны үзе алып кайтты... Өйдәге матәм хакында ул алдан кисәтте. «Игелексез оланнар, имансызлар!» дип кычкырырга хокукы бар картның... Тик, ни гаҗәп, бу диндар—тәкъва кешедән ялгыш кына да бер каргыш әсәре чыкмады. Идәннән күтәрелгәч тә, фәсен төзәтеп куйды, күкрәк кесәсеннән дисбесен чыгарды һәм шунын төймәләрен тартырга керешү белән бергә, салмак кына сүзләрен дә тезеп китте:

—Әй, кардәшләр, хәдисләрдә язылган шул, олы мәет үзе белән кече мәетне дә ияртер, диелгән. Хак сүз булуына үзегез инандыгыз инде. Ходай язганнан без дә аралана алмадык шул... Инде азагы гына хәерле була күрсен, оланнар. Мин сезнең хакта Аллаһыга ялварырмын. Хәзер корбанны, Хөрмәт угланны, мөселманча кадерләп җирләү хәстәрен күрик!..

## XIX

—Галиәсгаров!

Хабул сискәнеп китте. Кем кычкыра? Кайда ята ул? Немец барагындамы... Бюргер утарындамы... Әллә соң ракетчиклар арасында булып, бүтәннәре тик бастырулы төш кенәме? Ир, ниһаять, йөзтүбән яткан килеш башын борды. Таныш йөз... Заһитов икән. Тагын особистлар җәфалар инде...

—Энекәш, сүзем бар,—диде журнал тоткан майор. Күрәмсен, ул тагын тоткыннарны барлап йөри.—Сидоров белән син генә түгел, мин дә сөйләштем. Юкка чиргә сабышмагансың, энем, хәлең бик простойдан түгел икән шул. Тегеләй итәргә дә, болай итәргә дә була, ди бу иптәш. Анлыйсынмы, ишарәсен?

—Анлыйм, Давыт абый,—Хабул «Смерш» әфисәренең бәгырьсезлегеннән куырылып куйды.—Тик мина котылып кайтырга кирәк. Минем тапшырасы әманәтем бар. Командир гозере солдат өчен закон бит, Давыт абый.

—Әманәт—зур нәрсә, анлыйм,—дип баш какты Заһитов.—Командир әманәтен үтәргә җыенгансың икән, мин дә читтә калмам, энем.—Заһитов Хабулнын җилкәсенә сугылып алды, янә көлемсерәп торган, хушкүнелле абзыйга әйләнде.—Сидоров белән табыннарда утырган бар анысы. Бик начар егет түгел. Синең хакта тагын бер сүз катыйм әле, алайса...

Заһитов мылтыклы сакчыларын иялтеп китеп барды. Әмма Әстерхан татарынын сөйкемле шәүләсе Хабулны уйландырып калды. Үзе дә юньләп анламый, нигә бу кеше төрек Йосыф Әкрам белән янәшә басты соң әле? Каян килгәннәр иш янына куш? Берсе әфисәр, команда бирә, икенчесе байга хезмәтче, әмер үти... Берсе мәгърибтән, икенчесе мәшриктән аларнын. Әмма Хабул өчен Давыт та, Йосыф бәк тә бертигез якыннар. Икесе дә якты, магнитлы, җылы кешеләр болар. Тагын ничек атарга була әле бу очраклы танышларны?.. Әле сугыш чыкканчы ук, Псковта хезмәт иткәндә, бер карчыкның бозга таеп, кулыннан чәчелгән әйберләрен җыярга булышкан иде Хабул солдат. Кортканы иплэп кенә күтәреп торгызды, өстен какты,

кәрзиненә берәм-берәм чәен, шикәрен, икмәген юллап салды, тәгәрәшкән алмаларын җыйды. Әбинең яулык астыннан шуышып чыккан ак чәчләрен, йөзен, нурлы көрән күзләрен шәйләп шикләнгән иде шул. Маржа әби түгел бу...

—Ыспасибы, сынук! Бух даст здорови,—дип карчык телгә килгәч, инде үзе ярып салды:

—Һәй, әбекәй, Ходай исәнлек бирсен, диген!

Әлеге әби каршындагы шинельле, ачык йөзле яшь кешегә сөенеп карап торды, кинәнеп, кычкырып әйтте:

—Әй, балам, үзебезнең кеше икәнсең ләбаса!

Хабулның хәлләрен белеп, әллә никадәр теләкләр теләп озатып калды аны әбекәй...

Урыс шәһәрендә милләттәшен күреп кинәнгән карчыкның хисләре үз вакытында ничектер сәеррәк, ятрак тоелса да, дөнья казанында кайный-кайный аларның кадерен тулырак тоя башлады Хабул. Тел-лөгать, рух, күңел кардәшлегенә ия булган кешеләр бер-берсен ныграк аңлыйлар, адәмнәргә хас шәфкатьлелек, миһербанлылык тойгысын ныграк ачалар икән. Нәкъ шул сыйфатны олылаганга, Хабул күңелендә Давыт әфисәр белән Йосыф бәк янәшә басканнар да шул. Әле Минач абыйсы да шулар тирәсендә тора түгелме соң? Боларны ничек атарга дип аптырама син, Хабул. Псковта күргән әбекәй кебек сөенеп кычкыр. «Әй, абзыйлар, сез бит үзебезнең кешеләр!» диген. Һәм курыкма, бу һич тә чит кавемнәрдән читләшү, ераклашу түгел, ә адәмнәрнең үзара оешу, туганлашуын гына аңлата. Борынгы пәйгамбәрләрчә кеше кайгыртып гамьле, саваплы яшәү әмәле бит бу! Мәхшәр кичереп, Хабул менә шул хакыйкатьне ныграк таный, үз эченә сеңдерә барды.

Әйе, уйланырсың шул. Карл фон Ницше кешеләренең әлеге гаугалы төндә үк тоткын солдатларны кырга алып чыгып атуы мөмкин иде. Йөзәрләгән әсирне газ белән томалап, крематорий миченә ташлап һәлак иткән җирдә 9-10 азиат затын атып, җир белән каплап кую җинаятьме? Яисә боларны яңадан әсирләр лагерена илтеп ыргытсалар да, каршы сүз әйтүче табылмас иде. «Ләббәйкә, гауляйтер!» Тик Йосыф идарәченең хәлне ничек җайлавын бер Алла үзе генә беләдер. Тәкъва картның Ходай исеме белән ялваруы аркасында бит икенче көнне таң белән һәркем үз эшенә китеп барды. Бары чечен Шамилне генә кухняга үткәрмичә, дуңгыз абзарын чистартырга җибәрделәр...

«Смерш» капитаны Сидоров фильтрация лагере тоткыны Хабулга Карл фон Ницше һәм аның әсирләргә мөнәсәбәте, йорт тормышы хакында әллә никадәр сораулар биргәч, ниһаять, бик сәерсенеп әйтте:

—Син, Галиаскеров, төрки туганнарың белән бер тапкыр да качарга омтылмадыңмы? Сез бит совет солдатлары. Үзең исә «Сугыш Алласы» мәргәне, катюша ракетчигы. Илгә һәлакәт янаганда, тирес чистартып яткансың. Нинди патриот син? Теләгәндә, качып китеп, партизаннарга кушыла алыр идең бит...

Нәрсә дисең Хабул? Сидоров тикшерүче үз кыяфәтенә, асылына туры килгән сүзләрне әйтә. Уйланмады түгел, бу хакта да еш уйланды инде тоткын...

Август азакларында җиргә эңгер төшеп көз бәйләнә башлагач, Хабулның күзенә аҗаган уты ешрак чалына башлады. Тик шунысы гына гаҗәп, болытлар яңгырныкына, бозныкына тартым түгел. Аксыл сыртлы, каурый җилкәнле һәм кибәннәргә охшашлар. Шулай булса да, өсләрендә әледән-әле яшен камчылары уйнап китә. Гөрелтесе дә, шартлавы да юк үзләренең. Нинди Ходай могҗизасы соң бу?

Ат сарае ышыгында тәмәке көйрәтеп, күкне күзәтеп торганда Хабул янына Йосыф бәк килеп басты:

—Сталин килә, олан. Яшеннәре белән килә!

—Йосыф бәк, бу—сугыш утымыни?

—Шулайрак шул. Немецның эше харап. Хак Тәгалә тугры колларын аясын!

—Йосыф бәк, әсирләргә дә ярлыкау булмасмы инде?

—Хакимнән түгел, Ходайдан, вөжданыңнан ярлыкау көт, олан! Әсирлек сынавын Аллаһ үзе биргән бит сиңа. Язмыштан узмыш юк. Качып та котыла алмыйсың. Кем үз-үзеннән кача?—Йосыф идарәче зур күзләрен текәп Хабулга карап торды, Ю-у-к, кача алмыйсың, олан! Кая качарсың син? Кемгә барып, яклау таба алырсың? Кем сине аңлар? Телең дә, сәманың да юк. Качсаң, харап кына булачаксың син. Атарлар, таптарлар...

—Йосыф бәк, тире саклап яшәү дә егетлек түгел бит. Гөнаһны юу әмәлләре дә бардыр.

—Сталинга тугрылыгыңны кеше үтереп расламакчы буласыңмы? Кан белән юмакчысыңмы? Тик, олан, уйлан! Үз жирең, үз илең түгел бу. Шәһитлек кылу да соралмый синнән бу ят, чит Алман жирендә. Аннары шуны да исәплә син. Иленә каршы корал күтәрмәдең, сер сатмадың. Ходай кушып, кешелегеңне дә саклыйсың. Тагын нинди гаебең бар? Түз! Вөжданың саф булса, гаеп атар кеше булырмы сиңа?

Шулай тәкъва карт сабыр акылы белән Хабулны чарасызлыктан, дуамаллыктан, гыйсъян утыннан саклап калды. Ә «Сталин яшеннәре» һәр төн саен ешрак яшьнәде. Хәзер таң ягындагы кызыллыкны әсир солдат үзе дә авиаһөжүм, яисә катюшалар залпына юрый. Ә беркөнне әлеге «яшен ташы» барон йортына ук төшеп шартлады.

Хабул атларның аякларын яздыртыр өчен, көтүне болынга алып чыкты. Байтак вакыт юртакларны чирәмле уйсулыкта жилдерде. Йөреп ачыкканнар баһбайлар, суны да чиләкләп чөмерәләр. Сызгырып кыстыйсы да түгел. «Пегас» катына сугарырга дип килсә, янында хужа кеше—Карл барон үзе басып тора икән. Күнеле бик нечкәргән бугай моның. Түрештәге юләр Ибрай сыман, үзалдына мыгыр-мыгыр нәрсәдер сөйләнә. Атны башыннан, ялларыннан сыйпый. Ялтыр перчаткаларын салып ыргыткан әфисәр. «Салмыш бугай бу»,—дип уйлап куйды Хабул. Бәладән баш-аяк, исәрдән ераграк булуың яхшы...

Башка эшләр табып сарайның икенче очына юнәлде. Байтак вакыт шунда әвәрә килгәч, «Пегас»ның сугарылмавын хәтерләде ул һәм сулы чиләк күтәреп янә ат янына атлады. Шөкер, хужа киткән икән.

Сәнәк күтәреп синнеккә килеп керсә, үз күзләренә үзе ышанмый торды Хабул. Карл барон аяк-кулларын тәртипсез ташлап печән өстендә ята. Йоклый дияр иден, авызыннан күбек чәчелгән... Исереклек галәмәте генә түгел бу, хәтәррәк нәрсә, дип куркып уйлап алды ир. Нишләргә? Фрау Һилдага әйтсә, кайнар хатын аны-моны тикшереп тормас, башына житкәннәр, дуңгыз урыслар, дип үзенә ябышыр. Хабул Йосыф Әкрам бүлмәсенә чапты.

—Әй, олан, шул гына житмәгән безгә!—дип сыкранды Йосыф идарәче.—Үлгәнме? Аңсыз гынамы?—Һәм җавап көтмичә әсир солдат артыннан йөгерде.

Йосыф бәк жансыз гәүдәгә кагылып, йөзенә баккач та сыгылып төште:

—Хужабыз дөнья ташлаган, олан. Үз-үзенә кул салган, мескенем.

—Йосыф бәк, кул салган дисең дә, янында наган-фәлән күренми бит. Элмәк тә юк. Ялгыш нәтиҗә ясамыйсыңмы?

—Һитлерны белмисең шул, олан. Иблис сыман булып, яраннарына үзе гыйсьян уты салды. Инде җиңмәгәч, боларга үзе үк газраил булмакчы. Агулы төймәләр, куыклар өләшкән. Аңладыңмы? Якасына яшерелгән цианидны кабып үлгән барон. Адәм үз заманы, үз көне үткәнен белсә, Аллаһтан әмер көтми, үзе әҗәл чакыра, олан...

Гауляйтер булырга йөргән хуҗасының үлемен Йосыф Әкрам тетрәнү белән кичерде. Аерым серләшкән вакыттагыча, Хабул алдында дөньясын ачып салды:

—Әй олан, инде монда үземә сыеныр урын, картлык тынычлыгы табармын дип уйлаган идем. Буламы соң? Сталин дөньяның астын-өскә китерә инде. Хәерче булып, янә Төркиягә китеп котылсаң гына... Ходай нәфесен тыя алмаган бәндәләрен җәзасыз калдырмый шул, олан.

Хабул ныклап аңламады, Йосыф бәк әллә үзен әрли, әллә Гитлер өерен каргый иде...

Хабулның да үз хәле хәл, киеренке. Йосыф бәкнең «яка тешләү» хакындагы фәлсәфәсе миенең бер почмагына кереп утырды. Уйга кергән алдыңа чыга ди. Хабул ат сараеның аулак бер почмагында кием-салым төргәгенә тап булгач, кызыксынып әфисәр кителенең якасын капшады. Кулы төер тойды...

Ниндидер хисапсыз бер ашкыну белән яканы сүтте, аннан ак куык килеп чыкты. Моның белән чикләнмәде, гимнастерка якасыннан да шундый куык сүтеп алды. Этләр тырнагына эләгеп әгъзаларны талатканчы, җан әрнүләренә сызлануларга батканчы, куык кабып әҗәл кочагына төшүең хәерлерәк түгелме? Йоттың—вәссәлам... Хуш, каргышлы дөнья! Этләрең белән кал...

Шулай уйлап, Алман күчтәнәчен үзе белән йөртә Хабул. Күлмәкнең ышанычы азрак. Чәй кәгазенә төреп чалбардагы сәгать кесәсенә үк яшерде. Ходайның рәхмәте, шуларны капшагач, аның җанына, күңеленә тынычлык инә. Дүрт аяклы, ике аяклы этләр кулында түгел, шөкер, үз кулында, үз ихтыярында аның гомеркәе. Сидоров бәгырьдә пычрак итекләре белән бик биемәсен әле...

Менә шул вәсвәсәле, кайнар чакта Заһитовка рәхмәт әйтми буламыни? «Нәрсә, әзи, Сидоров белән серләшеп туймадыңмыгызмы әле?—дип көлемсерәп Хабулны үрти ул.—Булмаса, арагызга керәм, сине яклап сүз әйтәм. Җитәр монда борча симертеп ятарга. Бар, авылыңа кайт. Командир әманәтен якыннарына җиткер. Югыйсә, рухы тынычсыз ятар аның»...

Әллә төш, әллә өн бу...

Ниһаять, «Смерш» тикшерүчесе капитан Сидоров аңа ярлыкау кәгазе бирде. Шул сәгатьтә үк өлкән сержант Галиәсгаров та туган ягына, гаиләсенә кайту өчен биштәрен асып станцага чыга ала иде.

Тик Хабул майор Заһитов янына җилдерде. Аның аркасыннан тау шуып төшкән кебек. Аяк-куллары богаудан арынган сыман. Күзләрендәге сагыш, моң ярасы да эреп юкка чыккан. Йа Ходай, ул ирекле, азат! Кеше өчен хөрриятьтән дә кадерлерәк тагын нәрсә бар бу дөньяда?..

Интендант Заһитов кешеләре фильтрацияләү лагереннән котылган гаскәриләргә юл паеклары бирәләр. Майор Галиәсгаровны чиратка бастырмады, үз бүлмәсенә алып китте.

—Котылуың белән! Синең өчен шатмын, энекәш!—дип ихластан җилкәсенә сугып алды.

—Давыт абый, мең рәхмәт! Догага өйрәнеп, гомерем буе Ходайдан сиңа сәламәтлек сорармын.

—Дога? Ә... дога! Изге эш. Догалы кеше хаталанмый, диләр. Үрән, үрән, энем!

Заһитов эше тыгыз булса да, милләттәшен чәй белән сыйлады, бирәсе нәрсәләрен бирде. Күчтәнәчтән дә мәхрүм итмәде. «Улына миннән куян күчтәнәче!» дип шоколад тоттырды.

Эчендә яшәү чаткысы янып, янәшәңдә абзыең кебек якын ир-атлар торса, башыңа төшкән бәлане барыбер ерып чыгасың икән ул. Җинүчегә әҗәл куыгы нигә хаҗәт? Хабул үләксәдә казынган козгын кебек, немец генералының күлмәк якасыннан куыклар сүтеп алуы өчен оялып та куйды. Поездга якты уйлар белән утырды.

Әйдә, машинист, күмерне кызганма! Паровозыңны куа төш! Хабул үз өенә кайта бит!..

## XX бүлек

Иртәгә атнакич, Ходайга шөкер. Чиренә карамый, Сара һаман теркелди әле. Зәйнәп духтыр биргән даруларның да файдасы бик тия бугай. Шул төймәләрне су белән йоткач, тамактагы кылчыклар җуела, сулыш та иркенәя, гамь уяна. Шул чыбыркы булмаса, кортка түшәгеннән кузгала да алмас иде шәт.

Иртән аяклангач та, мунча турында уйлаган иде Сара. Юыну, чистартыну кирәк булыр бит... Тик бераздан уеннан кире кайтты. Чәршәмбе килешерме? Мунча көне—атнакич ласа. Иртәгә ягар ул аны, Аллаһ боерса!

Эш белән тегендә кагылгач, монда сугылгач та, карчыкның күңелен хафалану биләп алды. Юлга җыенгандагы кебек... Ниндидер шөгыле онытыла сыман... Тик нәрсә? Шуңа зиһене җитмәде һаман Сара кортканың. Чынлап, нинди эшкә кулы тими соң әле аның? Хабул янына сөртелде ниятләнгәне. Монда түгел. Ашаган-эчкән, тыныч кына ята карты. Йорт алдына чыкты, абзарга керде. Тик бу тирәләрдә дә түгел ымсынганы. Бәләкәй арт капканы эшереп бакчага чыккан иде, зиһене яктырып китте. Менә бит, менә эзләгәне! Кояш астында изрәп тыныч кына кыярын, помидорын, суган, бәрәңгесен үстереп яткан тере туфрак, җир, жиркәй ласа... Сара карчык җил белән саубуллашты. Ут белән хушлашты. Челтерәгән суга карап үз нәзерен әйтте. Инде менә Җир-ана каршында торып, аңа да соңгы сүзләрен ирештерер. Юк, юк, хушлашырга җыенмый Сара. Җир белән хушлашып буламыни? Җирдән килгәнбез, Җиргә китәбез бит. Җаныбыз бер рәвештән икенче тән рәвешенә күчеп, монда мәңгелек сәяхәттә, хәяттә яши. Кеше булып, тел-лөгать белән Җир-анага җан серләрен ирештерү өчен, иң уңай форсат бит сиңа, Бибисара!

Тик иң элек нигъмәтләре, сыйлары, тәгамнары өчен аңа рәхмәт әйтсен әле ул. Баласын яраткан шәфкатьле ана гына синең кебек бәндәсенә шулкадәр дә тәмле, искитәрлек мул ризыкларын бирә бит, Җир-ана, дисен. Кыр җимешен—кабарып пешкән икмәк—табын бөтенлеге, төенчек күрке. Игенче кулындагы ипикәйне татып карагач, бүренең дә авыз суы кузгалган бит: «Әйт, мажик, каян таптың мондый тәмлекәчне?» Тик комсыз бүре көткәнчә басуда түгел, мич каршында да ипикәйне тиз генә әвәләп булмый шул... Шулай да үз янында өтәләнгән бәләкәй Сараны әнисе кызгана. Күәшнәдән камыр алып, куна тактада баскалап кайнар табага тезә. Майда сызылып, эсседә чыжлап, ялкында алланып кабартма өлгерә. И, ул майда сызылып, ялкында алланып пешкән күперенке кабартма тәме! Аңардан кояш кайнарлыгы, җилләр рухы, туфрак сихәте белән бергә кырдан кайткан атаның кытыршы кул назлары да бөркелә сыман: «Ай, кызым, кабартмаң тел йотарлык! Тагын берне каптыр сана!»

Сыйлана башласаң, нәфес кабартма белән генә чикләнми анысы. Әнә бакчада яшькелт хәтфә булып әчкелтем-төчкелтем суган кыяклары күтәрелгән. Әрекмән, бака яфраклары арасына кереп качкан үрентедән

сары тәлпәкле яшькелт кыярлар асылынып тора. Ә карлыгандай җәелеп үсеп киткән куакта күзне кызыктырып помидорлар пешә... Түтәл-түтәл булып утырган кишер, шалканның да телдә, күздә калырлык үз тәмнәре, ямьнәре бар... Бакча җире дә Сара күнелендә муллык һәм җанга ямь бирә торган сихри почмак булып урын алган. Моның өчен дә Җир-анага рәхмәт әйтми ничек түзәсең?

Туфракка чәчкәннәр карасаң үсә, иҗтиһатына карап җимешен дә бирә. Әмма чалу, яланнарда үзең белеп, юмартланып та әллә ничаклы җиләкләр үстерәсең бит син, Җиркәй! «Ашагыз, балакайлар, сихәтләнегез, болары сәйәр күчтәнәче», диясеңдер инде, Олы Анакай.

И синең җәйге урманың, Җиркәй, ниләр белән генә сыйламый ул үз кунагын! Ерактан яшел дивар булып торган урман кешегә шом чыганагы бит. Аю, бүреләре белән куркыта. Ялгызың булсаң, агачлар арасыннан кети-кети уйнарга дип, мөгезле, ут күзле шүрәлеләр дә килеп чыгарлар сыман. Каядыр караңгы ешлыкта исә җеннәр, пәриләр оялагандыр кебек, яннарына килеп чыксаң, күз бәйләп адаштырып, кешелегеннән дә яздырып куярлар шайтаннар... Монда нинди тамак кайгысы калсын? Кискән агачыңны, сындырган минлегеңне арбаңа сал да сыпырт инде!

Тик эчендәге шик-шүрдән арынып, башыңны күтәрсәң, әнә яшел сәндрәдә сәйләннәрдәй булып чикләвекләр тезелгән. Юкә абзыйлары, каен апалары ышыгында үскән чикләвек куаклары—юмартның юмарты. Кешәнкәләре авыр, саллы, һәрберсендә дүртәү, бишәү, хәтта алтылап соргылт чикләвек баш төртеп тора. Чигүле, кара яшькелт яфраклар арасындагы кешәнкәләрне барлап күзләр биешә. Һу, Ходай бирсә дә бирә икән уңышны! Ә тәме?! Сусыл, майлы Түреш чикләвегенә эрбет, әстерхан, юнан чикләвекләре җитәме соң?

Чикләвектән соң берәм-берәм шомырты, баланы, миләшләре җитешә. Урмандагы «куян күчтәнәчләре»н Сараның үзенә дә еш ташыдылар. Сара, әни кеше булып, үзе дә нарасыена урманнан күп кайтарды бу күчтәнәчне. Моның өчен дә рәхмәт сиңа, Җир-ана! Әй, Җир-ана, күчтәнәчләреңне барлап хисләнүгә карап син Сара корткачы нини́дидер гуҗ, ашау турында гына кайгырткан зат дип уйлап куйма тагын. Син күңелгә рух та кертәсең бит. Кеше җанын шатлык-сөенеч белән сугарасың, ә кайчагында аны сагыш күленә дә чумырасың син. Адәм күңелен ямь, матурлык һәм иминлек чыганагы булып та яулыйсың бит син, Җиркәй. Анасын сагынган сабый кебек, кеше дә гел үз туфрагын җирси, туган төбәген юксына. Янәшәсендә һаман да яшел чирәмең, агар суларың, сайрар кошларың булсын аңа, күзләрен рәшәле тарафларың иркәләсен. Шул чагында гына кеше үзен гөлең кебек тамырлы, кошың сыман ирекле, пошидай гайрәтле итеп тоя бит, Җир-ана!

Матурлыгың, чагу бизәкләрең, салават күперендәгедәй мул төсләргә белән син рәссамнар, шагыйрьләр, көйчеләр тудырасың, Җиркәй. Алар кулы белән ясалган илаһи сурәтең кешеләрдә хиссият кузгата, яшәүне тагын да бизи, нурландыра. Кешене ашатып-эчертеп, киендереп кенә калмыйсың, сәҗдәгә китереп, аның рухын да сафландырасың бит, Җир-ана!

Сара корткага бүген генә килгән акыл түгел, күптән уйлана инде, яшәү тулысынча үзеңне җир белән бәйләү, аның кануннарына буйсыну, таләпләрен үтәү бугай ул. Болай яшәү һәркемгә кунактагы кебек матур, сөенечле гомер тәэмин итәр иде. Хәятта үкенечләр, аһ-зарларга да һичбер урын калмас иде. Тик бөтен бәла шунда шул, кешеләр үзләренең яшәү рәвешләрен Җир-ана, табигать белән яраштырып кормыйлар. Адәм—Һава балалары гомер-бакый бер-берсен рәнҗетеп, талап мал җыялар, үзара сугышалар, кан коялар... Адәм заты бер-берсен һәлак итәргә өйрәнгәч,

жаны корый, шәфкатьсезгә әйләнә. Кешегә түгел, баласына да наз, ярату, мәхәббәт әсәре күрсәтми ул. Ата-анасына да игелеге, кадер-хөрмәте югала аның... Ахыр чиктә кеше жирдәге тереклек каршында үз бәясен үзе жуючы, хәтта нәселен, үз-үзен ашаучы куркыныч жанвар рәвешен ала... Кайчан да булса, кошлар сыман бер-берсен санлап, ихлас аралашып дуслыкта һәм татулыкта яшәп мәгыйшәт корырга өйрәнерләр микән бу кешеләр, Жир-ана?

Әй, бу кошлар! Никадәрле яшәү итагате бар бу канатлы затларда. Бер-берсенә нинди саф сөю, ярату бар. Үз парларына ничек һәвәсләнеп жырлар башкаралар бит алар. Сандугачы да, сыерчыгы да, күгәрчене дә мәгъшукы өчен сайрый, гөрли, чутылдый. Ә аккош сөйгәнен югалтса, хәтта яшәүдән дә ваз кичә, күктән ташланып үз-үзен һәлак итүгә бара ул. Аккошның соңгы жыры барысын тетрәтә. Ходай юкка гына канат куймаган, күккә үрләтмәгән бу жан ияләрен. Жирдәгеләр, карагыз, күрегез, үрнәк алыгыз, дигәндер дә бит, кеше заты һаман жаһил булып кала шул...

Әй, Сара, жир белән серләшә башлап, яшьле күзләрең белән күккә багасың түгелме соң син? Жирдә тапмаганны күктән эзлисең түгелме?.. Шулай шул, жиңел сөякле, зифа сынлы канатлы жаннар Сара өчен гомер-гомергә изге булып килделәр. Менә ничәнче кат инде аның йөрәген күктәге бер тамаша талпындыра. Сентябрь азаклары иде, атлы арба белән колхоз механизаторларын ашатырга баруы. Ат тоягы дөпелдәүләренә кушылып, ашлы, чәйле бидоннары, савыт-сабалары зеңгелди. Ара-тирә арткы күчәрдә әвеш-тәвеш килеп барган тәгәрмәч жырлап ала. Шул «хорга» колак салгалап уйланып юл тотканда, хатынның колагына ниндидер ят, сәер авазлар чалынды. Нәрсә булыр бу? Арбадагы әйберләрне төзәткәләде, як-ягына каранды, юк, шикле әйбер күренми... Чү!.. янә, янә аның колагы сискәнде. Башын күтәреп күккә караса, хәйран калды Сара. Югарыда, бик югарыда торналар бөтерелә иде. Үзләре биниһая күп, галәмәт ишле. Айкалалар, чайкалалар кошлар. Төркем-төркем булып та оешалар, янә аерылып күздән жуелалар, һавада эреп төссезләнеп тә китәләр болар. Хас та күктәге күлнең жилдә кайнавы инде бу. Тик торна көтүенең болгану-тулгануына карамастан, күктә тоташ бер чыңлау, зеңгелдәү эленеп тора. Тарттырылган саз кылында көй сызалармыни? Йа Ходай, никадәр дә жанны айкаучы сагыш, моң кәркеше бу!

Сараның Түреш яланнары күгендә мондый хәлне гомерендә дә күргәне юк иде. Ул сихерләнеп атны туктатты, арбадан төште. Тагын нәрсә булыр икән, дип дулкынланып күккә бакты.

Хәер, кошлар буталышы озакка сузылмады. Гаскәриләрнең билгеле бер сафларга тезелүенә охшаган туплану, оешу хәрәкәте башланды. Менә, менә... башлыклары алга чыкты, өчпочмак рәвеше ясап иярүчеләре тезелә бардылар һәм торналар шулай бер тән, бер жан булып бердәм талпынып сәфәр дә башладылар:

—Торыйк! Торыйк! Торыйк!

Күз яшьләренә тыгылып, жаны кайнап уйлаган иде шул чакта Сара: «Әй, торналар, мине дә үзегез белән алыгызчы!»

Сара кортка туфракка тамган күз яшьләреннән оялмыйча, тарсынмыйча жиргә тезләнде:

—Илаһым Жир-ана! Ишет тавышымны! Гәүдәм сиңа күчкәч, минем жанымны да торна яисә аккош рәвешенә төр син! Мин дә шул кош кебек көчле канатлар үстерим, зәңгәр күкләргә күтәрелеп ерак сәфәрләргә чыгыйм. Кош юлларын күрим, илләр гизим, сөю-сөелү бәхетләрен татыймчы, Жир-ана!

## XXI бүлек

Түрештә кабер ачып, адәмне үлемнән коткарып калулары хакында белгән дә, ишеткән дә бәндә юк иде әле. Ясин чыгып, сине ләхеткә тыгып куйганнар, өстенә балчык ыргытканнар икән—мәетсең ни—тересең ни Нәнкир белән Мөнкир каршына торып басудан башка чара каламы соң? Һәм менә сиңа мә! Хабул белән Сараның төнге зираттан малайларын барып алулары авыл халкын тәмам телдән яздырды. Кайберәүләр хәбәргә ышанырга да базмады, карт-коры исә ләхәүләсенә ябышты.

Мәгәр Нәсибә духтыр шик калдырмады: «Малай исән!» Тик күпләп татлы чәй эчертегез һәм йоклатыгыз, дип кинәш, даруларын калдырып китте ул.

Табиб китүгә, чакыру-фәлән булмастан, Хабул йортына мөтәвәлли Шәрифулла килеп керде. Хәл-әхвәл сорашып, бераз тын алгач, ул сүзен болай башлады:

—Хәбибулла, Бибисара, җеназага үзем фатиха бирдем. Олан җан тәслим кылган иде бит. Тыны, өне беткән иде. Әсәре юк иде. Күзгеләр дә куеп карадым, тирләмәде ласа. Тән үлсә дә, җан чыкмаган инде болай булгач, Ходайдан фәрман булмаган... Ярар, оланны коткаргансыз. Хәерле булсын, алдагысы Алла кулында...

Мөтәвәлли бала ятагы каршына килеп ниндидер кыска бер дога укып бит тә сыпыргач, Хабул белән Сара җиңел сулап куйдылар, иншалла, динахирәткә бәйле тискәре гамәл кылынмаган болай булгач.

Шәрифулла урынын алмаштырып, өстәл янәшәсенә кунаклады.

—Хәбибулла, Бибисара,—диде ул янә җитди сүз әйтергә җыенганын аңлатып.—Оланга элекке исеме белән эндәшү хәвефле булыр. Сабыйны чир, өянәк, каһәрдән яшерү өчен исем алмаштыру пәйгамбәрләребездән калган гадәт. Безгә дә шул йоланы үтәү фарыз булыр. Каршы килмәссез бит?

Малайларының җиде ел өстендә йөрткән исемен алмаштырырга кушу ата-ана өчен үтә сәер бер шарт булып тоелса да, ил картына каршы төшмәделәр. Өйдә өстәл көйләнде, өч-дүрт кортка чакырылды һәм мөтәвәлли тәһарәт янартып балага исем кушу йоласын да башкарып китте. Ходайның рәхмәте, исем эзләп тә аптырамадылар. Шәрифулла мөтәвәлли догалар уку барышында Хабулга карап: «Ягез, исем-шәрифләрен ничек атыйбыз?» дигәч тә, ата кеше әйтте:

—Сугышларда йөргәндә Давыт исемле бик яхшы кеше очраттым. Давыт дип куйсак ярармы?

—Бик мәслихәт, Хәбибулла улым! Давыт атлы пәйгамбәребез булган. Мәкамле тавыш вә тимер-мәгъдән эшләре остасы ул. Малаеңа Давыт кушабыз,—дип янә догасына керешә мөтәвәлли Шәрифулла.

Яңа исемне рәсмиләштерү өчен авыл Советына Сара үзе барды. Әмма кәнсәләр башлыгы Гомәр Гаффарович гозерне ишетергә дә теләмәде. Беренчедән, икенчедән, өченчедән... дип сөйләргә яраткан рәис Сараны бүлеп монда да үзенекен тезде:

—Беренчедән, кешене терелләй җиргә күмдергән өчен мулла кисәген судка бирергә кирәк. Икенчедән, ниндидер хорафатка ышанып, метрика бозу ахмаклык, Сара Кыямовна. Һәм, өченчедән, Җәмилне Давыт ясап малайны ни хәлгә куясыз сез? Үртәрләр, хурларлар. Шулай түгелме?

Каян боларны исәплләп бетергән рәис? Әйе, Гомәр дөрес искәртә аңысы. Хәлнең бу ягы да бар икән шул, дип эчтән уйлап куйды Сара. Малайны үлемнән йолкып калу шатлыгыннан ул тәмам исәңгерәгән бугай шул. Тик сүздән кайтып, картлар гамәлен аста калдыру да килешмәс хәзер. Ана кеше үзенекен туглады:

—Бездәге закон исем-фамилия үзгәртүгә каршы килми бит, Гомәр Гаффарович!

Рәис бәхәсләшергә кыймады бугай, кулын гына селкеде. Сара язасы кәгазьләрен язып, тиешле суммада акчасын түләгәч, кәнсәләрдә дә малайның яңа исемен законлаштырып куйдылар.

Әйтәсе юк, пәйгамбәр аты ятышты Хабул белән Сараның яшен аткан малаена! Мәктәпкә төшеп ихластан укып китте. Әле күптән түгел генә Түреш мәктәбенә яшь белгеч булып килеп эш башлаган укытучы Мәрьям апасын бик яратты. Мөгаллимә дә Сара белән очрашса, Давытның тырышлыгын, зирәклеген мактап бетерә алмады. Шигырь сөйләргә дә, җырга да маһирлыгы бар иде аның. Бәйрәмнәр булып, мәктәпләр концерт куйса, Давыт халык күзендә иң шәп «артистләрнең» берсе булып үсеп китте. Кешене сокландыра, яраттыра торган ниндидер сөйкемле сөяге бар бугай. Дөрес, әле ул бәбкә генә. Тик текәп карый торган коңгырт күзләреннән яктылык, җылылык бөркелә. Ак, мөлаем йөзендә эчке уйлар сафлыгы, акыл чагылышы бар. Атасыныкына тартым җинел, төз, ашкынулы гәүдәсе дә аның нинди эшкә алынса да, шуны җиңел башкарып чыгачак унган кеше үсеп килүенә ишарәли. Давыт башлангыч мәктәпне бик яхшы билгеләргә тәмамлау өстенә ата-ана күңеленә дә бер борчу, кайгы әсәре төшермәде, һәркемгә тик шатлык, сөенеч нурлары гына чәчте.

Үсмернең тормыш көйсезлекләре бишенче сыйныфтан башланып китте. Хәзер аның мәктәп сукмагы да үзгәрде, укытучылары да алышынды. Аның уку төркеменә дә яңа ишләр өстәлде. Һәм Давыт Түрешнең аргы очындагы ике катлы агач мәктәптән бик еш сөмсере коелып кайта башлады. Дәресләрен әзерләргә дә авырлык белән генә тотынды. Иртән җиенып сабакка китүендә дә элекке ашкыну сизелмәде. Сара, билгеле, бу хәлгә үзенчә карады. Ата-аналар җыелышында директор Сәмига Хәйруллина искәрткән иде: «Белем алуның бу баскычында балада бик кискен психологик үзгәрешләр башлана. Уку предметлары күбәя, укытучылар ишәя. Болар барысы да укучы күңелендә җайлашу кыенлыклары хасил итәләр...» Ана Давыттагы төшенкелекне тик уку кыенлыкларына гына юрады. Тик чынлыктагы хәл үсмернең күңел көйсезлекләренә генә кайтып калмады шул. Тормыш мәсьәләсе такта алдында чишеләсе мәсьәләдән күпкә катлаулырак булып чыкты.

Түрештә эчкече Җамалны урыныннан бушатып, колхозга яңа рәис куйдылар. Каяндыр читтән Сәйфиев дигән кеше килде. Түреш халкы яңа түрәнең тәс-битеннән бигрәк корсагына шаккатты. Баш, аяклар күренүдән элек ишектә чүмәләдәй корсак шәрифләре пәйда була. Аннары гына зур борынлы итләч кызгылт йөз килеп чыга һәм кечкенә йөгерек күзләр чекерәеп бага:

—Исәнмесез, иптәш колхозчылар!

Халыкның гомергә мондый симез кешене күргәне юк иде. Цирк әкәмәте кебек булды бу. Техника паркына беренче тапкыр килеп киткәч, куркыныч җанвар сыман алпан-тилпән атлаган Сәйфиев артына карап тракторчы Гайфи әйткән икән:

—Временный персидәтел инде бу, егетләр...

—Временный түгел, беременный персидәтел диген,—дип төзәткән аны кулалмашы Салих.

Халык шаркылдап көлеп куйгач, комбайнчы Сәфәр тагын да өстәгән:

—Җамал колхозны эчкән иде, монысы әҗүҗ-мәҗүҗ кебек ашар инде, каһәрең...

—Җамал нәрсә? Челән бит ул. Бер стаканнан тәгәри иде. Ә бу чүмәлә корсак чиләге белән чөмерсә дә исермәс, едрит-кудрит...—ди икән тимерче Хәләф.

Шулай Сәйфиевка «беременный персидәтел» кушаматын тагып

куйдылар. Төртмәле телләр, кызык-мызыкка сусаган кешеләр ышыкта яна рәиснең ашау-эчүе хакында әллә ниләр сөйләделәр. Имеш, бер утыруда ярка билдәмәсен сыпыртып куя икән ул. Имеш, стакан тулы каймакны эһ тә итми суырып куя, ди бу гуж... Имеш, аракыны да бал бутап кына чөмерә ди Сәйфиев...

Ике ел рәис булып эшләп, өй өлгерткәч, Сәйфиев Түрешкә гаиләсен дә китерде. Хатыны да үзенә иш, симез, саллы ханымдыр дип фаразлаганнар иде, буламы соң... урман шүрәлесе кебек ябык, озын, килбәтсез хатын булып чыкты. Тавышы әче, чәрелдәвек. Хәтимә мәктәпкә урнашып дәресләр бирә башлагач, хәзер коридор зеңләп тора. Ә менә малайлары Ирек атасына тартым. Төп кебек юан гәүдә, салмак хәрәкәтләр... Кыл кебек тырпаеп торган чәчләр һәм астан баккан әрсез, чекерәеп торган күз—чынлап та, өлкән Сәйфиев курпысы. Сугар, төбен йомшарт, үскәнен кот һәм бу да нәкъ шундый ук «беременный персидәтел» кыяфәте алыр...

Менә шул рәис малае Ирек Давытның яшьтәше булып чыкты. Һәм болар Түреш мәктәбенең бишенче сыйныфында бер бүлмәдә утырып укый башладылар. Әлбәттә, аерым парталарда. Хәтимә Ирекка партадашны үзе сайлады. Улын сельсовет рәисе Гомәр Гаффаровичның ак башлы сыек гәүдәле малае Хәйри белән урта рәтнең өченче партасына китереп утыртты. Болар беренче көннәрдән үк ишәй белән кушай сыман булып киттеләр. Аларга тора-бара өч-дүрт елгыр малай мөрид булып иярде. Шулай сыйныфта, техничка Миләүшә апа әйткәнчә, «мушкетерлар бригаты» оешты. Әйтер дә шул, тәнәфесләрдә җыен чыкмаган тәртипсезлек шулардан чыкты, ызгыш, гауганы болар кубардылар. Әлеге мушкетерлар аркасында дәрескә кергән укытучы да байтак вакыт сабагын башлый алмый интекте.

Авылның иң зур түрәсе булган атасы кебек, Ирекнең дә сыйныфта лидерлыкка омтыласы килә иде. Укытучыларның да үзенә соклануын теләде ул. Һәм шул җирлектә рәис малае мөгаллимнәр мактаган укучыларны күралмады, алардан көнләште, җае чыккан саен сыйныф алдында аларны хурларга, мыскылларга омтылды.

Ирек Сәйфиевнең күңелендә көнчелек утын дөрләткәне Давыт Галиәсгаров булды. Бөтен яктан көнләште ул. Давытның такта янына басып тигезләмә чыгаруларына кызыкты. Аның мәсьәлә чишүләреннән дә, физкультура буенча ярышларда иң беренче булып «финишка» аяк басуыннан да, кызларның аның янында туктаусыз бөтерелүеннән дә, хәтта пөхтә киеменең гәүдәсенә килешле ятып торуыннан да көнле иде.

Көнчелнең йөзенә чыга, теленә йога. Ирек һәм мушкетерларның үзенә каравын Давыт күптән сизеп килде. Күлмәк аркасына акбур белән тәре сыздылар болар. Сумкасыннан үле тычкан килеп чыкты... Ярый әле йөрәге нык. Кыз-кыркын булса, шәрран кычкырып барысының котын алган булыр иде югыйсә...

Ә кышның салкын көннәренең берсендә озын тәнәфескә чыккач, Давыт каршысына яраннарын ияртеп Ирек килеп басты.

—Фокус-мокус күрәсең киләме?—ди бу мыскыллы елмаеп.

Ул ара янәшәсенә ак башлы куштаны Хәйри килеп кунды.

—Кая бардың?—ди Ирек моңа карап.

—Сал башына,—ди Хәйри.

Давытның күзеннән утлар күренде, арттан башына китереп суктылар...

—Кая мендең?—ди Ирек янә күз алдында маймылланып.

—Түбәсенә,—ди Хәйри авыз ерып.

Янә арт яктан Давыт башына йодрык килеп төште.

Давыт, аучылар боҗрасында калган юлбарыс сыман, каушап калды,

кемгә ташланырга да белмәде. Игътибарын тагын тегеләрнең пырдымсыз сүзләре җәлеп итте:

—Кайчан кайттың?

—Яна гына...

Тик сугучыга янак куеп тормады инде Давыт, кулын йодрыклап зырылдатып артына борылды. Һәм «мушкетерларның» төрле якка чәчелүләрен генә шәйләп калды ярсыган малай.

Телен тешләгән булса кирәк. Тик авызында кан булса да, төкермәде Давыт. Гарьлек, ярсу һәм тагын әллә кайсы йөрәк утлары белән бергә аны да эчкә йотты. Рәис малае өстеннән сүз әйтсә, укытучыларның шым булуын яисә Нәгыймә Харисовна сыман, «кеше өстеннән әләк белән йөрмә!» дип үзен хурларга керешүләрен Давыт белә бит инде. Һәм мона тагын бер кат ышанды ул.

Тел дәресендә Нәгыймә Харисовна төрле фигыль формаларын кулланып «Минем гаиләм» темасына бәләкәй генә инша язарга кушты. Җиңел генә әйтелсә дә, шактый авыр шөгыль бу. Хикәя фигыльнең өч заманы булсын, шарт фигыль булсын, боерык фигыль булсын... Тагын нинди фигыль бар соң әле? Ә... Ярдәмче һәм кире фигыльләр. Давыт шуларның һәркайсын кертеп җөмләләр корып ятканда, Ирек инде кычкыра-кычкыра кулын күтәрде:

—Апа, апа, мөмкинме?

—Йә, Сәйфиев, укып җибәр! Балалар, тыңлыйк, Ирек үз гаиләләре турынданиләр язды икән?

—Апа, моннан укыйммы, тактага чыгыйммы?

—Такта янына чык, Сәйфиев!

Ирек сал-сал батыр кебек лап-лоп басып такта янына чыгып басты, сыйныфка карап елмайды һәм кабарынкы куллары белән дәфтәрен кысып тотып укып китте:

—Безнең гаилә өч кешедән тора: әти, әни һәм мин. Минем әни Хәтимә Кәлиевна—укытучы. Аның әтисе следователь булган. Бик күп бандитлар, шпионнар тоткан. Минем әти Мәхмүт Сәйфиевны һәр кеше белә. Ул колхозда председатель булып эшли, колхозчыларга әмерләр бирә. Ул кушканнарны барысы да үтиләр. Унны бетергәч, мин дә институтка укырга керәчәкмен, әти кебек председатель булачакмын.

Ирек дәфтәрдән күзләрен алды, «Йә, ничек?» кыяфәте белән укытучыга текәлде. Мактау озак көттермәде:

—Ай, матур язгансың, Сәйфиев! Киләчәк заман хикәя фигыльне ничек яхшы кулланганcың син. «Институтка укырга керәчәкмен, әти кебек председатель булачакмын», дигәнсең. Менә, балалар, үрнәк алыгыз! Һәркайсыгыз үз алдына менә шулай Ирек кебек зур максатлар куярга өйрәнегез сез!

Нәгыймә Харисовна хозурланып Ирекка «биш»ле куйды һәм тегесе җиңүче кыяфәте белән партасына атлады. Укытучы:

—Йә, тагын кем укый?—дигәч, Давыт та кулын күтәрде. Ләкин укытучы күзенә әлеге дә баягы ак башлы Хәйри чалынды. Бу иншасын укыгач, Әлфия сүз алды. Купшы киемле, чәченә һәрчак ак бантлар тагып килгән матур кызның әтисе дә горурланырлык кеше икән. МТСта инженер дидеме? Ниһаять, Нәгыймә Харисовна Давытны да күреп алды:

—Йә, Галиәсгаров, син гаиләгез хакында нәрсәләр яздың?

Давыт партасыннан торып иншасын укырга теләп авызын гына ачкан иде, Ирек бөтен бүлмәгә шаулатып кычкырды:

—Нәрсә язсын ул, апа! Анасын персидәтельлектән куганнар, әтисе пленный аның. Аларда язарлык кеше бармыни?

Ак баш Хәйри һәм тагын берничә «мушкетер» хихылдап көлде. Тик бу

көчекнең төшләнеп өреп куюы кебек кенә, сыйныф күптән тын, өнсез тора. Һәм күбесе Давыт ягына төбәлгән. Мондый әче хурлаудан соң нишләр ул?

Чынлап та, Давыт нишләргә дә белми. Барып оятсыз Ирекнен бугазына ябышсынмы, елап бүлмәдән чыгып китсенме... Әллә соң иң әшәке сүзләр табып килмешәкләрнең үзләрен хурларга керешсенме? Давыт үзен һаман да аучылар божрасында калган чарасыз юлбарыс сыман сизеп, кызарып-бүртенеп партасына чүкте. Минутлар үтә торды...

—Йә, Галиәсгаров, көтәбез. Нигә укымыйсың? Укы!

Нинди сүз булса булыр, әмма ул мондый өндәүне һич тә көтмәгән иде. Ярсуына май сиптеләрмени?

—Апа, мин саңгырау түгел. Гаиләбезне хурлап торгач, нишләп укыйм мин?—диде ул сизелеп торган тискәрелек чәчеп.

—Кем хурлый?—диде Нәгыймә Харисовна үчегү тоны белән. Һәм нервыланып күзләрен уйнатып алгач, өстәде.—Ярар, мин ишетмәдем, ә син укы!

Әлфия ак бантларын уйнатып партасыннан күтәрелде:

—Апа, сез ишетмәдегезме? Ирек Давытның әтисе һәм әнисе хакында начар сүзләр әйтте бит. Моны бөтенебез ишетте бит инде!

Тик Нәгыймә Харисовна кызның нарасый карашын күрмәскә, ихлас сүзләрен ишетмәмешкә салышты. Көчәя барган ярсу белән һаман Давытка ташланды.

—Галиәсгаров, хәзер үк иншаңны укырга тотынмасаң, валлаһи, мин сиңа «икеле» куям. Бер... ике... өч... Юкмы? Укымыйсыңмы? Укучылар, бирегез әле ручка! Шул тискәре Галиәсгаровка «икеле»не чәпик әле без!

Укытучы үз өстәлендә ручкасы ятса да, кулын сузды һәм көтте... Гипнозланган сыман Ак баш Хәйри партасыннан торды һәм ручкасын тотып укытучыга юнәлде. Тик ни гаҗәп... Хәйри «мәгез, апа!» дип сораганын сузса да, Нәгыймә Харисовна аны кулына алалмый, бармаклары ток суккан сыман калтырый, үзалдына җыерыла иде. Аның йөзе дә кинәт үзгәреп китте, кызарды, бүртенде, күзләре дә зәһәрләнде.

—Ах, син, юньсез! Яшеннән калган нәрсә!—дип кычкырды укытучы һәм шундук ике куллап күкрәгенә ябышты.—Йөрәгем, ай... йөрәгем!—һәм Нәгыймә Харисовна йөгерә-атлый ишеккә юнәлде.

Дәрес бетәргә дә вакыт житкән иде инде. Менә-менә кыңгырау шалтырар дип көттеләр, парталарда утырып калдылар...

—Ну, Галиәсгаров, пәйгамбәр, күрсәтербез без сиңа моның өчен!—дип тынлыкта бармак янады Ирек.—Күрмәгәненне күрерсең әле син. Шулаймы, мушкетерлар?

—Каргышың—кара башыңа, Ирек!.. Имансыз!—дип әнисе ярсыганча, нәфрәтләнеп җавап кайтарды Давыт.

Һәм берничә көннән соң классны гына түгел, мәктәпне, авылны да таң калдырган бер фаҗига булды. Ял көнендә, яз житеп җир ачылганга сөенеп, Сәйфиев эреле-ваклы куштаннары белән сәйранга чыга. Бик ялынгач, малаен да үзләре белән ала ул. Мул сулы Шарлык буена килеп житкәч, учак ягып җибәрәләр, балык сөзәргә керешәләр. Эчү, сыйлану, гәп-көлеш кызып китә. Монда Сәйфиев малаена ни кызык? Тәм-томны кесәсенә тутыра да машиналар янына менеп китә бу. Өр-яңа «Газик» кабинасына утырып, рульне боргалый, тегесенә баса, монысын тарткалый кыбырсык малай. Һәм үрдә торган машина ахыр чиктә тышаудан арынып түбән тәгәри башлый. Житмәсә, кабынып китеп, мотор үзе көпчәкләрне куаларга керешә. Каушап калган малай нишләргә дә белми, аяк-куллары белән һаман идарә итү механизмнарында бутана...

Үрдән тәгәрәүче машинаның моторы үкереп җибәргәч тә, Сәйфиев эшне сизенеп ала, айнып китә һәм бар тавышына илереп кычкыра:

—Малай, рульне бор! Әй, малай!..

«Газик» машинасы елгага ыргып төшеп, суга бата башлагач та, артыннан өч-дүрт ир сикерә. Тик чумып-чумып, күшегеп эзләп, җәфа чиксәләр дә, кече Сәйфиевны кабинада табалмыйлар. Аны ургыган су үзе белән алып киткән була... Ирек Сәйфиевны тик бер атнадан соң, 15 чакрымлап түбәндә, елга борылышында, зирек тамырына эләгеп торган килеш табып алдылар.

Шул фаҗигадән соң бишенче сыйныф шым булды. Ирек әмеренә буйсынып, төрле ямьсезлекләр кылган «мушкетерлар» да, кырау суккан әрекмәннәр кебек сулып төштеләр. Мәрхүм Ирек Давытны «пәйгамбәр» дип мыскылларга теләгән иде бит... Әллә чынлап та изгеме, пәйгамбәрме соң бу Давыт?

## XXII бүлек

Тагын бер ел гомер узды.

Апрель азакларының кояшлы, җылы бер көнендә Сара Давытның башлангыч мәктәптәге укытучысы Мәрьям белән авыл кибетендә очрашты. Элеккечә җылы итеп серләшеп киттеләр. Аеруча Давыт хакындагы гәп икесенә дә кадерле, мөһим иде.

—Сара апа, без—кече мәктәпләр—зур мәктәпкә киңәшмәгә барган идек. Шунда мине Нәгыймә Харисовна тотып алды. Татар теле, әдәбияты укытучысы. Беләсезме икән?—дип сорады Мәрьям.

—Белмәскә тагын! Китапханәче булып эшләгәндә үк җыен кызыл, тозсыз сүзләр сөйләп кеше башын катырганы истә тора. Тик Давыт бер дә телгә алмый үзен. Тегесен сөйли, монысын мактый, ә Нәгыймә апасы хакында ләм-мим. Үзем дә аптырыйм. Тукайларны, Такташ, Кутуйларны укыта бит, ничек тәэссорат булмас икән?—Сара аптырап кулын тезенә чапты.

—Шул-шул менә! Дөрес сизенгәнсез, Нәгыймә Харисовна миңа үзе дә әйтте. Давыт мине яратмый, ди. Алай гына да түгел, Сәйфиев малае хәленә калудан курка икән. Каргышлы булудан шүрлим, анасы белән бер сөйләш әле, дип үзе миннән сорады, Сара апа.

Сара инде куш куллап бот чапты:

—Ай Алла, ишетмәсән, ишет! Ул Нәгыймә минем малайны колдун дип белә микәнни? Аннары мәрхүм балага Давытның нинди катнашлыгы бар икән?

—Сара апа,—диде Мәрьям шактый кыенсынуын сиздереп.—Сәйфиев хатыны Хәтимә чат саен улап йөри ди бит. Ишетмәдегезмени? Пленный Хабулның яшен суккан малае каргап үтерде улымны, ди икән...

—Монысын ишетмәдем. Ә персидәтель малаеның Давытка «анаңны эштән куганнар, атаң пленный синен», дип әйткәнен җиткерделәр. Малаеның теленә Хәтимә салганын аңладым инде мин, сеңлем.

—Шул сүзләрдән соң Давыт «Каргышын—кара башыңа!» дип әрнеп кычкырган да шул. Хәзер пәйгамбәр кушаматы такканнар, күзе каты, каргышы төшә дип шүрләп калганнар бит үзеннән. Нәгыймә Харисовнаның миңа сезнең белән сөйләшергә ялынуы да шул куркудан чыга бит, Сара апа. Үзегез Давытта ул-бу сизмисезме соң? Яшен суккан, өермә күтәргән, мәрткә киткән кешеләр турында төрлесен язалар бит хәзер. Экстрасенс дигән сүз дә чыкты...

—Ярар, сеңлем,—дип бу юлы куллары белән һаваны кисте Сара.—Юк белән баш катырмыйк әле! Мәктәп—фән, белем йорты ул. Аны гайбәт, хорәфәт оясына әйләндермәсеннәр!

Чебен куган сыман селтәнсә дә, әлеге сөйләшү Сараның күңеленә тирән сеңде. Мәктәп кебек изге җирдә үзләре, уллары турында ямьсез уйлар йөрүенә чиксез гарьләнде ул. Төшке ашка кайткан Хабулга да Мәрьям сүзләрен җиткерде. Башта ире чиксез гаҗәпләнде:

—Һе, Давытны пәйгамбәр диләрме. Каргышы төшүдән куркалар дисеңме? Ул юньсез Сәйфиев малае үз башына үзе җитте ласа. Безнең Давытның монда ни катнашы бар? Бер өйгәнгә һаман өяргә була диләр микәнни?

Ә бераз кашларын җыерып уйланып торгач, Хабулдан һич көтелмәгән сүзләр ишетте Сара:

—Ә нәрсә? Безне нахакка рәнҗеткәннәрне өчен Давыт пәйгамбәр тиешлесенә җәза җибәртә икән, Шәрифулла абзый әйткәнчә, бик мәслихәт, Сара. Ходай үзе беләдер. Мондый әйберләрне сугышта да күп күрдем инде мин. Гамәленә карап—хөкеме! Җан сафлыгын саклаганга исән калдым бугай дип еш уйланам хәзер. Ходайның бер рәхмәтедер инде бу... Менә шундый нәрсәләрне уйла да хафаланма син, Сара. Яклаучыбыз үсеп килә икән, безгә сөенергә генә кирәк!

Тик Давыт хакында кем нәрсә сөйләмәсен, Сара барыбер үз уенда калды. Җәмил булды ни, Давыт булды ни—барыбер шул ук бала инде. Исемгә карап кына җисеме үзгәрмәс. Ана үз сөяген белә ласа. Давыт та башкалар сыман ук гадәти җир кешесе булмый, кем булсын? Чикмәнле бәрәңге белән кара арыш ипие ашап үскән Хабул-Сара каныннан пәйгамбәр яралды ди. Көт! Көтә-көтә көтек булырсың...

Әмма тиздән үзләрендә булган бер вакыйга ананың уйлар җебен тәмам чуалтып ташлады.

... Иртән чәй эчкәндә Давыт күргән төшен сөйли:

—Мин үзебезнең зур бакчада чүп-чар җыеп йөрим. Иртәгә сөрәбез, чистарт, диде бит әти. Бер мәл күрәм, һавада самолет. Оча бу, оча, баш өстенә үк очып килде. «Эй, самолет, посади меня в полет!» дип кычкырам. Шуннан, әти, шуннан, әни, бу әйләнеп-әйләнеп төшә башлады бит. Валлаһи—төшә! Бакчага гына төшмәсен, чокыр-чакыр бит... Урамга, чирәмгә төш, дип кычкырам. Самолет, әллә ишетте, шулай итте дә, бакча буена төшеп кунаклады... Менә аннан хәзер бер кеше төшә. Погонлы, шәп киенгән бу. Әйтә миңа: «Син, малай, Түрештә Хабул Галиәсгаров дигән кешене беләсеңме?»—ди. Белмәскә, мин әйтәм, ул бит минем әти! «Давай, чакыр әтиеннe!»—ди летчик.

Мин, әти, сине дәшәргә дип бар куәткә өйгә йөгердем дә, уянып киттем. Әни уятты. Җәл инде, нишләп чакыртканын белә алмадым шул. Ачуланма әти!

Давыт шулай төшен тиз-тиз сөйләде дә, коймак бөгеп, чәен эчеп мәктәпкә сыпырды.

—Кара, малай, тырышып укы, укытучыңа каршы сүз әйтмә, кеше рәнҗетмә!—дип гадәтенчә нәсыйхәтен биреп озатты аны ана. Ата кеше исә, Давыт хикәятенә бирелгәнме, әллә уйларында башка берәр исәпме, байтак вакыт урындыгында кадакланган сыман утырды.

—Анасы, ишеттеңме, малай нәрсәләр сөйләде. Юк-бар төш түгел бу. Берәр хәбәр булмагае. Түлке нинди хәбәр икән? Тагын пленда булуны искә төшереп, мазага тиярләр микән?

—Төшне һәрчак яхшыга юрарга кирәк!—диде камыр кисмәге янында кайнашкан Сара кискен генә.—Хәзерге балаларниләр белән генә саташмыйлар. Тавык төшенә тары кергәндер, көяләнмә!

Малай төшен чәршәмбе сөйләгән иде. Җомга иртән үк Сара идарәгә китте. Берничә көннән колхоз чәчүгә төшә, кыр станында кухняны тергезергә кирәк. Казанын, савыт-сабаларын әзерлисе бар. Кибет, складлардан

продуктлар алыр өчен алдан ук накладнойларны яздыртып алу зыян итмәс. Сырт кашырга да вакыты калмас инде хәзер пешекче Саранын...

Идарә бүлмәләрендә тулганып йөргәндә, аны сельсовет рәисе Гомәр Гаффарович туктатты.

—Сара Кыямовна,—ди бу аһылдап, артыннан куып киләләр диярсең.— Кайда Хабул?

—Кайда булсын, эштә, техника паркында. Комбайн төзәтә.

—Шулаймы? Рәхмәт!

—Ә нәрсәгә ул? Берәр ашыгыч хәл бармы әллә?—дип пошынды хатын.

—Бар бугай шул. Югарыдан Түрешкә бер офицер килә, диделәр. Хабулны шуның белән очраштыруны сорыйлар.

Һәм рәис ашыгып үз мәшәкатьләре белән юлланды.

Саранын эче жу итеп китте. Малайның төше дөрескә чыга микәнни? Ходаем, хәерле гамәлләр генә булсын. Мөхлисов җомгасын гына күрсәтмә тагын... Аның каравы, сельсовет башлыгының хәбәре Хабулны һич гаҗәпләндермәде. Комбайн эченә кереп иләкләр белән маташкан чагы иде, эшеннән дә бүленмәде:

—Иртүк военкомат аякка баскан, сельсовет кешеләре өтәләнә, ә Мәскәү офицеры белән күрешәсе Галиасгаров уйлап та бирми. Вәт кеше! Бәлки башта веялкагыз астыннан чыгарсыз, Хабул иптәш?

Ниһаять Хабул чүкеч, ачкычларын күтәреп комбайн эченнән чыкты:

—Йә, ни боерасыз?

—Иң башта чистарынып, өс-башны алмаштырасы булыр, өлкән сержант Галиәсгаров!—диде рәис һәм мотоциклын кабызды. Утыр, бүген миңа кучерың булырга туры килә бугай.

—Каян килгән хөрмәт әле ул?

—Сюрприз!

Гомәр Гаффаровичның кабалануы бик урынлы булды. Хабул «егетләрчә купшыланып», кәнсәләргә кереп утырганнар гына иде, бина алдына авыл өчен ят «Джип» килеп туктады. Хуҗа кеше кунак каршыларга чыкты. Һәм менә бераздан шау-гөр килеп бүлмәгә хәрбиләр керде. Алдан район военкомы Шәмгунов атлый. Аның артыннан яшь, көяз капитан керә. Һәм менә тагын ишектә берәү күренә. Чалланган чигә чәчләре аның инде өлкән яшьтәге кеше икәнен раслый. Затлы яшел китель, зәңгәр чалбардан бу. Майор! Бәй, йөзе таныш түгелме? Җете зәңгәр күзләр... Җитди, хәтта шактый ук кырыс чырай... Кайда күрде? Кем соң бу? Сидоров... «Смерш» тикшерүчесе капитан Сидоров!... Теше арасыннан гына чыгарып, Хабулны «Галиаскеров!» дип атаган кеше.

Хабул үзе дә сизмичә солдатларча төз басты, үрә катты.

—Менә шул инде сез күрергә теләгән кеше, иптәш майор,—диде сельсовет рәисе Сидоровка карап.—Хабул Галиасгаров каршыгызда тора.

—Без танышлар!—диде майор һәм күрешергә дип ак, йомшак кулын Хабулга сузды. Ну, Галиаскеров, исәнме?

—Иптәш Сидоров, сез безнең Галиасгаров белән танышсызмыни? Гаҗәп!—дип аптырап калды Шәмгунов.

—Бу сугышта бик күп язмышлар бергә үрелде, Вахит Хазиахметович. Маңгайга маңгай бәрелешкән кешеләр дә байтак. Инде менә ташларны җыяр вакыт.

Майор җиңелчә генә Хабулның җилкәсенә кагылды, күзләренә карады:

—Өлкән сержант Галиаскеров, аптырап калдың бугай. Бу Сидоров нишләп әле мине эзләп Түрешкә килеп чыккан дисеңме? Сиңа әйтеп

өлгермәгән булсалар, сөенчегә өмет итәм. Сездә, «сөенче» дигән бик куанычлы сүз бар бит... Кыскасы, сина бүләк китердем, Галиаскеров. Зур хөкүмәт бүләге, «Ватан сугышы ордены» алып килдек без сина, герой... Йә, барып җиттеме инде?!

Менә, ниһаять, чынлап та Хабулга барып җитте. Орден! Тик ул моны һич тә көтмәгән иде. Шатлык хисе аңа берниндиәзерлексез китереп бәрде. Кинәт күзләреннән яшь атылды, бугазыннан үксү ымы ыргылды. Һәм Хабул барлык хисләрен, кайнарлыгын тапшырырга теләгәндәй Сидоровны кысып кочаклап алды:

—Рәхмәт! Чын күнелдән рәхмәт!

—Рәхмәт белән генә котыла алмассыз әле, өлкән сержант!—дип сүз катты военком һәм көлдереп күнелләрдәге киеренкелекне йомшартып җибәрде.

—Иптәш Гумер Гаффарович,—дип сүз җебен үзенең кулына алды Мәскәү кунагы. Менә без юлда үзара сөйләштек, киңәштек, сез ничек карыйсыз, иптәш Галиаскеровка орденны бүген үк халык алдында тапшыруны оештырып булмасмы? Клубта, мәсәлән...

—Ник булмасын, иптәш майор. Клубта оештырабыз! Авыл тарихында калырлык тантана бит бу,—дип кайнарланып җавап кайтарды рәис.

—Бик яхшы! Сез инде бу эшне үзегез башлап җибәрегез алайса. Мин үземнең ике тәкъдимемне генә әйтәм. Мәктәп укучыларын да чакырырга кирәк! Аннары рәсми өлеш беткәч, халыкка түләүсез кино күрсәтү мөмкин булмасмы? Мин өр-яңа нәфис фильм алып килдем. «Кеше язмышы...» Михаил Шолохов хикәясе буенча төшерелде. Төп рольдә кино йолдызы—Сергей Бондарчук. Бу кичәгә бик аваздаш булыр әлеге фильм. Йә, шуны эшлибезме?

Гомәр Гаффарович кичәне оештыру эшенең мондый аныклык алуына үтә канәгать иде һәм район хәрбиләре белән берлектә клубтагы мөһим чараны үткәрү хәстәрен күрә башлады. Янына клуб мөдире Хәсән дә йөгереп килеп керде.

Сидоров Хабулны җитәкләп кәнсәләрнең аулак почмагына барып урнашты. Фуражкасын салды, тәмәке кабызды.

—Башкалар ничектер, әмма мин үземне кеше күзләре белән күрергә гадәтләндем, Галиаскеров,—дип сүз башлады Сидоров.—Миңа кысадагы пыяла көзге кирәкми. Көзге—үз вөҗданым, үземне кеше карашы аркылы күрәм мин. Сөенеч тә, көенеч тә кешедәге чагылышым аша туа. Һәм туры әйтәм, минем синдә чагылган кыяфәтем һич тә матур түгел. Син мине еш каһәрләдең. Төшләреңә дә кереп, йокыларыңны качырганмындыр әле... Шулай, шулай, Галиаскеров, без бит ирләр, турысын әйтеп сөйләшик. Мин башкага исәп тә тотмыйм, вазыйфам шундый булды. Хәер, ил иминлеген, законны, тәртипне, кеше бөтенлеген саклар өчен каты кул, усал чырай кирәклеген сез аңладыгыз бугай, өлкән сержант? Сугыш, кан коелыш бик күпләрдә түбән хисләр дә уятты. Җиңү һәр кешедән Ватан алдындагы бурычын төгәл үтәүне таләп иткәндә генә яулана, Галиаскеров. Без бу сабакны шактый кырыс шартларда һәм бик күп хак түләп алдык бугай.

Сидоров элекке гадәтләрен ташламаган икән. Урыныннан торды, кысан булса да, йөреп алды, баскан килеш сүзен дәвам итте. Басып сөйләү—сүзне, кешене олылау, хисләнү галәмәте.

—Әллә никадәр кеше белән эш итеп, мин дә сине хәтерләп калдым, Галиаскеров. Катюшаны суга батырдым, дидең бит. Башта хәйләлисен дип уйладым. Аннары шундый корал тирәсендә Ставка таләпләрен үтәмәвең белән хәтергә кердең. Һәм онытмым дигәндә тагын искә төшердем бит әле сине, Галиаскеров. Катюшаны шартлату таләбе булгач, кырганнар гына. Сер саклыйлар, янәсе. Җавап бирүдән дә курыкканнардыр инде. «Сугыш

Алласын» тугандаш армияләргә дә күпләп озатканнар. Сугыш беткәч, хәтта музейга экспонат итеп куярлык әлеге БМ-13, БМ-31, БМ-8 корылмаларын табалмыйлар икән. Кино төшерергә дә кирәк легендар катюша...

Безгә задание бирделәр: катюшаларның төрле елларда чыккан төрләрен барларга, җимерекләрен сафка бастырырга, югалганнарын табарга! Менә шунда мин янә синең «Дело»ны архивтан алдым да инде. Туктале, мин әйтәм, ник син әйткән Днепр култыгыннан эзләп карамаска катюшаны? «Дубецкий вал» касабасы картада бар. Андагы военкоматка заявка җибәргәч, тиз генә әлеге син әйткән елга култыгына төшә торган урман полосасын ачыкладылар. Водолазлар алып очтык син әйткән җиргә. Таптылар, икенче чумуда ук таптылар «Сугыш Алласын». Трактор белән ярга тарттырып чыгардык. Төп-төзек! Могҗиза булды бу! Сугыш тарихына язарлык факт. Үзем өчен дә уйланырлык нәрсәләр күп монда...

Сидоров сүзеннән туктап, үз янына яшь капитанны дәшеп нидер сөйләшеп алдылар. Һәм күп тә үтмәде, әлеге әфисәр машиналарыннан алып кереп, майор алдына җинел кына төргәк куйды.

—Менә, Галиаскеров,—диде Сидоров төргәкне сүтә-сүтә.—Синең өчен кадерле ядкарь бу. Таныйсыңмы?—Һәм майор кулына фляжка алды.— Синең җиһаз бит бу?

—Минем фляжка бу! Сез аны кабинадан табып алдыгыз, иптәш майор. Шулаймы? Эчен ачтыгызмы соң?—диде Хабул, йөрәгендә көчәя барган дулкынлану галәмәтләрен сиздермәскә тырышып.

—Әлбәттә ачтык. Анда командир приказы ята. Синең кристалл сафлыкны раслаучы документ, Галиаскеров. Син командирның боерыгын үтәгәнсең. Өстеңә зур җаваплылык алуны раслау да бу. Сугыш хәлләрен инструкцияләр, боерыкларга гына сыйдырып булмый икән шул. Шәхси җаваплылык та бик кирәк экстремаль шартларда. Менә бу синең миңа биргән сабагың, өлкән сержант Галиаскеров.

Хабул сак кына үзе күп тапкырлар кулларында тоткан, кайнар иреннәренә тидергән, сулары белән сусауларын баскан фляжкага кагылды. Капкачын борды. Күгәрмәгән, каралмаган да, чын алюмин шул! Бармаклары белән эчкә тыгылып кечкенә кәгазь төргәген тартып чыгарды. Аны ике куллап җәйде. Һәм күзләренә Минач абыйсының таныш почеркы килеп сарылды. Саргая төшкән кәгазь кисәге зәңгәр күзле, мөлаем йөзле кешенең кул җылысын сирпегән, ипле, төзек тавышын ишеттергән сыман булды. Янә колак төбендә яңгыраган шартлаулар, пулемет, автомат тырылдауларын басып, политрук телгә килеп әйтә кебек:—«Бар, энем, машинаңны кабыз да полоса буйлап елгага сыптыр. Монда беребез үлү дә бик җиткән. Бәлки исән калырсың... Кайтсаң, минекеләргә дә сәламемне ирештер!»

Әй, Минач абый, дип сыкранып уйлап куйды фронтовик ир. Синең рәхим-шәфкатең аркасында мин бит исән... Синең хәер-фатихаң белән кырык үлем аша үтеп, авылга кайттым, өемдә утырам ласа мин, Минач абый... Хабул түзмәде, өстәлгә иелеп балалар кебек сулкылдый башлады. Үксү, яшь өере дулкын-дулкын булып, төер-төер булып агылды... Ниһаять, ир башын күтәрде, чыланган кульъяулыгын кесәсенә яшерде.

—Гафу итегез!—диде ул, күзләрен Сидоровка күрсәтмәскә тырышып.

—Оялма, фронтовик! Болар хәләл яшьләр.—Һәм майор үзе дә ничектер йотлыгып папиросын суырды.—Галиаскеров, мин синең рөхсәт белән фляжканы үзем белән алып китәр идем. Аны синең катюша белән бер экспонат рәвешендә музейга куярга ниятләдек. Каршы килмәссеңме?

Хабул ризалык белдереп башын какты. Бераздан Сидоров дәвам итте:

—Халык каршында бер-беребезгә эндәшергә туры килер. Мин сезнен исем шәрифләрне күңелемә нык сеңдердем. Хабибулла Харисович

Галиаскеров... Атың нинди мәгънә бирә икән синең, дип сүзлекләрдә казындым. Исемең фарсыдан икән. «Хәбиб»—белгеч була. Ә фамилияң катлы-катлы. «Гали»—гарәп телендә бөек. Ә «асгар»—кыйммәтләр. Бөек яисә зур кыйммәтләр... Кыйммәтле белгеч дип аңладым үзеңне. Димәк, асылың буенча бик шәп белгеч, һөнәрмән булып чыгасың. Дөресме?

Инде хәзер Хәбибулла Харисович, син дә мине фамилиям белән генә атамассың шәт? Рәсми булыр, килешмәс. Аннары яшькә дә күпкә өлкәнмен бит. Иван Ефимович мин. Урыс офицерлары династиясеннән. Анам ягыннан нәсел очым Суворовка барып тоташа... Ниһаять, кешеләрчә таныштык дисеңме, Хабибулла Харисович?

—Әйе, бу—безнең гомерлек һәм чын танышу. Минем караштa сез үзегезне сөенечле кыяфәттә генә күрерсез, Иван Ефимович,—диде Хабул һәм урындыгыннан торып ике куллап майорның кулын кысып торды.

## XXIII бүлек

Бу көндә пешекче Сараның кулы бер эшкә дә бармады. Җомга бер нәрсә дә ниятләмәгез, дия иде шул Шәрифулла мөтәвәлли. Мөэмин мөселманга бу көн—Аллаһ уйлары белән генә яши торган чак. Ходай ризалыгын алып, савaплар белән юаныр мәл. Җомгада күңелләрегез гел изгелектә генә булсын, дин-кардәшләр... Көне хатын ниятенә түгел, тәкъва карт әйткәнгә тартылды шул.

Идарәдә Гомәр үз хәбәре белән Сараны пошаманга салган иде. Кәнсәләргә нindидер ят машина килеп туктавын, аннан гаскәриләр чыгып баскычка күтәрелүен күргәч, инде йөрәге сыкрап куйды аның. Әфисәрләрнең Хабулга булган йомышларын нәрсәгә юрарга да белмәде ул, баскычка текәлгән килеш гасабиланып көтте: җитәкләп чыгаралармы, әллә үз аягы белән теркелдәп өйгә юнәлерме ир башы? Ничә ел Хабул хакында тәшвишле уйларга төшеп, энәләр өстендә утыра бит Сара: «Гайбәткә, чәйнәүләргә күнгән, Ходаем, инде казамат күрсәтмә Хабулга!»

«Пленда булган», дигән хәбәре Хабулның үзеннән алда кайтып, капкаларына дегет булып сыланды шул. Сара да рәислектән төшкән, ирнең дә авыз пешкән—кем ничек тели, ничек булдыра, шулай мәсхәрәләде инде аларны авылдагы әтрәк-әләм. Колхозга военкоматның списать ителгән автомашинасы кайткач, Җамал янына Сара үзе барып гозерләде: «Хабул әрмиягә алынганчы колхозда шофер иде бит, утырсын әле янә руль артына, Җамал Яппарович?»

Айнык сәгатьләре сирәк була торган рәис белән сөйләшүгә «күчтәнәч» белән килгәндә өметле буласы иде дә бит, әллә нигә яхшысынмады бит хатын. Элеккечә сүземне тыңларлар дип тә алданды бугай. Ә болай Җамал шешенке күзләре белән Сарага бер сөзеп карады да кулын гына селтәде: «Пленныйга руль ышандыра алмыйм, ә машина военный...»

Исән эшсез тора алмый, Хабул МТСка барып комбайнчы булып урнашты. Түрештән бер дистә чакрым ераклыгы Юашка исемле чуаш авылына китеп, арышын, бодаен урды, көнбагышын суктырды ир. Яңгыр яуса, ат җигеп өйгә кайтты. Йорттагы арбаны сырып Хабулның аты, Сараның сыер, бозавы, сарыклары хуш исле клевер, вика бөгә. Ир белән хатын исә болдырга кунаклап, таң атканчы тегесен-монысын серләшә, йортка, ниһаять яшәү яме иңүгә кинәнә...

Сара чуашлар арасында ире тынычлык тапты дип икеләтә сөенгән иде. Тик коры көннәр бик озакка киткәч, хәл белергә дип үзе Хабул янына юл тотты. Уракчылар бодай басуында төшлеккә туктаганнар иде. Сара камыл өстенә зур брезенттан табын ясап аш чөмерүче ир-атны күреп түгел, ә механизаторлар тирәсендә чүмеч, ипи тотып ак күгәрчендәй гөрләп торган

Пиннәрпине шәйләп телдән язды. Чынлап та ак күгәрчен шул бу. Бала итәкле ак зифа күлмәк өстеннән чигүле алъяпкыч бәйләнгән. Аякларында да ак тула оек, юкә чабата. Башында, шулай ук, чәчләрен каплап, маңгаена ук төшеп торган ак, чәчәкле ситса яулык анын... Кыланышлары да житез, килешле, ир-ат сыйлап ничек бөтерелә... Күгәрчен дә түгел бу Пиннәрпи, ә юл унаена тезелешкән ак ромашкаларның берсен хәтерләтә ак киемле, зифа буйлы, таза тәнле яшь чуаш кимпере. Шул сөйкемле зат күзенә чалынуга, Сараның бөтен тәне чемердәп китте, буыннарына көнчелек уты йөгерде. Житмәсә Пиннәрпи чишмә ташларына бәрелешкән су челтерәвен хәтерләтеп нәрсә ди әле?

«Пезнең Хабул перенчелекне пирми... Пезнең Хабул бик унган, чуаш пулмый гына хур пулган», диме... Үзе көрән сусыл күзләрен ялтыратып мут елмая чуаш кимпере.

Каян килеп сезнеке булды әле минем Хабул, Пиннәрпи? дип кеше каршында үчләшеп булмый бит. Телен тешләде дә пешекче хатын сузган итле шулпаны чөмерде Сара.

Ә иргә, аулакны туры китереп, әйтте әйтүен:

—Атналап өйгә кайтмый торуың аңлашыла хәзер, жаным. Пиннәрпи сыйлары тәмлерәкмени сиңа?

Хабул да нәкъ үз читәненә тигәнен аңлады. «Яна, яна бүрек...»

—Пиннәрпи? Кухарканы әйтәсеңме? Ире бар анын,—дип ир бик сәер итеп көлде көлүен. Әмма хатын күңеленнән көнчелек вәсвәсәсен корыта алмады. Төннәрен ялгызы түшәккә ятса, Хабулны һаман шул Пиннәрпи белән бергә күреп саташып чыкты Сара. Ир яратамы-юкмы? дип ромашка чукларын берәм-берәм өзә, аны тәмам ялангач итә, имеш... Ирнең үткәненә кагылышлы кимсенүләр көнчелек янәшәсендә пүчтәк кенә булган. Хәер, бу ике хисне, Сара, бер-берсеннән аерып буламыни? Бәбкә кебек чукымасалар, ир авылдан чыгып китмәс иде бит. Әллә кайсы Юашка Пиннәрпие дә хатын төшенә кермәс иде... Берсе алай, берсе болай, әмма икесе бергә бик зур куш! Тик үз сәманың түгел, кеше тәнкәсе бу. Түлә, Сара, түлә сугыш контрибуциясен. Бу ясак зур һәм аны жиңелгәннәр озаклап өлешләп түлиләр, Сара...

Әйе, өлешләп түләделәр. Вагын-төяген, сүз белән биткә чабуларны әйткән дә юк. Мир каршында хурлаулары да әллә күпме бит анын... «Үләргә киткән түтәбез, баеп кайта түгелме? Ләә-ләә...» дигән кебек, Хабулның Юашка кырларында эшләп беренчелек алып кайтуы, ашлыкка, акчага тигенүе авылга таралып, Жамал яраннарын тәмам чыгырдан чыгарды. Кар эреп, һавада жир исе, туфрак исе аңкый башлаган мәлдә йортка Сара урынына утыртылган Фәрух һәм өч халык вәкиле килеп керделәр. Гаилә төшке ашка утырган иде. «Әйдәгез, әйдә, бик мактап йөрисез әле»,—дип Хабул боларны табынга кыстады.

—Галиәсгаровлар, бакчагызны кисәбез,—диде Фәрух хужаны ишетмәгәнгә салышып. Һәм папкасыннан кәгазь чыгарып селкеде.—Мени дакумент. Сезгә закунный 14 сутый тиеш, ә 25не киртәләп куйгансыз. Каян кисәбез, арткы яктанмы, әллә читән буеннанмы, күрсәтегез!

—Туктале, Фәрух гадук!—диде Хабул чынлап аптырап.—Безнең бакча күптән 25 сутый йөри. Нишләп кисәргә булдың?

—Син закун белмәсәң, Сара белер. Калхуз спнсогында тормаган кешегә 14 кенә сутый тиеш. Хатынын калхузчы түгел, үзең МТСта бугай. Кису закуннай, гадук.

Шулай дип власть вәкилләре арткы яктан шапылдатып казыклар кагып, бакчаны кистеләр. Кишәрлек ел саен кысыр калып, тирә-юньгә алабута, билчән, эт эчәге орлыклары гына сибеп ятты. Хөкүмәт, колхоз

бу 10 сутыйдан нәрсә откандыр, Аллаһ белсен, әмма Җамал ягының Галиәсгаровларны кешегә санарга тырышмаулары халык өчен бик ачык иде. Хабул тиргәнде, әллә кемнәрне аты-юлы белән сүгеп ташлады. Әмма Сара үзе рәис чагында азгын Җамаллар нәселенә тышау куюларын хәтерләп, телен тешләде.

Җамал куылып, рәис урынына Сәйфиев килеп утыргач та, Хабул хакында чүбек чәйнәүдән, гаиләсен мыскыл итүдән туктамадылар. Шулай да идарә утырышында яшь механик Рәфкать, Кыям картның чыбык очы кардәше, мәсьәлә күтәргән: «Хабул абый районда танылган комбайнчы, тик хәерче шикәре сыман, тегендә-монда күчереп йөртүләр, үзебезнең колхозга беркетик аны». Идарә хуплагач, Сәйфиев карышмаган, Хабул менә берничә ел инде үзенең туган авыл кырларында ашлык суктыра. Ир-ат белән арасы яхшыра бара да бит, Ходай сакласын, бу әфисәрләр генә башына тагын берәр бәла салмасыннар тагын...

Ниһаять, гаскәриләрнең берсе баскычка тәмәке көйрәтергә чыкты. Икенчесе болдырдан ашыгып төшеп, машинасын кабызып куйды. Саранын янә йөрәге авырттырып сулкылдап алды: «Алып китәләр инде болай булгач...» Юк, Хабул ишектән ялгызы гына килеп чыкты һәм, чынлап та, теркелдәп өй ягына юнәлде...

—Хабул, тукта!—дип кычкырды Сара.

Ир тавыш иясен искәреп алды, хатынына каршы юнәлде. Чү, күзләре кызарган түгелме сон? Алай дисәң, елмая үзе, әнә көлә дә бит.

—Йә, Хабул, әйт, нишләттеләр?

Ир аны-моны әйтмәде, әмма килгән шәпкә каты итеп Сараны кочаклап алды.

—Кит юләр, көпә-көндез... урам уртасында... кеше күрер, җибәр!

Әмма Хабул хатынын күкрәгенә һаман ныграк кыса, тарта гына барды:

—Күрсеннәр! Миңа орден тапшыралар, җаным... орден!

—Орден! Ни өчен?

—Һай, орденны нигә бирәләр? Батырлык өчен! Ниһаять, безгә дә кояш чыга, Сара, аңлыйсыңмы?—Һәм Хабул бәреп чыккан шатлык хисләреннән үзен-үзе тыя алмыйча биеп җибәрде. «Эх-ма, Бибисара, кайда безнең гитара!» Сараның күптән, бик күптән инде Хабулны яшьлегендәге кебек чибәр, житез, очынгыч кыяфәттә күргәне юк иде. Хатын үзе дә түзмәде, иңбашларын сикертергә, кулларын чәбәкләргә керешге, теленә такмак та йөгерде:

Бие-бие Хәйбулла,
Биегән кеше бай була...

Бу көн Хабул белән Сарага гына түгел, бөтен Түреш өчен бәйрәмгә әверелде. Ирнең күкрәгенә сугыш орденын тагу кичәсен азак та, әле теге, әле бу уңай белән һаман искә төшереп тордылар.

Халыкка Мәскәү әфисәре Сидоров ифрат ошады. Чал чәчле, зәңгәр күзле һәм өлкән яшьтә булса да, һаман төз буйлы, шәп киемле гаскәринең сәхнәдән торып сөйләү рәвеше барысын шаккатырды. Гадәттә Аксудан, тегеннән-моннан килгән лекторлар трибуна артына басып кәгазьдә язганны укыйлар иде. Халык сүз табы корган бу кешеләрнең азак нәрсә әйтергә җыенганын да аңламый иде. Килгәне килгән, теле аерым, үзе аерым дигәндәй, партком Рәүф кушып, татар теле укытучысы Нәгыймә Харисовна доклад укый башласа да кеше интегә бит. Нәрсә әйтә, ни сөйли бу? «Партиябезнең тарихи карарлары белән рухланып, совет халкы коммунизм төзү юлыннан һаман

алга бара, җиңүләр яулый, ил, халык мәнфәгатьләрен үтәү сәясәтендә зур казанышларга ирешә бара»... Тел тегермәне тартканны Түрештәгеләр тыңлый-тыңлый да аптырауга төшә. Кайда бар икән мондый хәят: рухлану, җиңүләр, казанышлар... Түрәләр өстенә акырудан туктамый, кибеткә керсәң, керосин, шикәр юк. Юньле кием-салым сайлармын димә... Менә шулай мөнбәрдәге сүз үзенә, халык үзенә аерым яшиләр иде Түрештә.

Ә Сидоров кызыл комач ябылган трибунага күз дә салмады, төргәге белән язулы кәгазь дә чыгармады, үзара сөйләшкән кебек, залдагыларның күзенә карап, гап-гади итеп сүз башлады:

—Илдә үзгәрешләр көтелә, иптәшләр, һәйбәт үзгәрешләр... Гади хезмәт кешесенә карата борылыш бу. Аны шәхес буларак зурлау, кадерләү, дип әйтер идем мин моны. Бу юнәлеш халык рухын күтәрү белән бервакытта, тормышны, яшәү сыйфатын да сизелерлек яхшыртуга алып барачак...

Сидоров урысча сөйләсә дә, аның сүзләре һәркемгә аңлаешлы булып, зиһененә ятты. Сара да илгә, тормышка бәйле чыгышын ихлас тыңлады, тик олы кунак кайчан аның иренә кагылышлы сүзләрне әйтер дип тә дулкынланып көтте. Әһә, дип уйлады Сара. Менә хәзер әфисәрдән Хабулның исеме дә чыгар...

—Әсирлекне без дошман алдында калтырап кул күтәрү, җан саклап, ил, намус сату дип кенә карыйбыз. Әйе, аларга тискәре мөнәсәбәт тотып, хурлаучылар да байтак. Әмма безнең коллегалар төрле катлаулы хәлләр аркасында дошман кулына төшкән совет солдатларының язмышларын өйрәнеп, гаҗәеп батырлык фактларын ачтылар. Татар халкының сөекле улы Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында җыелган документлар таң калдыра. Солдатлар әсирлеккә төшсәләр дә, дошман белән көрәшкәннәр, җиңүне якынайтып, батырларча һәлак булганнар. Муса Җәлил тоткынлыкта тетрәндергеч шигырьләр язган:

Я не преклоню колен, палач, перед тобою,  
Хоть я раб и узник в тюрьме твоей.  
Надо будет смерть приму я стоя,  
Хоть и голову отрубишь мне, злодей...

Сидоров шигъри зәвык һәм рухлану белән яттан тагын ике куплет тезмә укыды, әсәрләнеп, башын иеп тынып калды.—Муса Җәлил,—диде ул янә,—татар шагыйре, сезнең шагыйрь. Аны туган телдә тыңлап үтүегез бик дөрес булыр. Шуның өчен сәхнәгә мин булачак некрут һәм солдат Давыт Галиаскеровны чакырам...

Сара ялгыш ишеттемме? дип дертләп куйды. Давыт Галиәсгаров дидеме? Бу нинди сәхнә тамашасы тагын? Юк, колагы алдамый, әнә рәтләр уртасыннан чыгып, сәхнә баскычына аның улы күтәрелә. Ак күлмәктән, кызыл галстуктан... Атасының бәйрәменә матур киенеп барсын, дип үзе тырышкан иде ана. Ә сәхнәгә чыгуын сер итеп тотканмы малай?.. Вәт, пәйгамбәр!

Давыт җиңел атлап сәхнә уртасына килеп басты. Бераз кызарып залга күз салды һәм дулкынланулы, әсәрле тавыш белән игълан итте:

—Муса Җәлил. «Ышанма»...

Һәм укучы класс алдында шигырь сөйләгәндәй табигый, яхшы билгегә өмет иткәндәй ышанычлы итеп, яңгыратып сөйләп җибәрде ул:

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,  
«Ул егылган арып»,—дисәләр.  
Син ышанма, бәгърем!  
Мондый сүзне  
Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр...

Залны чебен очканны да ишетерлек тынлык басты. Сәхнә уртасындагы малай күренмәс магниты белән күзне, колакны үзенә тартып, яна төр бәете белән күнелләрне биләп алды.

Сина миннән хәбәр китерсәләр.
«Алмаштырган илен» ,—дисәләр.
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.
Илдән киттем ил һәм синең өчен
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алмаштыргач,
Жирдә мина тагын ни кала?

Малайның тавышы һаман күтәрелә, көчәя барды, бәетендәге фажига да тирәнәя төште:

Сина миннән хәбәр китерсәләр,
«Муса инде үлгән»,—дисәләр.
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

Бу куплетны янгыратканда Давытның үзенең тавышы да калтырап куйды, шуңамы үзен-үзе нечкәрүдән тыеп, беркавым тынып торды ул һәм икенче тында инде ныклы, ышанычлы тавыш белән бәетнең соңын янгыратты:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы жыр тулы күнелне.
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Жинеп үлгән мондый үлемне?

Әлегә кадәр колакка чалынмаган бу ят бәетне тынлап әби-чәби тын гына күз яшьләрен сөртте, яшьрәкләр шаулатып кул чапты. Яхшы башкаруы өчен Давытка мәдхия булгандыр инде бу. Ул да булмый гозерле тавыш ишетелде—авылга килгән һәр китап, гәзит-журналны укып барган элемтәче Нәбиулла икән:

—Иптәш Сидоров, Муса Жәлилнең китабын каян табарга була?

—Муса Жәлилнең шигырьләре, һичшиксез, китап булып чыгар, иптәшләр. Басарга әзерлиләр. Мин исә хәзер укылганны Жәлил эшен тикшергән хезмәттәшләрдән алдым. Безнең чекистлар кулы аша шагыйрьнең блокноты үтте. Аны илчелеккә Андре Тиммерманс—Жәлил белән бер төрмәдә торкын булган бельгияле тапшырган иде... Кыскасы, шул, иптәшләр. Совет кешеләре әсирлектә дә батыр булып калдылар. Һәм менә бу батырлыкның жанлы бер үрнәге булып сезнең авылдашыгыз запастагы өлкән сержант Хабул Галиаскеров тора.—Кунак пауза ясады, иркен елмайды һәм дустанә тавыш белән эндәште:

—Яле, герой, сәхнәгә рәхим ит!

Хабул бу чакыруны көтә иде инде. Гәүдәсен, аяк-кулларын абайламады. Ике-өч сулыш эчендә ул сәхнәгә, авылдашлары каршына менеп басты. Мондагы кешене читтән, залдан күзәтү генә жинел икән ул. Ә үзең сәхнә түрендә булсаң... Чынлап та, каушарлык шул. Аңа, гомердә күрмәгән кебек, йөзләгән караш текәлгән, Сара да, малай да, бабай да, күрше-күлән дә аерылмый моннан. Күзләрнең дә күрәне, карасы, яшел-зәңгәре юк. Тик

текәлеп, кызыксынып яисә үтә житди булып сине күзләгән карашлар гына бар. Кем бу Хабул? Нинди кеше син? Халык күзенә кайсы тамга-калып кешесе булып чалынасың син?

Әйе, әйе, тамга-калып!.. Хабул бу турыда озак уйланды инде. Кешенең социаль әһәмиятен, кыйммәтен билгеләр өчен аны тамга-калыпка салалар. Сыер-сарыкка колак тишеп бирка суккан, кол-әсирне сан белән нумерлаган сыман, яисә буталмас өчен, адашларга кушаматлар чәпәгән кебек, хәяттәге адәмнәрне дә хужа-хезмәтчегә, бай-ярлыга, галим-томанага, батыр-куркакка, айнык-сәрхушкә, геройга, колга, ударникка, хөрәсәнгә аерганнар. Әлеге тамга-калыплардан чыгып адәмнәргә абруй, чин, дәрәжәләр ябыштырылган, тамга-калыпларына карап, йә күтәреп, йә типкәләп йөрткәннәр кешене. Әлмисактан башлап шулай булган бу, Хабуллардан соң да тамга-калыпларга салырлар мир кешеләрен. Кара өлешеннән язарга теләгән кеше каядыр ялгыз утрауга, яисә урман-чытырманга китеп качса, котылса гына инде...

Ярый, раббысына мең рәхмәт! Кичә генә әле Хабул үз өстендә хурлыклы тамга-калып йөртә иде. Яманатлы иде, әсир иде, мәхлук иде ул. Ә бүген шул ук Хабул халык күзе алдында герой булып танылырга тора. Аңа хәзер кеше каршында оялып, бәбәк яшерергә урын юк... Әйдә, Хабул, залга туры кара, мәгъруր кара, кыю кара син халыкка! Син хәзер, Аллага шөкер, үз тамга-калыбыңда...

Сидоров сәхнә уртасында солдат сыман үрә катып калган Хабулга канәгатьләнеп күз салды, папкасыннан мөһерле затлы кәгазь чыгарды:

—Иптәшләр, запастагы өлкән сержант Хабибулла Харис улы Галиаскеровны хәрби орден белән бүләкләү хакында Хөкүмәт указын укырга рөхсәт итегез!

Мәскәү кунагының көчле, тигез, рәсми яңгырашлы тавышын тыңлаганда Хабулны тик бер теләк чолгап алды: ничек тә күз яшен чыгармаска иде, ничек тә йомшармаска иде! Кәнсәләрдә майор каршында үксегән кебек, мышкылдый башласаң, ни эшләрсең? Хабул күз алдыннан үзе үткән сугыш кырларын, яңгырлы-карлы юлларны, яралы иптәшләрен, әсирлекнең бәгырьгә төшкән авыр мәлләрен үткәрде. Чынлап та бу читләшү аны нечкәрүдән коткарды, зал каршында хисләнү галәмәте күрсәтмәде ул.

Менә Сидоров указны укыды, кулына орденлы тартманы алды һәм шунда залны көлдерерлек сүз дә әйтте:

—Ашыкма, өлкән сержант, орденны син ничә еллап көттең. Хәзер дә берничә минут кына көтәрсең. Башта авылдашларыңа синең батырлыкларны сөйлим әле. Менә шуннан соң гына күкрәгеңне куярсың мина, Галиаскеров!

—Так точно, иптәш майор, күкрәкне сез сөйләгәч куярга!—диде Хабул һәм шул сүзләре белән залга янә көлке дулкыны өстәде.

—Алдыбызда басып торган Ватан сугышы ордены кавалеры минем үземне кристалл сафлыгы һәм сабыйлар тыйнаклыгы белән таң калдыра,—дип янә житди тон белән сөйләп китте Сидоров.—Мин Түрешкә килгәч, Гомәр Гаффарычка сорау бирдем. Сез Галиаскеровның сугышта кем булганын беләсезме? Юк, ди. Үзе хакында берни сөйләгәне юк аның, ди. Ә бит, иптәшләр, сезнең авылдаш легендар катюшада сугышты. Бик мөһим хәрби операцияләрдә катнашып, аны унышлы үткәрүгә өлеш кертте. Данлыклы ракетчик ул! Ә моны сездән сер итеп саклаган Галиаскеров...

Сидоров Хабул янәшәсенә басып, аның жилкәсенә еш-еш яратып кагылып тагын байтак нәрсәләр сөйләде дә сүзен шулай йомгаклап куйды:

—Бөек Жиңүне без Галиаскеров кебек рухи һәм мораль ныклыкка ия булган тыйнак, әмма үз бурычларына үтә жаваплы караган ир-егетләр аркасында

яуладык. Кадерләгез сез, саклагыз фронтовик авылдашыгызны!

Сидоров Хабул Галиәскаровның күкрәгенә орден беркеткәндә залдагы халык яше-карты аягына басты һәм байтак вакыт онытылып кул чабып торды:

—Рәхмәт. Түреш маркасын төшермәден, яугир!

—Афарин! Хабул! Афарин!

—Маладис парин!

Ире, якыннары, авылдашлары рухына канат куйган бу җомганы Сара бөтен гомере буена хәтерләде.

## XXIV бүлек

Сара күнеленә язылып калган гомер сәхифәләре бер генә түгел анысы... Бөтен тирә-юнь нурланып, елмаеп, көлеп торган май көннәрендә бакча буендагы чирәмгә оя тулы каз бәбкәләрен чыгарып таратуын ничек онытасың?! Үз йортыңның вагы-төяге дә кадерле бит хатын-кыз өчен. Яшькелт йомгакка охшаш җан ияләре берәм-берәм хуш исле хәтфә үләннәр арасына сибелә. Кайсыдыр томшыгына эләктереп сабак тарта, кайсыдыр башын кыегайтып еракта, өстә җылы һәм мәрхәмәтле нур чәчеп торган кызгылт шарга текәлә. Тумас борын, кош юлларына төшәргә әмәл эзлисеңме син, бәбкә-бала?

Сара эшен бетерә дә, куллары белән бөеренә таянып, бәбкәләрне санарга керешә. Белә инде бәбкә башын, санавы да күңел өчен генә. Аллага шөкер, быел да уңды бит казларыннан. Оя тутырып бәбкә чыгардылар. Унҗидесе дә ип-исән, йөгереп мыжгып торалар. Сара янәшәсендәге ана казның да ара-тирә каңгылдап куюы—аңлаганга үз булдыклылыгы белән мактану, горурлану галәмәте түгелме? Ә ата каз ишле, имин гаиләсенә ничек битараф кала алсын инде? Ул да шатлана, сөенә бахыр. Һәм ничек кенә сөенә әле! Башын өскә суза, гәүдәсен тартып, җыештырып куя һәм ... бии башлый. Бии, бии, аякларын кызык итеп, шапылдатып баса, Хабул әйткәнчә, гармун гына җитми моңа. Тик ничаклы биесә дә, канатларын җилпеми ул, җилпесә куанычтан хисләнеп очып китәрмен дип курка микәнни? Әйе шул, аңа бу ояны карыйсы, үстерәсе, һәркайсына канат куясы бар әле...

Ничә ел күрде инде хуҗабикә үз ата казының биюен. Бәхетле ояга карап бер сөенде, бер сагышка чумды Сара. Кошмы, кешеме—анабашка, атабашка иң зур шатлыкны, олы гамьнәрне бала бирә икән бит. Итәгеңдә сабый булганда гына дөньяң бөтен, бәхетең түгәрәк була икән. Инде кош юлына төшеп күздән җуелган киек кош кебек, ул-кызың йорт ташласа, тормышың бөтенләй сүнеп, сүрелеп кала... Бие, ата казым, бие! Ямьле яз фасылында гына була торган бәйрәм бит бу.

Ходайга рәхмәт, Хабул белән Сараны да олы бәхеттән мәхрүм итмәде. Әй, гомернең ул сөенечле фасылы! Вагы-төяге белән дә күңелне ымсындырып тора шул хәзер... Сара үзе—пешекче. Әллә Пиннәрпигә карап кызыкты, әллә колхоз эшенә ризалашып, бакчадагы сельсовет казыкларын суырып ату теләге көчле булды—кыр станына чыгып, механизаторлар ашата башлады. Яшькелт яздан башлап саргылт көзгә кадәр машина мае, бензин, солярка исен чәчкән җор телле ир-ат өчен ул—күз өстендә каш. «Сара килен, кәндиеңне таптабрак тотыр әле. Әппитет уйнап тора бүген... Сара апа, берәр әче-мөчең юкмы, махмыр бит, коткар!.. Сара, мәтрүшкәң шәп, кайсы аланнан җыйдың?.. Сара, Сәйфиев кунакларына аулакта табын корып куй әле! Авылга кайтмыйлар, төтәсләгән ашларыңны ярата икән персидәтель».

Колхозга «СК-3» маркалы үз йөрешле яңа комбайн кайткан иде. Икеләнеп тормадылар, Хабулны утырттылар. Бик кәнителле техника икән.

Элекке «коммунар»ларны тракторга тагып йөртсәләр, бу үз аягы белән йөри, ура, суга, җилгәрә, үзе төяп җибәрә... Тәҗрибәле кул, зирәк баш кирәк бу кыр карабына. Хабул китаптан карап, атна буена яна комбайнны өйрәнә. Чәй янында Сарага да сөйли. «Минем катюша сыман бу. Менә вариаторны гына ал. Руль янында синең чәнечке тоткасы кебек ябе дә бар үзенең. Шуны алга таба төртсәң кызурак йөреп китә, туктале, кызма, сабыррак бул, дип үзенә тартсаң, әкренәя... Менә синдә дә шундыйрак бер ябь булсын иде.

—Миңа синең вариаторың ни дә карбюраторың ни... Баллоның шартлап, үзең егылып төшмәсәң, миңа ничек барсаң да бер,—дип көлә Сара.

—Әни,—дип сүзгә кушыла боларны тыңлап торган Давыт.—Әти комбайнында карбюратор юк, син әйткән нәрсә бензин моторында гына була, ә «СК-3» исә дизель моторы белән эшли..

—Харап икән!—дип куя ана, исе китмәгән бер кыяфәттә.

Ә малай ата кешегә борыла да янә үзенекен сөйләп китә:

—Әти, вариатор трансмиссия тәгәрмәчен кечерәйтү-зурайту принцибына корылганмы ул? Тәгәрмәч зурлыгына карап тизлек үзгәрә бит. Шулаймы?

—Менә-менә!—дип комбайн моторы сыман үзе кабынып китә Хабул.— Маладис, улым, нәкъ шулай, механик башы синдә!

Шулай ата белән ул үзләре генә белгән телдә техника могҗизалары турында серләшеп китәләр.

Ә беркөнне Хабул хатынына болай диде:

—Сара, фатиха бирсәң, помощникка мин малайны алып чыгар идем. Чит кеше белән интеккәнче, мәйтәм... Башы эшли, кулы ята Давытның. Ә? Кергәне дә бер йортка булыр... Чыкканын яратмасаң да, кергәнен бик яратасың бит, әнисе, ә?

«Яшь түгелме соң?.. Үзең интекмәссеңме?.. Нәчәльникләр каршы булмасмы?!» дип хатыны сорауларга күмеп ташласа да, Хабул үзенекен итте, сигезенче сыйныфны тәмамлап каникулларга чыккач, Давытны ярдәмчесе итеп раслатып, кырга алып чыкты.

Әй, ул урак өсләре! И, ата белән ул әшнәлеге! Ис-күз итсәң, үзәкләр өзелә инде...

«Подьем!» дип атабаш әмер бирсә, малай: «Есть!» дип солдатча аягына баса. Чәй эчәләр дә, янәшә басып капкага юлланалар. Давыт әллә атасыннан буйчанрак булмакчы. Хәзер үк тигезләшкән, әле берничә ел үсәсе бар бит аның. Ә йөрүләре, аяк басулары, кул болгаулары тач атасыныкы: суйган да каплаган... Эшкә дә Хабул кебек тәвәккәл... Урак кызып китеп, ике көн ерак басудан кайтмыйча, ата-ул салам өстендә кунгач, хәлләрен белергә дип яннарына барган иде, Давытны штурвал артында күреп котлары очты Сараның.

Комбайн ажгыр җанвар сыман, төтен ялы, тузан өере чәчеп теземне суктырып килә, әллә кай җирләре шатырдый, зырылдап әйләнә аның... Ә бу шул җанвар өстендә ялгызы... Ходаем, берәр әгъзаларыннан эләктереп, үзен биртеп ташламасын тагын! Сара комбайнга менү түгел, якын килергә дә базмады, кул изәп малайны үзенә чакырып алды:

—Кая әтиең?—диде ул яман борчылып.

—Әти бер тимер алырга китте, килеп җитәр,—дип җаваплады Давыт кыбырсынып.—Көтсәң көт! Минем вакытым юк!—Һәм комбайнга сикереп менде дә, аны янә бар куәтенә ажгыртып китеп тә барды. Вәт малай, кайчандыр биләүдә шыңшып яткан бер имгәк булгандыр бу дип уйларга да җөрьәт итмәссең... Давыт пәйгамбәр—тимер остасы булган ласа!

Ата белән ул үзләренең беренче уракларында район комбайнчылары ярышында җиңүче булып чыктылар. Икенче елны исә боларның фамилиясе

республика күләмендә дә телгә алына, янгырый башлады. Кайдандыр бер үзәк гәзиттән сакаллы урыс ир-аты килеп, көнен-төнен кырда, яланда ятты һәм китүенә атна да үтмәде «Отец, сын—боевой экипаж» исемле зур язма басылып чыкты. «Правда» гәзите булды бугай бу. Халык мәж килде.

Гәзитне кыр станында кулдан-кулга йөрттеләр. Сара да укыды. Хабулның легендар катюша ракетчысы булып сугышуы белән тынычта комбайнда эшләве бергә искәртелеп язылган иде анда. Давытны да мактап ару гына телгә алган журналист: «Яшь Галиәсгаров атасы юлыннан бара, штурвалны ышанычлы тота, тормышка һәм үз киләчәгенә өметле карый яшь егет...»

Билгеле, ире белән малае өчен шатланды Сара, тик бераз гына күнеле дә кителде. Шулар рәтеннән Сара турында да берәр җөмлә язып бастырсаң, каләмең кителер идеме инде, сакалбай?! Пешекчедән башка кая китәрләр Галиасгаровлар? Ач корсак белән хезмәт унышларын яулап кара син. Әйе, берчак Хабул бик дөрес әйткән иде шул: «Кеше җүнен тамга-калыпка салып кына үлчиләр бездә».

Тамга-калып! Бу сүз ирексездән Сараны мәктәп директоры Сәмига Хәйруллина тирәсенә алып килә. Менә кем ул кешене тамга-калыпка салу остасы! Сәмига Кәшфиевна үз исәпләреннән чыгып, аяк-кулларыңны бөтәрләп сине бер калыпка салып куйса, җәсадыңны кабергә тыгып куйганчы, шул кысаңнан чыга алмассың... Кырыс тавышлы, тимер рухлы бу укытучылар башлыгының сүзләре канун. Ә канун нык була, үзгәрешсез нәрсә ул... Тик шунысы гаҗәп, Сәмига Кәшфиевнаның йөзе, җилгә карап борылган мәктәп флюгеры кебек, туктаусыз үзгәреш-янарышта. Бер карыйсың, болыт кебек караңгы, икенче карасаң, ул язгы кояшка тартым. Зәңгәр күзләре, чаларган чәчләре дә яктылыкны, рухиятлыкны раслап тора сыман... Әлбәттә, чырай тотышы, ханым теленең төчелеге яисә ачылыгы сымак ук, кешесенә карап үзгәрә. Сәламең нинди, җавабым шундый, диме әле урыс? Әйе, әйтсә, моны алчак урыс әйтер. Ә безнең Сәмига Кәшфиевна кешенең дәрәҗәсенә карап чыраен ачар. Чиның нинди—чыраем шундый, бигайбә, диярме бу нәзакәтле, нәзберек ханым?

Менә шундый зат белән бәрелеш түгел, янәшәсенә якын килергә дә базмас иде Сара пешекче. Тик ана булып малае хакында низаглашты шул.

Давыт унынчы сыйныфта беренче чирекне тәгәлләгәч, ата-аналар җыелышы булып узды. Малайның мәктәп хәлләре Сарага якынрак, әлеге салкын ноябрь кичендә дә хәвеф-хәтәрсез очрашуга килде. Сәмига Кәшфиевна чыгарылыш сыйныфы укучыларын берәм-берәм сыйфатлап үткәндә, Давыт Галиасгаровка да шактый канәгатьсез булуын белдерде. «Күзгә күренеп бозылды, күрәмсең, ата-ананың укучыны рәхимсез эксплуатацияләве эзсез калмады», диде.

Сара урыныннан торып сорарга мәҗбүр булды:

—Сәмига Кәшфиевна, Давытның укуы бик начарландымыни?

—Укуы хакында укытучылардан зур зар ишетмәдем әле. Әмма тәртибе безнең педагогларны бик борчый башлады. Давыт бик һаваланып киткән, дәрестә укытучылар белән бәхәс кора, темага карамаган сораулар да бирә икән. Белүемчә, иптәшләре белән дә мөнәсәбәте бик киеренкеләнгән бугай. Менә шул, Галиасгарова, малаегызга игътибарны көчәйтә төшегез. Болай барса, улыгызның урта мәктәпне Алтын медальгә тәмамлавы бик икеле...

Ата-аналар каршында ясалган кисәтүләрдән Сара ифрат хурланды. Гадәттәгечә ахирәтләре, таныш-белешләре белән дә гәпләшеп тормады, җыелыш бетүгә өенә чапты. Юл буена үртәлеп кайтты Сара: «Галиасгаровага әйләндеммени әле? Теге вакытта мәктәбегез бер пүлән утынсыз калгач, Сара Кыямовна, дип яшь сыгып янга килгәнең онытылдымы хәзер? Бик

кыска хәтерле икәнсең шул, Сәмига Кәшфиевна!.. Сара пешекчене хәзер урынына утыртыйм дисеңме? Малаең укытучы белән бәхәсләшә, сорау куя, дип хур итмәкче буласыңмы Сараны? Ә ник бәхәсләшмисез балалар белән, бәхәс корыгыз. Сорау бирәләр икән, нигә аңлатмаска? Укытучылар бит сез, балаларга зиһен бирегез. Ә, ә... Моның өчен туктаусыз укырга кирәк шул. Үз өстеңдә эшләргә кирәк. Балаларны үзеңә җәлеп итә белү маһирлыгы фарыз. Мәктәптә бит мондый иҗтиһад кылганнар сирәк. Күбесе гайбәт сата да бала, ата-ана тикшерә, ил-көнгә яраклашып көн күрә. Аның да үз товары бар: «Рәхим ит, кемгә бишле, кемгә өчле?.. Артыгын сорамыйбыз, бәя дә төшермибез. Бездә үтемле товар—грамота, кәсепле халык!» Шулай дип бәя күтәрәсеңме, Сәмига Кәшфиевна? Менә медальдән мәхрүм итәргә җыенуың куркыныч. Моны халык алдында Сара пешекчегә юкка гына әйтмисеңдер син. Берәр хикмәт бардыр. Алтын медаль мәктәпкә бик санаулы кайта бит. Аны кемнәргә тапшыру хакында исәп-хисап та корасызмы инде хәзер. Чинга карап, чырай күрсәтергә җыенасызмы?

Ана мәктәптән бик ярсып, тузынып кайтканда, Давыт бозда малайлар белән шар суга иде. Хабул комбайныңдагы теге туктале, кызма, сабыррак бул син дип япьне үзенә тарткандай, ипле сүзләре белән Сараны шактый тынычландыра төште. Кичен, Давыт өстәл янына, ата-ана каршына килеп утыргач, ана болай диде:

—Мәктәптә эшләрең бик начарланып киттемени шулай, бала? Бүген кеше күзенә күренерлегемне калдырмадылар бит. Тәртибе начар, һавалы, бәхәсләшә, әллә нинди сораулар бирә диләр... Нинди иптәшең белән тыныша алмыйсың син? Нәрсә бүлешәсең?

Давыт, күрәмсең, анасыннан мондый сүзләр көтмәгән иде. Кызарып куйды:

—Әни, мин чирек билгеләрен күрсәттем бит, барысы «бишле»,—диде ул кайнарланып.

—Бөтен нәрсәне дә әтмиткә аршыны белән үлчәп булмый болай булгач. Яшермә, Давыт, хәлне яхшылап сөйлә!

Атабашның катгый таләбеннән соң, малае чынлап та мәктәп хәлләре турында байтак нәрсәләр сөйләде. «Сорау бирмини, сорадым шул. Сәмига Кәшфиевна үзе әйтә бит. «Нинди сорауларыгыз бар, укучылар?»,—ди. Тарих дәресендә директор кулаклар турында сөйләде. Алар сәнәкчеләр булып, коммунистларны үтергәннәр, ашлыкларын яшергәннәр, колхоз атларын агулап үтергәннәр икән. Тагын шулай әллә нинди явызлыклар эшләгәннәр кулаклар. Мин Сәмига Кәшфиевнага сорау бирдем. Түрештә Гыймади крестьянны мактап сөйлиләр бит, апа. Иген үстергән, атлар тоткан, тегермәне булган, сәнәкче булып йөрмәгән ул, шулай да раскулачивать иткәннәр икән. Ул да сез сөйләгән кулаклар рәтенә керәме инде?

Сәмига Кәшфиевна мин сораганны бер дә яратмады. «Каян башыңны чүп-чар белән тутырдың, ата-анаң сөйлиме?» Юк, минәйтәм, халыктан ишеттем. Түрештә яшим бит, дидем. Аннан соң тагын әйтә Сәмига Кәшфиевна. Әгәр син балигъ кеше булсаң, мин сине, Галиәсгаров, икеләнми «антипартийный группа кешесе», дип атар идем, ди. Класс бу сүздән шаркылдап көлде. Әле тагын берничә көн миңа «антипартийный группа» дип кычкырып йөрделәр. Нәрсә, шуннан соң берсенең ипи шүрлегенә йодрыкны терәдем шул. Бар миндә андый гөнаһ...

—Өстеңә бүре китерәсең килмәсә, улым, укытучыныкын тыңла, китаптагыны сөйлә дә башкасына шым бул! Аңладыңмы?—диде Хабул шактый кырыс итеп. Һәм, бераз уйланып торгач, янә өстәде.—Эчеңдә сер тотарга өйрән... Сандыкта бик булсын.

Сара бу хәлдән соң, билгеле, Давытның укуын ныклап күзәтү астына

алды. Жаен туры китереп, укытучылар белән сөйләште. Ходайга шөкер, кайсысы белән сүз башласан да, эчкә жылы йөгерә. «Давыт,—ди математика укытучысы озын муенлы, шадра Минвәли.—Һичшиксез, берәр техник институтка кереп укый ала. Ул чишмәгән мәсьәлә, тигезләмә юк. Зерә башлы, күз тимәсен...»

Үзәк урамда урыс теле, әдәбияты укытучысы Марья Васильевна белән очрашкан иде Сара. Ананы танып, үзе сүз башлады.

—Пушкин, Толстой теленә чын-чынлап гашыйк Давыт. Үз өстендә максат куеп эшли. Сөйләү маһирлыгын үстерә, сочинениеларны да бирелеп яза. Сезнең халык мишәр бит. Акценты да сизелми хәзер. Мина аның әсәр геройларына карата үз карашын расларга тырышуы ифрат ошый. Бик фикерле, тел-әдәбият буенча берәр вузга жыенмыймы? Планнарын әйтмәдеме сезгә Давыт?

Менә шундый сүзләр ишеткәч, Сәмига Кәшфиевна янавыннан чыккан төрле шик-шөбһәләрдән акрынлап арына барган иде Сара. Иншаллаһ, укуын алтын медальгә тәмамлар Давыт...

Кара жир өстенә кырпак кар явып торган декабрь башында Түрештә көтелмәгән бер фажига булды. Жәвид исемле бер укучы асылынып үлде. Бу ак йөзле, сыек гәүдәле яшүсмер—Саралардан биш йорт аша яшәгән Мәсгут баласы. Анасы Рәвия өчме-дүртме ел элек күкрәк бакасыннан вафат иде. Исерек ир икенче кешенең башына житте, ләгыйнь, дип тирә-күрше үз хөкемен чыгарды да, укучыны, рәсми даирәләрдә артык шауламыйча гына, жирләп тә куйдылар. Хәтта Жәвид укыган жиденче сыйныф балаларын да мәрхүм белән хушлашуга китермәделәр бугай. Һәрхәлдә, Сара зират өстендә урам оч малайларын һәм үз улы Давытны гына дикъкатьләп күреп калды.

Мөселман кешесе булгач, күрше-күлән Жәвиднең жидесен үткәрүне көтте, әмма атабаш шешәдән аерыла алмады, тегендә-монда аунап, имәнеп ятты. Давыт бик сорагач, Сара мәрхүмне искә алу мәжлесен үз өендә ясады. Балалар укудан кайтып, көн кичкә авышканда табынга дистәләп кеше утырды. Давыт үзе житәкләп Шәрифулла мөтәвәллине дә алып килде. Өйдә моңлы мәкам яңгырап, «Жәвид Мәсгут углының рухына багышлыйм» сүзләре кабатлана башлагач, аш-су тирәсендә кайнашкан Сараның үз күзләренә дә яшьләр килеп тыгылды... Хисләреннән айный төшкәч, Давытның башына каян килде бу ният дип гажәпләнеп уйлап та куйды ана. Чынлап та, пәйгамбәр зирәклекләре бармы әллә малаенда?

Шәрифулла мөтәвәлли үз аять-сүрәләрен укыгач, оч малайлары дөнья ташлаган Жәвидне төрле яклап искә алырга керештеләр. Сагышы да, көлкесе дә булды. Үз-үзенә кул салган иптәш малайны Давыт Һ.Такташ поэмасындагы Мокамайга тиңләп, яттан озын гына өзек тә укыды әле:

Әкияттәге ике бала кебек,  
Каен башларына үрмәләп,  
Ике ыштансыз малай дөнья белән  
Танышып йөргән идек бергәләп...  
Әкияттәге ике бала кебек—  
Икебез дә кара борынлы  
Зурлар кебек, кулны артка куеп,  
Йөри идек таптап болынны...

Давыт Такташ әсәреннән якты сурәтләрне тезеп китте-китте дә, кинәт сагышланып әйтеп куйды:

Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең:
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишлисен...
Малайның тавышы янә үзгәрде, кайгыланды:
Юк, юк.
Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сөйләмәм...
Син яшәргә хаклы кеше идең,
Син яшәргә җирдә теләдең.
Тик син ачлык тырнагыннан,
Түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең...
Син белмәдең,
Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр:
Ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен
Күмәк тормыш җирдә төзиләр.

Сара китапханәдә эшләгән кеше буларак, үзен замандашы төсендә күргән шагыйрьне яхшы беләм дип уйлап йөри иде. Шул ук «Мокамай»дан үзе дә сизмичә юллар тезгәли иде. «Белмим, әллә күпкә, әллә бик озакка»... Әмма хәзер килеп малаен тыңлагач, гаҗәпләнеп бетәлмәде, ничек мәҗлес рухына туры килә Такташ. Аның фаҗигале Мокамае белән үзенә кул салган Җәвид нинди охшашлар лабаса! Түбәнлектән чыгу юлын белмәде шул бу малай. Атасы гаиләне ачлыкта, фәкыйрьлектә тотты. Аз гына гаеп тапса да, сабыйны кыйнады, тәнен, җанын биртте. Ә укытучылары малайны начар укуда гаепләп, хурлаудан, караңгы чырай күрсәтүдән башканы белмәделәр бугай... Ә сәвит өчен әллә бар, әллә юк бу бала. Нишләсен, ахыр килеп үз-үзенә кул салган инде Җәвид...

Сәвитчә яшәп ярты гасырлап вакыт үтсә дә, шулай кеше язмышларында бернинди үзгәреш-мазар юк микәнни?.. Саранын язын онытылып, хозурланып биегән ата каз кебек сөенеч кичерерлек мәлдән мәхрүм микәнни соң безнең кеше? «Тормыш», «яшәү бәхете» дигән нәрсә тик төтенме, яисә рәшә кебек бер алдагыч кынамы ул?

## XXV бүлек

Давыт мәктәп китапханәсенең бусагасын атлап ничә көн инде гәзитләр өстәленә килә, дулкынланып «Татарстан яшьләре» битләрен ача. Менә-менә аның ташка басылган язмасы килеп чыгар сыман. Тик йөрәк чабыш аты кебек юкка сикеренгән икән... Басмаганнар аның хатын. Түреш мәктәбе укучысының мәктәбен редакциягә тапшырмаганнар яисә анда ул укылмый ята, дип күңелсезләнә Давыт. Әмма көн тугач, эчкә янә өмет йөгерә. Казан гәзитендә бер синең хат кына ята, ди... Синең кебек меңләп кеше мәктәп язгандыр әле. Чират җитәр, укырлар... Яратсалар, басып та чыгарырлар әле. Анда Түрештәге чын хәл, үзенең ихлас уйлары язылды бит. Давыт хисләнеп хат юлларын күңеленнән кабатлый, шулай аның үз-үзенә ышанычы арта. Һәм тагын «Татарстан яшьләре» гәзитенең яңа санын дулкынланып ача ул.

Чыршы бәйрәменә ун көнләп вакыт калган иде. Мәктәптә гадәти уку көне иде бу. Кыңгырау чылтырап, математик Минвәли Гаязович китап, дәфтәрләрен җыйнап класстан чыгарга өлгермәде, аңа бәрелеп диярлек Сәмига Кәшфиевна бүлмәгә атылып килеп керде.

—Туктагыз!—директор мыжлый башлаган класс өстендә елтыр күзләрен

йөртеп алгач, Давыт тарафына якынлашты:

—Галиасгаров, без синнән мондый түбәнлек көтмәгән идек. Мәктәп өстеннән син әләк яздыңмы?

—Мин бернинди дә әләк язмадым, Сәмига Кәшфиевна,—диде Давыт директорның үз өстенә ябырылуына ихлас аптырап.

—Редакциягә хат язучы кеше син түгелме? Һаман ялганмы?

—Газетага хат язучы мин. Тик әләк язмадым, дөресен яздым. Нигә, язарга хакым юкмыни?—Давыт, ниһаять, «Татарстан яшьләре»нә юллаган хатның директор кулына төшүен яисә шул хакта берәр хәбәр алуын, шунлыктан аның тузынуына төшенеп алды һәм аптыравы сүзләренә бәреп чыкты.—Газетка юллаган хат нишләп сезнең кулга эләкте әле, Сәмига Кәшфиевна? Мине хурларга ни хакыгыз бар сезнең?

Үзләрен уратып күзәткән укучылар төркемендә торган директор Давыттан мондый ныклык һәм кыюлыкны көтмәгән иде. Укучы кеше аның каршында сүз әйтә алмыйча кызарып торыр, яисә гаебен танып, гафу сорарга керешер, дип көткән иде. Ә бу каршында кыя кебек тора. Сүзенә кара син. Язарга хакым юкмы, диме? Кара син бу үҗәткә, «Пәйгамбәр», имеш. Тәүбәнне укытырмын әле сиңа, малай актыгы! Танытырмын Сәлимә Кәшфиевнаны... Шулай да әлегә телне тыярга кирәк... Хатын да укымады бит! Районнан, комсомол комитетыннан шалтыратулары буенча гына ярсый. Сездә нинди «ЧП» диләр. Галиәсгаров кем дип сорыйлар... Сәмига Кәшфиевна кисәк үзе дә сизми уйлар каршылыгында торып калды. Әмма «ыбыр-чыбыр» арасында абруй төшерергә дә ярамый:

—Ярар, Галиасгаров, безнең сүз бетмәде әле. Сүз башлана гына. Корреспондент килгәч, ялганыңны тотарбыз без. Җавап бирерсең!

Соңгы дәрес Хәтимә Сүлтиевнаныкы—биология булды. Председатель хатыны дип тормыйлар, тавышы әче димиләр—ниләр генә кыйланмый укучы халкы моның сабагында. Хәтта укытучы өстәле каршында һәрвакыт кулларын кушырып утыра торган Әлфия записка язып, Давыт тарафына ыргытты. «Давыт, «әнкәй» нишләп сиңа ачулы? Нәрсәне тикшерербез, ди. Прием!»

Директор белән низагка керү егетнең үзен кайнап торган самавыр хәленә куйган. Уйларының очына чыга алмый. Ә «каргалар» аның партасына һаман куна торалар: «Әби эләктерә инде сине, малай...» «Давыт, гәзиткә нәрсә яздың син? Үлгән Җәвид хакындамы әллә?» «Давыт, беләсеңме, Җәвидкә бер укытучы әйткән: «Атаң—алкаш, сине дуңгыз фермасы көтә!» дигән. Кирәксә, сора, әйтермен. Рәүф». «Пәйгамбәр, каушама, без синең белән!»

Әлеге «каргаларны» ачып укыгач, кайберләренә җаваплар языштыргач, Давытка бераз хәл кереп китте. Димәк, сыйныфташлары «әләкче», «ялганчы» дигән сүзләргә ышанмыйлар, ярдәм кулын сузарга торалар...

Өйдә дә курыкканы рас килмәде әле. Югыйсә, кайтуга ата-анасы Сафура бураннары куптарыр дип көткән иде. Болай булгач, иртәгәсе көнен тыныч кына уйларга, көрәшкә әзерләнергә кирәк Давытка.

Икенче көнне ул мәктәпкә эчке ныклык, үз-үзенә ышаныч белән килде һәм көтте... Ниһаять, икенче тәнәфестә үк класс житәкчесе Марья Васильевна аны үзе белән ияртеп китапханәгә алып китте: «Галиасгаров, язган хатың буенча синең белән корреспондент сөйләшәчәк. Каушама!»

Бүлмәдә аны озын буйлы, күзлекле һәм бик мөлаем чырайлы бер егет каршылады. «Әнәс Әмирханов, «Татарстан яшьләре»ннән»—диде ул һәм Давытка кулын бирде. Кунак егет аягөсте торып шактый вакыт укучыны күзәтеп торды. Аннары өстәл артына утырырга, сөйләшергә чакырды.

—Таныйсыңмы?—диде ул папкасыннан конверт чыгарып.

—Минем хат!

—Язганнарыңнан баш тартмыйсыңмы?

—Юк!

Корреспондент таныш язманы кулларында тотып битләрне ачкалады.

—Җәвид Гыймрановның үз-үзенә кул салуын, димәк, син очраклылык итеп карамыйсың. Сәбәпләрне аның гаиләсеннән, мәктәптән эзлисең. Хәтта үзенне дә гаепле итеп тоясың. Битарафлык! Шулаймы, Давыт дус?

—Әйе, Әнәс абзый. Җәвид үзенә терәк-таяныч таба алмаган. Ул әле көз балалар йортына китеп булмас микән, дип миңа да әйтте. Әти кыйнап тора, укытучылар гел хурлый, диде. Аксу детдомында әйбәт диләр бит, диде Җәвид. Тик менә юллаучылар гына булмады. Ул бит балалар йортына үзе барып керәлми...

—Шулай, шулай,—дип баш какты корреспондент.—Мин монда син язганнарның барысы белән килешәм. Фактларың да расланып тора. Сүз дә юк, зур проблема күтәрәсең, Давыт. Хәтта артык зур! Гәзиткә басып чыгарсак, мин Түрештәниләр буласын яхшы күзаллыйм.—Кунак егет бермәл җитди итеп Давытның күзләренә багып торды.—Курыкмыйсыңмы, энем? Үч алырлар дип шүрләмисеңме? Матбага сүзе уттан, кылыч-мылтыктан хәтәр корал бит. Бу сүзне тотар өчен каләм генә түгел, көчле рух та кирәк! Бармы ул синдә?

—Әйе, Әнәс абый, мин нинди адымга барганымны яхшы беләм. Гәзитегезгә мин исем чыгару өчен генә язмадым. Хаклык өчен көрәшергә кирәк, дип үзегез безгә гел тукып, әйтеп торасыз бит.

—Шәп әйттең, энем!—дип Давытның җилкәсенә яратып кагылды корреспондент егет.—Әйдә, тәвәккәллик, хатыңны бастыру ягында мин.

Шулай алар аерылыштылар. Икесен дә күрешүдән канәгатьлек, мәкалә язмышына якты өмет биләде.

Ә бу вакытта Сәмига Кәшфиевна Сараларның өй ишеген шакыды. Хуҗабикә мич янында кайнаша иде. Күрше-күләннең ишек кагып тору гадәте юк—килә дә керә. «Керегез!» дип аптырап ишек катына килде, ачып җибәрде. Һәм телсез калды. Бусага төбендә мәктәп директоры басып тора... Чыраенда теге вакыттагы кәперәюнең әсәре дә юк. Гозерен әйтергә тартынган күрше нәүмизлеге...

—Гафу итегез, сөйләшеп алыр идек...

—Рәхим итегез, Сәмига Кәшфиевна!

Директор пәлтәсен салмыйча гына өстәл янындагы урындыкка килеп утырды. Бармакларын кагып торды, нервлана күрәмсең. Зәңгәр күзләре дә жетеләнгән, карашына хәсрәт чалымы эленгән.

—Сүз һаман улыгыз турында инде, Сара Кыямовна. Ишетмәдегезме әле, малаегыз безнең хакта гәзиткә язган бит, Җәвидне, янәсе, без үтергәнбез... Корреспондент килгән. Тикшерә...

Хуҗабикә бу сүзләрдән лып итеп артына утыра язды, аякларының тотрыгы шиңә бара, егылмыйм, дип, тизрәк урындыкка килеп чүмәште.

—Ай, Алла, күпме тукыдык, укытучылар белән каршылыкка кермә, спорлашма, шым бул, дидек. Тыңламаган икән... Әй бала!

—Алма агачыннан ерак тәгәрәми...—директор хатын читкә карап, беркавым уйланып торды да тәвәккәл тавыш белән сүз башлады.—Мин сиңа малаеңнан зарланырга да, үземне кызгандырырга да килмәдем. Син зур җитәкче булып эшләгән кеше, әйдә, тыныч кына икебезнең дә хәлләрне ачыклыйк әле. Давыт язмасын укыдым мин. Мәктәптәге кайбер укытучыларыбызның тупаслыгы дөрес әйтелгән. Шул хурлаулардан Җәвиднең муенына элмәк салуы да ышандыра. Тик тегеләргә нинди җәза элэгер, белмим, ә менә минем башка таяк төшәсе хак. Давыт язмасы

чыкса, урынымда каласы кеше түгелмен. Ярар, мин киттем, ди. Ә син, Сара Кыямовна, нәрсә отарсын? Малаена Алтын медаль эләгерме—менә мәсьәлә кайда. Мәктәп коллективы өйдәге чүпне дөньяга сипкән улыңны аямаячак. Бу—бер. Икенчедән, районда җәнҗал куптарган кеше турында ишетергә дә теләмәячәкләр. Кая ул медаль тоттыру?! Чөнки югарыдагылар төпкә, тирәнгә карый. Җәнҗалчы бит бүген монда низаг чыгара, иртәгә тегендә дөньяны айкый... Мондый кеше югарыга кирәкми, аңлыйсынмы, Сара сеңлем?

—Аңлыйм, Сәмига Кәшфиевна! Давытка шул фетнә ябышмасын дип куркам бит,—диде Сара төшенке генә.

—Менә, менә, мин дә бит сиңа шуны искәрттем. Һавалы диюем шуңа ишарә иде бит. Тәртибең ошамаса, төкерәләр белемеңә... Давытны коткару синең кулда, Сара сеңлем... Ничек?—дип аптырама. Әгәр бу язмасын гәзиттә чыгартмасаң, мин Давытка Алтын медаль вәгъдә итәм, шикләнмә!

—Әй, Сәмига Кәшфиевна, шундый өмет бирсәң, мин инде нишләргә дә риза.

—Мин әйтсәм—эшлим, Сара Кыямовна!

—Тик менә ничек итеп Давыт язганны ташка бастырмаска соң, Сәмига Кәшфиевна? Малай үзсүзле бит минем.

—Беләм. Малаеңны үгетләүдән файда чыкмас. Синең ана булып, корреспондент белән сөйләшүеңә генә өмет тотам мин. Сиңа ике сүз әйтергә кирәк, Сара сеңлем. Башта Давыт язмышын кабартырга кирәк. Сез Казаннан торып аның мәкаләсен басарсыз, эш күрсәтерсез, ә монда минем улымны терелэй ашаячаклар бит диярга кирәк. Алтын медаль тәтеми икән, институтка эләкми ул диң. Икенчедән, буе булса да, Давыт әле бит балигълык яшенә җитмәгән яшүсмер, бала гына бит диярга кирәк. Ә бала-чага башына ни килмәс тә ни китмәс? Бездә бит бала гамәле өчен ата-ана җавап тота, диң. Мин исә, анасы буларак, Давытның бу куркыныч язмасын бастыруга каршымын, закун минем якта дип тә куркыт. Мондый шартта кайсы редактор мәктәп баласының гаугалы хатын басар соң, Сара Кыямовна?

—Әйе шул!—Сара күкрәгеннән ташны алып ыргыттылар диярсең.—Әйтәм, Сәмига Кәшфиевна, сез сөйләгәнне дә, күңелемдә кайнаганны да әйтәм мин ул гәзит кешесенә.

Директорга ияреп Сара мәктәпкә юнәлде. Сәмига Кәшфиевна кабинетында гаҗәп итагатьле Казан кунагы белән ялгызы калып, күз яшьләренә манчылып, гозерли-гозерли Давыт хатын ташка басмаска ялварды ул...

Әй, ана! Тормышның әллә нинди авырлыкларын татып, күпме җил-янгыр, кимлек-хурлыклар кичереп, кешелеклегеңне саклаган, намусыңны сатмаган Сара ана! Рухыңа ят кына түгел, хәтта чит, каршы булган кешенең тозагына нишләп шулай тиз каптың, сатылдың соң әле син? Бала бәхете диденме? Газиземә Алтын медаль, матур киләчәк, бәхетле язмыш яулыйм дисеңме?.. Ярар, монысы кеше күзенә ананың олы шәфкате, мәрхәмәте булып күренсен, изге йөрәкле булуын расласын. Әйдә, еракган килгән хакыйкать кителмәсен, сабые хакына ана нинди генә хәтәр адымнарга, корбаннарга бармый шул...

Ә син, Сара ана, буй тарткан, акыл тешен ярган һәм үзе дә кеше булырга җыенган баланны үз шәүләң белән каплауны ничек аңлатырсың? Ул минем йөрәк парәм, аны мин генә иркәлим, теләсәм, һаман да итәгемдә тотам диярсеңме? Ә син шул уйларың белән балаң аша тик үзеңне сөйгән вак җанлы зат итеп күренермен дип шикләнмисеңме, ана? Әйе, әйе, бала синең өчен тик аяклы мәхәббәт көзгесенә әверелә. Көзге-сурәт килешләрәк,

матуррак булган саен, сиңа үзеңне сөю, ярату хисләре ныграк бәреләә, алар сине көчлерәк иркәли...

Тик анла, көзге чагылышы алса да, бу балаңа сукыр, кысыр мәхәббәт, ана. Син әлеге бу хисләрең белән газизеңне томалыйсың, аның юлына аркылы төшәсең, хәтта тора-бара аны тере мәеткә үк әйләндереп куясың бит. Ник менә шул нечкәлекләрне зиһенеңә алмадың, Сара. Ичмасам, гамәлеңә ниятләгәнче Давытның үзенә сүз катарга, Хабул белән киңәш корырга кирәк иде. Ана булсаң да, бала язмышын берүзең хәл итәргә кем хокук бирде соң сиңа, Сара. Аллаһмы? Закунмы? Түрәме? Бала үрмәләп киткәч тә, аягына баскач та, кеше булып китә бит ул. Ул һич тә кемнеңдер чагылышы түгел. Аның үз сызланулары, шатлык-сөенече бар. Сукмакны да үзе теләгәнчә салырга хакы бар аның. Заманны да үзенчә кора һәм яшәүне дә үзенчә яши бит бала дигән янәшәдәге ерак кеше... Шулай булгач, баланны үз нәфесеңнән чыгып шәүләң белән капларга ни хакың бар, Сара ана? Гөнаһлы гамәл бу! Бу адымыңның әче нәтиҗәләрен күреп, әй сызланырсың, сыкранырсың әле син, ана...

Журналист киткәч, Түреш мәктәбендә тормыш янә үз эзенә төште. Кыңгырау шалтырады, бер укытучыны икенчесе алыштырды. Дәрес бирделәр, җавап тоттылар, иншалар язылды, контроль эшләр башкарылды. Давыт та тыштан шул агымга ияргән сыман. Ләкин аның күңелендә көн үткән саен гамь көчәя, гәзиттә хатының басылуын көтә. Хәзер инде бу хакта шикләнми ул, Әнәс абыйсы басабыз дип өзеп әйтте бит.

«Татарстан яшьләре» киләсе көндә, өстәлдән күпме эзләсә дә, гәзит папкасын тапмады Давыт.

—Нәфисә апа, «Татарстан яшьләре»н берәрсе алып чыктымы әллә?—дип сорады ул китапханәчедән.

—Синең гыйсьян гәзитеңне директор алды. Ай-һай, кертер микән?

Чынлап та, әлеге яшьләр гәзите урынына кайтарылмады. Давыт мәктәптән кайткач та, почта ташучы Гөлсирәне сагалый башлады. Аларның очында берничә кешегә «Татарстан яшьләре»н китерәләр. Шунда кулына гәзитне алып күзләп кала ул. Менә Давыт капка алдына чыгып янә Гөлсирәне көтә. «Юк, энем, сине басмаганнар», дип еракан ук хат ташучы хәбәр салды ана. «Булмады, дип эчтән сызланды егет. Инде яңа ел да үтте. Гыйнварның яртысы бетеп бара...»

Янәдән йортка аяк басты Давыт. Сыер аранынннан әнисе чыгып килә иде, сүз катты:

—Улым, син шул гәзит дип җан атма инде. Тынычлан! Хатың басылмас синең...

—Каян беләсең моны, әни?

—Корреспондент белән үзем сөйләштем. Басмагыз, дидем. Гәзит бала-чага эше түгел, улым. Синең укуыңны төгәллисең бар. Без бит күптән әйтеп киләбез сиңа, укытучыларың белән бәйләнмә, укуыңны бел, дибез. Нинди бетмәгән тискәрелек соң бу? Аптырагач, мин үз сүземне әйттем. Һәм дөрес эшләдем.

—Менә бу яңалык!—Давыт аяк астындагы кар кисәкләрен тибеп очырды. Мин, юләр, гәзит көтәм тагын... Рәхмәт, әни, син мине терелэй суйдың болай булгач... Халык алдында мин бит ялганчы кешегә әйләнәм. Басмаганнар, димәк, ялган! Вәт хурлык. Сездә иман бармы? Барыгыз да чукынып бетегез!—Давыт капканы бәреп ачып, кая барасын да белмичә карлы урамга ыргылды.

Давытның анасына бәреп әйткән беренче каргышы иде бу.

«Пәйгамбәр» дөрес сизенгән, редакциягә хат язучыга «ялганчы» кушаматы чәпәргә торучылар озак көттермәделәр. Нәгыймә Харисовна

әдәбият дәресенә кергәч, тема игълан итәргә ашыкмады.

—Укучылар, карагыз әле бүген безнен мәктәп өчен нинди сөенеч, Ирекнен шигырьләрен гәзиттә басканнар.—Укытучы класс каршында тотып районда чыга торган «Ленин юлында» гәзитен күтәрде.—Менә сурәте дә бар. Яле, Хәйруллин, тактага чык, таныштыр безне үз иҗатын белән.

Хәйри салмак кына такта янына атлады. Бу инде кайчандыр Сәйфиев малаена мөрид булып йөргән кыбырсык «Акбаш» түгел. Ул хәзер атасы—сельсовет рәисе Гомәр Гаффарович кебек житди чырайлы, салмак һәм һәрчак үлчәнгән, дөрес сүзләр генә сөйли. Киемгә дә бик таләпчән—чалбар, күлмәк һәрчак үтүкләнгән. Шунадырмы, укытучыларның һәркайсы анын белән бик әдәпле, итагатьле сөйләшә. Чынлап та, Хәйринең кешене үзенә карата торган матур чалымнары бар шул. Менә әле дә ул укытучы сузган гәзитне кулына алмады. Шигырьләрен яттан сөйләп китте. Күзләренә нур чыкты, тавышында рухлану аһәңнәре яңгырады.

Кыр казлары китә,  
Кыр казлары!  
Жылы якка алар китәләр.  
Кыр казлары киткәч жылы якка,  
Монсуланып кебек иртәләр...

Хәйри шигырьләренә класс ихластан кул чапты. Шул күтәренке мизгелдә күрше Әмир авылыннан йөреп укучы төртмә телле Барый болай дип кычкырды:

—Апа, бездә бит каләм тотучы авторлар Хәйри генә түгел, мәсәлән, Давыт язганны ник басмыйлар?

—Динисламов, син моны Галиәсгаровның үзеннән сорасаң дөресрәк булыр иде.—Нәгыймә Харисовна тавышында әртистлык көчәйде.—Мин исә үземә кагылганына болай дип жавап бирәм, Барый. Гәзит бит ул теләсә нәрсә баса торган урын түгел. Язганны башта бик нык тикшерәләр. Дөресме, ялганмы? Дөрес булса гына басалар. Ә ялган гәзиттә чыкмый кала, укучылар. Аңлашылдымы?

Шул каһкаһәле сүзләр, әлбәттә, партасына сеңгән Давытка ишарәләнгән иде. Моны күпләр сизде, аңлады. Үзен сөзеп үткән дистәләрчә карашлардан егет куырылып куйды. Ялганчыны кем өнәсен?.. Өйгә дә Давыт үз-үзен күралмас бер хис белән кайтты.

—Бар, әни, Нәгыймә Харисовнага аңлат. Давыт язганнар барысы да дөрес иде, тик мин генә гәзиткә бастырмаска куштым, диген... Югыйсә, класс каршында ук мине ялганчы дип атый башлады бу укытучы.

Ана үз чиратында баласына нәрсәдер кычкырырга жыенган иде. Кисәк телен тешләде. Сәмига Кәшфиевнага ышанып дөрес эшләдеме соң ул?

Бер кадерең китсә, китә бит. Химия дәресендә тактага яза-яза магний белән реакциягә кергән матдәләр турында сөйләгәндә «редакция» дип ялгыш сүз ычкындырды Давыт. Шаркылдап көлделәр. Өлкән яшьтәге Кәримә апалары да елмаймый булдыра алмады:

—Әй, Галиасгаров, бу гәзит—редакция дигәннәре синең мигә үк сеңгән икән. Ахыры хәерле булсын, балакай!

Ахыры хәерле булсын... Шул уйлар белән тәэсирләнеп Давыт мәктәптән кайтышлый Түреш инеше тарафларына сугылды. Ач тамак үзен сиздерсә дә, аяклар никтер өйгә тартмый. Монда сулышка да, жанга да рәхәт. Ташу кузгалырга тора. Карлы инеш өсте көмеш күлләвекләр белән тулган. Кыр ягыннан сил төшсә, барысы ургып торган дәртле ташкынга әйләнәчәк инде... Давыт исә күңелендәге ургу-ташудан курка. Барысы бергә жыелып, укмашып

тора бит. Әнисенең яшерен адымы аны кеше каршында хурлыкка гына төшереп калдырмас әле. Директор һәм үчле укытучылар каршында көчсез, коралсыз да итәр. Әһә, син безне гәзиткә язып, тәүбәгә китерергә теләгән идең.

—Көт, без үзебез синең иманыңны укытырбыз, «пәйгамбәр». Ни чара кыла алырсың хәзер? Үзең әләкче, ялганчыга чыктың. Гәзиттәгеләргә тәнкыйть өчен мине рәнҗеттеләр дип инде зарлана алмыйсың. Кулыңнан корал төшкән, көчең беткән, Галиасгаров. Анаңа үпкәлә! диярләр. Житмәсә, алда дәүләт имтиханнары, аттестат алу тора.

Ахыры хәерле булсын... Мәрхүм Жәвид язмышы белән әсәрләнеп Түрештәге битарафлыкка, мәкергә, икейөзлелеккә каршы күтәрелим дигән иде... Менә үзе шулар корган тозакка килеп капты. Ничек аннан араланырга? Тагын өскә пычрак, шакшы ыргытсалар, ташкын кузгалып аның үзен һәлак итәргә дә мөмкин бит. Жәвид янәшәсеннән гүргә иңүенне дә сизмәссең... Әй, әни, нинди базга төшереп яптың, чарасыз иттең син мине? Ничек котылырга соң шул гажизлык, чарасызлык дип аталган баздан?

Малаеның сөмсере коелуын ата да сизми йөрми, күрәмсең. Йортта утын әрдәнәсен кардан арчып, тәртипкә китереп ятканда, Давыт янына Хабул килде. Эштән кайтуы, кибеткә дә сугылган бугай, култык астында төргәк бар.

—Әйдә, эш качмас, прәннек белән сыйлыйм.

Сый, татлыга мәче кебек сузыла торган малай бүген ашкынмады:

—Өлгерермен, эти, әрдәнәне ипкә китерим инде...

Ата дикъкать белән улына багып торды:

—Әйт, Давыт, мәктәбеңдә берәр зыян-зәрәт бармы әллә?

—Бар, эти,—диде Давыт. Һәм ул Жәвид үлеме уңае белән Казан гәзитенә хат язуын, әнисенең моңа нинди мөнәсәбәт күрсәтүен, хәзер укытучыларның әләкче, ялганчы дип үзенә таш атарга җыенуларын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ата малайны тыңлаганда ук каш җыерып, әледән-әле башын чайкап торды, аннары сузып кына:

—Пәр-рәч... Хәлгә тарыгансың бит син, олан. Болгаткан анаң дөньяны!

Нәкъ шул вакыт чиләкләрен күтәреп ана кеше баскычтан төшеп килә иде. Хабул ашыгыч эше бар сыман кычкырды:

—Кил әле, Сара! Давытның хәлләре турында нишләп миңа әйтмәден, ник кинәшмәден син. Малайга прокурор булдыңмы?

Сара хәлгә, үчегүгә бик тиз төшенеп алды. Аны шома гына үткәреп җибәрергә дә ымсынды:

—Нәстә, чәйнәшеп торырга! Үзең бит Давытка тукый килдең. Шым бул, укытучылар белән әрепләшмә, дидең. Нәстә, малайның медальсез калуын телисеңме?

—Мин берчакта да медаль, аттестат хакына малайның кешелеген сатыйк димәдем. Булса була, булмаса юк!

—Нәстә, Давыт, безнең кебек Сәйфиевлар колы булып калсынмы? Гомер буе тирес корты сыман казынсынмы? Ә институтка керер өчен Алтын медаль кирәк. Шуның өчен Сәмига Кәшфиевнага баш идем шул. Сина ни, бала ни дә, машина ни...

—Ә син, Сара прокурор, Сәлимә Кәшфиевнаң Давытка Алтын медаль тоттырыр дисеңме?—Хабул кисәк йөзенә үчегүле елмаю әсәре чыгарды.—Кунак ашы кара-каршы, Сара Кыямовна! Син мине урынымда калдырттың. Мин малаена медаль бирәм. Рәхим ит, Сара Кыямовна... Син моңа ышанасыңмы?

—Ник ышанмаска? Бирер! Син дә ышан. Мин гел хәлне яхшыга юрарга кушам сине...

—Ышанып шул хәленә төштең дә инде. Мине дә, сине дә Сәмигаң кебек ике аяклы этләр таладылар бит. Онытгыңмы?

—Ул сугыш вакыты иде. Хәзер замана башка, кешеләр башка...

—Күзеңне ач, Сара! Һаман шул битлекле адәмнәр кулында дөнья. Иблис, албасты да әллә кая урман эчендә, чокыр-чакырда ятмый. Шуларның берсе зәңгәр күзле Сәмигаң булып, малай жанын кимерә. Әй, сукыр булып, малайны кеше каршында адәм ыстырамы итәсен. Яшендә үзен үтерә яздың... Инде жанын һәлак итәргә жыенасыңмы?

Давыт әтисенең бик нык ярсыганда гына була торганча йөзе кызарып китүен, янак итләре биешеп торуын күрде. Йөрәге тотмасын тагын!..

—Туктагыз, зинһар! Үзем гаепле. Ни күрсәм, үзем күрермен. Бала түгелмен!—дип Давыт та йөрәк белән кычкырды.

Шуннан соң ачы кычкырыш бетсә дә, барыбер өйнең яме китеп барды. Атабаш белән анабаш ничек «сайрашадыр», Аллаң белсен, Давыт исә табыннан, учактан читләште. Укыймы—укымыймы, жаны үзенең аулак почмагына китеп ялгыз калуны теләде. Кушылган йорт, бакча эшләреннән арынса да, гадәтенчә өйгә, тәм-том эләктерергә ашыкмыйча, бакча артларына, су буйларына төшеп китте. Кичләрен гармун, жыр тынмаган тыкрыкка да күңеле тартмый башлады аның. Үзен гел албасты сыман киеренке, авыр уйлар басты һәм күңеле белән бик ачык тойды—өстенә ташкын килә Давытның...

Юраганы юш килде аның. Бер-бер артлы ике дулкын бәрде. Өченче чиректә гомердә булмаган хәл: өч фәннән «дүртле» чыгардылар аңа. Сәйфиев хатыны Хәтимә Кәлиевна биологиядән чәпәде бу билгене. Нәгыймә Харисовна Давытның контроль язмасыннан урынсыз берничә тыныш билгесе табып, татар теленнән «дүрт» куйды. Сәмига Кәшфиевна да тартынып тормады, «Син Галиасгаров, тарихи фактларга сәяси нигез бирә белмисең»,—дип сукрана-сукрана дәрестәге жавапларына «дүртле»ләр тезде дә, чирекне шул билге белән йомгаклап та куйды. Сәмига Кәшфиевна кешене тамга-калыпка салуның остасы бит. Кулында мөһер дә бар. Бәхәсләшә алмыйсың. Сыйныфта Хәйри Хәйруллин, Әлфия Шәрифуллина уку, фән нигезләрен үзләштерүдә сокландыгыч күрсәткечләргә ирешсәләр, Давыт Галиасгаров тырыш укучылар рәтендә калды...

«Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт! Монда үлем! Монда патша-газраилләр...»

Ялгызы калган сәгатьләрдә телгә һаман яраткан шагыйре Һади Такташның шул юллары килеп торды. Рәхмәт бу сердәшкә! Жанны коткаруның мондый юлы да бар икән бит. Тамга-калыбыңны салып калдырасың да, каргалган бу дөньядан китеп югаласың. Ә дөнья зур бит! Анда битлексез, чын кешеләр дә бардыр әле... Мәмлүк-мөһажир булып жан саклау әмәле жимерелгән Болгардан ук килә ласа!..

Өченче чиректән соң Давыт «пәйгамбәргә» дәүләт имтиханнары ничек булыр, дип күрәзәлек кыласы калмады. Хуш исле ландыш, умырзая чәчәкләре арасында күмелеп утырган комиссия әгъзалары каршына килеп тоткан жаваплары белән дә егет әлеге фәннәрдән «бишле» ала алмады...

Сара ана мәктәптәге өлгергәнлек аттестатын тапшыру кичәсенә кияр дип, Давытка бик килешле, үтә затлы костюм сатып алган иде. Ул киеп карау түгел, хәтта күз дә салмады:

—Әни, фрак киеп күңеленә ятмаган аттестатны алырга лаек кеше түгелмен мин.

Һәм үзенең гадәттә кигән замоклы вельвет курткасын, манжетлы кара чалбарын киеп кичәгә чыгып китте ул. Дөрес, күлмәкнең агын, үтүкләнгәнен киде. Китәр алдыннан патефон кабызды. Хабул әле яз гына Аксудан пластинка алып кайткан иде. Яңа бер жырчы Гөлзадамы, Минзифамы, Мөнзиләме шул түгәрәктә... Ата да, ул да әй әйләндерделәр әлеге жырлы түгәрәкне. Малай янә шул «Киек каз юлы» белән юанды.

Уза гомер, сүнә гамем,
Менәлмәдем инде бу юлы.
Әмма мине әүвәлгечә,
Тарта күккә киек каз юлы...

Моңлы жыр, әйтәсе юк. Бәгырьне өтә... Сара үзе дә сизми хискә чумды. Әй, кешеләр бәйрәм дип мәктәпкә жыена. Чәчәк-букет бәйли, кием-салым сайлый. Ә Хабул ишетергә дә теләмәде. Төкерәм мин жан ашаучыларга, диде. Хәер, ана үзе дә бармас, аяклары тартмас иде шул. Сәмига Кәшфиевнаның йөзенә карарга ук чиркана бит Сара. Чырай түгел, юха битлек бит анда. Ялгышты шул, әй хаталанды Сара. Гафу ит, улым, газизем! Медальсез калсаң да, яшьтәшләреӊ алдында йөзеӊ ак, вөжданың саф булыр иде. Халык та медальгә үрелә алмавыңның чын дөрес сәбәбен белер, төшенер иде бит. Кичер гөнаһлы ананны, улым!

«Киек каз юлы» исемле жыр яңгыратып, күңелдә әллә нинди хисләр, уйлар кузгатып кичәгә дип киткән иде Давыт. Тик шул китүдән өйгә әйләнеп кайтмады егет. Суга төшкән янсә һавага ашкан кебек эзсез-нисез югалды Сара белән Хабулның газиз малае. Атна узгач та, ай узгач та, ел булгач та табалмадылар аны. Якын-тирәләрдә, тегендә-монда сөрсегән, янган, тапалган мәетләр табып экспертлар тикшереп тә карадылар. Давыт түгелме?.. Юк, расланмады.

Август азакларында Казанга барып укырга урнашкан Әлфия Сараларга килгән иде. Әй гүзәл, әй инсафлы бу РТС башлыгы Ярмиевнның төпчек кызы! Тик Давытны хәтергә алып сөйләгәндә күзләре яшьләнде:

—Сара апа, үлмәгән ул! Мин моңа һич ышанмыйм. Тик менә ничек сезне, безне ташлап киткән ул... ничек безне ташлаган?..

Сугышта булса, хәбәрсез югалды, дип әдрис буенча кәгазь язып кешегә нокта куярлар иде. Ә монда, тыныч Түрештә нишләргә?

Кәгазь дигәннән, Давытка бәйле тагын зур мәрәкә калды. Кичәгә дип чыгып китсә дә, малай мәктәпкә бармаган икән бит. Кул куеп аттестатын да алмаган ул... Монысы да кеше башына сыймады. Ун ел букча сөйрәп әзерләткән шаһәдәтнамәгә ничек төкерергә була? Сәмига Кәшфиевна кеше аркылы әллә ничә кат Галиасгаровларга искәртте: «Аттестатларын килеп алсыннар!» Юк, Хабул да, Сара да барып алмады аны. Мөгаен, һаман да директорның яшькелт сейфында ятадыр ул...

...Сара үзе дә, анын яз саен оядан төшеп чирәм арасына кереп чүмәшкән бәбкәләре дә нишләп һаман күккә, киек кош юлына күз салалар соң? Бәбкәнеке аңлашыла, күк анның канында, асылында бар. Канатлар чыкса, очмыйча син түзеп кара?! Ә ана, канаттан мәхрүм ана, күктән ни көтә? Давытның жаны жирдә калмас, күккә, гарешкә ашкандыр дип уйлый, күрәмсең. Мәңгелектәге жаннар сәфәрендә улым белән янә бер очрашырмын әле дип өметләнә микәнни Сара ана?

## XXVI бүлек

Пәнжешәмбе таңы атып килә... Хабул белән Сараның шәригать белән хушлашу көне булыр бу. Ахирәткә сафланып аяк басарга кирәк. Мунча ягармын, дип уйлады карчык һәм сыкрана-сыкрана салкын идәнгә басты. Тамак әрнесә, сызласа да, йөрергә була әле. Сара әүвәлге эше итеп су белән даруларын йотты. Иншаллаң, аяктан екмас әле. Инде бүген түзсә, нәнкир-мөнкир каршына басып, шәрәйтүл иманын тотарга да була... Кинәт ул үз-үзеннән имәнеп китте. Әле ун-унбиш ел элек булса, яшьрәк Сара бүгенге Сараның ләкатьсез уйларыннан оялыр да иде. «Кит, дөрес булса да, әйтмә... көферне башыңа салма!» дияр иде...

Көферен көфер... Гайрәтле адәм күңеленә ятышмаган сүзләр анысы. Тик

адәм заты яши-яши дә көне, сәгате житеп дөньялыкны ташлый бит. Түрештә булмаса, Аксуда, тегендә-монда һәркөнне кешеләр үлеп тора. Алар соң нәрсә уйлый икән? Дөньялыкны кайгыртудан мәгънә юк. Телгә шул ахирәт сүзе инә бит, жанга шул юаныч бирә. Кеше үз башына төшсә генә, дөнья хикмәтен аңлауга ирешә шул. Читнекен беркем белми, төшенми. Аның сере генә түгел, авырту-сызланулары да үз тышчасы белән таш дивар кебек томаланган бит. Аны да беркем сизми, тоймый. Дөньяга ара-тирә инрәгән аһ-зарлардан яисә акыру-бакырулардан нәрсә тоясың? Моны ишетергә генә була, сизеп булмый, синеке авыртмый. Кеше шул авырту-сызлануларын кап яисә яшьник кебек, үзенә төяп, ахыр чиктә дөньядан китеп тә бара шул.

Газаплы, әрнешле бәндәдән арынгач, дөнья, әй сафланадыр, әй тынычланадыр инде... Таңнар да бүтәнчә ата, кичләр дә башкача байый башлыйдыр бөтәшкән жан көегеннән башка. Хәят тә кемнәргәдер бөтенләй иркенәеп, яктырып каладыр ул. Кеше өлешенә кереп, яшим дип тартышырга кирәкмидер шул. Һәркемгә тигезме-юкмы, замана бүленгән. Яшәвенне яшә дә, китеп бар. Ничек китәсең, анысы һаман адәмгә кагылмый. Бу синең хокук, синең сайланыш. Якты дөньяда читләр кулына эләкмәслек һәм кеше урламаслык тик ике нәрсәң бар икән, Сара. Синең яшәү, синең үлем...

Хужабикә түр ягында яткан карты тарафына юнәлде:

—Кыңгыравың шалтырамады, исән-иминсеңме?

Хабулның карчыкка төбәлгән күзләрендә елмаю әсәре чагылды:

—Кың-гырау кайгысы ю-юук! М-мот-торны кабыз-за алмый и-и-интектем...

—Һай, менәтерә! Төш күрә идеңмени?

Хабул башын селкеде.

Сара сөйләнә-сөйләнә иренең астын рәтләде, мендәр, юрганын җайлаштырды. Битен, кулын юдырды. Күптән уйлаган ниятләре хакында ничегрәк сүз башларга икән, дип аптырады. Аптырарсың шул, Хабулның аяктан егылган көннәре белән чагыштырсаң, бөтенләй алга китеш. Аяк-кулларын үзенчә тота, тарта-суза. Билен дә күтәрә. Әле беркөн куллары белән караватт башына тотынып торып ук утырды. Чәен дә үзе эчә. Тик кашык тотарга гына кулы калтырый. Өстен, түшәген пычратыр дип, ашавын Сара ашата сырхауны. Хабулның паралич сугып түшәктә ятуына өч ел тулды. Ир-ат дигәнең дөнья йөген тартуга маһир булса да, эчтән нәзек шул. Эче тиз өзелә. Кемдер Сарасы белән бик нык кычкырышкан, шуңа Хабулның башына кан йөгергән, дип Түрештә гайбәт тә таратты. Юу-ук! Сара түгел, түрә биртте ир башын. Һаман шул битлекле, жан ашаучы түрә заты аякка таяк тыкты...

Хабул житәкләгән кырчылык звеносы Керкәле кырында алтмыш гектар яхшы сортлы бодай чәчкән иде. Сабан туйлары тирәсендә шул кыр янынннан үткәндә Сара үзе дә бик сокланды. Куе, карасу-яшькелт сабаклы тере бодай басуы уңышка һич тә саранланырга җыенмый... Тик, тот капчыгыңны! Сәйфиев әлеге басуга ферма сыерларын керткән... Шул унай белән идарәдә бик нык кычкырыш киткән. «Минем сөт планым яна. Өстән бүген ашлык сорамыйлар, сөт сорыйлар. Миңа көтүлек кирәк», дип кычкыра икән Сәйфиев. «Көтүлеккә сусасаң, үлән чәч! Безнең сортлы бодай өстенә көтү җибәрергә ни хакың бар? Атаң җиреме бу?» дип председательдән дә ныграк сөрән салган Хабул. Тик Сәйфиев симез бит. Йөрәген дә биш катлы май урагандыр инде аның. Чуртым да булмады Сәйфиевка. Кычкырышырга өйрәнгән ул. Ә менә Хабулның кан басымы сикереп башына кан сауды шул. Мондый алчак кешеләр, хәйлә-мазар белмиләр, яуга ачык күкрәк белән ташланалар бахырлар...

Баштарак, төрлесен уйлады инде Сара. Телен дә әйләндермичә калакланган сыман ятты бит. Инде менә хәлләре яхшыга борыла дигәч кенә... Тик Сарадан

калса, аны кем карар соң? Кем астын алмаштытыр? Гарип булса да, ашынчаен әзерләргә кирәк. Анын кашык тотып, йотканын кем күтәр? Авылда чыбык очы күп булса да, кайсы кардәше түшәктә яткан картны карарга дип үз өстенә алыр икән? Кардәш ашка-чәйгә йөрешергә һәвәс булса да, ярдәмләшү хаҗәте чыкса, сәбәп таба бит ул... Сараны бу хәерсез тамак шеше алып китсә, ирнең дә эше хөрт инде. Икеләнергә урын юк, ният дөрес, бергә китәргә!

—Хабул, Алман кучтәнәченне онытмадыңмы? Бүген пәнҗешәмбе... атнакич...

—Хәл-ләр ничек? Там-мак?

Карчык иреннән мондый сорау көтмәгән иде. «Минем хәл белән кызыксына. Өметләнү юкмы, димәкче микәнни? Икеләнә»...

—Начар! Духтыр, операциягә диде бит. Бармадым... Үзең беләсең...—Сара хәлнең өметсез икәнен сиздереп кулын селтәде.

—Өй-лә-дән соң... Кичкә к-к-кал-мыйк! Кит-тик! Ан-ан-лад-дын-мы? Кеш-ше кер-сен!

Әй, бахыр! Төнлә, караңгыда, шыксызда мәетләр булып ятудан курка микәнни? Чынлап та, ызбада төнозын ике җансыз гәүдәнең таралып ятуы имәнеч булыр шул. Фәрештәләр куркыр... Фатыймага әйтеп куярга онытмаска кирәк әле. «Кызың чишмәдән кичкә су китерсен әле, диярргә кирәк»...

Күрше-күлән безнең китеп барганны белгәч, әй, ыгы-зыгы кубар инде! Фатыйма аһылдап килеп керер. Гапсаттар да озак тормас. Каршы яктан таягына таянып Камәрия җинги теркелдәр. Тагын башка күршеләр, урам очындагылар агылыр... Матәм мәҗлесеннән Шәрифулла мөтәвәлли каламы соң? Корьәнен тотып ул да килер. Өйдә моңлы мәкам, төрле сүрәләр яңгырар... Үлем-китем никадәр генә сагышлы булмасын, адәм өчен барыбер туй бит ул. Бабай тугач ясалган туй сыман, өйләнгәч, яисә кияүгә чыккач үткәрелгән кызыл туй кебек сөенечле, шатлыклы түгел, билгеле. Аның йолалары бөтенләй аерым, үзгә. Монда тегеләрдәге сыман җырлашу, биюләр юк. Кешене сагыш пәрдәсенә төреп, күңел түренә куеп, тавышсыз калып уйлау, зурлау, сагыну ята монда. Зурлау, олылау сагышы тирәнрәк булган саен мәрхүмгә дә әйбәтрәк. Күбәләктәй талпынган җаны сөенә. Сөенмәскә, матәм олылыгы Ходай каршында ахирәткә күчкән кеше затының кем, нинди булуын ачык күрсәтә бит ул...

—Ходайга тапшырыйк, Хабул!

—Тапш-шыр-рыйк, Бибис-сара!

Карчык күзләрен иренең карашыннан яшерергә теләгән иде. Тик аның дулкынланулы, назлы рәвештә үз исемен атавын ишеткәч, түзмәде, башын кыегайтты һәм Хабулның яшьләнгән, чыланган керфекләрен күрде. Тик, ни гаҗәп, чыраенда болыт әсәре юк, киресенчә, көләчләнә бара түгелме соң:

—Бибис-сара, к-кай-да без-нең гит-та-ра?

Сараның тамагына төер тыгылды. Бугазы чатнап әрнергә кереште. Көлсәң көл, еласаң ела! Ирнең хисләреннән шашкан чагындагыча: «Эх-ма, Бибисара, кайда безнең гитара?» дип биеп китәргә ымсынуы микәнни? Җефетенең җилкәләрен уйнатып кул чәбәкләвен, елмаеп такмак әйтүен көтәме:

Бие-бие, Хәйбулла!
Биегән кеше бай була...

Әй, биисе, такмаклап җырлыйсы иде шул. Тәннәре, аяклары очынып тыпырдый алмаса, җаннары биесен Хабул белән Сараның. Өсләренә тауташ ишелергә тора, һәлакәт килә, ә җаннары никах ныклыгына кинәнеп, һаман рухи берлек-бергәлектә булуга сөенеп парлашып бии... Яшь чакта, гайрәтле вакытта, тәннәр бер-берсенә язгы гөлләр кебек үрелгән мәлдә,

хәләл җефетләр кочаклашып бии ул. Ә менә әгъзалар тузып, берен аяктан гына түгел, телдән дә язып килгән картлык көнендә Сара белән Хабул кебек җаннарны бәйләү, бер-беренә елмаю әмәлен тап син, парлы кеше!

Шулай итеп, Алманнан кайткан дәһшәтле күчтәнәч боларны елатырга, күз яшьләренә батырырга теләдеме? Көт, капсалар да, синең алда тез чүгәргә җыенмый Галиасгаровлар, үлем куыгы!

Өйдә төрле хисләргә биреләп, озаграк юанган хуҗабикә. Баскыч төбенә үк килеп: «Нигә чыкмыйсың һаман?» дигән сыман кәҗәсе бәэлдәп тора. Сарыклары буш тагарак янында әйләнгәли. Тавык-чебешләре дә куначаларын ташлап йорт чирәме арасында тибенергә керешкәннәр. «Хәзер-хәзер малкайлар!» дип Сара һәркайсын тәрбияләү мәшәкатьләренә күмелде.

Бу шөгыленнән арынгач, мунча ягып җибәрде. Эш арасында һаман абзар бүрәнәсе ярыгында сакланган куыкларны искә төшерде. Кырык еллап гомер узган бит. Куәт-көче бетмәгәнме, дип хафаланды. Тычкан-фәлән тишмәгәнме, дигән уйдан шөбһәләнеп ахыр чиктә төргәкне кулына алды, өенә атлады. Ак куыкларда зыян-зәрәт шәйләнмәде. Аларны янә төрде һәм почмакка чәшкә эченә салып тәрәзә төбенә куйды. Алман күчтәнәченең сәгате сугуга да күп ара калмады шул...

Карчыкны сискәндереп кыңгырау шалтырады.

—Йомышың бармы?

—Чәй!—диде Хабул.

Әй, тишек зиһен! Хабулын ашатырга-эчертергә дә онытткан бит ул. Үзе тамактан язгач, башкалар да ураза тотар дип уйлады микәнни?

Тиз арада чәен, тәбәсен әзерләп, ирнең тамагын ялгады хуҗабикә. Инде тагын нинди мөһим эшләре кала? Әһә, Фатыймага кереп, чишмә суы хакында искәртергә кирәк!

Итәкләрен ычкырына кыстырган буйчан Фатыйма арт бакчаларыннан бәрәңге күтәреп керә иде. Кеше барын күреп, ашыгып күлмәген рәтләде.

—Нәстә, Сараттәй, тамак язылмыймы?

Сара авызын ачса да, сүз әйтергә өлгермәде, урамнан быргысын кычкыртып ниндидер ят машина узды һәм аларның капкасы төбенә килеп туктады.

—Сиңа Сараттәй... Духтыр чакырттыңмы?

—Юк! Кем булыр?—Сара кабаланып үз ихатасына юнәлде. Кабаланса да, сул аягын күтәргәнче, уны белән кая басыйм икән, дип биш уйлаган кортка күпме җир китә соң? Ул арада таза, килбәтле яшь ир машинадан төшеп капкадан йортка керде, сикереп-очып баскычка күтәрелде һәм ишектән дә кереп югалды. Нинди эшем кешесе бу? дип янә уйлап алды Сара. Күрше-күләннән, духтырдан башка адәмнең йортка аяк басмавына биш былтыр. Әллә соң Аксудан берәр табиб килеп төштеме?

Машина яныннан узганда, карчык аның гадәттән тыш матур булуына, шомалыгына, елкылдап торуына игътибар итте. Авылда йөргәннәр йортсыз алабай кебек, шыксыз-шөкәтсез булу өстенә бензин, май исләре чәчәләр. Моның борынга да зыяны юк... Кем йөрер бу шәп машинада!?

Сара, ниһаять, ишекне ачып, ызбага күз салды. Түгәрәк йөзле, сакалмыеклы әлеге өйгә кергән ир Хабул караватына иелеп нидер әйтәме, сөйлиме, ә түшәктәгесе балалар кебек җанланып тыңлый, елмая, мендәреннән башын күтәрә... Карчык бу тамашадан аптырап якынрак килде һәм... катып калды. Аннары илереп кычкырды:

—Давыт, синме бу, балам!

—Әни! Әникәем!

Баласы кочагында ана бөтенләй йомшарып күз яшьләренә күмелде. Елагач, бөтенләй җиңеләйде, рәхәт булып китте.

—Нинди духтыр килде дисәм...

—Әйе, мин табиб, әни! Хәлегездән фәрештәләр хәбәр бирде. Чирлисез икән... Кайттым менә, аякка бастырырмын әтине дә, сине дә...

Ана һаман йотлыгып улын күзәтте, куллары белән балачактагыча аның битен, кулларын капшап үтте.

—Улым, синме соң бу? Әллә Хозыр Ильясмы? Шул вакыт кая югалып тордың соң син, бала? Күпме еллар бит!

Ананың шелтә белән әйтелгән сүзләреннән сакаллы ир, малай чактагы кебек, кисәк кызарып куйды, яхшысынмыйча читкә төбәлде.

—Кичерегез, әни! Түрешнең кыр капкасы ачык булса да, мөһаҗиргә ил капкасы ябык булды бит. Үтеп булмады шул. Күзегезгә качкын булып күренәсем килмәде. Инде менә бикләр алына, илдә үзгәрешләр бара... Телевизор, радиогыз бардыр бит!—Давыт чыннан да әйткәнен күрергә теләгәндәй, ызбага күз йөгертеп алды.—Сез дөнья хәлләреннән читтәме әллә!

—Әйе, телевизор ватык. Ул радионы тыңласаң, баш кына авырта. Һәркайсы элеккене сүгә, сәвитнекен каргый. Хурланмаган башлык та юк... Халыктан чыкса, бер хәл. Һаман югарыдан торып кизәнәләр бит. Безгә нәрсәгә ул сүз боткасы?

—Хакыйкать тиз генә табылмый бит, әни?

—Хакыйкатьләрен белмим. Ә менә колхозны таркатып, авылны хәерчегә төшерделәр инде. Монысы хак.

—Колхоз таркалса, Гыймади крестьян кебекләр җиргә хуҗа булыр. Түрештә элек шундый кешеләр күп булган бит, әни.

—Әйе, Гыймадины еш искә төшерәләр хәзер... Ә син аны каян беләсең, бала?

—Белмичә, Сәмига Кәшфиевна нәкъ шул кеше хакында сөйләгәч, миңа «дүртле» чәпәде бит. Сәяси белексез, диде...

Сара ана жинел сулап куйды. Кыяфәткә кереп, Хозыр Ильяс кына килмәгән... Бу—аның баласы, Давыт!

—Хәтерең нык булса, шуны да әйт,—диде ана.—Әлфия дигән кызны истә тотасыңмы?

—Әлфия? Ярмиева Әлфия! Мине сораштымыни?

—Әйе, улым. Сине бик сагышланып телгә алды.

Давытның чырае да кисәк моңсуланды. Беркавым уйга батып торды:

—Әй, әни, бик күпне югалттым да, таптым да инде мин. Тик моны тиз генә сөйләп булмый... Курыкмагыз, хәзер сезне ташламам инде.

Давыт янә хисләнеп әнисен күкрәгенә кысты. Яратып әтисенең башыннан сыйпады. Һәм җай гына аларның авырту-сызланулары турында сораша башлады ул.

—Нинди хәл бу?—Табибны аңламассың, әллә житди шелтәли, әллә юри үчләнә.—Шул яшьтән авыруга сабышкансыз. Кеше кимендә йөзне яшәргә тиеш. Ярар, хәзер чәй куеп эчерсәгез, хакында тормам... Йөгереп йөрерсез!

—Әй, улым, кунакны сыйламый торам шул.—Карчык жилләнеп почмак якка кереп китте.

—Мин дә күчтәнәчемне оныткanмын, әни. Күчтәнәчсез кеше—нинди кунак? Диңгез арты күчтәнәчләре белән сыйлыйм әле үзегезне. Сезнең монда кибет, базар шыр күренде,—дип сөйләнә-сөйләнә Давыт машинасы янына чыгып китте.

—Сара!—диде Хабул карчыгын үз янына чакырып.—Күч-чтәнәч... Алман-нык-кын ыр-ыргыт! Дав-выт-ныкы бар бит! Һәм көрән күзләрен ялтыратып елмайды.—Шөк-кер! Пиг-гам-бәр к-кайт-ты!

Ыргыта, ыргытмыймы соң Сара Алманнан кайткан күчтәнәчне!

Тәшвишле, ни чарадан бичара куыгы инде бу. Гажизлек, өметсезлек чарасы. Явызлык кылып, дөньядан качарга карар иткән катыйльгә, бандитка яисә хыянәтчегә генә ярыйдыр ул. Ә Хабул белән Сара кешеләргә нинди начарлык эшләде соң? Нинди явыз гамәл бар боларда? Үлем кочагына нишләп ашыгырга тиешләр әле алар? Ходай шуны уйлап, әллә кайдагы Давыт күнеленә хәбәр салган да инде. Үлем куыгы Ходай иркенә бик ятышмаган нәрсә болай булгач, Иблиснекедер. Ярый, капмады куыкны, гөнаһлы булмады Сара белән Хабул.

Әйе, замана аларга бик кырыс булды. Гел рухларын кысты, жаннарын жәрәхәтләде. Чит-ят итте хәтта, шуңа үзләренә шеш жыйдылар да бит болар. Заманаaccount ташларга жыенулары да үзләрен артык кашык итеп тоюдан килде ласа. Тик «сезнеке», «безнеке» дип заманалар арасына кем казыклар каккан? Ходай биргән һәр көненә кинәнеп яшәргә кирәк. Давыт та әйтә бит, замана үзгәрә, хөррият, иркенлек, ачыклык ягына борыла ди... Ыргыта, ике дә уйламый ыргыта Сара бу гөнаһлы үлем куыгын! Аларның хәзер таяныр газиз кешесе бар, яшәүгә кинәнеп, каршылыйсы яңа таңы бар...

Биштәр сумкаларын күтәреп Давыт өйгә кергәч, ана чәй әзерләргә кереште. Ә малай эти-әнисенә бүләкләрен, күчтәнәчләрен бушатып бетерә алмый. Хөрмәсе дә, әфлисуны да, лимоны да әллә ничаклы. Кап-кап һинд, цейлон чәйләре, каһвә-мазары да сансыз. Тагын әллә нинди Сара гомер күрмәгән ят ризыклар да өстәлгә тезелә тора...

—Карале, улым, ахирәтләремне дә чәйгә чакырыймчы! Искәрмәгән шатлык бит бу! Син кайттың, без дә исән-имин. Бәйрәм булсын әле йортка!

—Чакыр, әни, чакыр! Өстәл көйләргә үзем дә булышырмын...

—Кит, хатыншаланма! Мин сиңа шөгыль табам. Әнә мунчам өлгергән. Шәпләп парланып, мунча кер!

—Мунча яккан идеңме, әни? Мин кайтканны белдеңме? Менә шәп! Ерак юлдан иң яхшы сихәт бу!

Давыт жырлый-жырлый мунчага жыена...

Сара ана улы биргән даруны капкан иде, Ходайның рәхмәте, бөтенләй тамагы басылды. Хәзер ихлас гамьгә чумып чакырасы кунаклары, әзерлисе табыны турында уйлый. Давытны күргәч, барысы да «аһ» итәрләр инде. Ходай кушып, ызбасы сөенечкә, күңелле чөкердәшүгә чумар Сараның...

Хабул да электәге сыман түшәмгә текәлеп ятмый. Күңелле нәрсәләр уйлавы күзләренә үк бәреп чыккан. Алай гынамы әле, күчтәнәч эләктергән яшь бала сыман, әфлисун суырырга тотынган ул...

*Мин хикәяләүче буларак, Галиәсгаровлар тормышында бу атнакич булган сөенечле алмашынуларга кинәнеп карап тордым да, инде үземне монда артык һәм кирәксез кеше санап, шыпырт кына йорттан чыгып киттем. Яшермим, Сара белән Хабулның тирән өметсезлеккә төшеп дөнья белән хушлашырга жыенулары мине чиксез дулкынландырды. Кайчандыр йорт ташлаган малайлары Давытның кош сыман кайтып картларны үлемнән йолып калуына ихлас шатланып бетә алмыйм. Изге бәндәләренә Ходайның ярдәме, кодрәте чиксез киң бит, үлчәнмәслек бит! Инде Түрештә моннан да гыйбрәтлерәк тагын башка хәл килеп чыгар дип өметләнмәдем мин. Каурый каләмемне кынга салып авылдан ук чыгып киттем. Бу вакытта кырлар, урманнар, инешләр өстеннән 1985 елның кояшлы, чуак сентябре үтеп бара һәм жиргә беренче кыраулар төшеп, каен, чаган агачларын алтынсу төсләргә дә манчып өлгергәннәр иде.*



Рәшит
Бәшәр

## БЕР ҖЫР ЙӨРИ КҮҢЕЛЕМ ТҮРЕНДӘ...

### Туган ил

**Бер җыр йөри күңелем түрендә,
Ничек шуны җырлап бирәсе?**

**Җиләкләрне алга буяп йөри
Бөр буеның баллы иртәсе.
Үләннәргә алмаз чыгын коя
Каеннарның яшел бөдрәсе.
Яңа көнне көлеп каршы ала
Әтәч кунган усак киртәсе.**

**Бер җыр йөри күңелем түрендә,
Ничек шуны җырлап бирәсе?**

**Сабыйчактан аваз сала миңа
Туган  өйнең җылы нигрәсе.
Әнкәй токмач кисә. Кичен безгә
Күрше апалары керәсе.
Сөйләшерләр авыл хәбәрләрен,
Түгәрәклап өстәл тирәсен.
Төн уртасы житәр. Һәм лампада
Янып бетәр соңгы керосин.**

**Бер җыр йөри күңелем түрендә,
Ничек шуны җырлап бирәсе?**

**Мөнәҗәтче чибәр апаларның
Исән микән әле берәрсе?..
Көзгә чаклы яшел үлән инде
Әнкәй яткан кабер тирәсе.**

---

Рәшит БӘШӘР (1949) — *шагыйрь һәм прозаик; Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премиясе лауреаты. «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Йолдызлы тай» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Йолдызларга карап уйга чумган
Ятим өйнең такта түбәсе...

Бер җыр йөри күңелем түрендә,
Ничек шуны җырлап бирәсе?

Ерак сабыйчактан картлыгыңа
Хәтер юлы буйлап киләсең.
Киләсең дә...
Туган илнең йомшак
Туфрагына башың иясең!

## Истә

Инде күп нәрсәләр онытылды, бетте, дисәм,
Әйләнә дә кайта үткән, хәтер исән.

Күп нәрсәләр чыккан истән, җилләр искән,
Сукмакларга төрле-төрле үлән үскән.

Истә ләкин ак мендәрле якты өем,
Ишетәм дә җаннарыма якын көен.

Атлап китәм. Тәүге адым! «Атла, улым!»
Башта тоям әниемнең җылы кулын.

Еллар узды, җилләр тузды, арды җаным,
Сүлпәнәйде, салмакланды инде адым.

Өметләнәм: «Бардым. Барам. Барачакмын!—
Алда әле бирәчәгем, алачагым».

«Аякта тор! Аякта тор! Горур чагың!»—
Ак рәшәдән дәшә миңа балачагым.

Бар җиһанга тургай моңы түгелгәндә,
Арыш басуына кереп күмелгән дә,
Әнә бит ул... Әнә генә, янәшәмдә
Күкчәчәкләр өзеп йөри ак рәшәдә.

## Инкыйраз

Үзгәрде заманалар:
Мең татарга—бер гармун.
Егылганчы эчертер,
Бер татарга—ун бармен.

Шыплап тулган калалар
Төнге клублар белән.
Яшьләрнең табынганы—
Пугачева да Билан.

Менә шундый үзгәреш,
Менә шундый тизләнеш.
Татарлыкка кул селтәп,
Чит-ятларга тезләнеш.

## Тукайга эндәшү

Саумы, шагыйрь!
Заманалар инде яңа,
Баш очында мәңгелек шул кояш яна.

Җилгә каршы тупыр-тупыр чаба атлар,
Иярләрдә әллә кемнәр, бик тә ятлар.

Ташка бәрә, очкын чәчә каты тояк,
Буталынган: кайда көньяк, кайда төньяк?

Ирекле тик төштә генә хәлсез татар,
Уян дисә, баштанаяк уйда татар.

Ишегалды тулы кош-корт, сыер, сарык,
Көн-төн эшли. Тиен санап тәмам гарык.

Шәһәр дә шул, шау да шоудыр, бәйрәм итә,
Мөнбәрдә бай, фәкыйрьләре хәйран читтә.

«Туган тел»не җырлап куя әле халык,
Бала-чага бара инде телсез калып.

Онытылды инде күптән бишек җыры,
Уйда бары футбол кыры, хоккей кыры.

Урман сирәк, берәм-берәм кыр ягыннан
Шүрәлеләр качты инде Кырлаеңнан.

Сулар кача тирәнгәрәк, елга кипкән,
Су анасы инфарктган вафат күптән.

Исе яман, бик тә яман җир маенын,
Кәеф әйбәт, кесә калын ил баенын.

«Болгар»ың да очты инде гарешләргә,
Хәлләр шундый, йөрәк җылый гарь эшләргә.

Сау бул, Тукай!
Китапларың чыкмый торса,
Ил нигезе киләчәктә тәмам корса,
Үткәннәрдә дәүләт тоткан шанлы халык
Юкка чыкса... Ни кылырбыз, ни әйтербез?
Юкмыни соң шушы илдә кадеребез?
Уенчыкмы? Берәр җансыз әйберме без?

Сулар кача... Астан юа Казаныңны,
Гөнаһлар күп. Җир убылса? Батса Казан?
И Ходаем! Күрсәтмәче шушы казаң!

«Исә жилләр, күчә комнар...» Шагыйрь әйткән,
Күптән инде ятимнәр без әкияттән.

Исә җилләр, күчә комнар... Күчә комнар...
Киләчәктә шушы җирдә яшәр кемнәр?!

## Тарих

Кан нурлары сибеп
Атты яңа ал таң,—
Янды да көл булды
Кол Галиле Ватан.

«Тынычлыкта калдыр,
Ал, Ил кызын сатам!»—
Егылды, кол булды
Кол Шәрифле Ватан.

Мәдрәсә ача бай,
Гыйлем чәчәк аткан.—
Мәгърифәтле булды
Хак Тукайлы Ватан.

«Йә тынычлан, татар,
Юкса башың ватам!»—
Төрмәләрдә черде
Дәрдемәндле Ватан.

«Аздыра халыкны
Бу милләтче шайтан».—
Илдән сөрде улын
Исхакыйлы Ватан.

Сталин ГУЛАГыннан
Исән-имин кайткан.—
Якты бер манзара
Урманчелы Ватан.

Авылда, шәһәрдә
Моң ташый һәр чаттан,
Татар җаны—монда,
Бу—Сәйдәшле Ватан.

...Кырык миргә инде
Ачык синең капкаң.—
Татарлыгың сакла,
Ак Барслы Ватан!

## Яшәеш

Кем кечкенә, кемнәр зур,
Кем хәерче, кемнәр бур.
Кемнәр затлы, кемнәр хур—
Очты илдән, очты нур.

Кемнәр кот та, кемнәр пот,
Кемнәр шут та, кемнәр мут—
Адәм җаны тоташ ут.

## «Казан утлары»ның үз сайты эшли башлады

Игътибар! Хәзер бездә басылган әсәрләрнең шактый өлешен интернет аша уку мөмкинлеге бар. Күптән түгел журналыбызның үз сайты ачылды. **www.kazanutlary.ru** адресы буенча кереп, таныша тора аласыз. Әлегә сайтны камилләштерү эшләре бара. Аны кызыклы һәм файдалы итү җәһәтеннән сездән тәкъдимнәр, фикерләр көтеп калабыз.



Ркаил
Зәйдулла

## ШУЛ БУЛДЫ ЭШ...

### (И минем яктыртучым!)

ДРАМА

**Катнашалар**

Тукай

Кара җиләнле—шагыйрьнең тәкъдире

Зәйтүнә

Фатих, Вафа, Ибраһим, Солтан, Кәбир, Шакир, Сәгыйт—Тукайның дуслары, әшнәләре

Җиһан—Зәйтүнәнең апасы

Шакир—Зәйтүнәнең абыйсы

Гөлсем, Фатыйма, Әминә—Зәйтүнәнең дус кызлары

Беренче ир—уяу

Икенче ир—Марат Ульмасович

Өченче ир—Шафкат Маратович

Дүртенче ир—куркыныч кыяфәтле

Беренче хатын

Икенче хатын

Өченче хатын

Доктор—табиб

Мария Карловна—немец теле укытучысы

1 нче жандарм

2 нче жандарм

Кызыл бантлы кешеләр

Төнге патруль: Күн, Матрос, Эшче

Малай

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962)—*шагыйрь, прозаик, публицист; «Ил», «Мәгарә», «Ташка ордым башны» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге әдәби премияләре лауреаты. Казанда яши.*

## Башлам

*Юл чатында Зәйтүнә басып тора. Тукай күренә. Зәйтүнәне күргәч, туктап кала.*

Тукай. Зәйтүнә! Син?..

Зәйтүнә. Мин, Габдулла, мин.

Тукай. Син монда нишләп торасың?

Зәйтүнә. Сине көтәм, Габдулла.

Тукай. Бу юлдан китәсемне мин үзем дә белми идем. Син кайдан белдең, Зәйтүнә?

Зәйтүнә. Күңелем сизде. Йөрәгем монда килергә кушты.

Тукай. Йөрәгеңә рәхмәт. Үземнең дә сине күрәсем килгән иде. Бәлки, миңа да бу юлга чыгарга йөрәгем кушкандыр?

Зәйтүнә. Әйе, Габдулла, акыл карышса да, йөрәкләр бер-берсенә тартыла шул. Минем сине күреп каласым килде.

Тукай. Нигә күреп каласың? Без әле... без әле, Зәйтүнә бәгърем, шундый кавышырбыз, беркем аера алмас.

*Янәшәдән кара җиләнгә бөркәнгән берәү үтеп китә... Бераз баргач туктый. Зәйтүнә аны күрми. Җил чыга, караңгылана.*

Зәйтүнә. Ялган сөйләмә, Тукай, сиңа килешми.

Тукай. Җил чыкты.

Зәйтүнә. Шулай да әйт, син кая юл тотасың?

Тукай. Мин ул сорауны үземә дә еш бирәм. Мин әле кая барам? Мин әле... кая барам? Зәйтүнә, син үзеңнең иртәгә кая барып чыгасыңны әйтә аласыңмы? Без барыбыз да Ходай хөкемендә.

Зәйтүнә. Алайса әйт, бу юл кая илтә?

Тукай. Бу юл—йолдызларга таба.

Зәйтүнә. Анда сиңа ни калган? Сизәсеңме, җил чыкты. Хәзер яңгыр явачак. Иң яхшысы, Габдулла, син безгә кайт.

Тукай. Кайда ул—сез?

Зәйтүнә. Чистайда. Чын әгәр, шәһәр читендә безнең үз өебез бар. Өй кечкенә булса да күңелебез киң.

Тукай. Беләм.

Зәйтүнә. Чын күңелдән чакырам, Габдулла.

Тукай. Халык ни әйтер, ә, Зәйтүнә? Татар кызы ят бер егетне өенә алып кайткан! Бу бит—сенсация!

Зәйтүнә. Ни?

Тукай. Вакыйга! Гайре табигый вакыйга, Зәйтүнә туташ. Чистай мишәрләренә ай буе сөйләргә азык булабыз бит.

Зәйтүнә. Сезнең Печән базары түгел инде.

Тукай. Әллә үпкәләденме? Халык кайда да бер ул, үсә төшкәч аңларсың әле.

Зәйтүнә. И сөрхәнтәй... Ни дип сөйләп торган була. Минме үсмәгән? Әле генә ишан улыннан яучы килгән иде.

Тукай. Сөрхәнтәй? *(Көлә.)* Әйбәт әйттең. Мин чыннан да сөрхәнтәй. Валлаһи!

Зәйтүнә. Гафу ит инде, Габдулла. Мин бит... уйламыйча... Яратып әйтеп ташладым.

Тукай. Уйламыйчамы, яратыпмы?

Зәйтүнә. Син... әллә ниләр әйттерәсең...

Тукай. Йә, ишан улының яучысы нинди җавап алды инде?

Зәйтүнә. Әни әйтте, Зәйтүнә кызыма әле бераз үсәргә кирәк, диде.

Тукай. Минем белән бер сүздә икән әниең.

Зәйтүнә. Әле бит күптән түгел генә апаны кияүгә бирдек. Җамал апаны. Хәтерлисеңме?

Тукай. Хәтерләмичә... Агылый да тагылый кебек сез бит гел икәү йөрдегез Казанда. Икәүдән-икәү рәхәтләнеп сөйләшә дә алмадык.

Зәйтүнә. Менә хәзер сөйләшәбез бит.

*Җил көчәя. Яңгыр сибәли. Кара җиләнле Тукайны әйдәп кулын болгый.*

Тукай. Сөйләшәбез, Зәйтүнә! Әле тагын күпме сөйләшербез... Киләчәк—безнеке! *(Кулын җәя.)*

Зәйтүнә. Ә беренче очрашуыбызны... хәтерлисеңме, Габдулла. *(Тукайга сыена.)*

Тукай. Хәтерләмичә, Зәйтүнә. Андый мизгелләрне онытып буламыни? *(Кочаклый.)*

Зәйтүнә *(кочактан шуып чыга).* Карангы төште. Мин кайтыйм инде. Син барыбер үз юлыңнан борылмассың. *(Китә.)*

Тукай.
И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр жирдә шәм;
Нәрсә ул дөнья кояшы! Син миңа нур бирмәсәң!

## Беренче пәрдә

### Беренче күренеш

*«Әл-ислах» редакциясе. Ул гап-гади фатирда урнашкан. Ике өстәл, урындыклар, диван. Ишегалды тәрәзәсе ачык. Фатих, Вафа, Ибраһим, Солтан газета чыгару белән мәшгуль. Фатих, аяклары йөрмәү сәбәпле, коляскага утырган.*

Ибраһим. Ниһаять! *(Учы белән өстәлгә суга.)*

Вафа *(сискәнеп).* Ә?

Ибраһим. Әзер дим гәзит...

Вафа. Өнемне алдың. Аны кешечә әйтсәң булмыймыни?

Ибраһим. Син бит колак итен ашадың, Вафа, басмаханәгә тапшырырга өлгермибез, дип... Хөрәсәннәр, имеш, фәлән-төгән.

Фатих. Тукайның шигыре кердеме соң?

Вафа. Шигырь? Монда бернинди дә шигырь юк.

Солтан. Аны беләсең бит инде, Фатих. Ахыргача сузмаса, Тукай Тукай буламы?

Ибраһим. Әйе шул, абый. Тукайсыз гәзитнең тәме калмый *(кулын селтәп укый.).* Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт;

Бу үлек вөжданны җанландыр, җылың белән җылыт!

Фатих. Кайда соң үзе?

Солтан. Ишетмисеңмени?

*Ачык тәрәзәдән тавышлар ишетелә: «Хәрәмлисен!», «Тимәде бит!», «Алдаша бу Апуш абый!», «Һай, шәп эләкте!».*

Вафа. Жыен бала-чага белән ишегалдында кузналы уйный.

Солтан. Бүген ике кесә тутырып ашык төяп килде ул. Оттырып бетермичә урыныннан кузгалмас.

Фатих *(урыныннан калкынып куя).* Бу нинди сабыйлык, ә? Ничә әйттем мин аңа. Татар шагыйре... Бөек шагыйрь! Бала-чага белән кузналы уйнап ятсын инде, ә... Бераз солидный булырга да вакыт, югыйсә.

Вафа. Һи, аны әйтәсең син... Ул әле Ташаяк ярминкәсендә агач атка атланып та әйләнә.

Солтан. Бөтен бала-чага аның янында...

Ибраһим *(Фатихка).* Абый! Үзең беркөнне сөйләп тордың бит: шагыйрьләрне бала-чага, хатын-кызлар һәм этләр ярата, дип.

Солтан. Әйтәм аны Тукайның исен сизүгә үк Казан этләре һау-һаулап өрә башлый. Яратканга күрә икән!

Вафа. Тукайның шигырьләренә тел тидерүем түгел, тик хатын-кыз дигәндә...

Ибраһим. Өстенә бастың! Әнә икәү килеп ята.

Фатих. Кемнәр?

Вафа *(тәрәзәгә үрелә).* Кичә дә Тукайны күрергә дип килгән иде алар. Чистай кызлары. Исемнәре ничек иде соң әле, аты коргыры.

Фатих. Тишек хәтер! Шушы яшеннән кызларның исемен оныта...

Солтан. Апалы-сенелле алар. Жамал белән Зәйтүнә.

Фатих. Менә бит! Солтаннан үрнәк алыгыз.

*Ишек кагалар.*

Керегез!

*Жамал белән Зәйтүнә керә. Алар ул замандагы татар кызлары кебек киенгәннәр. Бусага катында туктап калалар. Зәйтүнә кыюрак—ул апасының жиңеннән тартып түргәрәк әйди.*

Солтан. Кызлар!

Фатих. Хәерле көн, туташлар.

Вафа. Нигә ишек төбендә туктап калдыгыз, түргә узыгыз.

Зәйтүнә. Хәерле көн, әфәнделәр.

Фатих. Үтегез, үтегез, ятсынмагыз. Вәгаләйкем әссәлам!

*Зәйтүнә апасына төртә. Алар алгарак үтә.*

Жиһан. Әйбәт кенә яшәп ятасызмы?

Солтан. Әйе, әле утырып ята идек.

Фатих. Солтан! Утырыгыз, кызлар. Менә урындыкларга рәхим итегез.

Ибраһим. Сезне күрүгә без чиксез мәмнүн. *(Урындыкларны жайлап куя.)* Килегез, кызлар, кыенсынмагыз.

*Кызлар утыра.*

Фатих. Инде хәзер танышыйк, туташлар.

Жиһан. Иң башта дога кылыйк *(кулларын жәя).* Әгүзе билләһи...

Солтан. Вәт!

*Барысы да битләрен сыпыра.*

Вафа. Дөрес! Догалы эш уң була.

Солтан *(кыланып).* Әлхәмделилла...

Фатих. Инде белик, безнең шыксыз хөжрәбезгә нинди асыл затлар аяк басты икән? Фәрештәләр түгелме?

Зәйтүнә *(көлеп).* Юк, фәрештәләр түгел шул, Фатих абый. Гап-гади жир кызлары. Мин Зәйтүнә исемле, апам—Жиһан.

Фатих. Менә бит... Минем исемне дә беләсез икән. Ә болар Казан егетләре—Солтан, Вафа, ә бу—энем Ибраһим. Нинди жилләр ташлады үзегезне? Кайсы яклардан? Безнең Яңа Бистә кызларына охшамаган үзегез.

Жиһан. Чистайдан без, Фатих абый.

Ибраһим. Һо-о, Чистайның үзеннән!

Зәйтүнә. Без сезне күптән беләбез инде, Фатих абый.

Фатих. Шулаймыни?

Зәйтүнә. Әйе, сезнең хикәяләрегезне бик яратып укыйбыз.

Фатих. Рәхмәт, рәхмәт, кызлар.

Солтан. Чистай нишләп ята анда?

Зәйтүнә. Без киткәндә утырып ята иде.

Фатих. Үзегез монда озаккамы?

Жиһан. Әйе, күчеп килдек. Без мондагы урыс-татар школында укыйбыз.

Ибраһим. Ә-ә... Алайса, сез...

Фатих *(Зәйтүнәнең борсалануын күреп).* Зәйтүнә туташ, нидер әйтергә телисез, ахрысы.

Зәйтүнә. Дөресен әйткәндә, Фатих абый, без монда Габдулла Тукайны күрергә дип килгән идек.

Солтан. Аңа йомышыгыз бармы әллә?

*Тәрәзәдән: «Хәрәмләден, Апуш!», «Тиде! Тиде!» дигән тавышлар ишетелә.*

Жиһан. Кемнәр кычкыра анда?

Вафа. Урам малайлары кузналы уйный.

Зәйтүнә. Тукай монда көн дә килеп йөри дигәннәр иде.

Жиһан *(сеңлесенә төртеп).* Зыян юк. Безнең аңа йомышыбыз юк, болай гына.

Зәйтүнә. Без аның шигырьләрен бик яратабыз. Шуңа үзен дә күрәсебез килгән иде. Ниндирәк кеше ул?

Ибраһим. Шагыйрь нинди була? Алып гәүдәле, зур башлы. Бер утыруда бер сарыкны ашап бетерә. Бер төчкерсә Тегәржеп урамына кадәр ишетелә.

Фатих. Ибраһим!

Жиһан. Энегез бик шаян кеше икән, Фатих абый.

Ибраһим. Мин шунды-ый.

Фатих. Тукай бүген килмәде әле. Шулай да мин аны сезнең белән таныштырырмын.

Ибраһим. Һа...

Вафа. Тукай кызлар күрсә былбылга әверелә ул. «Син булмасаң» дигән шигырен беләсездер *(сөйли.)*

И матур! Мин янмас идем—яндыручы булмасаң;

Таммас иде жиргә яшьләр—тамдыручы булмасаң!

Бер минутта ташлар идем бу томанлы моңнарны,—

Син мине мескен кылып моңландыручы булмасаң!

Ибраһим. Шундый ул...

Жиһан *(Зәйтүнәнең жиңеннән тарта).* Без китик инде...

Зәйтүнә. Бигрәк хәле мөшкел икән Тукай абыйның...

Фатих. Ни диим? Ул яндыручы әле шагыйрьнең хыялында гына.

Ибраһим. Әйе! Алдан сизенеп шулай яза ул.

*Тукай йөгереп керә. Аның сулышы капкан. Чалбарының тез турысы үлән яшеленә буялган.*

Тукай. Фатих! Корт чаккыры! Тәки оттым бит бу юлы *(Әле кызларны күрми. Ашыгып читтәге өстәлгә бара.)* Ун ашык алып килгән идем. Хәзер менә ике кесәм тутырык! *(Кесәсеннән алып ашыкларын өстәлгә куя бара.)* Бер, ике, өч... жиде, сигез... *(Кесәләренә суккалый, әмма алар буш. Аптырап.)* Нигә монда сигез генә соң? Мин бит откан идем!

Фатих. Габдулла!

Тукай. Аһ, тәмуг кисәүләре! Әтәмби караклары!

Фатих. Габдулла!

Тукай. Мин аларны *(борыла.)* Ә? *(Кызларны күреп.)* Мин... ни...

Зәйтүнә (аптырап). Габдулла?

Фатих. Әйе, мәшһүр шагыйребез Габдулла Тукай җәнабләре...

*Зәйтүнә кулын сузып Тукайга таба килә.*

Зәйтүнә. Габдулла Тукай...

*Тукай аның кулына орына да тиз генә чыгып китә.*

Фатих. Габдулла!

Зәйтүнә. Бу ул идеме соң?

Ибраһим. Ә сез аны ыспай гәүдәле, күзлекле дип уйлаган идегез, шулаймы?

Жиһан. Зәйтүнә, әйдә, киттек! Күрмисеңмени, бездән көлә бит болар.

Фатих. Гафу итегез, туташлар. Сездән көләргә һич уебызда юк. Аллам сакласын. Үзегез дә күрдегез, Тукайның бүген кәефсезрәк чагы.

Солтан. Оттырса гел кәефсезләнә ул.

Жиһан. Тукай башы белән малайшалай арасында кузна уйнап йөриме? Булмаганны, Зәйтүнә, әйдә дим, болай да соңга калдык.

*Кызлар кузгала.*

Фатих. Кызлар, зинһар өчен гафу итегез. Тагын килегез, ишегебез һәрвакыт ачык.

Жиһан *(узалдына).* Әллә нинди кешеләр монда...

Зәйтүнә. Киләбез, Фатих абый! Киләбез! Сау булыгыз!

*Кызлар чыгып китә.*

Фатих. Унайсыз хәлдә калдык.

Вафа. Ә сез күрдегезме, Тукай белән теге кыз күрешкәндә бармакларыннан очкын чыкты!

Солтан. Юкны сөйләп торма әле.

Ибраһим. Кызлары чибәр бит... Ут чыкса да гажәп түгел.

Солтан. Бигрәк тә Зәйтүнәсе. Терекөмеш кебек, ә?!

*Тукай керә.*

Ибраһим. Һә, менә качкын да кайтып керде.

Солтан. Шагыйрь! Шагыйрь ул кызларга ябышып ятарга тиеш, ә син качып йөрисең.

Фатих. Алай ярамый бит инде, Габдуллажан.

Тукай. Мин алар белән ни сөйләшим?

Фатих. Мин сөйләшәм бит әле.

Вафа. Өйрән, шәкерт!

Тукай. Минем буш сүзгә фантазиям житми.

Фатих. Йә, хуш иттек. Гәзитәгә син шигырь бирмәдеңмени?

Тукай *(кәгазь суза).* Менә.

Фатих. О! *(Укый.)*

Чын бәхетледер—кулың тоткан колың;
Бер фәрештә күнледәй пакьтер кулың.
Яшь күнелне тотып ычкындырмый һич,—
Бер сихерле, серле кармактыр кулың.

Син моны әле генә язып кердеңме?

Тукай *(кызарып).* Юк, кичәгенәк язган идем.

Фатих. Яхшы! Вафа номерга урнаштыр шигырьне.

Вафа. Менә бит! Пәйгамбәр дими ни дисең?! Бүген кызлар кулын тотасын да кичә үк белеп торган.

Ибраһим *(Солтанга узара).* Күрдеңме, Солтан, муза пәйда булды.

Солтан *(акрын).* Аңа муза, мина кызы!

## Икенче күренеш

*Калку төштә Тукай. Ак япанча бөркәнгән. Кулында китап. Ул бу юлы кузна уйнаучы малайга бөтенләй охшамаган. Аста, бер почмакта кара җиләнгә төренгән кеше бөкшәеп утырган. Ул Тәкъдирне гәүдәләндерә, ахрысы.*

Тукай.
Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да,—
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күңелемдә минем шигырь утым саумы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз—һаман да яз,
Шагыйрь күңлендә кыш булмый да кар яумый.

Җырлый-җырлый үлərмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә...

*Өч-дүрт кеше, ике-өч хатын кыз йөгереп керә.*

Беренче ир. Кем ул? Кем кычкыра?

Икенче ир *(Тукайга)*. Әй син! Чаплашка! Төш аннан! Нәрсә канатларынны җәйден?

Беренче хатын. Мин йоклап кына киткән идем.

Өченче ир. Әйе! Йокларга жыенган идек.

Икенче хатын. Боже мой! Бу татарлар совсем обнаглели! Кара инде, Казанда! Татарча кычкырып маташа!

Өченче хатын. Туктагыз әле, бәлки, ул ярдәм сорыйдыр?

Беренче ир. Төш дим, йолкыш!

Дүртенче ир *(куркыныч кыяфәтле адәм)*. Йомдырам мин аны хәзер, к чертовой матери.

Беренче хатын. Малайка! Бәлки икмәк ашыйсың киләдер?

Тукай. Уяныгыз! Бер-берегезгә карагыз! Сез бит бер-берегезгә елмаеп карый да белмисез. Эчегез тулы зәһәрлек, явызлык, көнчелек. Бер-берегездән уздырып йортлар саласыз, фаэтуннарда җилдерәсез, ә үзегез ярлы-ябаганын, ятимнәрнен соңгы тиенен таларга оялмыйсыз. Сезнен өчен ил дә юк, ватан да юк, милләт тә юк. Сез Алланы оныткансыз! Ул хәрәм байлыкны үзегез белән алып китә алмассыз. Анда баргач ни дип җавап бирерсез? Туган телегездән, илегездән йөз чөердегез, таш пулатларга кереп качтыгыз. Тик Аллаһ хөкеменнән кача алмассыз!

Беренче ир. Кем бу? Ни сөйли ул?

Беренче хатын. Безне гаепли түгелме соң?

Икенче ир. Милиция чакырырга кирәк.

Икенче хатын. Авылдан киләләр дә! Нидер таләп итәләр! Авылда кеше калмады. Җир сөрүче юк, дип кичә генә әнкәй SMS җибәргән.

Өченче ир. Әйе! Монда килеп «Азатлык!» кычкырып йөриләр. Җыен эшлексез. Кайтып кит авылга. Пулный азатлык! Тирес чыгар, корт чүплә.

Икенче ир *(кесә телефонынннан чылтыратып маташа)*. Серый! Серый! Кайда йөри бу? Охрана, имеш *(чылтырата)*. Майор? Монда безнең каршыда бер шизик. Кычкырыпмы кычкыра. Наряд җибәрегез. Хәзер үк. Митинг дим монда, митинг!

Дүртенче ир. Чакырмаска иде. Мин аны хәзер үзем дөмбәслим.

Беренче хатын. Исеректер ул. Зарар юк, айнытып чыгарырлар.

Беренче ир. Һе! Таныдым. Бу бит газетка язучы. Шагыйрь кисәге. Исеме ничек соң әле, аты коргыры. Мулла малае... Габдулла... Габдулла...

Өченче хатын. Тукай!

Икенче ир. Булмагае! Тикшерерләр.

Икенче хатын. Алайса, аны психбольницага җибәрергә кирәк. Кайдан чыккан Пушкин?!

Өченче ир. Әйе! Мин дә таныдым. «Болгар» номерларында тора ул.

Беренче ир. «Болгар»ны җимерделәр бит инде. Бер төндә урынын җир белән тигезләп куйдылар.

Беренче хатын. Алайса, йортсыз-җирсез калганга кычкырадыр ул...

Өченче хатын. Бичара...

Икенче ир. Булмаганны... Ул тузган йортта беркем дә яшәми иде. Без аны хөкүмәт кушкач җимердек. Бу да

Тукай түгел. Самозванец бу! Тукайны мин беләм. Банкетта янәшә утырган идек. Депутат ул. Мыегы да бар. Бик тәртипле кеше.

Беренче хатын. Әй! Кем син? Нишләп йөрисең?

Тукай.

Кайчан кем сайлады Тәңре мине бу хак Пәйгамбәр дип,
Мине үзенә лаек күрде, фәрманым тәгаллләр дип.
Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә,
Ашамый, эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә.
Барлык якыннарым—дуслар, карендәшләр, замандашлар
Миңа каршы котырдылар, рәхимсез аттылар ташлар.
...Ходайга кылмадым үпкә золымнардан, каһәрләрдән;
Теләнче рәвеше белән мин качып чыктым шәһәрләрдән.

Беренче хатын. Сөбханалла! Кем ди үзен? Пәйгамбәр ди түгелме соң?

Икенче ир. Мания величия!

Өченче хатын. Бичара...

Өченче ир. Туктагыз әле. Шактый шома чыга түгелме соң сөйләгәне. Кем дидегез әле исемен?

Беренче хатын. Габдулла...

Өченче ир. Тагын?

Беренче хатын. Нәрсә тагын?

Өченче ир. Атасының исеме ничек?

Беренче хатын. Әллә инде. Белмим. Тукай диделәр түгелме соң?

Өченче ир. Габдулла Тукаевич! Булды. Аңладык кем икәнеңне. Төш безнең янга. Бик мөһим сүзем бар иде.

Өченче хатын. Әйе! Төш, Шафкат Маратович әйткәч...

Беренче ир. Сине бит халык шагыйре диләр. Халыктан аерым торма!

Дүртенче ир. Төш диләр сиңа! Алып төшимме, Шафкат Маратович?

Өченче ир. Тик тор! Габдулла Тукаевич! Көтәбез.

Барысы да. Көтәбез! Көтәбез!

*Тукай алар янына төшә.*

Өченче ир *(игътибар белән Тукайны күздән кичерә).* М-да... Киемен бик таушалган, шагыйрь иптәш. Йортжирсез яшәргә дошманыңа язмасын. Әсин безгә дошман түгел. Шуңа күрә мин сиңа эш тәкъдим итәм.

Тукай. Мин эшсез түгел.

Өченче ир. Эшнең төрлесе бар. Эш икән—кешегә дә файдасы булсын, үзеңә дә кереме калсын. Озын сүзнең кыскасы шул—миңа реклама язучы кирәк.

Тукай. Мин...

Өченче ир. Тукта, тукта... Реклама ул—сәүдәнең моторы, жаным. Авызыңа жылы аш тияр. Аш кынамы... Берничә айда мин синнән кеше ясыйм, жүләр. Миңа синең кебекләр кирәк. Юкса (кулын селти) берсе ни дип язып килгән? «Күңелле булыр жәең, эчсәң «Караван» чәен.» Хи-хи-хи.

Барысы да *(Тукайдан кала).* Ха-ха-ха...

Өченче ир. Бу рекламамы? Әкыш көне эчмәскәме? *(Пауза.)* Аннары, үзара гына әйткәндә, чәй эчеп кенә ерак китеп тә булмый... Ха-ха-ха...

Барысы да. Ха-ха-ха...

Тукай. Сезгә миннән ни кирәк?

Өченче ир. Әйттем бит инде. Реклама бүлегенә утыртам мин сине. Слоганнар уйлап чыгарырсың. Карале, син чәчеңне нинди шампунь белән юасың?

Тукай *(чәчен сыпырып).* Әллә тагын...

Өченче ир. «Амый» дигән шампунь белән юарга кирәк, туган. «Иң шәп шампунь «Амый», бер кавык та калмый!» Ничек? Шул-шул. Монысын үзем уйлап таптым.

Тукай. Сез мине кемгә саныйсыз?

Өченче ир. Курыкма. Башта үзем өйрәтермен. Син сәләтле генә күренәсең.

*Сирена тавышы ишетелә. Ике жандарм керә.*

1 жандарм. Бу нинди митинг? Санкциясез *(икенче ирне күреп ала.)* А-а, Марат Ульмасович! Исәнмесез, исәнмесез *(кул бирешәләр.)* Менә без килеп життек. ОМОН да юлда.

Икенче ир. Нинди ОМОН? Ахмак!

1 жандарм. Соң... митинг дидегез бит.

Икенче ир *(кулын селти).* Әнә Шафкат Маратович белән сөйләшегез.

Өченче ир. Инцидент тәмам, майор. Без аңлаштык. Сезне юкка борчыганбыз.

1 жандарм. Сез аңлашкансыздыр

да... Зерә анда-монда чабып йөрергә без бала-чага түгел. *(Тукайга күрсәтә.)* Кем бу?

Беренче ир. Дөресен әйткәндә, экстремист бу, иптәш майор. Татарларны фетнәгә чакыра бу. Туган телдә укырга да хакыгыз юк, нигә йоклап ятасыз, ди.

Икенче хатын. Әйе! Россиягә каршы котырта.

2 жандарм *(Тукайга).* Документы!

*Тукай кесәсеннән таныклык чыгарып бирә.*

Тукай. Мин экстремист түгел, мин—шагыйрь.

2 жандарм. Габдулла Тукай. Тукай... Тукай... Таныш исем. Колакка кергәне бар *(1 жандармга.)* Безнең исемлектә юкмы икән ул?

1 жандарм. Шагыйрь диме? Чынмы?

Өченче хатын. Чыны, чын!

1 жандарм. Чын булса, экстремист инде ул. Тоткарларга кирәк, соңыннан ачыкларбыз кемлеген.

2 жандарм *(Тукайга).* Китабыгызны бирегез әле! *(Тукайның кулыннан китабын ала.)*

Өченче ир. Майор! *(Читкәрәк алып китә, нидер аңлата.)*

1 жандарм *(уйланып).* Килгәнкилгән, без буш кул белән китә алмыйбыз.

2 жандарм *(Тукайның китабын актара).* Әһә! Исемә төште—бу китапка арест салынган иде. Тыелган китап бу.

Беренче ир. Әйтәм бит! Әйтәм бит! Экстремизмны әллә кайдан сизәм мин. Ваһһабит түгелме икән бу?

Өченче ир. Китабына арест салынгач, тоткарлагыз шуны гына. Буш китәсегез килмәгәч.

1 жандарм. Ну баш та инде үзегездә, Шафкат Маратович! Кайдан шундый бөек фикерләр башыгызга килә... Гражданин китап! *(2 жандармга)* Исеме ничек диден әле?

2 жандарм *(тышына карый).* Габдулла Тукай, дип язылган.

1 жандарм. Габдулла Тукай китабын, экстремистик әдәбият исемлегенә кергәнлектән, кулга алырга!

2 жандарм. Күптән кулымда инде.

1 жандарм. Киттек.

*Китапны тантаналы рәвештә алып китәләр. Халык тарала.*

Өченче ир *(Тукайга визиткасын бирә).* Иртәгә сәгать унга офиска кил. *(Тукайның аркасыннан кага.)* Эш көтә сине, егет! Балда-майда йөзәсен бар әле. Киләчәгенне уйла. Шундый талант белән эт типкесендә йөрергә, ышту син... *(Китә.)*

*Тукай визитканы карамыйча да бөгәрләп читкә ыргыта.*

Тукай. Мин әле кая барам?

*Кара жиләнле торып тиз адымнар белән чыгып китә. Тукай да акрын гына аңа иярә.*

**Өченче күренеш.**

*Шәрык клубы. Халык әдәби кичәгә жыелган. Ир-егетләр кара кәләпүштән, кызлар ак күлмәк, ак калфактан. Ханымнар калфак өстеннән ефәк шәл дә бөркәнгән. Тукай кара костюмнан, галстук таккан, башында да кара хәтфә кәләпүш. Ул кешеләрдән аерым—ялгыз басып тора. Сәхнә читендә кара жиләнле бөкшәеп утыра. Ак күлмәкле, кызыл хәтфә калфак кигән Зәйтүнә кызлар арасында. Почмактагы тәбәнәк сәхнәчектә салмак кына оркестр уйный. Гимназистка кызлар программа һәм гәзитләр сата. Чибәр генә хатын-кыз култыклаган Шафкат Маратович бер читтә басып тора. Ул монда очраклы килеп эләккән бугай.*

Гөлсем. Ишеттегезме, бүген беренче тапкыр татар егетләре хор белән жырлаячак!

Фатыйма. Ишетмичә! Аларны Аги әфәнде инде ярты ел әзерли. Егерме ике егет!

Жиһан. Кызлар хоры да булачак диделәр бит. Абау! Кемнәр икән ул? Кем кызлары икән? Ничек йөрәкләре житә?

Әминә. Син әллә аларны татар кызлары дип уйлыйсынмы? Музыка мәктәбеннән килгән хор ул. Трентер

ханым алып килде. Татар җырларын махсус өйрәнгәннәр.

Зәйтүнә. Татар кызларына ни булган? Мин рәхәтләнеп җырлар идем.

Әминә. Син җырларсың... Синең кебекләр бездә сирәк шул.

Гөлсем. Һи, без әле шундый итеп җырларбыз, аяк тибеп биербез. Маржалар да шаккатып калыр!

Фатыйма. Әйе, аларны шаккатырасыбыз бар әле.

*Фатих коляскасын тәгәрәтеп кызлар янына килә.*

Фатих. Кызлар, кайсыгыз бүген минем белән бии?

Гөлсем. Фатих абый, мин!

Фатыйма. Юк, бүген минем чират!

Җиһан. Минем белән дә биерсез бит, Фатих әфәнде?

Фатих. Рәхмәт, кызлар. Коляскам чыдам, барыгыз белән дә биермен. Зәйтүнә генә миңа карамый.

Зәйтүнә. И Фатих абый! Баядан бирле тутырып карап торам, үзегез игътибар итмисез.

Фатих. Белмим, белмим. Карашың гел бүтән якта.

Гөлсем. Зарыгып Тукайның сәхнәгә чыгуын көтә ул.

Фатих. Барыбыз да көтәбез. Бүген ул Казан сәхнәсенә беренче тапкыр чыга.

Игълан итүче. Сәхнәдә—яшь шагыйребез Габдулла Тукай!

*Тукай акрын гына укый башлый.. Зәйтүнә истәлеге: «Кулында бөгәрләп тоткан бер кәгазе бар иде. Тавышы бик каты да, йомшак та түгел—уртача. Яхшы итеп, интонация белән укый».*

Тукай.
Кайвакытта кара күзле, кара кашлы
Матур белән утырамын кара-каршы.
Шунда ул кыз, әллә ничек, сүзгә китеп,
Күргәннәрен, белгәннәрен сөйли башлый.

Мин күзеннән аның күземне алмагач,
Һәр сүзенә «чын, чын» димичә калмагач,
Мин гашыйкны сүз аңлый дип уйлый инде,—
Кадап куйган һәйкәл төсле кузгалмагач.

Һаман сөйли. Мин тик иренен, тешен карыйм.
Йөртәм күзне: калкып чыккан түшен карыйм.
Борынын, авызын, иякләрен, беләкләрен,—
Калмый бармак, тырнак—һәрбер төшен карыйм.

Мин ул кызны, үз уемча, фәрештә дим.
Дөнья белән ваклануын һич теләмим.
Аңар күрә үземне бик түбән саныйм,
Анын урыны күк йөзендә, гарештә, дим.

Минемчә, тик яралган ул сөелергә,
Сөяргә һәм куанырга, сөенергә.
Күргән саен, минем төсле гашыйкларга:
«Бу минеке булмас!»—диеп көенергә.

Шулай итеп сәгадәтле сәгать үтә,
Ул да торып, үз урынына чыгып китә.
Белмәс хәлне,—яшь нәрсә бит, аңлый алмас,
Кычкырсам да: «Кочаклашыйк, тукта! Тукта!»

*Кул чабалар. «Афәрин!», «Мең яшә!» дигән тавышлар ишетелә. Сәхнәдән төшеп килгән Тукай өстенә Зәйтүнә конфетти сибә. Алар сөйләшкәндә уйнаучы оркестрның тавышы ишетелми, биючеләр дә шәүләләр кебек кенә тоелалар.*

Зәйтүнә *(Тукайның кулын тотып).* Габдулла әфәнде! Сез шулкадәр матур сөйләдегез. Котлыйм! Чын күңелдән уңышыгыз белән котлыйм!

Тукай. Рәхмәт, Зәйтүнә туташ. Тик нинди әфәнде инде мин сезгә? Габдулла гына диегез.

Зәйтүнә. Сез миннән олы бит. Килешмәс.

Тукай *(көлеп).* Абый диегез, алайса. Миңа абый диюче юк әле моңарчы. Урам малайлары да мине Апуш дип кенә йөртә.

Зәйтүнә. Сез артык гади күренәсез. Ләкин сез гади түгел.

Тукай *(көлеп).* Сез бик күзәтүчән. Димәк, бүгенге кичә ошый сезгә?

Зәйтүнә. Бик ошый. Мондый кичәләрне күрмәгәнгә, артыгын күз алдына да китерә алмыйм.

Тукай. Биергә телисезме?

Зәйтүнә. Ә сез?

Тукай. Мин бии белмим шул *(көлеп.)* Өйрәнә башладым инде. Өйрәнгәч синең белән биермен, яме?

Зәйтүнә. Мин үзем дә әле генә өйрәнә башладым.

Тукай. Син дип дәштем. Үзем дә сизмичә. Ачуланмыйсызмы, Зәйтүнә туташ?

Зәйтүнә. Юк, Габдулла... абый! Киресенчә, мин шат кына сезнең үз итүегезгә.

Тукай. Алайса, Зәйтүнә, син дә миңа син дип эндәш *(Зәйтүнәнең кулын тота.)*

Зәйтүнә. Ярар, Габдулла абый.

Тукай. Габдулла гына дисәң дә була. Мин бит бик яшь күренәм. Мине еш кына малай-шалай белән бутыйлар. Ул гынамы... Шулай бервакыт пароходта барам, үзем озын чәчле, үзем ябык. Бер урыс сорый шунда: «Ты барышня или китаец?»—ди *(көлә.)*

Зәйтүнә *(көлеп)*. Син бит кысык күзле түгел.

Тукай. Мин татар бит! Димәк, кысык күзле күренәм. Зәйтүнә! Шул кысык күзләремә түм-түгәрәк дөнья сыйган минем! Һәм ул дөньяның уртасында—Син!

Зәйтүнә. Габдулла...

Тукай. Мине алда зур сынаулар көтә. Язмышымны үзем сайладым. Тәкъдирем үзем белән. *(Кара жиләнлегә ишарәләп ала.)* Мин янып та калырмын, бәлки, тик халкым үз юлын табарга тиеш, бәйсез булырга тиеш! Шуңа да мин унга, сулга аумыйм, алга барам.

Зәйтүнә. Юлда киртә күрсәм, тибәм дә аударам!

Тукай. Ә?

Зәйтүнә. Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә, мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам.

Тукай. Дөрес әйтәм бит?

Зәйтүнә. Дөрес, дөрес, Габдулла.

Тукай. Син миңа кушыласыңмы? Кулга кул тотынышып китәрбез бергә... Юл авыр. Кимсетерләр дә. Хурларлар да... Бөлгенлектән дә интегербез, бәлки... Син шуңа әзерме?

Зәйтүнә *(калтырап)*. Белмим, Габдулла. Шулай да, бергә булсак, мин сине беркемнән дә кимсеттермәм! Хурлап карасыннар! Бөлгенлеккә дә төшмибез, Алла боерса, дүрт саныбыз төгәл була торып.

Тукай. Син мине аңлап бетермәдең.

Зәйтүнә. Борчылма, Габдулла. Мин тегә дә беләм, чигә дә беләм. Ачка үлмәбез. Школаны тәмамлагач, мөгаллимә булып урнашырмын.

Тукай. И минем яктыртучым! *(Ярым кочаклап мангаеннан үбә.)*

Зәйтүнә. Габдулла! Нишлисең, кеше күрә бит.

Тукай. Күрсеннәр! Бүген мин бәхетле! Мин кемгәдер кирәк, ул да миңа кирәк! Бәхет шул түгелмени? Гап-гади, кеп-кечкенә бәхет!

Зәйтүнә. Мине апам югалткандыр. Бергә килгән идек. Халык киткәндә син дә кайтасыңдыр бит?

Тукай *(сүрән)*. Кая барасың инде тагын...

Зәйтүнә. Бергә кайтабыздыр бит? Без «Болгар» аша үтәбез.

Тукай. Бергә... бергә... гомергә...

Зәйтүнә. Алайса, мин урамда көтәрмен *(биючеләр янына китә.)*

*Тукай янына хатын-кыз житәкләгән Шафкат Маратович килә.*

Шафкат. О-о, Габдулла Тукаевич! Тыңладым, тыңладым сүләгәнеңне. Халыкка ошады.

Тукай. Рәхмәт.

Шафкат. Нигә офиска килмәдең? Сүздә торырга кирәк. Безнең эштә сүздә тормасаң, сикер башка.

Тукай. Мин сезгә сүз бирмәдем.

Шафкат *(Тукайны күздән кичереп)*. Өс-башың бөтәйгән. Табышлы заказлар булдымы әллә?

Тукай. Мин заказ белән язмыйм!

Шафкат. Яшь әле син. Аягыңа сыер басмаган. Менә өйләнә әле, итәк тулы бала-чагаң булсын. Үзең заказ эзләп чабарсың. Әнә бит—бер асылкош белән сөйләшеп тора идең. Аларның башта гына коры сүзгә һушлары китә. Дөнья шундый ул, апаем, мөмкинлегенә карап һәркем ни дә булса сата. Кемдер акылын, кемдер белемен, кемдер җанын, кемдер тәнен.

Тукай. Мин берни дә сатмыйм!

Шафкат. Син шигырьләрең өчен гонорар аласың бит? Димәк, син дә сату-алу белән шөгыльләнәсең. Матур сүзләр—милләт, мәхәббәт, галәм!—төтен жибәрү генә. Һәрнәрсәнең төбендә—акча! Син дә моны беләсең.

Тукай. Менә синең кебекләр аркасында без шундый хәлгә калдык та!

Шафкат. Мин нинди хәлгә калган? Бөтен нәрсәм бар!

Тукай. Бер-беребезне сата-сата илсез калдык! Колларның да колы булып яшибез. Кол икәнеңне яшерер өчен син менә мал артыннан куасың. Ин җирәнгеч кол—нәфес колы.

Шафкат. Син! Чамалап!

Тукай *(хатын-кызга)*. Гафу итегез, ханым. Ирегез әйбәт кеше сезнең. Яман да яхшы кеше.

Хатын-кыз. Ирем түгел ул. Мин модельный агентстводан. *(Авызын каплый.)* Мин... Мин... Ялгыш әйттем.

Тукай. Ә-ә? Аңладым.

Шафкат. Ха-ха-ха! *(Хатын-кызга.)* Син килешү шартын боздың! Эшеңнән очтым дип сана. Южный трассасы көтә сине.

Хатын-кыз. Пошел ты, козел! Тәмам туйдырды *(китеп бара, борылып.)* Син бу шагыйрьнең тырнак очына да тормыйсың!

Шафкат. Хе-хе... *(Тукайга.)* Прокатка алып торган идем үзен.

Тукай. Син курай уйный беләсеңме?

Шафкат. Нәрсә? Нинди курай...

Тукай. Син... курай... уйный... беләсеңсе?

Шафкат. Курай... курай... Шаяртасың, әйеме? Юморист. Соңыннан еларга туры килмәсен. Елатырмын да *(тиз-тиз атлап чыгып китә.)*

*Зал инде бушап калган.*

Тукай. Юлга аркылы төште бит, хәсис *(ишеккә омтыла.)*

*Каршында Кара җиләнле пәйда була.*

Кара җиләнле. Юк, юлыңа мин аркылы төштем.

Тукай *(туктап кала)*. Син?

Кара җиләнле. Ашыкма.

Тукай. Мине Зәтүнә көтә.

Кара җиләнле. Яшь баланың башын әйләндермә.

Тукай. Аныкымы... Минем үземнең башым әйләнгән!

*Кара җиләнле урындыкка утыра.*

Кара җиләнле. Өйләнергә җыенасыңмы?

Тукай. Зәйтүнә көтә. Ашыгам. Теш агартып торырга вакыт юк. Кит юлдан!

Кара җиләнле. Язмыштан узмыш юк.

Тукай. Житте! Һаман сиңа ияреп йөрергә мин инде малай-шалай түгел.

Кара җиләнле. Гашыйк булгансың. Андый чакта тәкъдирне дә җиңәрлек көч сизәсең үзеңдә.

Тукай. Әйе! Мин дә кеше бит. Өйләнсәм дә гаҗәп түгел. Җылы өй, янда яраткан хатын, тирәдә балалар йөгереп йөри. Мин балалар яратам.

Кара җиләнле. Кызганыч, син боларның берсенә дә тиенә алмассың. Син шагыйрь! Тәкъдиреңә шулай язган. Син яшен кебек ялгыз, зилзилә кебек бәйсез.

Тукай. Җир яшәрмәс, гөл ачылмас—төшми яңгыр тамчысы. Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы? Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә шигыремне, йә әйт!—Энҗедән ким кай төше? Мәхәббәт камчысы гына шагыйрьне алга сөрә ала.

Кара җиләнле. Мин моңа каршы төшәммени? Гашыйк бул, ярат, илһамлан! Ләкин өйләнү... Тирәндә чабып йөргән балаларың икмәк сорап елый башласа, мәхәббәт очкыннары бик тиз сүнәр. Дөрес, иң азында ел тәүлегенә биш йөз тәңкә килерең булса, өйләнсәң дә ярый. Гаилә хакына дип менә бу—кем әле?—хәзер киткән бәндә... Шундыйларга тәлинкә тотарга булса,—Алла сакласын!

Тукай. Ул бит... Зәйтүнәне әйтәм, минем сүзне көтә.

Кара җиләнле. Аңарда әле яшьлек юләрлеге. Күрмисеңмени, сабый бит... Ул сине кеше буларак түгел, шагыйрь буларак ярата. Үзең үк язган идең бит, оныттыңмы: «Син дисең, имеш ки, шагыйрьгә барам. Барма, барма—син әрәм аңар, әрәм!» Дәвам итимме?

Тукай.

Үз уенча, шагыйрь ул җырлый, дисең,
Җыр исә тыңларга күңелле, дисең.

Син алай иткәнче, и кашың һилал!
Бар да бер кош кибетеннән былбыл ал.

Ал да читлеккә ябып сайрат аны:
Мактасын гел сине—син саргайт аны.

Кара җиләнле. Сиңа ул читлек кирәкме?

Тукай *(өзгәләнеп)*. Нишләргә соң мина?

К а р а   ж и л ә н л е . Яратырга! Ләкин якын килмичә. Ерактагы кояш жылырак.

Т у к а й . Минем аны назлыйсым килә! Назланасым килә!

К а р а   ж и л ә н л е . Үзен дә беләсен, аның өчен тәтәйләр йорты бар.

Т у к а й . Син циник...

К а р а   ж и л ә н л е . Шигырь башка, дөньяны әйләндерүче чыгыр башка. Шигырь өчен шәп ягулык—жавапсыз мәхәббәт. Былбылларны кара син! Алар да бит кавышканчы гына сайрый.

Т у к а й . Син минем башны бутадын! Мин бит Зәйтүнәне озатырга тиеш идем. *(Кара жиләнлене этеп аудара да чыгып йөгерә.)* Зәйтүнә!

К а р а   ж и л ә н л е *(торып киемен кага).* Зәйтүнә әллә кайчан өендә инде. Ул сина рәнжеп кайтып китте, юләр шагыйрь.

*Өстән аваз ишетелә: «Әмма ләззәтле дә сон яшерен газап, яшерен яну!—Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?»*

## Дүртенче күренеш

*Тукайның дуслары, танышлары жыелган—Фатих, Ибраһим, Вафа, Кәбир, Шакир, Солтан. Ашыгып Сәгыйт килеп керә.*

С ә г ы й т . Әссәламагаләйкүм, кардәшләр.

Б а р с ы   д а . Вәгаләйкүм әссәлам.

*Сәгыйт утыра. Бит сыпырып амин әйтәләр.*

С ә г ы й т . Яна гына Әстерханнан кайтып төштем. Тукайҗанның авыруын ишеткәч, туры монда йөгердем. Хәле ничек?

Ф а т и х . Менә Шакир университеттан доктор алып килде.

С ә г ы й т . Алай... Күптән авырыймы?

В а ф а . Әдәбият кичәсе үткәргән идек. Икенче көнне урыныннан тора алмады. Бизгәк.

Ш а к и р . Үпкәсендә чир бар дип шикләнәбез.

К ә б и р . Хәле алай ук мөшкел түгел сыман. Күзендә яшәү нуры бар.

С ә г ы й т . Сүзең фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килсен, Кәбир.

И б р а һ и м . Әдәбият кичәсеннән соң мин аның бүлмәсенә кергән идем. Бик гасаби сыман күренде.

В а ф а . Ә кичәдә бик шат, күңеле күр сыман иде бит.

И б р а һ и м . Бер читтә Зәйтүнә белән дә шактый озак сөйләшеп тордылар. Әллә сүзгә килделәр микән?

С о л т а н . Сүзгә килергә... алар бит ул кадәр якыннар түгел.

Ф а т и х . Ул Зәйтүнәне бик якын итә. Сиздерми генә.

Ш а к и р . Шагыйрьләр бик нечкә күңелле халык. Әз генә кырын сүзне дә зур итеп кабул итәләр. Шулай бит, Сәгыйт әфәнде?

С ә г ы й т . Анысы инде кешенең холкыннан тора. Тукайның серкәсе су күтәрми, дөрес. Чак кына тәнкыйтьне дә кабул итми.

Ф а т и х . Нахакны кичерми ул!

К ә б и р . Йоклап яткан чирне уятырга күп кирәкми...

С о л т а н . Зәйтүнә берәр авыр сүз әйткән дип уйлыйсызмы?

В а ф а . Юк ла... Зәйтүнә акыллы кыз. Шагыйрь хәтерен калдырырлык сүз әйтмәс. Аннары ул Тукайны бик ярата да.

С о л т а н *(кискен).* Кем әйтте?

В а ф а . Әйтмәсәң дә күренә, Солтан. Син генә күрмисен.

*Түр ишектән доктор чыга. Ул ак сакаллы, пенсне кигән.*

Ш а к и р . Доктор?

Ф а т и х . Утырыгыз, доктор әфәнде.

Д о к т о р *(утырып).* Әйе, аягөсте хакыйкатьне әйтмиләр...

С ә г ы й т . Доктор! Хәле шулай авырмыни?

Д о к т о р *(кырысланып).* Ашыктырмагыз, егет.

С ә г ы й т . Түбәнчелек белән гафу үтенәм.

Д о к т о р *(Фатихка).* Фатих Зарипович. Монда авыруның якыннарымы? Диагноз хакында сөйләшә алабызмы?

Ф а т и х . Без барыбыз да аның дуслары, доктор. Монда сөйләгән монда калыр.

Д о к т о р . Яхшы. Аңарда туберкулезның соңгы стадиясе.

Барсы да. Ә?

Фатих. Бер дә өмет юкмыни, доктор?

Доктор. Сез инде аңа игътибарлы булыгыз. Күп булса берничә ай гомере калган. Хәер, дөресен Алла белә. Бәлки, Швейцариядәге берәр шифаханәгә җибәрсәгез...

*Доктор китәргә кузгала. Шакир аңа акча бирмәкче була.*

Шакир. Рәхмәт сезгә, доктор.

Доктор. Рәхмәтегезне кабул итәм *(Шакирның кулын этә.)* Монысы кирәкми. Шагыйрьләрдән акча алмыйм. Хушыгыз, әфәнделәр *(чыга.)*

Вафа. Башка суккан кебек булды бу.

Фатих. Ятып калганчы атып калырга. Швейцариягә җибәреп карарга кирәк.

Кәбир. Нинди акчага?

Ибраһим. Табарбыз. Бөтен Казанны кузгатсаң...

Солтан. Ай-һай, кузгалыр микән? Казан татары акча дисәң саңгырауга әйләнә ул.

Вафа. Аңа әле бер озатучы да кирәк булачак.

*Түр бүлмәдән кара җилән ябынып акрын гына Тукай чыга.*

Тукай. Һай! Бөтен дуслар җыелган. Сәгыйт тә монда. Исән-сау кайттыңмы, Сәгыйт *(күрешә.)* Нигә кәрт сукмыйсыз?

Фатих. Менә... докторны озаттык та.

Тукай. Доктор түгел, фәрештә булып чыкты ул.

Кәбир. Әйе, әйе, ир-ат фәрештә. Нәрсә диде?

Тукай. Сезгә бер сүз дә әйтмәдемени?

Фатих. Әйтте. Берәр санаторийга барса әйбәт булыр, диде.

Ибраһим. Мәсәлән, Швейцариягә.

Тукай. Швейцариягә! Анда ни калган? Доктор миңа андый юк-бар сүз сөйләмәде.

Шакир. Ни әйтте соң?

Тукай. Терелсәң, диде, барлык авыруың юып алгандай юкка чыгачак! Шуңа да борын салындырып утырмагыз...

Вафа. Аллага шөкер икән, алайса.

Тукай. Инде бу кадәр җыелгансыз икән, коры кашык авыз ерта. Кем, мулла Кәбир, барыбызга да җитәрлек сыра алып кер *(өстәлгә акча куя.)*

Кәбир. Ярамас бит...

Фатих. Бүтән вакытта рәхәтләнеп утырырбыз әле, Габдулла. Ял ит син.

Тукай. Ял итеп ятасылар алда әле. Мулла Кәбир, син әллә әйләнеп тә кердеңме?

*Кәбир акчаны алып чыгып китә. Вафа кушеткадагы мендәрне рәтли.*

Вафа. Бераз таянып тор, Тукайҗан.

Сәгыйт *(торып).* Мин әле урнашмаган да... Габдулла, мин китим әле. Соңрак килермен.

Тукай *(кушеткага ятып).* Син курай уйный беләсеңме?

Сәгыйт. Белмәскә! Рәхәтләнеп гыжылдатам. Утырырбыз әле, Габдулла. Син җырларсың, мин уйнармын *(китә.)*

Вафа. Минем дә басмаханәдә эшем бар иде.

Фатих. Тукай йоклады.

*Чыннан да Тукай кушеткада тигез сулыш ала. Барысы да акрын гына чыгып китә. Зәйтүнә йөгереп керә. Өстендәге плащын, ишектән узгач, идәнгә ташлап калдыра да Тукайның баш очына килеп утыра.*

Зәйтүнә *(шыпырт кына сөйләнә).* Бүген генә ишеттем бит, Габдулла. Авырганыңны бүген генә ишеттем. Мин, юләр кыз, сиңа үпкәләгән идем. Вәгъдәсендә тормады дип... *(Тукайның мангаен сыйпый.)* Йоклый. Болай булгач, тереләсең, шагыйрем. Яшьнисе көннәрең алда әле.

*Сыра шешәләре кочаклаган Бәкер килеп керә. Тукай янында Зәйтүнәне күреп аптырап кала.*

Бәкер. Үлдеме әллә? *(Шешәләре идәнгә төшеп ватыла.)*

Тукай *(башын калкытып).* Үләрсен монда сезнең белән...

Зәйтүнә. Борчылма, Габдулла.

тыныч кына ят. Сина тынычлык кирәк. Син, Кәбир абый, бар, юлында бул. Кирәген чыкса, чакыртырбыз.

*Кәбир башын чайкап тора да шешә ватыкларын җыймакчы булып иелә.*

Зәйтүнә. Бар! Үзем җыеп алырмын...

*Тышта тонык кына булып күк күкри.*

Тукай. Күк күкри. Быел беренче тапкыр. Яз килә. Иртәрәк түгелме соң әле?

Зәйтүнә. Яз ул, Габдулла, үз вакытын белеп йөри. Кыш кына һәрвакыт көтмәгәндә килә.

## Икенче пәрдә

### Бишенче күренеш

*Зәйтүнәләр фатиры. Ул гадәти татар өйләреннән берни белән дә аерылмый диярлек. Китап шкафы гына монда укымышлы кешеләр яшәвен күрсәтә. Өстәл тирәсендә Җиһан белән Зәйтүнә чигеп утыра.*

Җиһан *(авыз эченнән җырлый).*
Күк күгәрчен күктә уйный, башларың әйләнмәсә,
Бик сөйсәң дә баралмассың, чәчләрең бәйләнмәсә.

Зәйтүнә. Әй, ачу китереп әллә нинди җырлар җырлап утырмасаң.

Җиһан. Мин чыгарган җыр түгел, борынгыдан калган.

Зәйтүнә. Миңа төрттерәсең инде.

Җиһан. Төрттермим, турысын әйтәм. Акылдан шашкандай егет өенә барып керү нинди киртәгә сыя? Илдәкөндә булмаганны. Әни ишетсә, ник туганыңа үкенерсең.

Зәйтүнә. Авыруның хәлен белү дә борынгыдан калган гадәт.

Җиһан. Кешегә сагыз булып ябышу кемнәрдән калган гадәт? Беркөнне дә, юлда очрагач, бер артына, биш алдына төшәсең. Шулхәтле чекрәя-чекрәя күзенә кермәсәң, күреп туймассынмы әллә? Котым калмады. Кочагына кереп бетә дип торам.

Зәйтүнә. Ул бит миңа абый кебек кеше. Апа, нигә алай сөйлисең?

Җиһан. Мин синең бәхетле булуыңны телим. Тик ул өйләнә торган кешегә охшамаган. Аннары аның турында төрле сүзләр йөри.

Зәйтүнә. Казан чухырлары кем турында гына сөйләми. Аның өчен Көфер почмагына гына барырга кирәк. Баштанаяк буялып кайтырга була.

Җиһан. Утсыз төтен чыкмый. Аны тәтәйләр йортына йөри диләр. Эчке белән дә дус икән.

Зәйтүнә. Ялган! Теге көнне Кәбир диган дусты сыра күтәреп кергән иде. Ул аны эт итеп куып чыгарды. *(Пауза.)* Ә тәтәйләр йорты нәрсә ул?

Җиһан. Бозык кызларның оясы. Азгын ирләр тирескә кунган чебен кебек шунда ята.

Зәйтүнә. Булмас! Тукайдан күнелем кайтсын өчен боларны сөйлисең. Шундый мөкатдәс шигырьләр язган кеше андый түбәнлеккә бармас.

Җиһан. Шагыйрь дә кеше. Менә син аңа кияүгә чыктың да ди. Ул сина рәсемгә карагандай сокланып кына торса, риза булыр идеңме соң?

Зәйтүнә. Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәте турында белмисеңме әллә син?

Җиһан. Алар бит өйләнешергә өлгерми кала. Син артык яшь шул әле, сеңелкәем.

Зәйтүнә. Тупасланып бетәләр дә, тормыш дигән булалар. Ә мин саф, самими дөньяда яшәргә телим!

Җиһан *(Зәйтүнәне кочаклап ала).* Зәйтүнәкәй! Фатих та шәп бит, ә? Аягы йөрмәсә дә, коляскасында хан җәнаблары сыман утыра!

Зәйтүнә. Апа *(бармагын селки.)*

Кызлар җырлый:
Бүген күргән өч егетнең җем-җем итә кигәне,
Фатих алма, Ибрай хөрмә, Тукай кура җиләге.

*Алар җырлаганда бүлмәгә Солтан керә. Тамагын кыра.*

Солтан. Исән-сау яшәп ятасызмы, кызлар?

Жиһан. Шөкер, Солтан әфәнде. Түргә узыгыз.

Солтан. Рәхмәт. *(Өстәл янындагы бер урындыкка килеп утыра.)* Сез гаҗәпләнмәгез. Соңгы вакытта күзгә башка күренмисез. Хәл-әхвәл сорашырга кердем... Рөхсәттер бит.

Жиһан. Нигә рөхсәт булмасын, Солтан әфәнде. Без бик шат шундый кадерле кунакка. Хәзер, самавыр гына куеп керим әле *(чыга.)*

Солтан. Югалдыгыз, Зәйтүнә туташ. «Шәрыкъ клубы»нда да күренмисез. Бик кызыклы кичәләр булды соңгы арада. Лекцияләр. Сез бит тәрәккыятькә омтылучы кыз. Өйдә бикләнеп яту сезгә килешми.

Зәйтүнә. Вакытыбыз булмады. Әнигә заказ күп, эшләрен өйгә дә алып кайта. Менә чигәбез, аңа булышабыз.

Солтан. Сезне сагынучылар бар, шуны онытмагыз, Зәйтүнә...

Зәйтүнә *(очынып китеп).* Әллә... Хат-фәлән алып килдегезме, Солтан абый?

Солтан *(ризасызлык белән).* Хат? Үзем килдем. Мин әллә хат ташып йөрүчегә охшаганмы?

Зәйтүнә. А-ай, гафу итегез. Сагынучылар бар дигәч кенә әйтеп ташладым. Әйттем исә кайттым. Әллә үзегез сагындыгызмы мине, Солтан абый?

Солтан *(сикереп тора да йөгенеп Зәйтүнәнең кулын иренәнә китерә).* Сагындым! Сагындым...

Зәйтүнә. Чү, нишлисез! Акылдан шаштыгызмы әллә?

Солтан. Шаштым. Сезне беренче күргәннән бирле ут эчендә мин. Сизмисезмени: эчем-тышым ут!

Зәйтүнә. Эчегезне белмим, әмма кулыгыз салкын.

*Солтан торып үз урынына утыра.*

Солтан. Перчаткасыз килгәнгә ул, Зәйтүнә туташ! Мин юкны бушка аударып йөрүчеләрдән түгел. Шуңа күрә боргаланып-сыргаланып маташмыйм. Мин сезгә өйләнергә телим!

Зәйтүнә *(көлемсерәп).* Шулай... тиктомалданмы?

Солтан. Әйтәм ич, сезне беренче мәртәбә күргәннән бирле ашым аш, йокым йокы түгел. Мин озак уйладым. Миңа өйләнергә вакыт. Яшем җиткән. Беләсездер, мин Казан егете. Үз йортыбыз белән торабыз. Әни дә әйтте, син миңа тиң булырлык кыз. Үкенмәссез. Өрмәгән җиргә дә утыртмам.

Зәйтүнә. Бөтенләй көтмәгәндә...

Солтан. Яучылар җибәргәнче икәүдән-икәү үзебез сөйләшик дидем. Без бит тәрәккый яшьләр.

Зәйтүнә. Сезне бик хөрмәт итәм, Солтан әфәнде. Сез Казанның күркәле кешесе. Тукайның дусты...

Солтан. Әйе, Тукай минем дустым. Киләчәктә аннан әйбәт кенә шагыйрь чыгар иде, минем уемча...

Зәйтүнә. Бу уегызны үзенә әйттегезме соң?

Солтан. Әйтеп кара... Ул үзенең бөеклегенә шикләнми. Туктагыз әле, Зәйтүнә туташ, мин монда Тукай турында сөйләшергә килмәдем бит.

Зәйтүнә. Мин сезгә барыр идем дә...

Солтан. Барыгыз соң, сезне кем тота? Әниегез, туганнарыгыз белән яучылар сөйләшер.

Зәйтүнә. Тота шул, бернәрсә чабудан тота.

Солтан *(сагаеп).* Йә-йә?

Зәйтүнә. Мин башканы сөям.

Солтан. Һм-м... *(арлы-бирле йөренә.)* Ялгышмасам, сез Габдулла әфәндегә битараф түгел бугай.

Зәйтүнә. Битараф түгел! Нинди ахмак сүз.

Солтан. Ул үзе... Сезгә мәхәббәтен белдердеме соң?

Зәйтүнә. Анысы инде безнең эш...

Солтан. Кире сыйфатлары булса да, Тукай яхшы кеше. Ул сезгә начарлык теләмәс.

Зәйтүнә. Менәтерәк... Мәхәббәтен төшү начарлыкмыни? Карап-карап торам да, Солтан әфәнде, бик сәер кеше булып чыктыгыз әле. Үзегез үләнмә келисез.

Солтан. Әйе, сез Чистайдан бит әле. Пыялачы Хәйдәр кызы.

Зәйтүнә. Сез инде бөтен нәселебезне өйрәнгәнсездер.

Солтан. Шунсыз ярамый.

Зәйтүнә *(көлеп).* Сез инде үзегез затлы нәселдән, шулай бит.

Солтан *(тыйнак кына).* Нәселебез Сөембикәгә барып тоташа, Аллага шөкер.

**Зәйтүнә**. Бүген Казанда һәммәсе морза!

**Солтан**. Тукайга өметләнмәгез сез. Аның жыры жырланган.

**Зәйтүнә**. Ни сөйлисез?

**Солтан**. Доктор карады аны. Күп булса, бернечә атна гомере калган Тукайның.

**Зәйтүнә** *(торып)*. Ялганлыйсыз! *(Шомлы музыка уйнап ала, Зәйтүнә колакларын каплый.)*

*Жиһан керә.*

**Жиһан**. Әллә кычкырышасыз инде? Зәйтүнә, ни булды?

*Зәйтүнә өстәлгә иелеп төшә.*

Солтан әфәнде! Берәр авыр сүз әйттегезме әллә?

**Солтан**. Зарар юк. Истерика. Тиздән үтәр *(чыгып китә.)*

**Жиһан**. Зәйтүнә... Зәйтүнә...

**Зәйтүнә** *(күзен сөртеп)*. Булды, апам, булды.

**Жиһан**. Ни әйтте ул?

**Зәйтүнә**. Өйләнергә килгән.

**Жиһан**. Бә-тәч... Хәзер үкме? Вәт Казан егетләре... Син шуңа елап торасыңмы? *(Кочаклый.)* И-и, бәләкәчем.

**Зәйтүнә**. Мин ничек Аны ташлап бу күркәгә кияүгә чыгыйм? Тукайның дусты булып йөри бит әле, адәм тәгәнәсе.

**Жиһан**. Дус... Аның шигырен оныттың мәллә? «Әйе, дуслар, якын дуслар! Гажәеп нинди дуслар сез? Татарча әйтәм инде: дус түгел, бәлки буклар сез.»

**Зәйтүнә** *(дәвам итә.)* «Әгәр шатлык, бәхет килсә—әзерләрсез бүләргә сез, әгәр ямьсез вакыт килсә—әзер миннән көләргә сез.»

*Хафиз керә.*

**Хафиз** *(утырып)*. Эшләр ничек бара, сеңелкәйләр? Кәләпүшләр әзерме? Бетмәдеме әле?

**Жиһан**. Аз гына калды, Хафиз абый. Ярты сәгатьтән төгәллибез.

**Хафиз**. Хуп *(Пауза.)* Солтан әфәнде бездә булдымы ул? Кәефе кырылганмы соң, юньләп исәнләшмәде дә...

**Жиһан**. Безгә кергәндә үк кәефсез иде ул.

**Хафиз**. Хуп.

**Зәйтүнә**. Нindидер сүзең бар, ахрысы, абый. Газапланма, турыдан яр. Безнең бит яшерен серебез юк.

**Хафиз**. Алай димә, алай димә. Буй житкән кызларның эч серләре булса да гажәп имәс.

**Зәйтүнә** *(көлеп)*. Хуп.

**Хафиз**. Көлмә. Печән базарында төрле сүзләр йөри.

**Зәйтүнә**. Анда да йөрмәгәч. Сүзнең оясы шунда бит инде.

**Хафиз**. Ана ис китми. Тик менә...

**Жиһан**. Әйт инде. Безне дә газаплама.

**Хафиз**. Зәйтүнә Тукайга ябышып чыгарга жыена, дип сөйлиләр.

**Жиһан**. Менә сиңа, кодагый. Иске авыздан яңа сүз.

**Зәйтүнә**. Син шуңа ышандыңмы?

**Хафиз**. Нумерыннан чыкканынны күрүчеләр дә булган.

**Зәйтүнә**. Чыкса... Кемдә кемнең эше бар?

**Хафиз** *(кычкырып)*. Бу бит хурлык! Кыз бала буйдак егет бүлмәсеннән...

**Жиһан**. Абый! Печән базарының гайбәтен өйгә ташымасаң...

**Хафиз**. Тукай күз өстендәге каш кебек ул. Һәр хәрәкәтен күзәтеп торалар. Әйт дөресен, Зәйтүнә, кердеңме Тукай янына?

**Зәйтүнә**. Кердем. Хәлен белергә кердем. Каты авырый ул.

**Хафиз**. Авырый? Бүген генә бер мимеч хатыны белән култыклашып киткәнен күрдем.

**Зәйтүнә**. Абый! Ни сөйлисең?

**Хафиз**. Мин синең инсафлы кыз икәненне беләм. Тукай белән арапны өз син.

**Зәйтүнә**. Тукай кемнән ким?

**Хафиз**. Исеме зур. Үзе кем? Каккан казыгы да юк. Акча тота белми. Аңа чыксаң гомергә бәхетсез буласың.

**Жиһан**. Тукта әле, Хафиз абый. Зәйтүнәгә кадәр мин бар бит әле. Йолада булмаганны! Мине узып кияүгә чыкмас Зәйтүнә.

**Хафиз**. Ташы кызса, белмәссең. Кисәтеп куюның зарары юк. Хуп. Мин тәрәккый кеше, Зәйтүнәнең ихтыярына каршы төшмәм, иншалла. Ни теләсә дә ирекле ул.

**Зәйтүнә**. Рәхмәт, абый.

**Хафиз** *(кискен)*. Ләкин минем сүз-

дән чыксаң! Үзенә үпкәлә.

Зәйтүнә *(көлә)*. Абый, кызык кеше син *(кочаклап.)* Абый, усал булып кыланма, сиңа килешми.

Хафиз *(эреп)*. Уенга борма. Әнә Солтан. Күрәм, аның да сиңа күзе төшкән. Менә чын ир-егет ичмасам! Костюмын гына кара—англиски постаудан. Штиблетлары ялык-йолык! Үз өе бар. Әтисеннән калган коттеж.

Зәйтүнә *(ярсып)*. Син миңа нигә әллә кемнәрне мактыйсың? Димлисең мәллә? Беләсең килсә, Тукай янында алар кемнәр? Жыен чүп... Ә Тукайның исеме киләчәктә...

Хафиз. Киләчәктә! Нигә миңа киләчәк, анда үзем булмагач? Миңа бүгенгесе кыйммәт. Өч көнлек дөньяда миңа бөтен нәрсә хәзер үк кирәк! Һәм тиз кирәк. *(Тора.)* Шул. Мин әйттем. Әнигә сиздермәгез, аның йөрәге болай да зәгыйфь.

Жиһан. Бүген «Шәрекъ клубы»нда лекция иде.

Хафиз. Бүгеннән ул якка юлны онытыгыз! (Чыга.)

## Алтынчы күренеш

*«Әл-ислах» газетасы редакциясе. Фатих, Ибраһим, Солтан сөйләшеп утыра.*

Ибраһим. Тукайның хәле яхшырды бит! Теге доктор ялгышты бугай, Аллага шөкер.

Фатих. Мәхәббәт могжизалы көчкә ия шул. Зәйтүнә туташ терелтте Тукайны. Сүнеп яткан учагына ут өстәде. Бөтенләй үзгәрде бит Тукай, күрәсездер. Шат, көләч. Шигырьләрне дә коеп кына тора.

Солтан. Минемчә, доктор үзгәртеп китте аны. Тукай бит ул наив, исем-дәрәжәсе булган һәркемнең сүзенә ышана. Докторның юатып әйткән сүзен чын итеп кабул иткәндер. Кеше организмында үзе дә белмәгән әллә нинди мөмкинлекләр бар.

Фатих. Син рационалист, Солтан. Мәхәббәткә дә ышанмыйсыңмы?

Солтан. Зәйтүнә туташның Тукайга мәхәббәт тотуына ышанмыйм, әлбәттә. Үзе артында ул аңардан көлә генә: бичара шагыйрь, мәҗнүнчик, дип кенә атый.

Ибраһим. Кайдан беләсең?

Солтан. Сөйлиләр. Казанда төчкерсәң дә кайтавазы өч көн ишетелеп тора.

Фатих *(өстәлдән кәгазь алып)*. Менә... Кичә генә язылган шигырь. Тукай анда сиңа җавап бирә.

Ибраһим. Йә-йә...

Фатих. Күрәсең, Солтан гайбәтен аның үзенә дә әйтүчеләр булган: «Сөймә юкка, көймә юкка, йөрмәче шул кыз белән. Бер дә сөйми ул сине, син юкта ул синнән көлә».

Ибраһим. Солтан үзе үк житкергәндер әле.

Солтан. Юк ла, мин нишләп алай вакланыйм...

Фатих. Менә Тукайның җавабы:

Көлсә көлсен, шул кирәк шул, анда синең ни эшең?
Әйдә көлсен ул матур, дөньяга күрсәтеп тешен.
Теш нурын чәчсен дә дөньяны җибәрсен балкытып,
Жире, күге яктырып китсен әле бер ялт итеп!

Ибраһим *(кул чабып)*. Афәрин!

Солтан. Остроумно...

*Вафа керә.*

Вафа *(күңелсез)*. Мине көтеп утырасызмы?

Фатих *(гәптәшләренә)*. Вафаны Цензор чакыртып алган иде.

Солтан. Ул бит баш редактор! Аны чакырмый кемне чакырсыннар.

Фатих *(Вафага)*. Йә?

Вафа. Хәлләр мөшкел. Марат Ульмасович Синдикатмедиа төзегән. Барлык татар матбугаты шуның астында кала.

Ибраһим. Ә без риза булмасак?

Вафа. Газетагызны ябабыз, диләр. Марат Ульмасович шат, Тукаегызның авызын томалыйбыз, халыкны күп болгатты, ди.

Солтан. Әйе, алар юләр түгел, төрмәгә тыгып, Тукайдан герой ясамаслар. Культурно гына авызны томалап булганда, төрмәнең кирәге юк.

Ибраһим. Тукай моны кичермәс. Аның бит барлык тормыш мәгънәсе—дөреслекне язу.

Солтан. Туры әйткән туганына да ярамый. Мәнге шулай дәвам итәр дип уйладың мәллә? Нинди илдә яшәгәненне онытма!

Фатих. Паникага бирелмәгез әле. Барлык журналистлар, мөхәррирләр җыелышып Азатлык мәйданына чыксак?

Солтан. Юкны сөйләмә, Фатих. Үзен дә беләсен бит—аларның күбесе тынын да чыгармаячак. Шафкаттан тамган тиеннәргә ләббәйкә дип торачаклар. Курку безнең каныбызга сеңгән.

*Тукайның җырлаганы ишетелә.*

Тукай.
Башымдагы чабатаның сиксән сигез серкәсе,
Бу дөньяда шөһрәт алды Бәдигъ мәзин күркәсе.

Фатих. Аң булыгыз! Хәлебезне Тукайга сиздермик әлегә.

*Тукай керә.*

Тукай. Һа, җыелганнар! Вата шуннан соң авырта башлый ди аягы сиерныкы!

Фатих. Кәефең әйбәт күренә.

Тукай. Һи, Фатих... Канатым! Фәрхадның ничек шулай җинел генә тау-таш җимергәнен аңлыйм хәзер. Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны!

Солтан. Син бәхетле. Ә мин сикереп шатланырлык бер сәбәп тә күрмим.

Тукай. Сәбәпне табарга кирәк, Солтан дустым. Эзләсәң табыла ул! Их, егетләр. Йөрәгегезгә мүк үскән мәллә, боегып утырасыз?

Фатих. Син шат булсаң, безгә дә күңелле, Тукайҗан.

Тукай. Әле генә бүлмәмдә уйланып яттым да монда ашыктым. Син, Фатих, мин, ул... без! Хәзерге көн татар яшьләре. Безгә авыр, билгеле. Безне аңламыйлар, хурлыйлар, аяк чалалар. Ләкин безнең юлыбыз изге. Изелгән, үлем йокысыннан исергән милләтебезне без уятырга тиеш! Ул аңласын кем икәнен! Исенә төшерсен элекке данын! Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? Мин ышанам: иртәме-соңмы ул үз арбасына утырыр, үзенең җырын җырлар. Үз халкың өчен көрәшкәндә ярты юлда егылып үлсәң дә үкенечле түгел.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.
Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,—
Без аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!

Солтан. Афәрин! *(кул чаба.)* Браво! Нинди матур сүзләр!

*Тукай ачык тәрәзә янына килеп баса. Кульяулык белән авызын каплап йөткерә. Аннары кульяулыкка карый да бөгәрләп кесәсенә тыга.*

Фатих. Тукайҗан! Болай күңелгә үткәреп син генә әйтә аласың.

Тукай. Яз җитә, яз! Тиздән чирәм шытар... *(Солтанга.)* Матур сүзләр түгел бу. Бәгыремнән кан белән саркылып чыккан сүзләр. *(Теләмичә генә көлә.)* Чорт белә, мин ахрысы сөюдә дә милләтче! Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам. Әгәр хур кызлары татарча сөйләшмәсә, мина җәннәттә дә рәхәт булмас иде.

Солтан. Ә кайда соң ул милләт?! Синең януыңнан, әрнүеңнән хәбәре бармы? Анарда тамак кайгысы. Күбесе инде синең теленне дә аңламый. *(Кулын селтәп чыгып китә.)*

Тукай. Ни булган аңа?

Фатих. Нишлисең, безнең милләткә инде өч йөз елдан артык ясин чыгалар. Ә ул яши, тырмаша.

Ибраһим. Һәм яшәр дә! *(Кузгала.)*

*Тукай тәрәзәдән карап тора.*

Тукай. Яз җитә, яз. Бер атна-ун көннән мин казакъ даласына кымызга китәм.

Фатих. Соңгы көннәрдә күзгә-башка күренмәдең, кая югалдың син?

Тукай. Мимеч телен өйрәнәм.

Вафа *(гаҗәпләнеп)*. Немец телен? Ник кирәк ул сина?

Тукай *(көлеп)*. Фатих! Кара инде баш редакторыңны! Бигрәк наив кеше, валлаһи! Чит тел өйрәнү нигә кирәк, ә? Чит телне белү өчен!

Вафа. Ә, әйе шул.

Фатих. Репетитор яллadыңмы?

Тукай. Әллә тагын... Маржа Карловна дигән мимеч кызы белән таныштырганнар иде, шул өйрәтә.

Фатих. Мария Карловна? Беләм мин аны. Кабан күле буендагы урамда яши.

Тукай. Ул мине мимеч теленә өйрәтә, мин аны татар теленә. Баш на баш.

**Фатих**. Бик интеллигентный хатын. Өендә булганым бар.

**Тукай**. Харап инде. Чәнечкене ничек тотканны да күзәтеп тора. Ул безне варварларга чутлый бугай. Шуңа күрә ташладым мин мимеч телен. Бу вакытта мин айн, цвайн ятлап утырасы кеше.

**Фатих**. Зерә ташлагансың.

**Тукай**. Варварга нигә мимеч теле?

**Вафа**. Дүрт тел белгән кеше варвар буламы? *(Бармагын бөгеп саный.)* Гарәп теле, фарсы, төрек, урыс. Үз телебезне чутка кертмим дә инде.

**Фатих**. Алар чын мәдәният Аурупада гына дип уйлый.

**Тукай**. Ярар, баш катырмагыз юк белән. Минем шигырь газетага кердеме?

**Вафа**. Ни бит... Габдулла...

**Тукай**. Нәрсә ни бит?

**Вафа** *(Фатихка карый)*. Ни бит...

**Фатих**. Габдулла, син йөрәгеңә якын алма. Безнең хәлләр мөшкел.

*Кара жиләнле ишектән кереп бусагага утыра.*

**Тукай** *(тәрәзәгә ишарәләп)*. Яз җитә, яз! Тиздән алмагачлар ак күбеккә күмелер. Сайрар кошлар аваз бирер. Ә син хәл мөшкел, дисең. Вак мәшәкать, ыгы-зыгы бар да үтә. Их, яшәүнең кадерен белмибез.

**Фатих**. Анысы шулай...

**Тукай**. Йә, нигә борыныгыз төште?

**Вафа**. Бүген Марат Ульмасович чакырды. Газетагызны Синдикатның канат астына алабыз, ди.

**Тукай**. Әһә. Акыллары алтын икән!

**Вафа**. Синдикатка кермәсәк, газета бүгеннән ябылачак.

**Тукай**. Алар чүбеген чәйнәгәнче ябылуың артык!

**Вафа**. Сиңа әйтүе җиңел. Минем ике балам бар, хатыным. Әнкәй дә ярдәм көтә. Эшсез калсам, аларның күзенә ничек карармын?

**Тукай**. Без шундый...

**Фатих**. Әйе, беткә ачу итеп, тунны утка ягу ярамас.

**Тукай**. Алайса, гомер буе бетле тун киеп йөр инде! *(Чыга башлый.)*

**Фатих**. Габдулла, тукта. Начар хәбәр ул гына түгел әле.

**Тукай** *(туктап)*. Йә?

**Фатих** *(кесәсеннән кәгазь чыгара)*. Синдикат Суд палатасы прокурорына хат юллаган *(укый.)* «Габдулла Тукай шигырьләрендә Синдикат илдәге иҗтимагый төзелешне җимерергә чакыру күрә. Мәсәлән, «Изге эштер тартышмаклык хокук өчен, Тартыш эшче! тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!» дигән юлларда ул эшчеләрне турыдан-туры восстаниегә чакыра. Шунлыктан Г.Тукай китабында Синдикат Җәза бирү уложениесенең 129 статьясының 6 пунктында каралган җинаять билгеләрен таба».

**Тукай**. Кайдан алдың бу нәҗесне?

**Фатих**. Суд палатасында бер танышым эшли. Нәҗесен нәҗес, тик алар сине төрмәгә утыртырга тели! Бер журналистны, телен тыймаган өчен, спецпоселениегә хөкем иттеләр инде.

**Тукай**. Димәк, сез Синдикатка керергә ризалык биргәнсез, ә мине бу кәгазь белән куркытасыз?

**Вафа**. Заман үзгәрде, Габдулла, син шуны сизмисеңмени? Власть вертикале хәзер.

**Тукай**. Әйе, бишенче елда йодрык белән һава кыйнаучылар яфрак астына посты! Заман, имеш... Заман түгел, без үзгәрдек!

**Фатих**. Тукай, кызма... Минемчә, сиңа беразга югалып торырга кирәк. Кымызга китәргә җыенасың түгелме?

**Тукай**. Фати-их! Син дә минем югалуымны телисеңме?

*Урамда сирена тавышы. Кара жиләнле тиз генә килеп Тукайны чабуы белән каплый. Шафкат Маратович килеп керә. Исәнләшмичә түргә үтә. Тукай Кара жиләнлене читкә этәреп җибәрә. Шафкат Тукай каршына килеп аңа курай суза.*

**Шафкат**. Мә, уйна.

*Тукай курайны әйләндереп-әйләндереп карый.*

**Тукай**. Әйбәт курай.

**Шафкат**. Өйрәнә тор. Уйнарсың. Тик дәртле көйләрне генә. Сузынкыларны җенем сөйми.

**Фатих**. Әфәндем! Сез курай ясаучымы, әллә бүтән йомышыгыз бармы?

**Шафкат**. Тик кенә тор! *(Фатих белән Вафага.)* Сез икегез! Чыгып торыгыз. Минем Тукай белән сөйләшәсем бар.

**Фатих**. Сез! Бу нинди оятсызлык. Хәзер үк чыгып китегез!

**Шафкат**. Юк инде, хөрмәтлем. Бу

минем йорт. *(Кәгазьләр чыгара.)* Менә документлар. Телим—сутәм, телим—яндырам. Тиздән Яна Бистәдә бер генә иске йорт та калмаячак. *(Фатихнын колляскасын ишеккә таба тәгәрәтә. Вафага.)* Чыгып торыгыз.

*Вафа коляска тәгәрәтеп Фатихны алып чыгып китә. Шафкат өстәл башына килеп утыра.*

Тукай. Сөмсез!

Шафкат. Андый сүзләрне анламыйм мин. Эт өрә, бүре йөри. Көчленеке—замана!

Тукай. Дөнья—куласа.

Шафкат. Булмагае. Ничек әйләнсә дә ахыр чиктә сезне баса ул, без һәрвакыт читкә сикереп калабыз. *(Пауза.)* Йә, сөйлә!

Тукай. Ни сөйлим?

Шафкат. Авыр хәлгә калгансың икән. Сөйлә. Ярдәм итәргә тырышырмын.

Тукай. Ярдәм итүче табылган! Ил байлыгын умырып алалар да күз буяр өчен сәдака өләшкән булалар. Мина синен хәерсәдакан кирәкми. Мин хәерче түгел!

Шафкат. Кем соң син?

Тукай. Мин—шагыйрь!

Шафкат. Шагыйрь... Шагыйрьләр заманы узды, апаем. Шигырь язып кемне шаккатырасын хәзер? Халыкка сез кирәкмисез. Ул безнең күзгә карап тора. Чөнки бездә власть, акча. Без кул изәмәсәк, жил дә исми.

Тукай. Нәкъ шулай! Тик шунысы бар: кайчан да булса власть китә, акча бетә. Шулардан коры калгач, кем сез? Мескеннәр...

Шафкат. Безнең өчен борчылма. Власть акчаны саклый, акча исә властьны яклый. Һе, әйбәт килеп чыкты! Баннерга яздырып куярга кирәк.

Тукай. Давыл күләгәсен күрәм.

Шафкат. Һәркемнең үз бәясе. Милләт атасы булып уйнаучылар булды сезнең арада. Без аларга премияләр өләштек, түшләренә елтыр калайлар тактык, сәхнәләргә мендереп затлы машиналар бүләк иттек. Бөгелә-сыгыла рәхмәт әйттеләр. Дөрес, хәзер дә аларның кайсысы коммунист, кайсысы милләтче булып эшли.

Тукай. Мина сездән берни дә кирәкми.

Шафкат. Берни дә кирәкми икән, димәк, син бу дөнья кешесе түгел... Без болай да синең бәянне күтәрдек.

*Кара жиләнле ишек төбендә тавышсыз гына елап утыра.*

Тукай. Димәк, синең белән алышбирешем юк. Хуш иттек, алайса...

Шафкат. Юк инде, апаем. Хушлашырга ашыкма. Кайда эшләвенне онытма. Син—газета хезмәткәре *(торып баса.)* Менә сина задание—бүген үк Әлмәткә китәсен. Анда минем тавык үрчетә торган фабрикам бар. Шуннан репортаж алып кайтасын.

Тукай. Нәрсә?

Шафкат. Бәдигъ мәзин куркәсе турында яздың бит әле. Минем тавыклар турында да язарсың *(көлеп.)* Мактап, әлбәттә. *(Өстәлгә сугып ала.)* Эшләргә вакыт! *(Китә.)*

*Шафкат чыгып китүгә Тукай курайга өреп «Тәфтиләү» көен чыгара. Аннары курайны сындырып ташламакчы була да, кире уйлап, сак кына өстәлгә куя.*

Тукай. И мөкатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз, син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы. *(Өстәлгә башын сала, жилкәсе дерелди, шагыйрь тавышсыз гына сулкылдый бугай.)*

*Мария Карловна керә*

Мария. Абдулла... Сез нигә занятиегә килмәдегез? *(Акрын гына Тукайга якынлаша.)* Онытгыгызмы? Поэтлар таркау халык. *(Учы белән Тукайнын чәченә орына.)* Авырыйсызмы әллә?

Тукай *(сискәнеп башын күтәрә).* Ә? Бу сезмени, Мария Карловна...

Мария. Сез дәрескә килмәгәч, мин... Эзләп килдем менә *(ясалма көлә.)*

Тукай. Сезнең миннән башка да шәкертләрегез житәрлек.

Мария. Үзем дә анламыйм. Ничек сезгә шулай тиз күнектем. Сездә... сездә... нинди дер тылсым бар. Тарта торган көч бар.

Тукай. Алдамагыз үзегезне. Юатмагыз мине дә... бернинди көч юк миндә. Минем хәтта сөйгән ярыма да күзенә карап: «Мин сине яратам! Синсез яши алмыйм!»—дип әйтергә кыюлыгым житми.

Мария. Әйтмәгез. Нигә артык сүз? Мин сезнең күзегездән күрәм.

Тукай. Сез?

Мария. Шагыйрьләр шундый. Алар дөньяга ярашып яши белми. Бүгеннән мин сезне үз канатым астына алам. Меланхолияне куабыз к черту. Җилкәләрне язып алга кузгалабыз. Киттек!

Тукай *(үзалдына).* Гаҗәп. Барысы да мине үз канаты астына алырга тели. *(Пауза.)* Юк, Мария Карловна. Кызганыч ки, немец теле миңа якын киләчәктә кирәк булмас. Мөнкир белән Нәнкир җавапны миннән татар телендә алырлар кебек.

Мария. Мөнкир? Нәнкир? Кемнәр алар? Жандармнар?

Тукай. Үлем фәрештәләре.

Мария. Абдулла! Алай пессимист булырга ярамый. Бөтенләй төшенкелеккә бирелгәнсез. Аңлыйм мин... Сезгә игътибар җитми. Менә бит—костюмыгыз таушалган, күлмәгегез керләнгән. Сезгә ныклы тыл кирәк. Дөнья мәшәкате сезнең өчен түгел. Бернигә борчылмыйча гүзәл-гүзәл әсәрләр генә язарга тиеш сез!

Тукай. Ул мине аңлар. Кичерер. Соңыннан... Күп еллар үткәч...

Мария. Беркем дә аңламый сезне монда. Аңламаслар да. Күкләр белән сөйләшүче бөек шагыйрь төс түгел аларга. Бу халык тирестә казынырга яратылган. Тирестән аерылганы исә үз телен оныта, асылыннан ваз кичә.

Тукай. Алайса, сез нигә монда? Мин дә шул халык вәкиле. Баскан җирем тар, сөйгән халкым—татар.

Мария. Шулай, шулай. Бар да дөрес. Тик сез аларга кирәкмисез. Абдулла! Әйдәгез, чит илгә китәбез. Аурупага. Чын мәдәният шунда гына. Мондый талантыгыз белән сез беркайда да югалмассыз.

Тукай. Мария Карловна! Мин беркая да сыймыйм. Шат яратса да җиһанга, ят яраткан Раббым!

Мария. Алай димәгез! Мин сезне бу сазлыктан тартып чыгарам!

Тукай. Бу сазлык—минем туган җирем. Казанны алгач, безне бирегә куып төшергәннәр. Мин шушында гына тамырланам, шушы һаваны гына сулый алам *(йөткерә.)* Ә сез, Мария Карловна, китегез. Ватаныгызга кайтып китегез. Без инде монда... Монда калырга хөкем ителгән. Чыннан да каргалган ил бу... Тик безнең ил. Үзебезнеке.

Мария. Әле сез хисләнеп кенә сөйлисез. Без, алманнар, прагматик халык. Бераз суынгыз әле, минем белән килешерсез.

Тукай. Ярлы бер шагыйрь...

Мария. Шагыйрь... Күңелегез сизмимени? Мин сезне яратам! *(Тукайның башын кочаклап ала.)* Яратам. Майн гот! Нишләттегез сез мине?

*Зәйтүнә керә. Тукай белән Мария Карловнаны күргәч шашып кала. Кычкырмас өчен авызын каплый.*

Тукай *(Мариянын кочагыннан арынмакчы була).* Мария Карловна! Буасыз бит...

Мария. Сезне минем кебек беркем дә аңламый. Беркем дә бу кадәр югары бәяләми. Каршы килмәгез сүземә! Татар поэзиясе хакына...

*Тукай Зәйтүнәне күреп ала. Зәйтүнә йөгереп чыгып китә.*

Тукай. Зәйтүнә! (Аның артыннан омтыла.) Зәйтүнәм... *(Ишек янына җиткәч егыла.)*

*Кара җиләнле урыныннан тора да Тукайны күтәреп чыгып китә.*

Мария. Тукай! *(Үзалдына.)* Бәхилләшеп кул да изәмәде.

*Шактый ук исерек Солтан керә.*

Солтан. Һа! Кемне күрәм! Маша! Синме бу? Мине эзләп килденме, кадерлем? *(Мария Карловнаны кочакламакчы була.)*

Мария. Китегез. *(Солтанны читкә этә.)* Сез исерек.

Солтан. Һи! Әллә беренче тапкыр гына күрә! Әйе, әз генә коньяк каптым. Ләкин ул сиңа булган мәхәббәтне сүндерә алмады. Әйе, сүндерә алмады. Әйе, мәхәббәт ялкыны шундый көчле, Маша-а! *(Тагын кочакламакчы була.)*

Мария. Сез... ничек җөрьәт итәсез... *(Солтанны этә.)*

Солтан. Сез дә сез! Әле кайчан гына күгәрченең идем. Черт побери! Бу хатын-кызларны аңламассың. Ма-ша! Кил, кер кочагыма. *(Кочакламакчы.)* Төкерик дөньясына.

Мария. Фу, тупас татар. Гун!

Солтан. Әйе, һун! Сезгә һун кирәк. Үзегез безнең халыкны сүгәсез, үзегез иң шәп егетләребезне чүпләп торасыз.

Чөнки каныгыз сыекланган. Анемия! Токымыгыз ныгысын өчен безнең кан кирәк. Без—донор!

Мария. Без сезгә культура алып килдек. Сез шуның кадерен белмисез.

Солтан. Белмәгән кая, Мария Карловна?! Сезгә охшатып чукынмыйбыз гына. Тиздән чукынырбыз да! Аннан гына эш калмас. Син шуны әйт: нигә сиңа бүген мин ярамыйм әле? Тукайга күзең төштеме? Тукай! Тукай! Барысының да телендә Тукай. Кем соң ул? Йолкыш бер шәкерт...

Мария. Бөек шагыйрь ул!

Солтан. Аның кебек шагыйрьләр бездә йөзләп. Менә аның турында хәзер ни язалар... *(кесәсеннән газета чыгара.)* Һәм дөрес язалар! *(укый.)*

Улмы, ул, кем ул дисезме? Ул шагыйрь бит, белсәгез!
Мәрсия, такмак язарга бик маһир бит, белсәгез.
Сибә борчак һәр сүзендә, ата ук, туп, пушкины,
Кыскасы мин сезгә әйтәм: нәкъ татарның Пушкины.
Ул кечекле, ул зураймый, ул прастуй, нәкъ суфи;
Җиндә маңка, чабу каткан, һич кирәкми пакьлисе.

Ха-ха-ха! Шәп әйткән, әйеме?

Мария. Әнчекләр өреп кенә йолдызның нуры сүрелми. Көнчел халык сез. Берәвегез аз гына өстен булса, эчегез яна башлый. Күмәкләп чабуына барып ябышасыз. Аптырыйм Аллага, нигә Тукайны сезнең арага җибәргәндер?

Солтан. Яклыйсың. Югыйсә син аны каһәрләргә тиеш! Ул синең мәхәббәтеңне кире какты. Гадәттә хатын-кыз моны кичерми.

Мария. Мин дә кичермим. Эшләпәнне алып киткән җилне дә кичермисен. Тик аның синдә эше юк, исүен белә.

Солтан. Без икебез дә бәхетсез. Минем дә мәхәббәтемне кире кактылар. Икебез дә Тукай аркасында бәхетсез. Бәхетле булыр өчен безгә кушылырга кирәк. Ике нәфрәттән бер мәхәббәт яралыр. *(Мария Карловнаны кысып кочаклый.)* Бәхетле булыйк, бәхетле булыйк. Бүген, хәзер үк. Чәнчелеп китсен дөньясы.

Мария *(тартыша).* Җибәрегез!

*Солтан аны өстәлгә аудара. Каршылык күрсәткәндә Мария Карповнаның кулы таш көл савытына тия. Ул шуны әләктерә дә Солтанның башына суга. Солтан башын тота, Мария Карловна чыгып йөгерә.*

Солтан *(бармак арасыннан саркыган канны күреп).* Кан?

*Сәхнә карангылана. Тавышлар бәреп керә: «Яшәсен!» «Долой!» Мылтыктан аталар, туп гөрселди. Сәхнә яктыра. Солтан шул килеш башын тотып басып тора. Бүлмәгә кеше тула башлый: Вафа коляскада Фатихны этеп кертә, Ибраһим, Шакир, Кәбир, Гөлсем, Фатыйма, тагын кемнәрдер йөгереп керә.*

Солтан. Кан...

Барысы да. Ни булды? Ни булды?

*Тәрәзәдә бер Малайның башы күренә.*

Малай. Фатих абый! Халык кузгалды! Урам тулы халык! Буржуйларның кирәген бирәләр. Качып калыгыз!

*Гөлсем Солтан янына килә.*

Гөлсем. Солтан абый! Ни булды? Йөзегездә кан...

Солтан. Буржуйлар атты. Башка төбәп аттылар. *(Йодрыгын өскә күтәрә.)* Р-революция!

Гөлсем. Абау! Башына зыян килгән... *(Солтанны кушеткага алып китә.)* Ятып тор. Хәзер башыңны бәйлим. *(Солтан ята, Гөлсем аның башын бәйли.)*

Солтан. Революция корбаннар сорый...

*Туп гөрселди.*

Фатих. Инкыйлап! Без көткән инкыйлап башланды.

*Тәрәзәдә Малай башы күренә.*

Малай. Кибетләрне талыйлар! Җипларны яндыралар! Шафкатны аягыннан баганага астылар! Качыгыз!

Вафа. Без нигә качарга тиеш? Без үзебез пырлитар!

Солтан *(калкынып).* Шаярма! Син газета редакторы. Димәк, Синдикат вәкиле. Эксплуататор. Эшең кәкәй синең, Вафа. Эмиграциягә качарга туры килмәсен Марат Ульмасович артыннан. Качып өлгерсәң әле.

Вафа *(ачыргаланып).* Нигә бәйләнәсең? Нигә бәйләнәсең? Мин куш-

канны үтәүче генә. Ни куштылар, шуны бастырдым гәҗиттә. Ләкин барыбер үз фикеремдә калдым.

Солтан. Әйе, аларның җырын җырладың. Чөнки синең ике балаң бар. Хатының. Әниең. Тукай китте әнә. Беркемнең дә җырын җырларга теләмәде.

Вафа. Нишләргә, ә? Нишләргә? Нишләргә?

Кәбир. Без халык белән! *(Барысына да кызыл тасмалар өләшә.)* Чыгабыз да халыкка кушылабыз. Без аларга дөрес юк күрсәтербез.

Солтан. Кабул итмәсләр. Халык интеллигенцияне яратмый. Аннары син кибет тә тотасың бит әле. Бизнесмен! Өзгәләп ташлыйлар сине.

Кәбир. Шулай. Без инкыйлаб көтәбез, үзгәрешләр телибез. Чөнки өстәгеләр чаманы белми талый, изә, кимсетә. Суларына сулыш калмагач, халык күтәрелеп чыга, юлында кем очрый—үтерә, талап үтә. Ә юлда анарга без очрыйбыз. Өстәгеләр бу вакытта күптән чит илгә качкан була, Куршевельдәме, Ниццадамы коктейль чөмереп, шәрә кызларның биегәнен карап... Ә халык барлык ачуын бездән ала.

*Туп гөрселди. Тәрәзәдә Малай башы.*

Малай. Халык Черек Күлгә бәреп керде! Кара йортны яндыралар! Тәрәзәләреннән көйгән кәгазьләр ява.

Шакир. Эз яшерәләр. Революцияләр шулай башлана.

Ибраһим. Аңламыйм сезне! Ташлагыз буш сүзне! Ил язмышы хәл ителә! Киттек мәйданга!

*Тәрәзәдә Малай башы.*

Малай. Монда киләләр!

*Кызыл бант таккан берничә кеше керә.*

Кызыл бантлы. Фатих Әмирхан кайсыгыз?

Фатих. Мин.

Кызыл бантлы. Әйдәгез!

Вафа. Аның гаебе юк! Гап-гади мөхәррир ул.

Фатих. Кая боерасыз?

Кызыл бантлы. Мәйданда халык сезне көтә.

Фатих. Мине?

Кызыл бантлы. Сезнең сүзне көтә.

Солтан. Фатих, аларга сөйли белүче кирәк. Алар әкият тыңларга күнеккән.

Шакир. Фатих! Без синең белән.

Фатыйма. Без дә барабыз!

Фатих. Инкыйлаб минем кебек гарипкә калганмы?

Кызыл бантлы *(Фатихка).* Сез кем белән? Безнең беләнме, әллә безнең дошманнар ягындамы?

Фатих. Мин инкыйлаб корбаннары белән.

Кызыл бантлы. Аңламадым.

Солтан. Халык белән ул, халык белән. Инкыйлабның төп корбаны халык үзе бит инде.

Гөлсем. Киттек соң, алайса. Халык көтә!

*Барысы да чыгып китә.. Фатих коляскада утырып кала. Аны оныталар.*

Фатих. Мин бу канлы туйда кияү түгел.

## ЭПИЛОГ

*Төнге шәһәр. Җил. Кар катыш яңгыр сибәли. Караңгы урамда Зәйтүнә белән Тукай. Ул ак җиләннән, үзеннән сәмави нур бөркелә. Зәйтүнәнең башында таушалган шәл, өстендә иске бишмәт.*

Тукай. Юк, без бу шәһәрдә сыеныр урын табалмабыз.

Зәйтүнә. Кем дә булса кертергә тиеш бит инде? Күпме таныш-белешебез бар.

Тукай. Алар кайсы кая качып бетте. Монда калганнары да, урамда аяк тавышы ишетелсә, почмакка поса. Ишекләре бикле, тәрәзләре томаланган.

Зәйтүнә *(дерелдәп).* Көз салкын килде быел.

Тукай. Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил жылый.

Зәйтүнә. Җил жыламый, ач үлемнең куркусыннан ил жылый.

Тукай. Шаккатырсың! Үз шәһәреңдә

ышык урын эзләп, кангырап йөр инде.

Зәйтүнә. Син бит кая китсәң дә «Болгар»га кайтып егыла идең.

Тукай. Анда хәзер нииндидер затлы йорт. Безнең ишеләрне якын да китермиләр.

Зәйтүнә *(урам исеме язылган элмә тактага карап)*. Габдулла! Тукта әле.

Тукай. Ни бар, Зәйтүнә?

Зәйтүнә. Менә *(элмәгә күрсәтә.)* Тукай урамы дип язылган.

Тукай. Әйе шул. Тукай у-ра-мы *(көлә.)* Урамым бар, кереп кунарга өем генә юк.

Зәйтүнә. Габдулла! Менә... музей. Тукай музее дип язылган. Кереп карыйкмы?

Тукай. Бикле ул. Музейларны төнлә бикләп куялар. Аннары анда салкындыр да...

Зәйтүнә. Шулай да без борчылмыйбыз, име, Габдулла?

Тукай. Юк, нигә борчылырга ди? Вокзалга моннан ерак түгел. Берәр поездга утырырбыз да китәрбез... Кая да булса, еракка, ераккарак.

Зәйтүнә. Безне утыртмаслар, Габдулла.

Тукай. Нигә утыртмаслар икән, Зәйтүнә? Поездларны бит кешеләр утырсын өчен ясыйлар.

Зәйтүнә. Акчалы кешеләр өчен. Ә безнең сукыр бер тиенебез дә юк.

Тукай *(кесәсенә суккалый)*. Чыннан да... Юк шул, сукыры да, күзлесе дә. Аның юклыгы әйбәт тә әле бер уйласаң.

Зәйтүнә. Юкны сөйләмә, Габдулла. Бер дә әйбәт түгел.

Тукай. Хәзер күзгә карап кычкыртып талыйлар. Акча булмагач, безгә тимәсләр.

Зәйтүнә. Нигә акчагыз юк, дип бәйләнмәсәләр ярый да. Акчалы бит ул түләп котыла. *(Пауза.)* Икәүдән икәү безгә барыбер рәхәт, име, Габдулла?

Тукай. Һи, рәхәт булмыймы, Зәйтүнә. Чыдап булмаслык рәхәт!

Зәйтүнә. Без бит бәхетле булырбыз, име, Габдулла? Илдәге бу чуалышлар бетәр, без бер куышта тыныч кына яши башларбыз. Балаларыбыз булыр.

Тукай. Бу илдә чуалышлар беркайчан да бетмәс, Зәйтүнә. Аның зиһене борынгыдан чуалып куйган.

Зәйтүнә. Өмет юкмыни?

Тукай. Нишләп булмасын? Өмет бар. Өмет тә булмаса, яшәүнең ни мәгънәсе кала? Мин дә ышанам—без икәү бәхетле булырбыз, Зәйтүнә! Мин монда бик ышанам.

*Артта аяк тавышлары ишетелә. Өч кеше якынлаша: берсе, башлыклары булса кирәк, тоташ Күннән киенгән, икенчесе Матрос, өченчесе элеккеге Эшче, ахрысы, киеме гади генә.*

Күн. Туктагыз!

*Зәйтүнә белән Габдулла адымнарын кызулата.*

Матрос. Туктагыз! Югыйсә атабыз! *(Мылтык затворын тарта.)*

*Зәйтүнә белән Тукай туктыйлар.*

Күн. Сез кемнәр?

Зәйтүнә. Без?

Тукай. Без монда яшибез!

Матрос. Документларыгыз бармы?

*Зәйтүнә куеныннан чыгарып бер кәгазь бирә.*

Матрос. Бу нәрсә?

Зәйтүнә. Укыгыз. Укый беләсездер бит?

Матрос *(кәгазьне эшчегә биреп)*. Нинди чүп бу? Сезнеңчә язылганмы соң?

Күн *(Тукайга)*. Документ!

Тукай. Юк документым.

Эшче *(кесәсеннән күзлек алып кия)*. Документыгыз юк? Төн уртасында шәһәрдә йөрисез. Комендатский час икәнен беләсезме?

Матрос. Ник сөйләшеп торасың? Кәгазьне укы!

Эшче *(укый)*. Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл; Бәйләмеш бу җирдә безне Тәнребез...

Матрос. Бу нинди галиматья? Алар бездән көләләрме әллә?

Эшче. Әҗәл эзләп йөриләр...

Күн. Гражданин! Исем-фамилияң ничек? Без монда уйнап йөрмибез. Кем син? Кайдан?

Зәйтүнә. Габдулла Тукай ул!

Тукай. Казаннан... Казан татары...

Күн. Бу коры сүзләр генә... Ничек раслый аласыз сүзегезне?

Матрос. Нигә алар белән сөйләшеп торырга? Стенага терәргә дә Алла әппәр. Олаксыннар айга.

Тукай. Айга? Сезнең шундый кодрәтегез бармы?

Күн. Кодрәт тә бар, мандат та.

Эшче. Тукай дисезме? *(Иптәшләренә.)* Алдыйлар болар! Тукай әллә кайчан үлде ул. Мин үзем җеназасын күргән кеше. Бөтен урам халык белән тулган иде. Иң алда муллалар. Димәк, буржуй булган ул Тукай.

Матрос. Әйттемме? Буржуйларны без кабердән торып чыксалар да атарга тиеш.

Күн. Ашыкма. Әгәр дә ул ышпиун булса? Иптәш Шейнкман янына алып барырга кирәк.

Матрос. Ышпиун икән, ике тапкыр атарбыз! Төрмәдә урын юк. Революция хөкеме тиз һәм аяусыз!

Күн *(икеләнеп)*. Син дә хаклы.

Зәйтүнә. Нишлисез сез? Ул халык шагыйре... Гомере буе гади халыкны яклады.

Матрос. Телеңне әрәм итмә, мадам. Лутшы бисмилланны укы. Стенага терәлегез!

Эшче. Халыкны яклаган, имеш. Халык сезнең яклауга мохтаҗ түгел. Халык үз язмышын үзе хәл итә.

Күн. Тукай... Ишеткән дә бар сыман... Бәлки, ул безнең кара исемлектәдер?

Матрос. Ну да, шунда... *(Тукайга.)* Күзенне йом, контра!

Күн *(Зәйтүнәгә)*. Ә син, кызый, бар, өеңә йөгер.

Матрос. Син! Кузгалма!

Күн *(Матроска)*. Кем монда комиссар? Кызый, яхшы чакта өеңә йөгер!

Эшче. Алла бәндәсе, сиңа әйтәләр...

Матрос. Ну, ярар. Шейнкман алдында җавап бирерсез! *(мылтыгын Тукайга төзи.)*

*Зәйтүнә, ачыргаланып, Тукайны гәүдәсе белән каплый.*

Зәйтүнә. Юк!

*Күн Зәйтүнәне иненнән тотып этеп җибәрә. Зәйтүнә егыла. Матрос Тукайга ата. Тукай шул килеш басып тора. Пуля ана бернинди дә зыян китерми. Матрос тагын ата, тагын...*

Матрос. Нәрсә бу?

Эшче. Әстәгъфирулла...

Зәйтүнә. Үлми ул, үлми! Юкка маташмагыз. Үлемсез ул!

Күн *(яраннарына)*. Киттек моннан тизрәк!

Матрос *(мылтыгын ташлап)*. А-а, Христос воскрес! *(Чыгып йөгерә.)*

*Иптәшләре дә төнгә кереп югала. Тукай Зәйтүнәне күтәреп торгыза.*

Тукай. Берәр жирең авыртмадымы, Зәйтүнәкәй?

Зәйтүнә. Алар киттеме?

Тукай. Киттеләр. Күптән киттеләр инде. Алар китте, тагын буржуйлар килде. Дөнья шундый ул, Зәйтүнәкәй. *(Пауза.)* Кузгалыйк булмаса.

Зәйтүнә. Кая, кая кузгалабыз?

Тукай. Онытылу үзәненә.

Зәйтүнә. Минем анда барасым килми!

Тукай. Син кал. Син әле бик яшь бит, Зәйтүнә. Өлгерерсең. Кал син.

Зәйтүнә. Китмә. Сине барыбер читтән үткәрмиләр.

Тукай. Арыдым мин. Бәлки, анда тынгы табармын *(китә.)*

Зәйтүнә. Мин! Мин сине онытмам...

Жыр ишетелә:

Көчләремне кара көнгә
Һич тә саклый алмадым.
Шул булды эш, шул булды эш, шул булды эш...

Көннәремнең һичберен дә
Чөнки ак ди алмадым.
Шул булды эш, шул булды эш, шул булды эш...

Залимнарны, өстеннәрне
Чөнки яклый алмадым.
Шул булды эш, шул булды эш, шул булды эш...

Керләнеп беттем үзем, һай!
Сезне пакьли алмадым.
Шул булды эш, шул булды эш, шул булды эш...

*Пәрдә.*

*2010 ел.*



Рушания
Арсланова

# БИК САГЫНЫП ИСКӘ ТӨШЕРЕРМЕН...

## Солдат һәйкәле

Пьедесталда басып тора солдат,
Яшькелт-сары бронза киемнән.
Ватан туфрагына сәлам биреп
Чүт-чүт кенә башы иелгән.

Кем улы ул солдат, исеме ничек?
Габдуллаҗан, әллә Алеша?
Аны озатып калган ярлар кемнәр?
Гөлсем, Җәүһәр, әллә Катюша?
Аны өзелеп көткән ярлар кемнәр?
Гөлсем, Җәүһәр, бәлки Алена?

Пьедесталда басып тора солдат,
Моңсу шәүлә калган күзендә.
—Әйтер сүзләрем бар! —дия кебек,
Тик әйтми шул, әйтми бер сүз дә...

Бик тә иртә гомерең өзелгән лә,
Ватан өчен көрәш кырында.
И, каһарман, мәңге яшәрсең син
Сызлап сызган халкың моңында.
Ил онытмас сезне, гасырларга
Алып китәр үзенең җырында.

Пьедесталда басып тора солдат,
Яшькелт-сары бронза киемнән.
Ватан туфрагына сәлам биреп
Чүт-чүт кенә башы иелгән.

Рушания АРСЛАНОВА–*шагыйрә; «Моңнар бүләк итәм» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

## Татар иле, сиңа ни булды?

И, мәһабәт, садә, сабыр җанлы
Татар иле, сиңа ни булды?
Ни куасың, кемгә юл куясың?
Синең белән уйный кем кулы?

Кушылганда яңа агымнарга
Булсын иде алтын урталык.
Олысы-кечесе канәгатьлек белән,
Тыныч күңел белән хупларлык.

... Әрнеп уйлап куям: и, Ходаем,
Ник саташты безнең балалар?
Сәхнәләрдә «гүзәллек» күрсәтә
Шәрә кызлар, шәрә аналар.

Урамнарда төнге фәхишәләр,
Тән сатарга тезелеп басканнар.
Алар түгел, без гаепле моңа,
Каргасалар безне каргарлар...

Бөтен дөнья, имеш, шундый хәзер,
Без кемнән ким? Әле артык та, –
Диеп чаба-чаба, и җәмәгать,
Китте түгелме соң артыкка?!.

Кайберәүләр битлек кияләр дә,
Чын йөзләрен каплап куялар.
Сиңа дигән өлешне дә умырып,
Дөнья малы артыннан куалар.

Үзенә кулай түгелләрне таптый, изә
Иблискә җанын сатканнар.
Мондый сыйфат безгә төс түгел бит,
Нишлибез без туган —Татарлар.

Китап-сүзгә инде хөрмәт бетте,
Әдипләрне санлау, зурлау юк.
Милләтенә—телгә тугры җаннар
Үкреп еласа да мәгънә юк.

Аңлыйм, дөнья яратылган көннән
Яшәеш ул—көрәш икәнен.
Тик аңламыйм камилләшәбез дип
Булдырганны җимерү кирәген.

Төпләп уйлап эшләнмәгән эшнең
Хәерле булмавы бар ахыры.
Агачлар да һәр ел яфрак коя,
Яңарырга кала тамыры.

Шаккатыра кыргый яңарышлар,
Тынычландыра алмыйм үземне.
Җан ачысы белән аваз салам:
—Тамырыбыз корый түгелме?

## Сират күпере

Сират күпере бакый дөньяда ул,
Фанида юк, дия күрмәгез.
Бар ул сират күпере һәркайда да,
Ул күперне һәркөн үтәбез.

Кылдан нечкә булган бу күперне
Бергәләшеп кирәк үтәргә.
Ярдәмләшеп, бергәләшеп үтсәк,
Беркем тәгәрәмәс түбәнгә.

Тайпылганга ярдәм кулын бирми
Күзәтүче булып калганнар,
Гөнаһланыр һәм Бакыйда алар
Сират күперен кичә алмаслар...

## Озатып кал

Китеп барам, күздән югалтканчы
Озатып кал мине кул болгап.
Отып китим әле синең җырны,
Озат әле мине җыр җырлап.

Начарлык белән искә алма, зинһар,
Сөйләп калма юкны артымнан.
Гомеремнең якты хатирәсе –
Кадерле син миңа җанымнан.

Калдырып китәсең дип рәнҗемә,
Берүк миңа үпкә саклама.
Язган булса әйләнермен әле
Тагын да бер хәтфә язларда.

Кыерсытылганда, кагылганда
Булыр микән кешем якларга.
Бик сагынып искә төшерермен
Дөньям караңгыланган чакларда.

Әллә бәхет, әллә бәхетсезлек
Синең белән булган көннәрем.
Аерыласыбыз алдан белдем,
Яшь түгәрмен диеп белмәдем.

Күзләремнән яшем кипкәне юк,
Үзәкләрем һаман өзелә.
Мин бәйлемен кырыс язмышыма,
Ә син бәйле башка кешегә...

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Айгөл
Әхмәтгалиева

# ҖЫРЛАП ЯШИ МӨХӘММӘТҖАН

САТИРИК КЫЙССА

—Болай булмый бит инде, атасы. Эштән чыгардылар дип түшәмгә төкереп ятарга димәгән. Тор, киен, жыен!—Дөньяга булган бар ачуын шуннан алырга теләгәндәй, уклавын дөбер-шатыр китереп токмач камыры җәйгән Мәрьямбикә, җавап ишетелмәгәч, аш бүлмәсеннән башын сузды. Иренең айлар буе берүзе кәрт сугып утыруына күнегеп тә беткән кебек иде, тик бүген зал ягыннан «милләт өчен» дигән җырның торган саен ешрак кабатлануы, аның әле «Интернационал», әле Рәсәй гимны көенә салынуы эчен пошыра башлады. Алай гына да түгел, саруын кайнатып, күңелен болгатып җибәрде.

—Сез, тулыр-тулмас алтылылар, җиделеләр! Туз-корольләр алдында бил бөгеп, ләббәйкә дип кенә яшәргә тиешсез! Болай яшәвегез милләт өчен кирәк! Милләт өчен, милләт өчен...—Аяк бөкләп идәндә утырган Мөхәммәтҗан, алдына тезелгән кәртләрне багучы җитезлеге белән бер болгатып, бер таратып, яңа көй шыңшыган җиреннән, хатынына күтәрелеп карамый гына:

—Кая?—дип теш арасыннан сыгып чыгарды.

—Кая булсын, гаделлек эзләргә! Ничек инде сине—егерме биш еллык стажы булган укытучыны, дәүләт теле укыткан җиреннән кыскартып атарга тиешләр?.. Их, теге юлы мине тыңласаң, бүгенге көндә ак сакаллы карт буласы идең! Күпме ялындым, күпме ялындым, кызыл дипломыңны балкондагы сандыкка минем кебек чыгарып ат та яныма сатучы булып күч дип еландай телләремне чыгарып ялвардым—тыңламадың. Имеш, тел укыта! Бөтен нәмәне уптым илаһи кыскартып баралар—озакламый авыздагы теленне дә кисеп алырга күп сорамаслар... Эте-бете кампитрда гына сөйләшеп утырганда анысы да ерак йөрмәс.—Мәрьямбикә, тутырган тавык кебек гәүдәсен дер селкетеп, әллә Мөхәммәтҗанны, әллә күзгә күренмәгән ниндидер дошманны бәргәләп ташларга теләде—кулындагы уклавы белән һаваны кыйнады. Тегеннән-моннан бүселеп чыккан җирән чәчләрен яшереп бетерә алмаган кызыл яулыгы, болай да юан гәүдәсен тагын да юанайтып күрсәткән аркылы сызыклы кызыл алъяпкычы, мәче башлы башмаклары аны хатын-кыздан бигрәк, кабиләсен яуга өндәгән юлбашчыга охшатып тора иде.

Мөхәммәтҗан аның чәпчүенә әлләни игътибар итмәде, ак майкасы

астыннан тырпаеп күренгән инбаш сөякләрен сикерткәләп, янә алдындагы кәртләренә иелде. Кыска балаклы чалбарыннан шырпы таягыдай сузылып күренгән аягына бер әрсез чебен кунган икән—карга дамасы белән жилләнгәч, үз телендә безелдәп, аш бүлмәсенә юл тотты.

—Тә-әк, крест тузлары, корольләре безнең татар дамаларын ярата диләр... Валет әфәнде, хөрмәтлем, ә сез кая үрмәләп маташасыз? Тук чырайлы депутат кыяфәтендә булсагыз да, бу урынны дәгъвалый алмыйсыз, заня-то! Понял? Анладыңмы, дим? Һәрнәрсәнең, һәркемнең бишбылтыр алдан язып куелган үз урыны бар, дим, надан. Син дә, тугызлы, башын түгәрәк булуга карамастан, шуны аңламыйча, валет артыннан ияргәкче буласыңмы? Син туганчы ук ләүхүл-мәхфүз китабына урыныңның кайда, кем артыннан икәне язып куелган ләбаса, көненә кырык сайлау үткәреп, синең өчен бөтен жир шары тавыш бирсә дә, язмышын билгеле—син унлы артында, үскәнем, ятлап кал! Борчылма, үкчән белән сигезләнене рәхәтләнеп изә аласың—күрәсеңме, син дә властьта, жанашым! Тә-әк, дүрәк каласын килмәсә, менә бу шестерканы да таптап-сытып китә аласың... Милләт өчен синең ишеләр дә кирәк! Милләт өчен, милләт өчен...

Мөхәммәтжанның «Наласа» көенә күчүе булды, күзем күрмәсен, колагым ишетмәсен ичмаса дип Мәрьямбикә зал ягының ишеген шапылдатып япты да яңаклары буйлап тәгәрәгән эре тамчыларны кул аркасы белән сөртә-сөртә, суыткыч өстендәге радиоалгычны кабызды. Төчкереп, йөткереп, шыңшып алганнан соң, Наласа көен күмеп, дикторның тынкыш тавышы яңгырады: «Исәннәрмесез, хөрмәтле радио тыңлаучы дусларыбыз! Шулай иттереп, башладык «Өр-яңа заман» каналының «Жырлы сәлам» тапшыруын. Тыңлыйлар безне, карыйлар безне планетаның төрле почмакларында, шулай иттереп, дуслар, шалтыратыгыз, эфирга чыгарга ашыгыгыз. Без республиканың йөзек кашы булып, безне төрле төбәкләрдә тыңлыйлар. Сынатмагыз, дуслар, сәламнәрне жыр аша житкерәбез. Минга шалтыратучы бар дип хәбәр итә оператор кызыбыз. Кызганыч, элемтәбез өзелеп китте. Кем белә, бәлки тыңлаучыбыз кисәк кенә сөйләшергә теләми башлагандыр. Анысы аның ихтыяжында. Хәзер мәхәббәт турында чираттагы жырыбызны тыңларбыз, дуслар. «Синга» дигән жыр. Аны танылган йолдызыбыз, милләтебезнең йөзек кашы булган Элизабет туташ башкара. Шулай иттереп, «Синга»!

Әллә радиодан агылган моң, әллә зал ягыннан ишетелгән «Наласа»ның «Туган тел» жыры белән үрелеп баруы Мәрьямбикәнең күңелен тагын да йомшартып жибәрде—ул, онга баткан бармаклары белән күз төпләрен сыпыра-сыпыра, лып итеп урындыкка утырды, куна тактасына тып-тып тамган яшьләрен алъяпкыч итәге белән сөртеп алганнан соң, ун катлы йортны дер селкетерлек итеп:

—И-и-и-их!—дип сөрән салды. Гажәп, тирә-як үз тәгәрмәчендә әйләнүен дәвам итте.—И-и-и-их, ичмасам, бүлнистән тиле дигән кәгазь тоттырып чыгарсалар, рәхәтләнеп пенсиясен алып ятар идек. Юк инде, безгә килеп тәрәлсәме... Әнә бит, авылдагы килендәш Саимә әзмәвер кебек иренә бер баруда ыспрафка апкайтты да, үзе тиле, үзе инвалид дигән булып уч тутырып акча санап тик ята хәзер.—Мәрьямбикә, радио дикторының күзләренә «текәлеп», башын шул якка борды да, эчемдә калмасын дигәндәй, ярсып-ярсып сөйләргә тотынды.—Жаныкаем, үткән айда Саимәгә ияреп үзем дә бардым бит Казанга, сатарга дип вьетнам базарыннан польский блузкалар төяп кайттык. Базарда йөргәндә Саимә апаң үзе дә, ире Назыйм да кәртинкә тек кәртинкә иде, бермәлне бүлнискә кереп чыгабыз дип машинада чишенә-киенә башламасыннармы? Битендәге бөтен буявын сөртеп, чәчен-башын туздырган Саимә багажниктан иске куфайке тартып чыгарды, аягына тишелеп беткән чүчинкә киеп куйды. Назыймның башындагы кеш бүреген салдырып, яз көне

тавык утырып чебеш чыгара торган алама бүрек элде, минсинәйтим. Кызык итеп, артларыннан ияреп мин дә кердем врачка. И-и, җаным, аның бер сүзенә бише белән җавап кайтарып, пулемет урынына сиптерә генә Саимә апаң! «Ирең эшлиме?»—ди врачың. «Кая эшләсен, ничек эшләсен, тиле бит ул, эш рәте дә, ни кылганын да белми!»—ди Саимә күзен дә йоммыйча. Гомер буе балта остасы булып шабашкада йөргән Назыйм да эш рәте белмәсә... Врачы да төшеп калганнардан түгел икән. Назыймның ике кулын әйләндереп кенә карады да: «Эшләмәсә, уч төбе тулы сөялләр каян чыккан?» ди мәкерле елмаеп. Һи, безнең Саимәне алай гына төп башына утыртырсың: «Соң, тиле дип әйтеп торам лабаса, тиле булмаса, көннәр буе ишегалдында утын түмәре тәгәрәтеп йөрер идеме?» ди апаң, керфек тә какмыйча. Тәки үзенекенә иреште, иренә тиле дигән ыспрафкы алып чыкты. Ә безнекенә, безнекенә... Ай буе бүлнистә ятса да... Акылдан язганлыгы күренеп торса да...—Мәрьямбиканең сабыр савыты тәмам тулды, аның үз-үзе белән әңгәмәсен сүзсез үкерү алыштырды. Алдында торган табакны терсәге белән төртеп җибәрүгә, табак идәнгә әйләнеп тә төште, Мәрьямбиканең борын төбендә он тузаны пәйда булды.

—Әптчи! Әптчи! Нишләп безнең ишеләргә бөтен дөньясы арты белән генә тора соң? Әптчи! И-и-их!—Мәрьямбикә башындагы яулыгын җен ачуы белән йолкып алды һәм һөҗүмгә ташланган кыяфәттә зал ягына атылды.

«Гөлҗамал» көе ярты юлда өзелде. Кемнең дурак икәнлеге хакында җырлый-җырлый кәртләр белән бәхәсләшеп утырган Мөхәммәтҗан хатынына танымагандай бертын карап торды, аннан, гадәтенчә, сүзсез генә инсәсен җыерып куйды. Ул да булмады, Мәрьямбикә печән күбәсе кадәр гәүдәсен дер селкетеп, кире борылды. Күз ачып йомганчы, бер кочак кием-салым күтәреп керде дә, Мөхәммәтҗанның җан кебек күргән кәртләре өстенә китереп салды. Иренең челт-мелт килеп торган сыек зәңгәр күзләренә җен ачуы белән кадалып, бер генә сүз әйтте:

—Киен!

—Ка... ка... кая барабыз?

—Барабыз түгел, барасың! Син барасың! Башкалага! Йә гаделлек табып, милләтеннең кем-нәрсә икәнен белеп кайтасың, яки тиле дигән ыспрафкы апкайтасың! Әнә, ачык базарларны бетерәбез дип ду киләләр—мин дә эшсез калсам, тараканнар кебек ачка тинтерәп үләрбезмени? Ни кала, ни сала булмаган бу бистәдә эш урыны әзерләп куйганнар дисеңме әллә? Ир кеше булсаң, дөньясын дер селкет, тәртипкә сал әзрәк. Вәт тапты бу ир-ат җайлы юл, ә: кайсы кукрәкчә, кайсы памперс сатарга ләфкә артына кереп басты да, тәвә кошына әверелде. Андыйларга телең ни, милләтең ни. Берсе утыра менә монда милләт өчен дип үзалдына җырлап...

Сыер дуласа, аттан яман ди. Хатынының холкын яхшы белгән Мөхәммәтҗан каршы әйтеп, бәхәсләшеп тормады, борыны гына утырып калган йөзен җыера төшеп, сүзсез генә киенергә тотынды. Терсәкләре кыршылган ике-өч кәчтүме арасыннан күрер күзгә юньлерәк тоелган көрәнсу төстәгесен сайлады. Укытканда ата-аналар җыелышына гына кигән кара чалбарын әйләндереп-тулгандырып карады—тегендә-монда сизрәгән җирләрен исәпләмәгәндә, өр-яна диярлек әле. Ярар, башкалага икән, башкалага!..

***

Барсам бардым, бармасам юк дигән кыяфәттә тукталышка таба атлаган Мөхәммәтҗан, чаттан борылган автобусны күргәч, адымнарын кызулатты. «Әнә, тагын биш йөз тәңкә йөгерә» дип, шоферга кондуктор хатын ым какмаса, кеше өстенә кеше төягән, тышына аллы-гөлле буяулар белән урысчалап «Только лучшие минуты жизни» дип язылган автобус чыжылдап үтеп кенә китәсе иде.

Сынар аягына басып, дүрт сәгать буе кысыла-төртелә килгәч, Мөхәммәтҗан

шәһәр үзәгендә төшеп калды. Бермәлгә кая, нигә килгәнен оныткандай, исе китеп тирә-ягына карап торды. Мәрьямбикәнең базардаш ахирәтләре кыш булсын, җәй булсын, чит ил, чит ил дип авыз суларын корытып мактаналар иде, Мөхәммәтҗанның башыннан «мин дә чит мәмләкәткә килеп эләктем!» дигән уй сызылып үтте. Чөнки күпме генә әйләнеп-тулганмасын, күзгә кырып салырлык та татарча сүз очратмады, урамда ул таный торган хәреф калмаган—бөтен дөньясы чит ил сүзләре белән чуарланып беткән иде. Тора-тора торҗагун булып берникадәр аптыраганнан соң, ул гел пыяладан эшләнгән алагаем бер кибеткә сугыласы итте. Биредәге герман күлмәген, әмрикә чалбарын, фин сапагиен, төрек җимпырын күреп күзләре мангаена менсә, бәя кәгазендә тезелешкән нольләрне санагач, тагын инфаркт була язды...

Берсе артыннан икенчесе тезелеп киткән кафе-рестораннарны күргәч, Мөхәммәтҗан түш кесәсеннән валидол алып, тел астына салды. Бөтен урамны кытай, япон, итальян, төрек рестораннарыннан агылган ризык исе тутырган иде. Ашказанының кытыкланып куюын сизгән Мөхәммәтҗан, кесәсендәге унлыкларны капшап алды да, як-ягына каранды: көндез шәм тотып эзләсәң, берәр татар ресторанын да табылмый калмас иде калуын, ярар инде, ашамаган өчпочмак түгел лә...

Аны иң аптыратканы шул булды: шәһәр урамында татарның сүзе генә түгел, үзе дә калмаган, вәйт әкәмәт! Югыйсә, авылда туып, бишектән төшкән чеп-чи татарның һәрберсе калага сыпырта тора. Мисал өчен, Мөхәммәтҗан туып-үскән, кайчандыр гөрләп торган авылда гына да карт-карчыктан гайре адәми зат калмады. Садигын, мәктәбен, клубын, бүлнисен яптымизация дигән афәт аркасында юкка чыгаргач, бар да калага тайды. Әмма ләкин шәһәрдә дә күренмәделәр: урам тулы, базар тулы, кибет тулы алтын тешле кара чутыр җегетләр баскан дөньяны! Татар бил бөгеп үстергән кишер-бәрәңгене дә өч тапкыр арттырып алар сата!

Уйларының очы-кырыена чыга алмаган Мөхәммәтҗан кәпәчен кашларына төшеребрәк киде дә, бертын каккан казык шикелле басып торды. Бу дөньяны аек акыл белән аңлау мөмкин түгеллеген ул үзе дә күптән төшенгән иде төшенүен, шулай да сыра шешәсе тоткан егет-кызларга кызганулы караш ташлады. «Болар мин эзләгән гаделлекнең, мин эзләгән милләтнең кайда икәнен белми дә белми инде... Кемнән сорарга, кая барырга?» Баш очында балта урынына эленеп торган бу сорауга җавап тапмыйча Мәрьямбикә янына кайтып керү гайре табигый бер хәл иде. Мөхәммәтҗан бу юлы кәпәчен баш артына шуыштырып куйды, өмет тулы күзләрен әле бу якка, әле теге якка төбәде. Футболкаларына «Мин татарча сөйләшәм» дип язылган ике егетнең каршыга килүен күргәч, кош тоткандай сөенеп, шул тарафка талпынды. Ләкин җиде катлы мат белән русчалап сүгенгән егетләр аның яныннан керфек тә какмый узып киттеләр. Футболкаларының аркасына да «Мин татарча сөйләшәм» дип язылган иде югыйсә...

Бер яктан, шау-шулы шәһәр һавасы Мөхәммәтҗанның сулышын буды, башын әйләндерде; икенче яктан, чирек гасыр мәктәптә татар теле укытып, аның дөньядагы башка телләр арасында тоткан урыны турында һәрвакыт горурланып сөйләгән укытучыны гарьлек хисләре биләп, бугазына төер утырды. Төрле төсләрдә җемелдәгән гүзәл каланың нинди милләт башкаласы икәнен күрсәтердәй мактанычын очрата алмау ниндидер хурлыклы тойгы булып күкрәгенә үрмәләде. Үзен урап алган тирәлек шулкадәр ясалма, шулкадәр төче, шулкадәр буш һәм мәгънәсез булып тоелды. Мөхәммәтҗанның ябык йөзендә тагын да өчлаебрак күренгән борыны, соңгы вакытта гел сораулы җыерылырга гадәтләнгән кашлары, баш түбәсенә кадәр сузылган мангае, гомумән, бөтен барлыгы тирә-якны аңламаудан гаҗиз кыяфәткә керде. Ул, бер кулын аркасына куеп, икенчесен Ленин бабай кебек селки-селки,

шәһәрнең машина йөрми торган урамында әрле-бирле йөренә башлады. Һичшиксез, кем дә булса сорауга җавапны—милләтнең кайда икәнен белергә тиеш иде. Моның шулай булачагына инанган Мөхәммәтҗан, сабырлана төшеп, чит ил музыкасы агылган кибет янындагы эскәмиягә таба атлады. Кешелеккә генә кия торган чалбары пычрана күрмәсен дип уч төбе белән такталарны сыпыргалагач, эскәмиянең бер почмагына сыенды.

Аның ашыгыр җире юк иде, бик дикъкать белән тирә-юньне күзәтә башлады. Менә бит, Ходайның рәхмәте, каршысындагы кибет ишегенә, инглизчә, русча зур-зур итеп язылган тактага, черки мыегы кадәрле генә хәрефләр белән булса да, татарча да өстәп куйганнар түгелме: «Өс хатын-кыз киемнәре». Янгырашы әлләни дан түгел түгелен, аның каравы чын безнеңчә, милли телебездә!—Мөхәммәтҗанның әлегәчә карангы чыраена сүрән генә җылылык йөгерде, карашы яктырып киткәндәй булды. Ул өмет нуры ингән күзләре белән янә тирә-якка төбәлде. Затлы кибет артындагы ярымҗимерек йортның каралып, күгәреп беткән стеналары арасына, урта бер җиргә, арба тәгәрмәче кадәр хәрефләр белән «Матурлык үзәге» дип язып куелган иде. Дөрес, язуын урысча гына язганнар, ләкин әлеге күренеш Мөхәммәтҗанның ачуын китермәде. Киресенчә, аның кинәт кенә кәефе күтәрелгәннән күтәрелә башлады. Сул яктагы галәмәт зур реклама тактасында зәңгәр күк йөзе, зәңгәр дингез уртасында «Зәңгәр дөньяга рәхим итегез!» дип утыз ике тешен балкытып көлеп торучы егет рәсемен күреп, шаркылдап көлеп үк җибәрде. Ныклабрак текәлеп, туристик агентлык телефонын тәкъдим итүенә төшенгәч, көлү өянәге тагын да көчәя төште. Уң яктагы тактада күзлек кенә кигән шәрә кыз сурәтен күреп, яшьлегендә тырышып-тырышып та сызгырырга өйрәнә алмаган Мөхәммәтҗан абзагыз «фью-ү-үт» дип сызгырып җибәрмәсенме? «Ноутбуклар! Бары тик бездә генә! Ташламалы бәяләр!..» Кызның кендегенә язылган сүзләр быел укытучыларга таратылган ноутбукны, ул ноутбук үз чиратында мәктәпне, мәктәп исә эштән куылуны, эштән куылу милләт өчен икәнлекне, милләт өчен дигәне башкалага килү сәбәбен исенә төшерде дә Мөхәммәтҗан корт чаккандай сискәнеп китте. Ни эзләгәнен онытып, җәелеп утыра түгелме сон? Мәрьямбикә аермачык әйтте ләбаса: йә милләтнең кайда икәнен белеп кайтасың, яки ыспрафкасыз күземә күренмисең, диде. Кайсы юлның җиңелрәк икәнен белсә икән ул...

Уйлардан авырайган башын иеп күпме утыргандыр, кемдер шактый саллы итеп җилкәсеннән каккалагач, күзен күтәрде. Каршысына туп шикелле түгәрәк гәүдәле, өреп кабартылгандай тулы кызыл йөзле милиционер килеп баскан икән.

—Гражданин, сезнең документларыгыз?

Хәл-әхвәл сорашмыйча, әңгәмәне шактый дорфа төстә урысча башлаган җиз мыек Мөхәммәтҗанга һавалы караш ташлады. Мондый әдәпсезлектән ачуы кабарган Мөхәммәтҗан җебеп төшмәде, үзе дә ярыйсы гына тупас тавыш белән:

—Сезне кеше белән исәнләшергә өйрәтмәделәрме әллә, иптәш милиционер?—дип сорауга сорау белән татарча җавап кайтаруны кирәк тапты.

—Милиционер түгел, ә полицейский! Дөньяның кая таба тәгәрәгәнен белмисезме әллә, абзый кеше?

—Татар теле укытсам да, математикадан да төшеп калганнардан түгел мин, энем. Кушылучыларның урынын алыштырудан гына сумма үзгәрмәгәнен бә-әк әйбәт беләм. Аннан килеп, минем бабайны, Бөек Ватан сугышы вакытында полицай булып эшләгәне өчен стенага терәп атканнарын да онытканым юк.—Мөхәммәтҗан кирәкмәгәнне һәм артыгын ычкындыруын

аңлап, телен тешләде. Ләкин жиз мыек Бөек Ватан сугышының кайда, кайчан булганлыгыннан бихәбәр иде, ул, билсез гәүдәсен көзгә кереп симергән үрдәк кебек як-якка чайкалдырып, ирнең янәшәсенә үк килеп утырды. Куен кесәсеннән паспортын алып маташкан Мөхәммәтжанга, кирәкмисенә дигән шикелле кул гына селтәде дә, эш эшләп арыган кыяфәттә уфылдап, эскәмиягә кырын ятты.

—Авыр көн булды бүген. Бер нарушитель дә таба алмадым.

«Эзләп тә маташмадым, диген». Мөхәммәтжан үз уеннан ирен чите белән генә көлемсерәп куйды. Бу милиционерның, түгел лә, полицейскийның үз-үзен тотышында нindidер капма-каршылык һәм нindidер... самимилек(!) бар иде.

—Энем, иптәш полицайский, Ходай үзе жибәргәндер сине минем янга, как раз син генә ярдәм итә аласың да инде.—Мөхәммәтжан, әллә кайчангы танышын очраткандай, ифрат куанып, сингә кучүен дә сизмичә, салпы якка салам кыстыруын дәвам итте.—Сәясәт һәм милләт мәсьәләсендә бик тирән йөзүең чыраеңа чыккан, энем, бер генә соравыма жавап табарга булышсаң...

Мондый мактауны ишеткәч, жиз мыек тураеп утырды, тук чыраена көчкә кысылып урнашкан күзләре дә түгәрәкләнеп киткәндәй булды, йөзенә нindidер канәгатьлек таралды.

—Тыңлап карыйк.—Тавыш бөердән чыкты.

—Менә син, энем... атыңны белмим...

—Атым юк минем, машинам гына бар.

—Исемеңне диюем...

—Чукынып китсен, үзебезчә Вәлиәхмәт дип эндәш.

—Кыскасы шул, Вәлиәхмәт энем, милләт өчен дип эшләттеләр, милләт өчен эштән кудылар, милләт өчен дип хәзер телевизор, интернет, сыра шешәсе белән кыйныйлар. Соравым шул: кем ул милләт һәм кайда ул?

— Һи, абзый кеше, исең киткән икән. Мин дә менә үземне белә-белгәннән бирле гел кыйналып үстем, аның нәрсәсе бар... Иң беренче кыйналуым мәктәпкә укырга кергәч булды. Макулатура жыярга кушканнар иде, үч иткәндәй, өйдә ник бер гәжит бите булсын. Күкәй тәрергә шәп дип алдыра торган район гәжитеннән дә жилләр искән, шәһәрдән апалар кайткан иде... Ул чагында баш шәп эшли иде әле минем, күп уйлап тормадым, караңгы төшүгә, бер дустымны ияртттем дә, мәктәпкә элдерттем. Вәт шул. Төнлә белән тәрәзәдән китапханәгә кереп, иң калын китапларны сайлап тутыруыбыз безгә беренчелек китермәде. Укытучыны әйтер идем, үлчә дә алып куй бит инде, капчык актарып утырмаса... Әткәй үзем урлап чыккан китаплар белән төйде генә башны.

Өйләнгәч, хатыным кыйный башлады. Теле белән дә, кулы белән дә дигәндәй... Бермәлне шулай телевизор карап утырганда:

—Кризис дигән сүзгә менеп атландылар да тагын гади халыкны изәргә тотындылар. Меңәрләгән кешене эшсез калдырдылар, ә катлы-катлы түрәләр барысы да үз урынында,—дип үзалдыма ярсып утыра идем, уклау белән берне башыма «шап»! Көтелмәгән сугудан чак кына телемне тешләп өзмәдем.

—Күп сөйләнмә, телеңне кыскартырлар!—Хатын елан кебек бер генә ысылдап куйды...

Шуннан соң үз-үземә сүз бирдем: тукта, Вәлиәхмәт, авыл малае бит син, күпме кыйналып яшәргә була?! Давай, мин әйтәм, кулыңа таяк тотып, үзеңә кыйный... эһем, эһем, үзеңә командывать итә башларга пора! Шул фикерне бажай белән уртаклашкан идем, айн маминт хәл итте дә куйды—үзе янына милициягә эшкә урнаштырды. Эшкә кергәндә илле жиде кило идем, менә,

бер ел эчендә туксан тугызга җиттем. Ну, абзый кеше, сер итеп кенә әйтим, милициядә эшләү өчен әлегә талант житеп бетми минем. Лутчы жырчы булып кына киткән булсам... Бераз гына арттан этсәләр, татар сәхнәсендә йолдыз буласы кеше идем бит мин...

Вәлиәхмәтнең һич көтелмәгән моңлы тавыш белән «Сарман буйларында» дип сузып җибәрүе булды, Мөхәммәтҗан, өстеннән тау төшкәндәй, ихлас елмаеп куйды. «Имәндә икән чикләвек. Әйтәм аны нормальный гына кешегә охшап тора. Эчендә татар моңы бар икән».

Мөхәммәтҗан түзмәде, арык гәүдәсенә ятышып бетмәгән калынрак тавыш белән җырга кушылды. Ташкаланың үзәк урамында, ярымкиенгән хатын-кызларның керт-керт баскан биек үкчә тавышларын, сыра шешәсе күтәргән яшьләрнең мәгънәсез көлү авазларын, теге яки бу почмактан ишетелгән чит ил музыкасын күмеп, «Сарман» көе янгырады. Узып баручылар, эскәмиянең бер почмагын биләгән какча Мөхәммәтҗанга һәм утыргычның дүрттән өч өлешенә рәхәтләнеп җәелгән полицийскийга кызыксынулы караш ташлап, аю биеткәнне тамаша кылырга теләгәндәй, берәм-берәм алар янында туктала башладылар.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Нинди юллар белән лә үтәрбез;
Дус-иш белән бергә эш иткәндә,
Теләкләргә тизрәк лә житәрбез...

Дуэт «Иске кара урман» көенә кучкәндә эскәмия тирәсен байтак халык уратып алган иде. Берәүләр сержант Вәлиәхмәтнең авыз күтәреп җырлап утыруыннан кызык табып, мыек астыннан елмаешты, икенчеләр, җырның сүзләренә колак салып, уйга калды. «Исеректер алар, йә булмаса җүләрләр йортыннан качкандыр, ашыгыч ярдәм чакырырга кирәк» дип фикер алышучылар да бар иде арада. Мөхәммәтҗан исә тирә-юньдәге беркемне күрми-ишетми, күзләрен йомып, җыр әсирлегенә, җыр фәлсәфәсенә бирелде. «Дус-иш белән бергә эш иткәндә! Менә! Менә, төп хикмәт кайда! Их, шул бергәлеккә, бердәмлеккә өйрәнә алсак! Милләт өчен дигәннәренең дә мәгънәсе, асылы аңлашылыр иде! Ә бола-а-ай... Милләт өчен, милләт өчен...»

Мөхәммәтҗан әлеге сүзләрне, өендәге кебек, «Интернационал» көенә салып, кычкырып җырлап утыруын үзе дә абайламаган иде. Вәлиәхмәтнең, тамагына кылчык кадалгандай, кинәт кенә тукталып калуын, эскәмиядән сикереп торуын күргәч, аптырап китсә дә, җырын ярты юлда өзәргә ашыкмады.

—Молча-ать! Син нәрсә, абзый кеше, башкала уртасында митинг оештырырга булдыңмы әллә? Тә-әк, кузгалырга, уянырга кушасың, димәк. Безнең иреклe халкыбызны астыртын рәвештә генә коллар һәм ачлар дөньясы дип мыскылламакчы буласың? Беләбез, беләбез синең ишеләрне...—Вәлиәхмәт, жен алыштырган диярсең, әле генә ингә-иң терәп җырлашып утырган Мөхәммәтҗанны йолкып диярлек урыныннан торгызды. Сержантның әлегәчә кызыл йөзе көрән төскә кереп, күзләрендә бая пәйда булган самимилек юкка чыкты. Күптән түгел генә монда тибрәлгән теле аждаһа теленә әверелде.—Ныклап тикшерә китсәң, террористлар белән элемтә тотучы провакатордыр әле үзең. Милләт өчен, имеш. Бүгенге кешелекнең милләте дә, ата-анасы да, сөйгән яры да акча, абзый кеше! Бу яшенә житеп, шуны да аңламаска... Тагын берничә елдан Җир шарында акчадан башка бер генә кәгазь дә калмаячак. Давай, абзый, калганын участокта ачыклап бетерербез!

Вәлиәхмәт, ясалма елмаеп, Мөхәммәтҗанны култыкларга үрелде.

—Аны безгә калдырыгыз!—Урам почмагына «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктаган икән. Озын җинле зәңгәрсу күлмәге аша тыгыз мускуллары беленеп торган яшь егет, халык агымын ерып, Мөхәммәтҗанга таба атлый иде.

Сержант Вәлиәхмәт исә, «кайсыгыз шалтыратырга өлгерде» дигән сүзсез сораулы карашын төркем өстеннән йөгертеп узды да табибның колагына иелеп нидер әйтте.

Мөхәммәтҗан тирә-яктагы бушлыктан гайре берни күрмәде. Ул сержант белән табибның үзен бүлешүләреннән, табиб егетнең: «Безнең эш хакы клиентлар санына бәйле», дип, Вәлиәхмәтнең кесәсенә акча төртүеннән, тирә-яктагы халыкның: «Әйттем бит җүләрләр йортыннан качкан дип, менә, алырга да килделәр», дип гөжләвеннән бихәбәр иде. Алай гына да түгел, үзен хастаханәгә алып китәчәкләрен дә, эшсез калуының сәбәбен сөйләячәген дә, үзенә психик яктан сәламәт түгел дигән белешмә язып бирәчәкләрен дә белми иде әле.

Ул, сержантка да, табиб егеткә дә һич әһәмият бирмичә, кулларын черки кугандай болгый-болгый:

Тик очалмыйм, карап калам,
Кыр казлары артыннан,—

дип, биектә-биектә нокта булып кына күренгән горур, иректә кошларга күз төбәп, яңа җыр башлады...

---

Фидаил
Мәҗитов

## Замана чибәркәенә

*Биткәемнең иң очына миң яраткан...*
Дәрдемәнд.

**Чәчкәйләрен кат-кат манган төрле төскә,**
**Кыршау кигән, турайсын дип өске тешкә.**
**Пах-пох килә, паровоздай бөркеп төтен,**
**Тырнаклары гүя кылыч: очлы, үткен...**

**Тәмәкесен карап тормый атты аска.**
**Кырт-пырт атлап кереп басты автобуска.**
**Кендегендә ялтыр-йолтыр килә чылбыр,**
**Мәхәббәтнең ятьмәләре менә шулдыр...**

**Төтен катыш хушбуй исе капты башка,**
**Исән-имин җитсәм иде тукталышка.**

## Люция Әблиева

***

**Кырмыскалар йорт салалар,
Көн дә килә комиссия.
Килмәс иде комиссия
Аңарда шундый миссия.**

**Комиссия—Арысланнан,
Арыслан бик кырысланган:
«Тикшерегез, тикшерегез
Тикшерегез... төкерегез!»**

**Бүредән дә комиссия
Аны яза, моны яза.
Иншаллаһ, кырмыскалар
Бүредән дә алыр җәза.**

**Ә саескан сай йөзсә дә
Серләрендә төзелешнең.
Сөрән сала: «Саескансыз
Киләчәге юк бу эшнең!»**

**Кырмыскалар йорт салалар,
Үз эшләрен алар белә.**

**Әйтер идем, бу осталык
Токымыннан аның килә.**

**Әмма ләкин бар миссия
Хөрмәтле комиссиядә.
Яхшы булса отчетлары
Булыр аның почетлары.**

**Җанып-пешеп комиссия
Хата эзли, акт яза.
Кәгазь булсын, алай-болай
Була калса, бәла-каза.**

**Җитмеш төрле Комиссия,
Берсе килә, берсе китә.
Кырмыскаларның көннәре
Комиссия белән үтә.**

**Бу эш, дуслар, шулай бетә.
Ел азагы килеп җитә.
Тагын килә комиссия
Әзерме йорт? Түгел... Ния?**

**...Комиссия акт яза.**

***

**Ата казга сәлам бирдем,
Дуңгызга җизни дидем.
Начальникны, әйбәт, диеп,
Җиде кат күккә чөйдем.
Туташ диеп эндәштеләр—
Елмаеп кабул иттем.
Түтәй дип урын бирделәр—
Трамвайдан төшеп киттем.
Сөймәгәнгә сөям дидем,
Яратканнан арындым.
Сикереп үттем чокырларны,
Тигез җирдә абындым.
Дустым упкынга очканда
Мин аны ныграк эттем.
Тагын ниләр булыр иде—
Шөкер, уянып киттем.**

***

**Бу дөньяда күпме ялгышабыз,
«Онытмыйк» дип, тамга асабыз...
Урап килеп шушы ялгышларның
Өсләренә кабат басабыз.
Бу дөньяда күпме алдашабыз,
Алдашмаска вәгъдә бирәбез.
Вәгъдәләрне бик тиз онытабыз,
«Борчакларны учлап сибәбез».
Бу дөньяда күпме урлашабыз,
Урлашмаска антлар итәбез.
Антларыбыз таулар булып үсә,
Без аларны урап үтәбез.**

---

## БАТУЛЛИЗМНАР

- *Элек хатыннарның чәче озын, акылы кыска иде, хәзер чәче дә, акылы да кыска. Элек ирләр акыллы-сакаллы иде, хәзер сакал да юк, акыл да.*
- *Русиядә үзгәртеп кору була алмый, Русиядә үзгәртмичә кыру гына була ала.*
- *Русиядә миһербан һәрвакыт нәҗестә, нәҗес тәхеттә булды.*
- *«Тукай»ны алыр өчен усал әсәр язарга кирәк яки бүләк дауларлык усал хатынга өйләнергә кирәк.*
- *Һәр сабый уенчык мылтыктан атканда чынлап кеше үтерергә тели.*
- *Базарда иң кыйбат, иң үтемле товар—Татар теле. Ана телен сатып баеганнар бар. Иң елгыр бизнесменнарны Гиннес китабына кертергә кирәк.*
- *Түбәтәй киеп кенә татар булмассың, түбәтәйне салып таптап та урыс була алмассың!*
- *Мәхәббәт белән генә өйләнешсәләр, дөньяда җиде миллиард түгел, җитмеш кеше дә булмас иде.*
- *Батарея—суык чакта сап-салкын, җылы чакта кап-кайнар бер нәрсә.*
- *Сөяркә—башка берәүнең хатыны.*
- *Сыер—бер тапкыр ашатып, өч тапкыр саву өчен биоҗайланма.*
- *Хатын-кыз ир-ат белән тигез хокуклы булам дип, тәмәке тартып, аракы эчеп, ыштан салып, чалбар кигән бер зат.*
- *Бүрелеген җуйган бүре бүрек булыр.*

**Рабит БАТУЛЛА**

## *«Казан утлары» архивыннан*

СИБГАТ ХӘКИМ ЯДКАРЕ



*Сибгат Хәкимовка 21 яшь, мәктәптә пионервожатый булып эшләгән чагы. 1932 ел.*



*Ватан сугышы башланырга бер ел калганда алынган рәсем. Сулдан уңга—Хәсән Туфан, Әхмәт Исхак, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи. Васильево ял йорты. 1940 ел.*



*Ике фронтовик—ике дус—Сибгат Хәким һәм Михаил Львов (Габитов Рәфкать). Үткән гасырның 70нче еллары.*



*Илленче елларда әдәбиятка килгән әдипләр Шәүкәт Галиев, Хисам Камал, Илдар Юзеев, Гамил Афзал үзләренең остазы Сибгат Хәким белән (уңнан икенче). 1958 ел.*




*Сибгат Хәким "Казан утлары" журналының 60 еллык юбилеенда чыгыш ясый. 1982 ел.*



*Сибгат Хәким. 1973 ел.*

# ЯКТЫ ШӘХЕС, ОЛЫ ИҖАТ

КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Егерменче гасыр татар әдәбияты тарихын, бигрәк тә егерменче-илленче елларын өйрәнгәндә еш кына Кави Нәҗми эшчәнлеге, иҗаты турында уйланырга туры килә. Әйе, К.Нәҗми әлеге унъеллыклар әдәби хәрәкәтенең үзәгендә тора. «Октябрь күмәге» дисеңме, ТАПП оешмасымы, 1934 елда төзелгән Язучылар берлегеме... Һәрберсендә К.Нәҗми җиң сызганып эшли, оештыру-җитәкчелек вазифаларын башкара. «Кызылармеец» газетасында, «Совет әдәбияты» журналында мөхәррирлек итә, Татарстан Язучылар берлегенең тәүге рәисе була. СССР язучыларының беренче съездында «Татар әдәбияты» дигән темага махсус доклад ясауга ирешүе һәм шул чыгышта милли сүз сәнгатебезнең үткәнен һәм хәзергесен бөтен дөнья алдында (анда 52 илдән каләм әһелләре катнаша) шактый тулы итеп күрсәтә алуы үзе бер тарихи адым дип каралырга тиеш. Болар барысы да бу шәхеснең гаять киңкырлы эшчәнлеген, көчле рухын, оештыру талантына ия булуын күрсәтә. К.Нәҗми үткән юлны җентекләп карасаң, исең китә, ул бер үк вакытта берничә вазифа башкарган (әле нинди генә!), шуның өстенә актив рәвештә әдәби иҗат белән шөгыльләнгән.

Язмыш үзе аны хәрәкәттә булырга яраткан, күрәсең. Яңа гасырның беренче елы ахырында Нижгар якларында туган малай бала вакыттан ук сәяхәттә, хәрәкәттә. Авылдагы көнкүреше шактый авыр хәлдә булган Һибәтулла агай, гаиләсен ияртеп, Идел буе, Кырым, Урал, Алтай якларында бәхет эзләп йөри. Малайга алты яшь вакытта Бакчасарайда да яшәп алалар. Әтисе атаклы «зынҗырлы мәдрәсәдә» (Исмәгыйль Гаспралы мәктәбе дип тә йөртәләр) каравылчы булып тора. Яшь булу сәбәпле, Кави әле бу мәдрәсәдә укымый, гаилә тагын юлга кузгала. Кави аннан иске генә булса да фәс киеп китә. Актүбәдә урнашып, казакъларның көтүләрен көткәндә дә шул кыршылган баш киемен киеп йөри. Шуның өчен аңа «төрек малае» дигән кушамат та тагыла. Ун яшендә әлеге «төрек малае» Актүбә байларыннан берсе Сабит Алюков дигән кешегә хезмәткә керә. Шундагы казакъ, нугай балаларын рус рухында тәрбияләү максаты белән махсус миссионерлык мәктәбе ачалар. Күрәсең, «инородецлар» дип йөртелгән кешеләрнең балалары ул мәктәптә укырга атлыгып тормаган. Хакимият вәкилләре С.Алюковка да шул мәктәптә укытыр өчен балалар табуда ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән булырга тиеш. Ник дигәндә, ул үзендә хезмәттә булган Кавины ирексезләп булса да әлеге мәктәпкә бирә. Әмма малай бу чит-ят рухлы мохитне үз итә алмый, аннан качып китеп, алты сыйныфлы татар-рус мәктәбенә укырга керә. Монда беренче тапкыр Тукай исемен ишетә, аның әсәрләрен күңелендә йөртә башлый. Беренче шигырен дә шушы мәктәптә укыганда яза. Әмма тиздән аның әти-әнисе үлеп китә. Ятим калган энеләрен-сеңелләрен авылда калган туганнарына алып кайта. Үзе янадан юлга чыгып китә: гражданнар сугышында катнаша, педагогик курсларда белем ала, хәрби мәктәптә укый, байтак еллар кораллы көчләр сафында хезмәт итә. Тора-бара тормыш барышы К.Нәҗмине әдәби иҗатка алып килә һәм ул шагыйрь, әдип, публицист, әдәби эшне оештыручы буларак танылу ала.

Язучы турында сүз алып барасың икән, әлбәттә инде, аның эстетик карашлары мәсьәләсе дә алгы планга чыга. К.Нәҗми кулга иҗат каләме алган вакытны илдәге яшәешнең асты-өскә килү чоры дип билгеләргә мөмкин. Кешенең дөньяга карашын,

эш-гамәлләрен, еш кына әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәтен билгеләгән, рухи дөньясын тәшкил иткән дингә, изге китабыбыз «Коръән»гә тискәре мөнәсәбәт барлыкка килү бик күпләр өчен акылга сыймаслык хәл була. Гомер буе тир агызып эшләп, ару тормышта яшәгән кешеләр яңа хакимият алдында гаепле затлар булып чыга. Мал-мөлкәтләре таланып, «халык милке» игелә. Шул ук вакытта таланган байлыкның кем кулына килеп керүе дә, халык дигәннең кем икәнлеге дә билгесез булып кала. Көчләп алынган мал, бармак арасыннан аккан ком кебек, чәчелеп-сибелеп бетә. Бу хәлләр әдәби-мәдәни даирәгә дә үтеп керә. Рухи нигезебез дип саналган әйберләр инкарь ителә. Сәнгатьлелек дигән бик тә мөһим үлчәм әдәби әсәрләрне бәяләүдә кирәксезгә әйләнә. Аның урынын социологизм дигән төшенчә, ягъни хакимияткә килгән «эшчеләр» сыйныфы партиясе житәкчеләренең карашлары үткәрелү яки аңа битараф булу авторны бәяләүдә төп бизмәнгә әверелә.

Әдәбиятта кабул ителгән эстетик кыйммәтләрне саклап калу тарафдарлары булган кебек, шул өлкәдә партия өйрәтүләренә бәрабәр карашларны иң дөрес методологик нигез итеп алган кешеләребезгә дә кытлык булмый. Үз карашларына даими рәвештә тугры булып калучы фидакарьләр дип Ж.Вәлиди, Г.Сәгъдиләрне атасак, Г.Гали, Г.Нигъмәтиләр инде, сәнгатьлелекнең гомуми кануннарын таныган хәлдә дә, социологик карашның өстенлек ала баруын тәэмин иткән галимнәр була. Әдәбият тарихчысы һәм галиме буларак караганда, Г.Ибраһимов менә шушы ике карашның уртасындарак тора. Әдип буларак, сүз сәнгатенеңерактан килгән хасиятләреннән ваз кичә алмаса да, нәзари мәсьәләләрдә көндәлек идеологияне искә алырга тырышып эш итмичә булдыра алмый.

Яңа буын каләм әһелләренә исә пролетар идеология таләпләренә буйсынып эш итү жинелрәк була. Ник дигәндә, яңа гасыр башындагы эзлекле инкыйлабый вакыйгалар тәэсирендә үскән һәм формалашкан буын буларак, аларга бу идеяләрнең тормыштагы чагылышын нәзари генә түгел, көндәлек хәл-әхвәлләрдә дә күрергә туры килә. Кави Нәжми менә шушы буынның бер вәкиле була. Ул егерменче елларның яңа шартларында әдәбиятның билгеле юлдан китешен иң эзлекле тәэмин итүчеләрнең берсе. Сүз дә юк, яшь язучы тоткан юнәлеш пролетариат диктатурасына хезмәт итә. Ул елларда имажинизм белән мавыгып алуы да шуның белән бәйләнгән. 1923 елның 5 декабрендә «Кызыл Татарстан» газетасында ул имажинизм турында болай дип яза: «Иске әдәбиятның, иске шигъриятнең форма, мөндәрижә, стиль ягыннан жимерелүен тизләтүче инкыйлабый агымнарның берсе». Күрәбез, имажинизм «инкыйлабый агым» икән. Татар шигъриятендә иске кануннардан качам дип, 8-9-10 ижекле тезмәләр белән язудан баш тартуы да шуннан килә. 1923 елда язылган «Ташкала фажигасе» поэмасы тулысынча имажинизм белән мавыгу нәтижәсе булып тора. «Кабыргасы белән тора», «Ләпшерәгән читекләр» әсәрләрен дә шуның янында карарга туры килә. Яшь шагыйрь татар шигъриятенең арттa калуын анда һаман да «зиләйлүкчелек»тә, ягъни Г.Тукайның «Зиләйлүк» әсәре ижат ителгән үлчәмнең яшәвендә күрә. Әмма тора-бара форманы үзгәртүдән бигрәк, «үз ижатының пролетариат диктатурасының идеология коралы» булырга тиешлеген алгы планга куя һәм имажинизмнан китү кирәк дигән карарга килә. Ун елга якын вакыт узгач, 1932 елда »Шигырьләремә карата берничә сүз» дигән мәкаләсендә «форма белән эчтәлекнең бердәмлеге мәсьәләсен үзләштереп житмәү аркасында, минем бик күп шигырьләремдә әсәрнең форма ягы белән мавыгу—образларны бер ноктага тыгызлап өю, образлар белән реаль күренешләрне алмаштыруга хәтле барып житү кебек ялгышлар күренде» дип яза.

К.Нәжминең «Әдәбиятыбызда марксизм тәнкыйте һәм Галимжан» дигән мәкаләсе бар. Ул «Казакъ кызы» романы авторына 50 яшь тулу уңае белән 1928 елда чыккан «Галимжан Ибраһимов» дигән китапта басылган. Егерме жиде яшәр К. Нәжминең эстетик карашы биредә шактый ачык төсмерләнә. «Г.Ибраһимовның,— ди ул,—ул чордагы тәнкыйтьләре, әдәби әсәрнең төзелешенә, сәнгатьчә ничек эшләнешенә күбрәк урын биреп, идеализмга нигезләнгәннәр иде». Болай дигәндә, Г.Ибраһимовның ул вакытта пролетар рухтагы әдәбиятның киресен белдерү өчен кулланылган «сәнгать сәнгать өчен» дигән карашка якын торуын әйтергә тели. Бер үк вакытта әле инкыйлабка кадәр үк Г.Ибраһимов тәнкыйтендә марксизм нигезләренә

китереп чыгаручы омтылышлар булуын да билгели. Әдәбияттагы марксизмны К.Нәҗми, шикләнмичә, реализмга нигезләнгәнлектә күрә. Г. Ибраһимовны менә шул марксизмнан читтә тота торган нәрсә, ул да булса, «идеализм нигезендәге уйланучанлык (мечтательлек) һәм романтизм билгеләре» икән. «Уйланучанлык» дигәндә, К.Нәҗми «иҗтимагый сәбәпләргә кагылмыйча» дигән фикер иканлеген әйтә. Ул бу очракта «иҗтимагый сәбәпләр» турында сөйләгәндә дә уйланучанлыктан башка эш итеп булмавын онытып җибәрә.

К.Нәҗми карашынча, әдәбияттагы марксизмга мөнәсәбәттә Г.Ибраһимов урта бер җирдә торса, Ж.Вәлиди исә бөтенләй каршы якта икән. Ул моны кистереп әйтә: «Ж.Вәлиди кулланган тәнкыйть системасы идеализмга тамыр җибәргән. Бу системадан икенче бер системага (марксизмга—Ф.Г.) күчмичә торып, матур әдәбият барышындагы зур мәсьәләләрне генә түгел, бәлки бик кечкенәләрен дә, мәсәлән, таң турындагы кечкенә бер шигырьнең нинди яктан бәя алырга тиешлеген дә аңлавы мөмкин түгел. Марксизм карашларына күчкәнче, Г.Ибраһимов та шул ук хәлне башыннан кичерде». Шушындый һәм башка дәлилләүләр белән К.Нәҗми, ниһаять, ахыргы нәтиҗәгә килә: «Марксизм тәнкыйтенең өстенлеге—аның башка фәннәр төсле үк гыйльми булуындадыр». К.Нәҗми марксистча язылган классик хезмәт сыйфатында Г.Ибраһимовның «Кара маяклар һәм ак әдәбиятлар» (Мәскәү, 1924) исемле китабын саный, чөнки «анда,—ди ул,—татар һәм төрек акгвардеецлары тарафыннан чыгарылып килгән матбугатка, әдәбиятка шул хәтле үткен, шул хәтле туры анализ ясый ки, аның һәрбер юлын укыган саен үз көчләребезгә ышанычыбыз арта һәм җимерелгән сыйнфый катлауларның бөтен черүләре экрандагыча килеп күз алдына басалар». Менә шушында без К.Нәҗминең, үзе икрар иткәнчә, әдәбиятны марксизмча аңлауга Г.Ибраһимов кебек читкә тайпыла-тайпыла түгел, бәлки турыдан-туры төбәп килүен күрсәтергә теләвен күрәбез. Дөрес, шулай ук ул үзе аңлатканча, аның да бу тарафка юлы бернинди дә бормаларсыз гына булмаган икән. «Баштагы чорда,—ди ул,—минем җитди генә ялгышларым булды. 1923 елда Ф.Бурнаш редакциясендә чыккан «Көрәш җырлары» җыентыгындагы дистәгә якын шигырьләремне шундыйлардан саныйм. 1923-24 елларда имажинистлар иҗат методы белән язылган кайбер әсәрләремне дә шулар белән бер рәткә куям». Ул шундый ялгышлары итеп «Ташкала фаҗигасе», «Тормыш төбендә», «Көзге әкият», «Чабатаңны кемгә тукыйсың?», «Җәллад күләгәсе», «Курай», «Тилергән кошлар төркеме» шигырьләрен, «Тукран даласы», «Башланды...» кебек проза әсәрләрен кертә. Ул аларның кимчелекләрен нәрсәдә күрә? «Тукран даласы» (1921) хикәясенең төп гаебе анда сүз алып барыла торган затларның сыйнфый яктан кем булулары тәгаен билгеләнмәгәнлектә булса, «Башланды...» хикәясендә куелган проблемаларны чишү ягы, төгәлрәк әйткәндә, «формаль детальләр, сюжет вак-төякләре белән үтә мавыгып, төп фикергә зарар китергәнлегем». Ә төп фикер аның сүз чолганышыннан ачык аңлашыла, авторның идеалы «чын күңелдән диалектик материалист булу».

Үз-үзенә менә шулай тәнкыйди рухта матбугатта чыгыш ясауда ул оригиналь түгел. Ул чорда, башкалар әйткәнчә, үземне үзем камчылап калыйм да, идеологик гаепләрдән котылып калып булмасмы дип, бер дә булмаса аларны йомшарту максатында бик күпләр шулай итәләр. Ләкин утызынчы еллар афәте барыбер аны да читләтеп үтми. Аның илгә, халыкка, фиркагә каршы нәрсә дә булса эшләгәнен күрсәтә алмагач, җәза органнары бер дә аптырап тормыйлар—син Язучылар союзындагы халык дошманнарын фаш итү буенча таләп ителгәнчә актив эш итмисең дигән гаеп тагалар. Бу хакта Язучылар союзында уздырылган җыелышта өлкә комитеты вәкиле Т.Имаметдинов дигән кеше болай дип белдерә: «Халык дошманы, буржуаз милләтче К.Нәҗми, адым саен икейөзләләнеп, Ф.Сәйфи, Г.Гали, З.Гали, Ш.Усманов, Гинзбург, Толымбайский һ.б. шундый иң кабахәт дошманнарны аңлы рәвештә күтәреп, халык дошманнарына астыртын җимерү эше, корткычлык эше алып барырга материаль һәм мораль ярдәм итеп килде. Бу фактка каршы бәхәсләшү мөмкин түгел» (*Казан утлары.—1989.—№ 10.—Б. 180*).

Шулай итеп, фирка өлкә комитеты 1937 елның 28 апрелендә К.Нәҗмине Язучылар берлеге идарәсе рәислегеннән азат итә. Шуннан соң ике ай чамасы үткәч, Язучылар берлеге әгъзалыгыннан ук чыгаралар. Аның белән бергә Х.Туфан, Ф.Кәрим

дә шундый ук хәлгә тарый. Бер атнадан, ягъни 21 июньдә фирка билетын да тартып алалар. Язмышын унсигез яшеннән шушы сәяси мохит белән бәйләгән кеше өчен бу, әлбәттә, авыр хәл. Тагын шунысы куркыныч, ул вакытта фиркадән читләштерелү бер үк вакытта кулга алыну юлындагы иң зур киртәнең алып ташлануын да аңлата. Бу шулай булып чыга да. 2 июльдә Кави Нәҗми артыннан да төрмә камерасының ишеге ябыла. Бер тамчы да гаебе булмаган кеше 15 елга ирегеннән мәхрүм ителә (шуның биш елы сөргенлеккә). Алай гына да түгел, 1938 елның башында хатыны, шулай ук язучы Сәрвәр Әдһәмова да кулга алына һәм Красноярск өлкәсендәге лагерьга җибәрелә. Уллары Тансыкны та Свердловск ягындагы балалар колониясенә илтеп ябалар, әмма ул аннан качып кайта. Туганнары, гаилә дуслары малайны күзгә ташланмаслык җирләрдә яшереп тоталар. Тансык Кави улы зирәк малай булып чыга, галим булып үсеп җитә. Казан университетының радиофизика кафедрасына җитәкчелек итә. Хатыны Сания ханым белән әти-әниләренең гаять катлаулы һәм фаҗигале тормыш сәхифәләрен барлауга зур көч һәм хезмәт сала. Ул аларның бик күп хәлләренә ачыклык кертә, әти-әнисенең язмышында уңай һәм тискәре роль уйнаган кешеләрнең гамәлләрен документлар нигезендә раслый. Аның «Бу эш ничек булды?» *(Казан утлары.—1989.—№ 10)*, «Мертвым не больно, больно за них» *(Советская Татария.—1990.—7, 14 июль)* дигән язмалары матбугатта басылып, укучыларның киң катлавына хакыйкатьне ачыклауга ярдәм итә. Әнисенең Себер тоткынлыгыннан язган хатларын укучыларга тәкъдим итеп, Т.Нәҗметдинов 1996 елда болай дип яза: «Сезнең алда әнинең—язучы һәм тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмованың СИБЛАГ сөргененнән язган хатлары. Аларда, көзгедәге кебек, караңгы репрессия елларының якты нуры булып, нык ихтыярлы, какшамас рухлы татар хатынының мөлаем образы калка. Аны ялган әләк тә, суд карарлары да, иң хәтәр концентрацион лагерьлардан булган Камышлаг җәһәннәме дә, сөрген еллары да сындыра алмаган» *(Әдәби мирас.—Казан: Татар. кит. нәшр.,1996. 3 китап.—114 б.)*.

Ил өстенә шәхес культының кара канаты җәелгән ул елларда кешенең язмышын бик җиңел хәл иткәннәр. Ниндидер өч кеше составындагы хөкем коллегиясе («өчлек») дүрт-биш минутта, берниндә тикшерүсез-нисез, каршы якларны тыңлап вакыт уздырмыйча, шаһитләр дә чакырып тормыйча, әзер карарны игълан иткән. Күбесенә үлем җәзасы чыгарылган. Апелляциягә бирү мөмкинлеге дә калдырылмыйча, шул ук төндә әлеге карарны җиренә дә җиткергәннәр. К.Нәҗмигә бу яктан язмыш рәхимлелек күрсәтә, гадәттәгедән чыгарма буларак, аның эшен Татарстан Югары Судында караганнар. Монда инде суд рәвеше сакланган. Алай гына да түгел, К.Нәҗми сорау алулар вакытында җәзалауларга түзә алмыйча, кул куеп үзе «раслаган» гаепләү фактларыннан суд барышында баш тарткан. Нахакка гаепләүләрен күрсәтү өчен бөтен сүз куәсен файдаланган. Ә ул, замандашлары хатирәләренә караганда, көчле бәхәсче, сүз белән эш итү остасы булган, фикерләрен дәлилле һәм ачык итеп җиткергән, кыскасы тыңлаучыларны ышандыра алган. Нәтиҗәдә 1939 елның 22 июнендә (бер гаепсезгә ике ел төрмәдә газаплангач) аны азат итү турында хөкем карары чыгарыла. Әле аннан соң да биш ай төрмәдә тотыла. Бары тик 1940 елны каршыларга бер көн кала гына ул, ниһаять, төрмәдән чыгарыла.

Судның карарына Сәрвәр ападан да артык сөенгән кеше булмагандыр. Ник дигәндә, аны кулга алганда иренең «халык дошманы» булуы төп сәбәпләрнең берсе икәнлеген ул яхшы аңлый. Шуна күрә инде үзен дә азат итәрләр дип өметләнә. Әмма ана әле бер елга якын Себер урманнарын кисәргә туры килә. Ул 1940 елның 16 октябрендә генә азат ителә. Т.Нәҗметдинов язуына караганда, аның әти-әниләре тоткынлыктан нык авыру хәлендә кайталар: әтисенең йөрәге авыртулы булып кала. Сәрвәр ханым исә үпкә авыруына дучар була, өстәвенә, аяк-куллары өшегәнлектән, сызланып-әрнеп яши.

Сугыш башланганда К.Нәҗми 40 яшендә була. Сәламәтлеге начар булу сәбәпле сугышка чакырылмый. Бу елларда ул радиокомитетта редактор булып эшли. Бинаның бер бүлмәсендә бердәнбер тимер мич була. Ана тәүлегенә бер генә тапкыр—көн уртасында ике чиләк торф ягып алалар. Шул арада чәй кайнаталар, җылы мич тирәсендә, юк-бар ризыкларын уртак итеп, тамак ялгап алалар. Мичкә

ягуны бары тик К.Нәҗмигә генә тапшыралар. Чи торфка ул гына, әфсен укып дигәндәй, ут тергезеп җибәрә ала. Шул елларның күренекле журналисты Галия апа Гаязова истәлекләренә караганда, радиокомитет коллективының үзәгендә «чиксез көч чыганагы, җылы сирпеп торучы булып, зур гаиләдәге таләпчән һәм гадел ата кебек, Кави абый Нәҗми тора иде. Ул эштә кинәше, ярдәме белән генә түгел, кыен минутларда тапкыр сүзе, күнел күтәренкелеге белән дә унай йогынты ясый, сине канатландырып, синдә өмет тудыра иде» *(Тыңлагыз, Казан сөйли!—Казан: Тат. кит. нәшр. 1998.—55 б.)*.

1942 ел ахырына таба К.Нәҗми, Х.Ярми һәм Г.Кашшафка «Татар халкының фронттагы солдатларына хат» текстын язу бурычын йөклиләр. Инде бу вакытта кайбер халыклар тарафыннан мондый хатлар язылган була. Алар ил буенча радиотапшырулар, газеталар, листовкалар, плакатлар ярдәмендә тарала. Бу хатларда фронттагыларга бер адым да артка чигенмәү, бары тик алга бару бурыч-гозере җиткерелә. К.Нәҗми һәм аның каләмдәшләре милләттәшләрне җиңүгә рухландыру мөрәҗәгате иң җылы, иң тәэсирле, иң рухландыручан булырга тиеш дип тырышалар. Бу хат, чынлыкта да, башка халыкларның шундый хатларына караганда көчлерәк тәэсир итүе белән аерылып тора. Чөнки ул рәсми, коры телдә түгел, күңел җылысы салып, аталарча самими итеп языла. Ул дошманны көнбатышка таба куарга тиешле Татарстан каһарманнарына, кайсы милләттән булуларына карамастан, хәер-фатиха булып яңгырый. Хатка Татарстанның миллион ярым ата-анасының кул куйган булуы да аның тәэсир көчен нык арттыра.

К.Нәҗми ягымлы, кешелекле мөнәсәбәте белән дә үзенең күңел җылысын уртаклашып яши торган шәхес була. Аны көчле рухлы, һәрвакытта да дөреслекне кыйбла иткән кеше буларак искә алалар. Ул әдәбият мәйданындагы кешеләр язмышы турында аеруча борчылып, кайгыртып яши. Үзе дә ялган әләк аркасында ирексезлек газапларын кичергән кеше буларак, ул әнә шул елларда әдәбияттан читләштерелгән, төрмәләрдә интектерелгән, хәтта юк ителгән каләмдәшләренең якты исемнәрен торгызуны намус эше дип карый. Г.Ибраһимов, Ф.Кәрим, К.Тинчурин, Г.Гали, Ш.Усманов, Х.Туфан, И.Салахов, Г.Мөхәммәтшин һәм башкаларның гаепсез булуы, аларның эшен яңадан карау кирәклеге турында 1955-56 елларда СССР Югары судына һәм аның Хәрби коллегиясенә хатлар яза. М.Җәлилнең исемен һәм иҗатын халыкка кайтару буенча аның эш-гамәлләре барыбызга да билгеле. А.Фадеев белән берлектә К.Нәҗми югары оешмаларга мөрәҗәгать итә. Шагыйрьнең хатыны Әминә ханымга карата гаделсез мөнәсәбәт күрсәтүчеләр белән көрәшә. Ул М.Җәлилнең Советлар Союзы Герое исеменә һәм Ленин премиясенә лаек булуы белән чиксез горурлана, чөнки моның белән татар халкы һәм аның әдәбиятының бик югары бәяләнүен тирәнтен аңлый. Шуннан биш-алты ел элек К.Нәҗминең һәм Г.Бәшировның СССР Дәүләт премиясе (ул вакытта Сталин премиясе) алулары да шундый югары бәяләү буларак кабул ителгән була. Күп еллык хезмәт авторларга әнә шундый мәртәбә, шөһрәт китерә.

К.Нәҗми төп әсәрен әле утызынчы еллар башында ук яза башлый. 1935 елда үз алдына аны тәмамлау бурычын куя. Шул елның 5 гыйнварыннан март башына кадәр (ике ай ярым чамасы) әдәби фонд юлламасы белән Ялтада яшәп ала. Төп максаты—«Гарнизон» («Язгы җилләр») романын язып бетерү. Казанда калган хатыны Сәрвәр Әдһәмовага язган хатларында әсәрне иҗат итү барышының байтак нечкәлекләре белән таныштырып тора. Безгә, әлеге әсәр белән таныш кешеләргә, хатларны укыгач, шул аңлашыла: К.Нәҗми Ялтадан романны нигездә тәмамлап кайткан икән. Чөнки ул әлеге хатларда телгә алынган бүлекләрне нәкъ менә шул атналарда өстәгән, аерым урыннарын кыскарткан. Сәрвәр ападан, кайбер персонажларның сөйләмен аларның эчке дөньяларына туры китерү максатында, киңәшләр сораган. Тәүлеккә унике-унөч сәгать язу өстәле янында утырып, бик тә нәтиҗәле эш алып барган. Баштарак язган хатында (19 гыйнвар) Галимҗан Ибраһимов янына «көн аралаш барам» дисә, 14 февральдәгесендә «өч көнгә бер барам», ди. Бу, ихтимал, иҗат эшенә чумуы белән бәйледер. Авыру кешене бик борчымаска теләгәнлеге белән дә аңлатып буладыр. Галимҗан абый «җәен Кремлевский больниска, Мәскәүгә күчеп дәваланырга уйлый» дип язуыннан шул аңлашыла. Әмма Мәскәү ярдәм итәргә бик ашкынып тормаганга

охшый. «Галимҗан абый,—ди ул,—Мәскәүгә бернichә җиргә язса да, җавап килмәде әле. Ике атнадан артык инде температурасы 37,5—38 тирәсендә». К.Нәҗми хатынына Галимҗан абый өчен бик кирәкле даруларны Казаннан табып җибәрүен үтенеп тә яза. Менә шулай иҗат белән бергә өлкән әдип турында кайгыртып узган кыш айларында К.Нәҗми әсәрен дә очлап чыга. Шуннан соң байтак өзекләрен төрле матбугат органнарында бастыргаласа да, әле аны тулаем китап хәлендә чыгару эше һаман да сузыла. Ике елдан язучының үз хәле бик нык үзгәреп китә—аны 1937 елның июль башында кулга алалар. Тансык Кави улы әйтүенә караганда, әтисе «белән бергә, аның барлык кәгазьләрен дә алып киткәннәр». Ул кәгазьләр арасында, әлбәттә инде, «Язгы җилләр» романының да кульямасы булгандыр дип фаразларга кирәк. Әсәре исә ун елдан соң булса да укучыларга тулысынча барып ирешә һәм авторына зур мәртәбәләр китерә. Роман 1948 елда «Совет әдәбияты» журналында, ә бер елдан соң Татарстан дәүләт нәшриятында, 1950 елда Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында рус телендә басыла. Авторы СССР Дәүләт премиясенә лаек булгач (1951), әсәр илебезнең төрле халыклары телләренә (казакъ, әзәрбайҗан, үзбәк, эстон, украин, латыш, мари, уйгур, удмурт һ.б.) тәрҗемә ителә, болгар, словак, чех, алман, кытай, монгол һәм кайбер чит ил халыклары да аны үз телләрендә укый. Шул рәвешле, «Язгы җилләр» романы, үзенең авторын гына түгел, тулаем татар әдәбиятын, татар халкын дөньяда танытуга ярдәм иткән әсәрләрнең берсе була.

Бүген К. Нәҗми исеме һәм аның әсәрләре бераз онытылып та бара кебек. «Кояшлы яңгыр», «Якты сукмак», «Яр буенда учаклар» повестьлары һәм дистәләрчә хикәяләре, поэмалары, йөзләрчә шигырьләре, публицистикасы, хатлары 1958-1960 һәм 1981-1984 елларда чыккан дүрттомлыкларда, 1925 елдан башлап чыга башлаган китапларында саклана. «Язгы җилләр»не исә Татарстан китап нәшрияты 1977 елда «Мәктәп китапханәсе» сериясендә бастырып чыгарган иде. Димәк, өч дистә елга якын инде бу язучыбыз иҗатын халыкка тәкъдим итү эше тукталып тора. Хәлбуки, К.Нәҗми шәхесе һәм аның әсәрләре онытылуга дучар булырга тиеш түгел. Ни өчен дигәндә, К.Нәҗми—халкыбызның сүз сәнгатен үстерүгә һәм каләме, һәм оештыру эшчәнлеге белән эзлекле эш алып барган шәхес. «Язгы җилләр» романына килгәндә, ул татар халкының патша Россиясе шартларында изелеп, ачлы-туклы, хокуксыз яшәвенең дәвамлы тарихын шактый киң күренешләрдә күрсәтеп биргән әсәр. Дөрес, аны сыйнфый каршылыклар алгы планга куелып язылган роман диярләр. Язучы каләме өстеннән пролетариат диктатурасы идеологиясе басып торган заманда башкача була да алмый иде. Ләкин әсәрне бүген милли мәнфәгатьләр күзлегеннән укып бәяләргә кем комачаулый? Шул ук вакытта бездә сыйнфый билгеләр буенча кысу-кимсетелүләр булмады дип кем расларга алыныр икән? К.Нәҗми язганнарга менә шулай төрле яклап якын килгәндә, аның татар халкы язмышы мәсьәләсен бик тирәннән каерып алып, кыю күтәргән булуына сокланырбыз һәм ана карата рәхмәт хисләре кичерербез. Халкыбызның исемен «татар-монгол игосы» гыйбарәсе эчендә, бары тик тискәре чолганышта гына телгә алу гамәлдә булган бер вакытта аның турындагы хакыйкатьне роман кадәр роман ярдәмендә ничәмә-ничә дөнья халыклары телләрендә таратуга ирешү К.Нәҗми кебек олуг шәхес һәм талантлар тарафыннан гына эшләнә ала. Шуңа күрә без К.Нәҗмине хәтерләргә, белергә, аның әсәрләрен, хезмәтләрен гомуми әдәби һәм иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнештә өйрәнергә тиешбез. Бу исә халкыбызның олылыгын, киң күңеллелеген раслый торган гамәл булыр.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

## «ТӨШЛӘРГӘ КЕРЕП ГЕЛ ЙӨДӘТӘ...»

СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Сүзләрне рифмаларга салу кыен түгел. Шагыйрь булу кыен.

Роман яисә трактат язарга була, шул ук вакытта кешелек җәмгыятенең бөтен сызлануын дүрт шигъри юлда чагылдырырга мөмкин.

Шагыйрьләр пәйгамбәрләргә тиң. Алар юкка гына пәйгамбәрлек темасын яратмый бит. Әлеге традиция бәлки Горациядән киләдер, иртәрәк тә туган булырга мөмкин. Пушкинның пәйгамбәр турындагы шигыре, бигрәк тә Шаляпин башкаруында, бөтен җанны кузгата бит.

*Восстань, пророк, и виждь, и внемли,*
*Исполнись волею моей*
*И, обходя моря и земли,*
*Глаголом жги сердца людей.*

Пушкин әлеге шигырьне декабристларны җәзалаганнан соң, патшага чакыру рәвешендә, намуслы кешеләр ягыннан рәнҗетелгәннәр өчен үч алуга чакыру буларак язган. Ул билгеле шагыйрьләрне дә күздә тоткан. Лермонтов әлеге теманы дәвам итә. Татар шагыйрьләре шулай ук пәйгамбәрләр турында язганнар, кирәксә русчадан тәрҗемәләгәннәр, кайвакыт исә үзләре иҗат иткәннәр. Күрәсең, шигърият һәм пәйгамбәрлек сыйфаты нәрсә белән дә булса үзара якын...

Ни өчен Пушкин гасырларда калды? Дөрес, дөньяда Толстой һәм Достоевский күбрәк билгеле. Әмма Пушкин шундый шәхес, үзеңнең уй-фикерләреңне чагыштырып карау өчен аңа әйләнеп кайтасың. Ул милли тормышның тирән катламнары турында, димәк, мәңгелек төшенчәләр турында язган. Гомумкешелеккә хас күренешләрнең милли үзенчәлекләрдән башка мәгънәсе юк. Миллилек—рухи сусауны баса ала торган чишмә. Хәтта дин дә миллилектән башка әлеге функцияне үти алмый. Дин миллилектән башка шәфкатьсезлек төсен ала, чөнки кеше әле туганчы ук ана сөйләмен ишетә, шуның белән яши һәм үлгәндә соңгы сүзләрен ана телендә әйтә.

Тукай гомеренең соңгы көннәренә кадәр Пушкинга сокланып яши. Татар шагыйре дә үзенең халкы турында нәкъ шулай уйлаган. Бу исә аны поэзия биеклекләренә илтә.

Минем өемдәге китап киштәсендә Сибгат Хәким кулы белән билгеләнгән һәм нидер кыстырылган Тукай томнары тора. Тукай иҗатын шулай җентекләп өйрәнүгә белән һәрбер әдәбият белгече дә мактана алмый. Ә бит бу үз уйларыңның дөреслеген аның фикерләре белән чагыштырып карау.

*Янда Тукай... Рухы кагына өстә,*
*Йөрәк сизә, тоя, сикерә.*
*Аның белән мин барырга риза*
*Җир читенә, дөнья читенә.*

*Эзли күңел, ник ул җитми һаман?*
*Ник борчуда уза күп айлар?*
*Калдырып зур мирас, нәрсәнедер*
*Алып китте кебек Тукайлар...*

Кин планда караганда Тукай турында ихласый һәм гаять тәэсирле итеп Сибгат Хәкимнән башка беркем дә язмады. Ә анын чыганагы бик гади—синең халкыңның язмышы. Халык арасыннан чыгып, анын белән яшәү һәм анарда эреп бетү. Әйтү җиңел...

Сибгат Хәким биографиясе бик гади. Татарстанның төньягындагы Күлле-Киме авылында туа. Казан артында туфрак уңдырышлы түгел. Зур елгалар юк, бары инешләр, чын урман шулай ук юк. Нефть тә юк. Әмма ул төбәктән ислам реформаторлары Г.Курсавый һәм Ш.Мәрҗани, әдәбият классиклары Г.Тукай, Г.Камал, музыкант С.Сәйдәшев, сәяси эшлекле С.Максуди һәм тагын уннарча атаклы шәхесләр чыккан. Бу җир рухи яктан бай.

Сибгат Хәким нәселендә барысы да крестьяннар булган, дөресрәге, балта осталары. Ул «ала карга» булып чыга, чөнки анын куллары кечкенә булып, балта тота алмыйлар. Бу унайдан әнисе бик нык кайгырган:

—Улым, син үзеңне ничек туйдырырсың соң? Күрәсең, сиңа авыллар буенча йөрергә һәм «Зингер»дә кием-салым тегәргә туры килер.

Шундый профессия булган. Кышларын, «Зингер» тегү машинасы булганнар, аны чанага салып, авыллар буйлап йөргәннәр һәм кешеләргә кием тегеп биргәннәр.

Сибгат Хәким нәселендә икенче бер сыйфат та була—гаделлек. Риваять буенча, Сибгат Хәкимнең җиденче буын бабаларыннан берсе Мемке община тарафыннан җир бүлүче итеп сайлана. Ул чорларда кешеләрнең тереклек итә алуы моңа бәйле була. Бабасы чылбыр тартып барган һәм анын эзе буенча ызан-чик ясаганнар. Авыр йөк. Бервакыт Күлле-Киме җирләренең бер өлешен күрше авыл крестьяннары басып ала. Мемке буразнага яткан һәм аларны каргаган. Күршеләрдә өч ел уңыш булмый. Шуннан соң алар авылга килеп гафу үтенәләр һәм җирне кайтарып бирәләр. Риваять шул турыда сөйли.

Сибгат Хәкимнең әнисен гадел Газзә дип йөртәләр. Беркем дә судка йөрмәгән, анын янына килеп, карар чыгаруын сораганнар. Халык тарафыннан танылудан кыйммәтрәк нәрсә булырга мөмкин! Бу тормышта һәркем үз чылбырын тарта.

Авыл мәктәбе. Феномен. Анын диварларыннан күпме бөек шәхесләр чыккан. Татарларда университетлар булмаган, Россия империясендә алар тыелган булган. Патша хөкүмәте укымышлы татарлардан, аларның башка халыкларга йогынты ясавыннан курыккан. Авыл нәкъ менә «университет» булган да инде. Бик күп талантлы кешеләр җәдид мәдрәсәләрендә һәм мендәллык мәдәният сакланган авыл мәктәпләрендә эшләгән.

Истәлекләрендә Хәсән Туфан шундый уен булу турында яза: кем күбрәк мәкальләр һәм әйтемнәр әйтә. Санны коймага күмер белән билгеләп баралар. Х.Туфан, бер уенда 700 чамасы мәкаль һәм әйтем әйтеп, җиңеп чыгуын билгеләп үтә. Безнең заманда бу өлкәдә белгеч саналган профессор-филолог шулкадәр әйтемне әйтергә авырсыначак. Фольклорда, җырларда, әкиятләрдә калган, бәйрәмнәр вакытында көчле ташкынга әйләнгән халык акылы татар мәдәниятенең нигезен тәшкил итә. Ләкин әле китаплар, газета-журналлар, театр, музыка төсендәге профессиональ мәдәният тә бар бит.

Һәрбер авыл өендә, мич һәм башка әйбер-предметлар белән бергә, китаплы киштә-шүрлек тә була. Озын кышкы кичләрдә безнең бабайлар, кемнең дә булса өендә җыелып, Кол Галинең «Йосыф кыйссасы»н тыңлаганнар, геройлар язмышына борчылганнар. Әледән-әле кемдер бозлы су салынган агач чиләк янына килгән һәм шул рәвешле җан кызулыгын суыткан.

Сабан туе. Әлеге бәйрәмнең тамырлары бик борынгыга китә. Шуңа да ул халыкның иң яраткан бәйрәме санала. Дөньяның кайсы да булса бер төбәгендә унлап татар бар икән, алар яз көне бергә җыелып, һичшиксез, сабан туе уздыралар. Әле тагын Сабан туе көнне татарлар үзләренең авылларына йә шәһәрләренә, йә инде республикага әйләнеп кайтырга тиешләр. Татарча бу төшенчә нәкъ шулай яңгырый: «килү» түгел, ә «әйләнеп кайту». Син үзеңнең башлангычыңа әйләнеп кайтасың. Минем Казанда тууым турында барысы да белә, шуңа да карамастан, хәтта күршеләр дә сорый: «Син кайсы төбәктән?» Минем тамырларны беләселәре килә. «Казан артыннан!»—дип җавап бирәм.

Жәен Сибгат Хәким туган авылына кайта иде. Искәрмә булып сугыш еллары һәм бер коры ел тора, шагыйрь икмәкнең кибеп-корып бетүенә тыныч кына карый алмый. Ә сабан туе—изге нәрсә.

*Ходайдан мин сорыйм: алданрак,*
*Яки соңрак, димен, ал җаным,*
*Тимә миңа, тимә син миңа*
*Сабан туе көнне Арчаның.*

*Ходайдан мин үтенәм: кичектер,*
*Халәтемнең үлчәп бар ягын,*
*Тимә миңа, тимә син миңа*
*Сабан туе көнне Арчаның.*

Бездә артта калган атка бүләк бирү кебек дулкынландыргыч йола-гадәт бар. Бу өмет-ышаныч аты. Туганнары фронттан кайтмаган яисә якыннарын югалткан, әмма күңелләрендә өмет тамчысын саклаучы һәркем чабышта артта калган атка үзләренең яулыкларын китергән. Еш кына әлеге атның бүләкләре күбрәк тә булган.

Сибгат Хәким бөтен дөньяга туган авылы, хәтта үз тыкрыгы күзе белән карый иде, әйтерсең туган авылы Күлле-Киме бөтен галәм үзе. Кешелек җәмгыяте абстракт булмый, ул синең белән янәшәдә яши торган конкрет кешеләрдән гыйбарәт.

*Әллә ничек әрнеттерел шунда*
*Кыштырдавын тойдым камылның;*
*Туган җирнең ялганмыйча яткан*
*Кылларына гүя кагылдым.*

Сибгат Хәким беренче шигырьләрен мәктәптә укыганда яза башлый. Язучы Гадел Кутуйның апасы, Күлле-Кимегә кунакка килгәч, аның шигырьләрен тынлый һәм яшүсмер егетне Казанга чакыра. Әнә шулай Сибгат Хәким шәһәрдә яши башлый.

Юл башы бервакытта да җинелдән булмый. Сиңа кемнең дә булса ярдәм итүе, һич югы йомшак сүз белән яклавы бик мөһим. Бәлки шунадыр Сибгат Хәким гомере буе яшь шагыйрьләргә ярдәм итеп яши. Аны кайвакыт бигүк талантлы булмаган авторларның китапларына кереш сүз язуы өчен шелтәлиләр, имеш, син вакланасың. Әмма беренче адым һәрвакыт кыен. Әгәр кешегә башта ярдәм итсән, аннан язучы чыгарга мөмкин, ә бәлки чыкмас та. Әмма дә ләкин ярдәм итмәсән, ул вакытта талантлар да бу ыгы-зыгылы тормышта югалып калырга мөмкин.

Педагогика институтында уку, беренче китапны әзерләү... Ул чыга алмый. Инде җыелган китапны нәшриятта таркаталар. Республика язмышында 30 нчы еллар авыр була. Бер-бер артлы кешеләр югала. Яшь, талантлы прозаик Мәхмүт Галәү төрмә тәрәзәсеннән ташлана. Кызыл сугышчы, әсәрләрендә совет власте өчен көрәшне чагылдырган Шамил Госманов, сорау алулар вакытындагы җәберләүләргә түзә алмыйча, ручка белән күзләрен чыгара һәм каны бозылудан үлә. Фатих Кәрим пограничниклар турында поэма яза, анда японнар белән бәрелештә совет солдаты һәлак була. Әсәрне патриотик түгел дип бәялиләр, авторын комсомолдан чыгару турында күрсәтмә бирәләр. Сибгат Хәким оешманың җитәкчесе була. Ул Ф.Кәримне комсомолдан чыгарудан баш тарта. Шуннан соң икесен дә чыгарып ташлыйлар.

Билгеле оешма күзәтүе астында булып, бер ел эшсез утыра. Бу вакытта С.Хәким Кремль астындарак урнашкан фатирда яши, төрмә каршында. Соңрак анда якын дусты Фатих Кәрим утыра. Шундый легенда бар: янәсе, сугыш алдыннан Хәсән Туфан әлеге төрмәдә Фатих Кәримне очрата, аның аяк киеме машина шиныннан ясалып, тимер чыбык белән бәйләп куелган була... Берсен ерак Себергә озаталар, икенчесе исә сугышка җибәрелә.

Сибгат Хәким вакыты белән шәһәр төрмәсеннән тавышлар ишетүе турында искә ала. Язучылар Берлеге сәркатибе булып эшләүче Гази Кашшаф аны эш белән

тәэмин иткәли—әдәби әсәрләргә рецензияләр яздыра, ә авылда яшәүче абыйсы бәрәнге белән ярдәм итә. Дусларыннан кайберләре, караңгы төшкәч кенә, куенына күмәч тыгып, аның янына килгәли. Сибгат Хәким авылга китәргә дә уйлый, әмма партия оешмасы житәкчесе ачык сиздерә, киреәксә, без сине теләсә кайдан табабыз. Әлеге кеше сугышта Австрия жирендә һәлак була.

Сибгат Хәкимнең бәхете шунда була, ул ниндидер житди әйберләр язарга өлгерми. 1938 елда сәясәттәге арттырып жибәрүләр, ялгышлар турында Сталин карары чыга һәм аны эшенә кайтаралар, әмма китабы барыбер чыкмыйча кала.

Игътибарга лаеклы беренче әсәрләре Тукай турында була. «Пар ат», «Шагыйрьнең бала чагы» поэмалары сугыш алды татар поэзиясендә танылу ала. Кемдер Сибгат Хәкимнең поэзиягә «Пар ат»та килеп керүе турында яза. Бу темадан ул бервакытта да читләшми, танылу алып, төрле премияләрнең лауреатлары булгач та Тукайга әледән-әле әйләнеп кайта.

Кайбер шигырьләрнең язмышы искитәрлек. Сугыш елларында «Сагыну» жыры гажәеп популярлаша. Фольклорчылар аның 34 вариантын таба. Күпләр әле бүген дә жырның авторы барлыгын белми, чөнки ул чын мәгънәсендә халыкчан булып китә. Бер мәжлестә әлеге жырны жырлыйлар һәм сүзләренә бәйле бәхәс башлана. Берсе икенчесен дөрес жырламыйсың дип шелтәли. Ә авторның өстәл янында утыруы һәм читтән генә аларны кызыксынып тыңлавы беркемнең дә башына килми. Әсәрнең авторы онытылып, халыкныкы булып китүендә иҗат биеклеге чагыладыр инде. Сибгат Хәким тарафыннан язылып, халыкныкы булып киткән тагын берничә жыр бар. «Фазыл чишмәсе» жырының халыкныкы булмыйча, бәлки автор ижаты булуына бер танылган язучыны ышандырырга озак вакыт кирәк булды. Ул мона авырлык белән ышанды.

Сугыш вакытында кешеләр фронттан сөйгәннәрен, якыннарын көтә һәм әлеге сагыш аларны «Сагыну» жырына үзгә мәгънә салырга мәжбүр итә.

*Яратам мин, әйтмим генә аны,*
*Син йөрәкне минем белмисең.*
*Кошлар кайта безгә, син һаман юк,*
*Син һаман юк, никтер килмисең.*

Ә бит шигырь сугыш белән бәйле булмыйча, бөтенләй башка унай белән язылган була.

Үзе эшләгән газета редакциясендә Сибгат Хәким шигырьләр язу белән мавыгучы яшь кыз—булачак хатыны Мөршидә белән таныша. Кулаклар дип читкә куылган гаиләдән булган кыз 15 яшендә берүзе чит шәһәргә шәфкать туташы булу теләге белән укырга китә һәм үзен туендырып тору өчен шигырьләр яза. Аның «Чигелгән яулык» исемле бер җыентыгы чыгарга өлгерә. Туйдан соң Сибгат Хәким хатынына бу шөгылен ташларга куша, янәсе такмакчы шагыйрьләр аннан башка да житәрлек. Яшь хатынның иҗаты шуның белән тәмамлана. Бары ире үлгәннән соң гына ул янадан кулына каләм ала һәм истәлекләр яза башлый. Аның текстларын редакцияләргә кирәк булмый, алар профессиональ дәрәҗәдә язылганнар. Чарланган гыйбарәләр, ачык фикер һәм назлы, ягымлы хисләр. Истәлекләр басылып чыга. Хатын булу авыр түгел, ә менә тормыш иптәше булу—монысы чын сәнгать. Шигърият аларны кавыштыра, ә аннары тормыш буенча алып бара.

Медучилищены тәмамлаганнан соң, Мөршидәне фельдшер булып эшләргә авылга жибәрәләр, шунда ярәшкән егете Сибгат тә килеп йөри. Бервакыт алар ачуланышалар. Сәбәпчесе исә кыз белән озаграк биегән яшь летчик була. Сибгат үпкәли һәм Казанга китеп бара. Ә берникадәр вакыттан соң газетада түбәндәге шигырь юллары басылып чыга:

*Бакчабызда шомырт агачлары*
*Җәй буена сине көттеләр.*
*Син килмәдең, көзге җилләр инде*
*Яфракларын җиргә сиптеләр.*

Мөршидә татулашырга кирәк дигән карарга килә һәм үзе аның янына китеп бара. Шактый гадәти мәхәббәт тарихы, әмма сугыш вакытында әлеге гади шигырь юлларына халык бөтенләй башка мәгънә сала. Язылып дөньяга чыккан әсәр үз тормышы белән яши.

Сугышнын яшенле болытлары сизелгән хәвефле 1939 ел азагында нәкъ яна ел алдыннан туйлары була. Ин якын дуслары җыела: Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан һ.б. Тиздән сугыш аларнын төрлесен төрле якка ташлаячак.

*Минем сугыш алдындагы туйда*
*Хәсән Туфан туйны ярды соң!*
*Бар тавышка: «Ачы, ачы!»—диде,*
*Сизгән кебек ачы язмышын.*
*Муса Җәлил аннан басты торып:*
*«Шампанский, Хәким, ач элек...»*
*Ачтым... «Ачы!»—диде, шуннан бирле*
*Яна йөрәк, яна ачынып.*

Өстәлдә төп ашамлык чөгендер кушылган катык була.

Муса Җәлил әсирлеккә эләгә. Гадел Кутуй Польша жирендә күмелә. Хәсән Туфан Себергә җибәрелә.

Офицерлар курсын тәмамлаганнан сон, Сибгат Хәким Курс дугасына эләгә. Әлеге «иттурагыч»тан бик азлар гына исән чыга. Алар батальонынннан тугыз кеше кала, шул исәптән ике тапкыр контузия алган рота командиры Сибгат Хәким. Бөтен сугыш дәвамында окопларда, немецлар сөйләшүе ишетелеп торган алгы позицияләрдә. Сугышны Молдавиядә тәмамлый. Аннары озакка сузылган дәвалану еллары.

Муса Җәлил дә кайта, туры мәгънәсендә түгел, ул реабилитацияләнә.

Сугышта танклар һәм самолетлар гына җинми, бәлки, беренче чиратта, кеше рухы җинә. Еш кына Т-34 танкын символ төсендә пьедесталга куялар һәм ул аңа лаек та. Шулай ук һәйкәлләрне ПЕ-2 яисә ПЕ-8 штурмовигына да куярга мөмкин. Әмма җинүнең төп сәбәбе—какшамас рух. Безнең ил өчен Икенче бөтендөнья сугышынын чын символы булып Муса Җәлил тора. Ул үзенең шигырьләрендә җинүне билгеләгән төшенчәне—җинелмәс рухны чагылдыра. Гаҗәп хәл, хәрби әсирләрдән төзелгән татар-башкорт «Идел-Урал» легионынын дүрт полкыннан беркем дә коралын үз иленә таба юнәлтми. Власовчылар, бандерачылар, Төркестан, Грузия һәм башкаларнын легионнары булган. Алар сугышкан. Татарлар үзебезнекеләргә атмаган, җәлилчеләрнең йогынтысы зур булган.

Муса Җәлилне һәм анын иптәшләрен җәзалап үтерүнең шаһите булган патер Юрытко әйтүенчә, татарлар батырларча үлгәннәр.

*Кайвакыт исним дә*
*Чәчәкле җил исен,*
*Килә бер җир буйлап*
*Кычкырып йөрисем:*
*«Чәчәкләр үсәләр,*
*Көн саен тормышта*
*Сез кирәк, торыгыз,*
*Торыгыз, Мусалар...»*

Яшьлек, сугыш, ә аннары һәйкәлләр, мемориаль такталар яисә дуслары хөрмәтенә урам исемнәре һәм хәтта Җәлил шәһәре.

Хәсән Туфан кайта. Вокзалда аны Сибгат Хәким хатыны белән каршы алгач, ул әйтеп куя: «Сез һаман бергә икән!» Уналты ел аерылып торганнан сон очрашу вакытында туган «Сез һаман бергә икән» дигән җыр ул елларда популяр була.

Хәсән Туфан кебек шагыйрьләр инде булмаячак. Ул гонорарнын ни икәнен анламады, ничек акча эшләргә һәм үзенең нинди акчага яшәгәнен белмәде. Себердә сыер көтүе көтә һәм сөт эчеп кенә исән кала. Анын яшәешкә карашын гади итеп

болай әйтергә мөмкин—галәм матур, әлеге матурлык шигырьләрдә сурәтләнергә тиеш. Тормыш мәгънәсен миңа шулай аңлатты. Әнә шуның белән ул яшәде. Хәсән Туфанның «Прометей» кушаматлы үгез турында шигыре бар. Әлеге үгез бер төнне чылбырларын өзә һәм Хәсән Туфан шигырь язып утырган өйнен тәрәзәсен ватып кермәкче була. Сибгат Хәким шаярып, андый үгез булмаган инде, бу синең образың, күзаллавың, ди. Хәсән Туфан моңа үпкәли: «Бар иде!» Хыялда гына булса да булган бит. Хыял—шулай ук чынбарлык, билгеле инде, шагыйрь өчен. Ә бит шагыйрь кайвакыт яшәешнең тирән мәгънәсен ачыграк күзаллый. Хыял ул—дөньяның бертөрле моделе, аннан исә киләчәк оеша.

Гаяз Исхакый революциядән соң Россиядән китеп, Польшада большевикларга каршы «Прометей» оешмасын төзи. Ана Польша президенты Пильсудский булыша. Гаяз Исхакый төрмә камерасында бергә утырган дусты янына бара һәм тегесе аның үтенечен кире кага алмый. Прометей—символ, ул инде меңнәрчә еллардан килә. Димәк, чынбарлык. Хәсән Туфан артыннан йөргән үгез дә билгеле бер символ.

Сибгат Хәким һәм Хәсән Туфан дачада күршеләр иде. Аккош күлендә Әхмәт Фәйзи, Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Риза Ишморат, Нәби Дәүли, Рөстәм Кутуй, Рафаэль Мостафин, алардан соң Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов һ.б. яши. Һәрберсенең алты сутый җир, щитлардан ясалган йорт, яшелчә бакчасында төрле яшеллек, җиләк-җимеш һәм алмагачлар. Язучылар, берәрсенең беседка-чатырына җыелып, яңа гына язылган әсәрләрен укыйлар. Искиткеч күренеш. Әлеге гадәт бетте, ул күренеш башка юк. Бары сагынып искә алырга гына калды.

Газеталарда шигырь чыгу белән шунда ук авторына шалтыраталар, котлыйлар, тәэсирләре белән уртаклашалар. Бервакыт Сибгат Хәким мондый фикер әйтте: «Без киткәч, бары шабашниклар гына кала». Кискен, каты әйтте, әмма ул әйткәнчә булды.

Хәсән Туфан участогы башкалардан кискен аерылып тора иде. Бернинди культуралы үсемлекләр юк. Әйтерсең кыргый кыр. Чүп үләннәренә тулы иркенлек. Әрекмән, кычыткан һәм урман чәчәкләре котырынып үсә. Йорт әйләнәсендә сыерчык оялары. Хуҗа кулдан ясалган утыргычта утыра һәм үз дөньясы белән соклана. Әйләнә-тирәсендәге кешеләр кыяр, помидор, җиләк-җимеш үнышы өчен борчыла. Хәсән Туфан исә шигърият дөньясы белән яши.

Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким бик тә йомшак, принципиаль һәм аз сүзле кешеләр иде. Һәркөнне очрашып, бер-берсе белән нәрсә турында булса да сөйләшәләр иде. Шулкадәр сүз каян тапканнар? Хәсән Туфан, үзенең яшел карасы белән Сибгат Хәким шигырьләрен вертикаль буенча бүлеп, график гармония эзли. Аның өчен бөтен дөнья ниндидер гармониядә чагыла иде.

*Төнге ике. Өстәл, кәгазь, кара.*
*Яз дим үземә, нигә туктадың?*
*Яз, язмау бит оят—тәрәзәдә*
*Уты янган чакта Туфанның.*

Фатих Кәрим сугыштан әйләнеп кайтмады. Төрмәдән аны алгы сызыкка штраф батальонына алып китәләр һәм ул Кенигсберг тирәсендә һәлак була. Маршал Жуков Сталинга бүләк әзерләргә тели һәм шәһәрне штурмлауга бөтен гаскәрен ташлый, гәрчә бу сугыш нәтиҗәсен хәл итми. Фатих Кәримнең тишкәләнеп беткән шинеле музейда эленеп тора.

Шагыйрьләр иҗаты турында Сибгат Хәкимнең үзенчәлекле теориясе бар иде. Аның фикеренчә, Пушкин теләгәнен барысын да язып бетерә. Лермонтов та үзен чагылдырып өлгерә. Тукай тулар-тулмас 27 яшьтә шәхес буларак үзен күрсәтә. Ә менә Фатих Кәрим өлгерми кала. Аның белән бергә фикер-карашлары да үлә. Моның үз дәреслеге бар. Шолохов—гражданнар сугышы чорын җырлаучы. Совет чорында Чыңгыз Айтматов иң дәрәҗәле язучы иде. Һәрбер иҗади шәхеснең үз вакыты була. Үзе турында Сибгат Хәким булдыра алганча теләгәнен әйтүен белдерә һәм шул ук вакытта болай дип яза:

*Барын да мин язып бетердем дип,*
*Йөрдем уйлап, бик нык алдандым.*
*Язын төртеп яңа үлән чыкты,*
*Хәбәр итсен нигә алдан бер.*
*Туган якта язын яшел үлән—*
*Яңа буын... бүтән, башкача...*

*Әйтми калган сүз күк чыкты үлән*
*Әнкәй каберендәге таш аша.*
*Кыякларын җәеп чыкты, яши,*
*Мин дә яшим, мин дә бүген бар...*
*Кабатларга мөмкин түгел икән,*
*Кабатланмый икән буыннар...*

Шигърият—үз дәвеpенең чагылышы. Татар поэзиясендә лирика аз, сәясәт күп. Партияләр төзергә һәм матбугатта ачыктан-ачык фикер әйтергә мөмкин булмаганда шагыйрьләр әлеге авыр йөкне үзләренә алалар. Шагыйрьләр—азатлык жырчылары. Моның белән күп нәрсә аңлатыла. Билгеле, мәхәббәт темасы поэзияне таләп итә, әмма иҗатчы шәхси хисләрен генә түгел, бәлки чор кичерешләрен дә чагылдыра.

Вакытлар үтте, заман үзгәрде, шуңа да карамастан Сибгат Хәкимне хәтерлиләр. Ул халык хәтерендә калды һәм моның җитди сәбәпләре бар. Ул Казан турында, Казан арты, туган авылы, республика турында күп яза. Аның ачык, яңгырашлы шигъри юлларын мисалга китерергә яраталар:

*–Сез кайдан?—дип сорыйсыз.*
*–Без Казаннан, Иделдән.*
*Идел—эчкән су булыр.*

*Иделдә иген иккән,*
*Яшәгән, көнен иткән*
*Татарстан шул булыр.*

Бер караганда, шигырьдә тирән эчтәлек һәм хыял очышы да юк, әмма эчкерсез, саф хисләр бар. Шигырь шуның белән үзенә җәлеп итә һәм ул хәтердә саклана.

Телдән башка поэзия яши алмый, киң планда бу—тел стихиясе. Шигырьләр башка телләргә начар тәрҗемә ителә, кайбер теоретиклар фикеренчә, алар бары тик үз мәдәни мохитендә генә яшиләр һәм принципта тәрҗемә ителмиләр. Пушкинның «Я помню чудное мгновенье...» тезмәсе башка теләсә кайсы телдә баналь яңгырый. Нәкъ менә шигърият туган телгә аеруча сизгер. Проза белән сөйләү җинелрәк, ә поэзия телнең бөтен нечкәлекләрен тоемларга тиеш.

Бервакыт Сибгат Хәкимне Казандагы бер мәктәпкә чакыралар. Ул шигырьләрен укый, ә балалар татарча аңламый. Өйгә кайткач, андый очрашуларга башка бармаячагын әйтте. Авылда аны аңлыйлар, ә шәһәр инде телне оныткан. Авыр вакытлар иде. Бүген татарча сөйләшү зыялылык, тәрбиялелек билгесе санала, ә ул елларда моның өчен эштән чыгаралар иде.

Туган тел турындагы шигырьләр рәсми даирәләрдә популяр булмый, ә халык күтәп ала. Аларны бастырып чыгару да кыен була, андый вакытта Сибгат Хәким шигырьләрен сәхнәдән укый. Бервакыт Мәскәүдәге иҗади очрашу вакытында ул халык, тел, мәдәният турындагы шигырьләрен укый һәм залдан чәчәкләр килә башлый. Ахырда Тукайның «Туган тел»ен жырлыйлар, протест йөзеннән, гимнны жырлаган кебек басып жырлыйлар. Бүген дә республика гимнын барысы да белми, ә Тукай сүзләрен беләләр.

Сибгат Хәким халыкның мәдәнияте яңарышын көтте. Киеренке халәттә көтте. Ихтимал, шуңа да аңарда инфаркт булгандыр. Ул үзгәртеп коруларның таңын күрде. Әмма Чернобыль атом станциясендә шартлау булгач, болай диде: «Тормыш мәгънәсен югалтты». Һәм вафат булды. Әгәр дә ул татар мәктәпләре ачылуын күргән булса, аның рухы бәлки яңарыр, ә тормышы дәвам итәр иде.

Сибгат Хәкимнең тормышы аның иҗаты иде. Иртәләрен ул шуны авырлык белән, авыр ташлар ташыган кебек, кыска строфаларда чагылдыра. Бүлмәдән ыңгырашулар ишетелә. Шигырьләр газап-михнәт белән языла. Аларны уку җиңел, ләкин алар җанга үтеп керсен өчен кешеләр белән йөрәкнең бер кисәген уртаклашырга кирәк.

**Рафаэль ХӘКИМ,**
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих*
*институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*хакыйкый әгъзасы.*

## Сибгат Хәким турында замандашлары

*Син вәзир дә, министр да түгел,*
*Кинрәк синең*
*Рухи күләмен:*
*Антей күтәрмәсне күтәрә бит*
*Чын шагыйрьнең лирик герое.*

*Синең хисләр*
*Халык күңелендәге*
*Өметләрен җыеп алалар;*
*Шигъри кошлар булып ул өметләр*
*Илнең үзенә кайта баралар.*

**Хәсән ТУФАН,**
*халык шагыйре*

***

Кайчандыр миңа поэзия яшьлек булып, проза зирәк картлык булып тоела иде. Сибгат Хәким бер үк вакытта яшь тә, зирәк акыллы карт та була алды. Талантлы яшьләргә—шагыйрьләргә генә түгел, прозаикларга да, публицистларга да, тәнкыйтьчеләргә дә, хәтта тәрҗемәчеләргә дә, сәнгать өлкәсендә хезмәт итәргә керешкән талантлы һәркемгә—җырчы-рәссамнарга һәм музыкантларга ул гел якты йөз белән карады, алар хакында көндәлек матбугатта язды, бер сүз белән әйткәндә, татар культурасының киләчәген кайгыртты. Менә шуңа күрә ул халык шагыйре иде. Поэзиядә ул үз мәктәбен тудырды, үз йөзен тапты.

**Гариф АХУНОВ,**
*халык язучысы*

***

Сибгат абый Хәким, искитмәле уй-моңлы иҗатың өчен, халык язмышы белән язмышланып, шигърият өчен, аның үткәне белән горурланып, киләчәге өчен кайгыртып һәм янып яшәгәнең өчен сиңа мең рәхмәт!

**Нажар НӘҖМИ,**
*башкорт шагыйре*

***

*Бу йөзләрнең күбесе онытылыр,*
*Гел хәтердә тормас бу табын.*
*Әмма онытмам Сибгат Хәкимнең*
*«Туган тел»не җырлаган чагын.*
*..............................*

*Сибгат Хәким җырлый. Кемдер, бәлки,*
*Ишетмидер аның тавышын да.*
*Тойган—тояр, аның моңы баса*
*Җырчыларның монда барсын да.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*халык шагыйре*

***

Сибгат җыр-музыканы бик ярата. Аның шигырьләре үзләреннән-үзләре көйгә салуны сорап тора. Үзләренә кунакка чакырганда Сибгат «чанага балаларың янына каз муеныңны да (ягъни скрипкаңны) салырга онытма» дип шаярта иде. (...) Мин Сибгатнең җыр-музыка яратуы тумыштан килгәндер дип уйлыйм. Сибгаткә кадәр сүзсез яңгыраган халык көйләре дә ул язган сүзләр белән искиткеч күркәм, тагын да моңлы, ягымлы, тагын да халыкчан яңгыраш алды, көйләргә Сибгат канатлар куйды, ул җырлар чын мәгънәсе белән мәңгелек яңгырашлы халык көйләренә әйләнделәр. Моның шулай икәнен «Таң атканда» җыры үзе генә дә бөтен тулылыгы белән раслый.

**Әнвәр БАКИРОВ,**
*композитор*

***

Мин бик сагынам аны. Минем дөньям ничектер бикләнде хәзер. Сибгат абый барысын да җанына сыйдыра иде. Елап барып кереп, рәнҗетелүем турында сөйләүме, әллә берәрсенә үлеп гашыйк булу турындамы—барысын да аңлый иде ул. Олы җан. Хәзер дә бар дуслар, якыннар, ләкин алар берсе дә Сибгат абый түгел инде.

**Вафирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
*җырчы*

***

Мин белгән Сибгат Хәким гомумән яклаучы булды дисәм, һич тә хата булмас. Ул гомере буена яклаучы булды. Ул изгелекне яманлыктан яклады һәм ярдәмгә мохтаҗ һәркемгә ярдәм кулы сузды. Бик күпләр аны чын күңелдән хөрмәт иттеләр. Кайчан һәм кайда гына очратма, аның янында һәрвакыт кеше булыр. Һәркем аңа үзенең берәр сүзен, фикерен, гозерен әйтергә тырыша. Ул беркемнән баш тартмый—яшьләр белән дә, өлкәннәр белән дә сөйләшергә сүзе, уртаклашырга фикере була.

**Нурихан ФӘТТАХ,**
*халык язучысы*

***

*Бер карасаң, Тукай кебек «ерак»,*
*Туфан кебек якын син безгә,*
*Тукай белән Туфан туганлаша*
*Сибгат Хәким туган нигездә.*

*Нәселеңдә—балта осталары,*
*Шундый бер йорт салдың син безгә:*
*Күпләр яши шигъри җылы тоеп,*
*Сибгат Хәким салган нигездә.*

**Илдар ЮЗЕЕВ,**
*халык шагыйре*

***

*Без әтисез моңлы балаларның*
*Җан, рухына терәк идең син,*
*Шагыйрьләре үлеп ятим калган*
*Халкыбызга кирәк идең син.*

*Уттан чыксаң да син утта булдың—*
*Һәр көнеңне яның озаттың.*
*Януларың, моңың, җырың белән*
*Татарның син гомерен озайттың.*

**Шәүкәт ГАЛИЕВ,**
*халык шагыйре*

***

Сибгат Хәким—буяп, бизәп, идеаллаштырып, почмакларны тигезләп күрсәтүгә мохтаҗ шәхес түгел. Ул тормыш юлыннан сөенечләре һәм көенечләре, югалтулары һәм ачышлары белән бергә атлады. (...)Шагыйрь башкалардан кешелеклелеге, матурлыкка сизгерлеге, халкына риясыз мәхәббәтенең олылыгы белән аерылып торса да, үз чоры баласы иде. Бөтен әдәбиятлар тар кысаларга куып кертелгән караңгы 30-50 нче елларда аның каләменнән дә конъюнктур әсәрләр аз төшмәде. Чор кабул ителгән кагыйдәләрне бозучыларны яратмады. Сталин урнаштырган мәкерле, кешелексез һәм рәсми сәясәтнең бер үзенчәлеге шунда иде.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*тәнкыйтьче*

## «ТУРЫ КАРАП КҮЗЕГЕЗГӘ...»

ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Зәки Нури гаять тапкыр, үтә шаян һәм көләч кеше иде. Шаянлык һәм көләчлек бөтен иҗатының буеннан-буена ак нур булып сызылып килсә дә, шагыйрьнең тормышында һәм тәрҗемәи хәлендә шактый кыенлыклар да тудырды. Шаян кеше бит ул күзгә туры бәреп, чынын әйтеп шаярта. Аның «Туры карап күзегезгә» дигән юмористик китабы да бар.



1934 елда Зәки Нури Кукмара ягындагы атаклы Лубян урман техникумына укырга керә. 1937 елда ул үзенең шаянлыгы, күзгә туры бәреп әйтүе белән бик авыр хәлгә кала. 1937 еллар СССРда күренеклерәк кешеләргә нахак бәла тагып репрессияләүләрнең иң котырган чагы. Зәки Нури шаярып сөйләшүләрендә ул чор хакимиятенә ошап бетмәгәнрәк сүзләр ычкындырган булса кирәк, аны 1938 елны Ерак Көнчыгыштагы диңгез портына «хезмәт белән төзәтергә» җибәрәләр. Анда урманчы икәнен белгәч мәҗбүри рәвештә Чувашстанның Шемурша урман хуҗалыгында «хезмәт белән тәрбиялиләр». 1940 елда ул ирек ала һәм 1941 елда Лубян урман хуҗалыгы техникумында өзелеп калган укуын тәмамлый.

Минем тоюымча, бу «хезмәт белән төзәтү»ләр Зәки Нуриның гомерлек иҗатына шактый катлаулы тәэсир иткәндер кебек. Ул үзенең шигъриятендә катлаулы сәяси һәм илнең иҗтимагый тормышы темаларына бик үк тирән керергә тырышмады. Дөрес, аның юмористик әсәрләрендә Зәки Нурича шаянлык иҗатының буеннан-буена сугарылып килде. Шагыйрь балалар өчен дә күп һәм нәтиҗәле иҗат итте—балалар әдәбиятында бит сәясәткә бик тирән керәсе юк. Шул ук вакытта ул СССРның атаклы шагыйрьләренең зур-зур күләмле поэмаларын тәрҗемә итүгә дә шактый иҗат тормышын багышлады. Үз поэзиясендә аның төп темаларыннан мәхәббәт һәм әхлак иде. Бу өлкәдә ул озак һәм нәтиҗәле эшләде.

Зәки Нуриның тормыш катлаулылыгы Бөек Ватан сугышы елларында да дәвам итте. Ул 1941 елның маенда армиягә алына. Бер айдан Ватан сугышы башлана. Зәки Нури ике ай үтүгә алгы сызыктагы полк белән чолганышта кала. Ул чакта бит Сталин күрсәтмәләре буенча немецларга пленга эләгү—илне сату итеп карала иде. Зәки Нури язмышына әнә шул куркыныч яный. Ярый әле чолганыштагылар тиз генә атаклы Константин Заслонов җитәкчелегендәге партизаннар отряды белән элемтәгә кереп, отрядка кушылалар. Шулай итеп, Зәки Нури 1942 елның мартыннан 1944 елның августына кадәр партизанлыкта була.

Шагыйрьнең бу партизанлык гадәтләре гомере буена дәвам итте. Партизанлык белән шаянлык бергә кушылып Зәки Нурида гаҗәеп үзенчәлекле, кешелекле, эш сөючәнлек холкы тәрбияләде. Узган гасырның алтмышынчы елларында әдәбиятка килгән яшь язучылардан һәрберебезгә диярлек Зәки Нуридан ниндидер яхшылык тими калмады. Зәки абый көне-төне җәмәгать, дәүләт, әдәби хәрәкәтне оештыру эшләре белән мәшгуль булса да, әдәби иҗатта иң актив язучыларның берсе иде.

Әйтик, ул Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, берлек рәисе һәм «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшләгән елларында эшкә

һәр көнне иртәнге сәгать 7-8ләрдә килә дә, башка хезмәткәрләр сәгать 9-10нар тирәсенә килеп җиткәнче шигырь яза иде. Минемчә, ул гомеренең бер генә көнен дә иҗатка багышламый калмагандыр. 25 китап бастырып чыгаруы да әнә шул турыда сөйли.

Күзгә туры карап әйтә торган Зәки Нурины язучыларның олысы да, кечесе дә хөрмәт итәләр иде. Чөнки ул рыясыз, ярдәмчел дә.

Без бүген бу өлкән каләмдәшебезне сагынабыз һәм һәркемнең күзенә туры карап: «Зәки Нури XX гасырның икенче яртысындагы күренекле әдип, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе иде!»—дип әйтә алабыз.

**Гәрәй РӘХИМ,**
*Татарстанның халык язучысы.*

# Зәки Нури

## Ышану

**Тамчы күрсәм, күл була дип уйлыйм,**
**Бөре күрсәм, чәчәк була дим.**
**Елга кичсәм, гүя диңгез буйлыйм...**
**Бары шулай яшәп була дим.**

**Түтәл күрсәм, бакча бар дип беләм,**
**Яз терелсә, кышлар үлә дим,**
**Көзләр узгач, кар явар дип беләм,**
**Тагын тиздән язлар килә дим.**

**Йөрәк икән—яратмыйча типмәс,**
**Көрәш икән—җиңми калмабыз.**
**Гомер икән—бушка янып үтмәс,**
**Ә ил кушса—куркып янмабыз.**

## Хуплана

**Көймәнең—зур суда батмаганы,**
**Мылтыкның—кешегә атмаганы,**
**Баланың—дистәләп туганы,**
**Җилләрнең—болытны куганы,**
**Кизләүнең—мөлдерәп тулганы.**
**Кешенең—кешечә булганы.**
**Җиләкнең—вакытында өзгәне,**
**Йөрәкнең—сагынуга түзгәне,**
**Тинтәкнең—читтәрәк азганы,**
**Шагыйрьның—кыскарак язганы...**

Моннан тыш та бик күп нәрсә хуплана,
Әйткәннәрдән шундый фикер туплана:
Яхшылык—ул юлда текә яр төсле,
Менсен иде шушы үргә һәр кеше!

## Вислада су кергәндә

...Генрих—поляк. Ә мин—Казан улы
Бергә төштек талгын Вислага.
Мин Вислада йөзәм, ә күңелдән
Идел булып тулган хис ага.

Сине яклап, Идел, көрәшкәндә
Мин бу суда бата яздым бит.
Күптән йөрдем шуны ничек әйтим,
Ничек итеп шуны языйм дип.

Фашист атты миңа кат-кат төбәп,
Кат-кат атты... ләкин тимәде,
Йөрәк әйтте: ярга чык та ат,—дип,—
Качыйк моннан тизрәк!—димәде.

Арган тәнне Висла суы юды...
Текә ярга менә алдым мин.
Бу атышта шулай Идел өчен,
Илем өчен исән калдым мин.

Сез якыннар җанга, елга-күлләр,
Һәркайда да рәхәт сез тәнгә.
Әмма кочам Идел дулкыннарын
Нинди генә суда йөзсәм дә.

## Кырым чәчәкләре

Салкын болыт ятты бүген
Бөтенләй җиргә төшеп.
Без борчылдык: «Ә чәчәкләр
Шиңмәсләр микән өшеп?»

Мин тау түбәсендә идем,
Биектән күреп тордым;
Борчылдым, янар чәчәкләр
Хәленә кереп тордым...

Ә алар—җир йолдызлары,
Җир батырлары кебек,
Ут чәчеп күккә карыйлар
Һаман елмаеп-көлеп!

...Ут чәчәк шиңми, бары тик
Буш чәчәк шиңә икән.
Ямьсезне дә, суыкны да
Матурлык җиңә икән!

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кодаш

Кодаш авылы Биектау районында урнашкан һәм Айбаш җирле үзидарә советына керә. Кодаш район үзәге Биектау тимер юл станциясеннән 47 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Айбаш авылыннан—5, Казаннан 33 чакрым ераклыкта.

Бу авылда шушы хезмәтнең авторы, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе Фирдәвес Гарифҗан кызы Гарипова туып-үскән.

Авыл шактый күп тарихи чыганак-белешмәләрдә телгә алына.

Д.А.Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) Кодаш авылы теркәлгән һәм анда 55 яшаклы татар яшәгәнлеге күрсәтелгән. 1766—1861 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында Кодаш авылы Каракүл исемле күл һәм Ташлы чокыры янына урнашкан авыл дип искә алына. А.Артемьев хезмәтендә билгеләнгәнчә, Кодашта (XIX йөздә) 42 йорт булып, анда 151 ир-ат һәм 160 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән. Н.Н.Вечеслав китабындагы (XIX йөз) мәгълүматларга караганда, авылдагы 62 хуҗалыкта 189 ир-ат һәм 185 хатын-кыз көн иткән, агач мәчет булган. Халкы Кодаш авылы җәмгыятенә кергән. Кодаш авылын И.А.Износков болай сурәтли. Чыршылык чокыры янына, Гәреч сәүдә юлының уң ягына утырган Кодаш авылында 1872 елда 22 йорт каралты-куралары белән янып бетә. Авылдагы 68 хуҗалыкта ислам дине тота торган 187 ир-ат һәм 193 хатын-кыз яшәгән. Тормыш-көнкүрешләре бай, тегерменчелек, чабата ясау, умартачылык белән шөгыльләнгәннәр.

Н.Б.Борһанова мәгълүматларына караганда, Кодаш авылы халкы июнь ае ахырында күршедәге Зур Битаман, Кече Рәс авыллары белән бергәләшеп Кушкапка җыены үткәргән. Икенче төрле ул Кушнарат җыены дип тә аталган.

Авыл атамасының барлыкка килүе Кодаш исеменә нисбәтле дип уйларга нигез бар. Күрәсең, аны беренче башлап Кодаш исемле кеше нигезләгәндер.

И.А.Износков авыл халкын байлык белән гомер итәләр дип язуга карамастан, мин кечкенә вакытта юклыкка аптырап, Сахалинга кадәр киткән гаиләне хәтерлим әле. Алар киткәндә кышның бик салкын көне иде. Бөтен авыл халкы җыелып, аларны елап озатты. Китүчеләр исә бәхилләшеп, күз яшьләрен түгеп киттеләр. Әйбергә төрелмәгән зур, иске ястыклары чананың бер ягында моңаеп ятканы төшемә керә дә, сискәнеп уянам...

Коллективлашу вакытларында авылда әйбәт кенә торучы гаиләләрнең (шуларның берсе Көлек Хәйруллалары һ.б.) тормышын пыран-заран китереп, алар башка урыннарга күченеп утырганнар. Ул гаиләләрнең зур-зур алма бакчалары авыл халкына истәлек булып калган иде. Әлеге бакча әле дә исән.

Сугыш елларында авылда (1942—1944) минем әтием (Гарифҗан Шакирҗан улы) колхоз рәисе булып эшләгән. Бер елны ул икмәк өлгерүгә, колхозга бирелгән

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

йөкләмәне (заданиене) үтәгәнгә кадәр үк, халыкның хезмәт көненә ашлык бүлеп бирдерткән. Авылның кайбер кешеләре, бу хәлне гаепкә санап, аның өстеннән район хакимиятенә шикаять язып җибәрәләр. Тикшерү каты була. Тикшерергә килүчегә ул болай җавап бирә: «Тракторларны кырга чыгарыр алдыннан май салалар, атларны ашаталар. Җимертеп эшләр өчен үз тамагың, балаларың тамагы тук булу, күңелең тынычлыгы кирәк». Бәхеткә, аны бу эше өчен төрмәгә утыртмый калалар.

Әти рәис булып эшләгәндә беркемне дә суд юлында йөртми, төрмәгә утырттырмый. 1944 елда ул үз теләге белән рәислектән китә.

Кодаш авылының утырган җире искиткеч матур. Аның тирәсен инеш, күлләр, чишмә-кизләүләр, коелар, урманнар һәм болын бизи. Бакчабыз янынннан агып үткән инеш балачагымның җуелмас бизәге булып хәтеремдә калган. Бераз гына көннәр җылыту белән янындагы үзәндә бөтен дөньябызны онытып уйнадык, суында тирләп-пешеп ташбаш сөздек, каз бибиләрен шул инеш янында саклап, ата казлар белән сугыштык. Янәшәдәге Ышна һәм Кәләпүш тауларына көненә йөз генә мәртәбә мендекме икән? Алар артындагы Күл безне гел үзенә тартып тора иде. Каз бибиләре бераз исәю белән, Күлгә хуҗа була идек. Коенып чыгуга Кече урманга йөгерәбез. Кечкенә генә бу урманда җиләк һ.б. урман нигъмәтләре белән тукландык, арыганчы уйнаганнан соң, чишмәләр суыннан авыз итеп тагын күлгә юнәлә идек. Балачакның бу бәхетле мизгелләре зәңгәр офыклар артында калды... Алар күңел бизәкләре, юаткыч хатирәләр булып гомер буена саклана.

Күлдән Ювас авылы ягына таба барганда зур булмаган бер калкулык Ханнар зираты дип атала. Түмгәкләнеп торган урыннарны таптамыйча гына, шыпырт кына яныннан үтеп китә идек. Аның артында Кәрәкәле күл. Ул күлне бик тирән диләр. Үзе зур, уртадагы сулары каракучкыл булып күңелне шомландырып һәм куркытып тора. Аның янына барырга курка идек, шулай да сирәк кенә карап кайта торган гадәтебез бар иде. Кәрәкәле күлдән ун якка китсәң, кечкенә генә түгәрәк шикелле, өсте тулы төнбоеклар үскән Урман күле... Янында урман юк, ләкин кайчандыр ул булган, исеме әйтеп тора. Соныннанрак ул күлне халык Сәйпи күле дип тә йөри башлады, чөнки анда Сәйфетдин исемле бер кеше батып үлгән. Ул күлне дә бик тирән, хәтта төпсез дип сөйлиләр. Элек янында мүк җиләге бик мул була иде. Мүкле күлдә мүк күп үсә иде...

Югарыда искә алынган Буа янында Зиннәтулла исемле абзый (авыл халкы аны Хәки Зиннәте дип йөртте) үзенең шактый зур гаиләсе белән көн итте. Яннарында зур өянке агачы үсте. Буа янындагы бу урынны авыл халкы гомер бакый Кирәмәт асты дип йөртте. Авыл халкының болай эшләргә ярамый дип кат-кат әйтүенә карамастан, көннәрдән бер көнне бу зур агачны Хәки Зиннәте кискән. Шуннан соң озак та тормый Зиннәтулла абзыйның матур гына кызы аяксыз калды, гомере буе култык таягы белән йөрүгә дучар булды.

Авыл янындагы зират турында уйлаганда да йөрәгем кысыла. Минем дә анда әби-бабаларым, әти-әнием, сабый чакта ук вафат булган имчәктәш туганнарым, туганнан-туганнарым, нәсел-нәсәбем... Авыл зираты әйбәтләп тотып алынган, каберләр тазартылган, ташлар куелган. Зират хәзер авылга таба шактый зурайтылган. Чөнки мәрхүм булучылар бик күбәйгән. Казаннан авыл зиратына алып кайтып күмүләр дә ешайган.

Кодаш кайчандыр шау-гөр килеп яшәгән күңелле авыл иде. Хәзер ул кечерәйде. Хуҗалыклар саны 50 чамасы. Ләкин минем күңелемдә авыл зур, олы. Һәм шулай булып калыр да. Йортларга газ керде. Әле юллар асфальтланмаган. Мәчет бар. Китапханә, мәктәп юк.

***Редакциядән.***

*Бу айда галимә, журналыбызның даими авторы Фирдәвес Гарипованың түгәрәк юбилее. Аны ихластан туган көне белән котлыйбыз! Тазалык, күңел көрлеге, алга таба да безнең белән хезмәттәшлек итүен теләп калабыз.*

## Әхәт Сафиуллинга 75 яшь



Язучы Әхәт Хафизулла улы Сафиуллин (әдәби тәхәллүсе—Әхәт Хафизулла) 1936 елның 26 декабрендә Украинаның Донецк өлкәсе Путилов районы Путиловка бистәсендә шахтер гаиләсендә дөньяга килә. Әхәткә сигез ай тулганда, әти-әнисе туган якларына—Татарстанның Балык Бистәсе районы Иске Арыш авылына кире әйләнеп кайта. Булачак язучының балачагы һәм үсмер еллары шунда уза. Иске Арышта—башлангыч, биш чакрым ераклыктагы Балыклы Чүкәй авылында җидееллык һәм унбиш чакрымдагы Олы Солтан авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанга килеп, төзү осталары әзерли торган техника училищесында укып һөнәри белем ала. Бу елларда ул республика яшьләренең матбугат басмасы «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы һәм Казан авиация заводы эшчеләре газетасы «Алга» редакциясе каршында эшләп килгән әдәби иҗат түгәрәкләренә яратып йөри, каләм тибрәтә башлап, үзенең беренче өйрәнчек хикәяләрен, шигырьләрен яза.

Ул 1966 елда Казан төзүче-инженерлар институтының кичке бүлеген тәмамлый һәм 1992 елга кадәр Казан шәһәренең төзелеш оешмаларында эшли, мастердан төзү идарәсенең баш инженеры дәрәҗәсенә кадәр озын хезмәт юлы уза.

Әхәт Сафиуллин бер үк вакытта әдәби иҗат эше белән дә даими шөгыльләнә. Баштарак ул үзенең күңел ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен генә язгандай була, әсәрләрен матбугатка тәкъдим итәргә ашыкмый. Шуңа күрә аның язган әйберләре җитмешенче еллар ахырында гына газета-журналларда күренә башлый, 1982 елда беренче проза китабы («Язларында ялгыз йөрсәң...») дөнья күрә. Хәзер ул—төрле нәшриятларда чыккан унлап китап авторы. Алар арасында бәян һәм хикәя җыентыклары, юмор-сатира, балалар өчен язган әсәрләр, шигырьләр, истәлек китаплары бар.

1992 елда төп хезмәт урыныннан лаеклы ялга чыкканнан соң, Ә.Сафиуллин үзенең көч-сәләтен журналистикага багышлый: әүвәл юмор-сатира журналы «Чаян»да, аннары «Заман-Татарстан» газетасында эшли, «Ватаным Татарстан» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге хезмәткәре вазифасын башкара.

Әхәт Сафиуллин—1991 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Юныс Әминевның тууына 90 ел

Юныс Әминевнын пьесалары сугыштан сонгы татар драматургиясенен үзенчәлекле бер өлешен алып тора.Аларда тормыш чынбарлыгы, тамашачыны җәлеп итә алырлык сөйләм теле—Ю. Әминев драматургиясенен төп сыйфатлары.

Ю. Әминевның әдәбиятка килүе —укучыларда татар әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләү белән бәйле. 1921 елнын 1 декабрендә Татарстанның Әгерҗе районы Салагыш авылында туган егет 1936-39 елларда Минзәлә педагогика училищесында укый, аннары Актаныш районында мәктәптә балалар укыта. 1940 елда исә гаскәри хезмәткә алына, хәрби мәктәптә укый, взвод командиры сыйфатында фронтка җибәрелә, немецлар белән барган сугышта яралана, әсир төшә. 1944 елга кадәр Совет гаскәрләре азат иткәнче Румыниядәге хәрби әсирләр лагеренда тоткынлыкта була. Тикшерү үткәннән соң 1945 елда яңадан фронтка җибәрелә, сугышны ул Прагада тәмамлый.

Сугыштан кайткач Ю. Әминев үзенең яраткан хезмәтен—укытучылык эшен дәвам иттерергә теләсә дә, тоткынлыкта булу аңа комачаулык тудыра, бераз вакыт чит төбәкләрдә төрле эшләрдә хезмәт куя. 1947 елда ул укытучы булып эшләргә рөхсәт ала һәм Әгерҗе районы Баржы авылы мәктәбендә укыта. Читтән торып Алабуга укытучылар институтында белем ала.

Ю. Әминев әдәбиятка узган гасырның илленче елларында килә. Иң беренче әсәрләреннән булган «Язылмаган законнар» исемле пьесасы Минзәлә драма театры тарафыннан сәхнәгә куела һәм Ю. Әминевны сәләтле драматург итеп таныта. Әлеге әсәре 1957 елда Мәскәүдә уздырылган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында да югары бәя ала.

Ю. Әминевның барлык әсәрләре дә диярлек төрле театрларда куела. Заманы өчен актуаль булган үзешчән сәнгать коллективлары да, Татарстанның Әлмәт, Минзәлә Күчмә, Башкортстанның Салават, Сибай театрларында «Минем җинаятем» (1962), «Умырзая чәчәкләре» (1959), «Ужым бозавы» (1966) һ.б. әсәрләре уңыш белән бара.

«Умырзая чәчәкләре», «Гөлҗәннәтнең җәннәте» пьесалары Татар дәүләт академия театрында да куела.

1959-61 елларда Ю. Әминев Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институтының икееллык Югары әдәби курсларында укый. 1969 елда ул гаиләсе белән Әлмәт шәһәрендә яши башлый. Нефтьчеләр тормышы белән бәйле булган бу мохит Ю. Әминев иҗатына яңа төсмерләр өсти. Аның әсәрләрендә производство-хезмәт, шәһәр тормышы темалары киң яктыртыла. «Кан кардәшләр» (1972), «Сафура бураннары» (1975), «Сөймим дисәң дә...» (1975) әсәрләре нәкъ шундыйлардан. Танылган драматургның Әлмәт шәһәрендә яшәп иҗат итүе Әлмәт татар драма театры өчен дә файдалы була, автор алар белән иҗади дуслыкта яши, ул чор идеологиясенә хас булган, патриотик темаларга язылган, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләгән әсәрләре әлеге театрның даими репертуарында була.

Ю. Әминев утыз еллык иҗат гомерендә ике дистәдән артык сәхнә әсәре иҗат итеп, үзен комедия, драма, психологик драмалар остасы итеп таныта. Үзе исән вакытта уннан артык китабы дөнья күрә. Ул 1958 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Драматургия һәм театр сәнгате өлкәсендәге казанышлары, татар драматургиясен баетудагы хезмәтләре өчен аңа 1981 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Ю. Әминев 1982 елда Әлмәт шәһәрендә вафат була.

# ИГЕЛЕК ИЯСЕ

...Фәиз абый белән хушлашканга да инде 14 елдан артык вакыт үтеп киткән. Тәнкыйтьче, әдәбият белгече, публицист, шагыйрь, «Идел» журналының баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәй нибары кырык алты яшендә фаҗигале төстә һәлак булды...



Яңа гасырда яшәүче буын әдип хакында ни-нәрсә белә ала икән дип интернетка күз салдым, ике язма таптым.

«Фәиз Мәүлит улы Зөлкарнәй 1951 елның 4 декабрендә Башкортстанның Бакалы районы Сөендек авылында туа. Куштирәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, авылда клуб мөдире, мәктәптә лаборант һәм рәсем укытучысы булып эшли. 1970-1972 елларда армиядә хезмәт итә. Аннары колхозда механизатор, соңыннан Азнакайда янгын сүндерүче хезмәтләрен башкара. 1974 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1979 елда аны тәмамлап, берникадәр вакыт Мәдәният министрлыгының халык иҗаты йортында социолог, 1980—1983 елларда «Ялкын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1983 елдан Татарстан китап нәшриятына эшкә күчә. 1987 елда Мәскәүгә Югары әдәби курсларга укырга китә. 1989 елда татар яшьләренең әдәби-иҗтимагый-сәяси «Идел» журналында баш мөхәррир урынбасары булып эшли башлый. 1991 елдан журналның баш мөхәррире итеп сайлана...»

Икенчесе—торгынлык дип аталган дәвердә Фәиз Зөлкарнәйнең Уфада татар яшьләре өчен әдәби журнал чыгаруны сорап-дәгъваләп КПССның Генераль Секретаре Л.И.Брежневка язган хаты һәм шул хаттан соң башына төшкән бәлаләр хакындагы язма. Монысы «Тулпар» журналы сайтына урнаштырылган.

Бары тик ике язма... Алгарышлы һәр яңалыкка—шул исәптән интернетка да—хәерхак караган, «Идел» журналын да татар яшьләренең маягы итеп күзаллаган, шул хакка хәл кадәри гомерен багышлаган шәхескә карата бик аз түгелме соң бу мәгълүматлар?!

***

Узган гасырның туксанынчы еллар әдәбиятын укып, татарның мәдәни вә иҗтимагый хәл-халәтеннән хәбәрдар кешеләр белә торгандыр: бу дәвердә милләтнең рухи язмышын кайгырткан галим-голәмә, әдәбият-сәнгать әһелләренең бер төркеме «Идел» журналы тирәсенә берләште, аларның фикере, әйтер сүзләре «Идел» аша халыкка иреште.

Шәхсән үзем дә «Идел»нең Фәиз Зөлкарнәй дәверендә эшләдем. Аның урынбасары, аркадашы вә мәсләктәше, фидакарь зат—Рәфикъ Юныс, ә журналның шигаре—«Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!»—иде. Менә хәзер шул еллардагы саннарны актарып утырам. Инде уңа-саргая да башлаган «Идел» ул заманнарда үз кыйбласына—шигаренә тугры булган! Янәшәдә генә—журналның узган елгы, быелгы саннары... Җентекләп актарып карасам, сискәнеп киттем: затлы кәгазьдә басылган, һәр бите төсле сурәтләр белән бизәлгән «Идел»дә мәгънәле маяк-шигарьгә урын калмаган икән инде...

Әйе, зыялы затларны үзенә тарту сәләте, оештыру көче зур иде Фәиз Зөлкарнәйдә. Ил агасы—олпат әдипләр белән дә, әле яңарак кына каләм чарлый башлаган яшьләр

белән дә үз итеп гәп кора, бәхәсләшә, аралаша иде ул. Яшьләр дигәннән... Цензура кайчысыннан зарланган Равил Сабырга (бүгенге көндә—талантлы хикәяче, танылган драматург) ул мондый киңәш биргән иде: «Баш мөхәррир дә кабул итәрдәй, укучы да ни әйтергә теләгәненне аңлардай итеп тә язып була ич кыю әйберне. Бер уйласаң, болай язуы читен, икенче яктан исә—кызыклы, язу кимәленне сынап карыйсың». Кыскасы, Эзоп теле—мәңгелек.

Безнең өчен Фәиз абый чын мәгънәсендә остаз булды. Һәер, белүемчә, өлкәнрәк Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Рәдиф Сәгъди, Ләис Зөлкарнәй, Заһид Мәхмүди һәм Зөлфәт Хәкимнәр дә әсәрләрен иң әүвәл аның хөкеменә тапшыралар, ә инде остазның: «Булган бу!»—дип ике генә сүз белән югары бәһа куюы исә бик сирәк хәл иде. Чөнки юк-бар мактау сүзләренә гаять дәрәҗәдә сак-саран иде ул. «Казан утлары» һәм «Идел»нең әдәби юнәлеш, рухият сагында торуын, кем-кем, ә минә зыялы зәвык иясе, милләтпәрвәр Зөлкарнәй бик яхшы белә иде.

Үз иҗатына ул аеруча таләпчәнлек белән карады. Исән чагында аның фәкать өч кенә китабы чыгып калган: «Кешем, асылың кем?»—әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм парчалар (ТКН. 1984.). «Әверелеш: шигырь парадокслары (ТКН. 1988) һәм «Чакма чакмый ут чыкмый»—әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм парчалар (ТКН. 1991).

Күренекле шагыйрьләребез Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмовлар иҗаты яисә яшьрәк буын әдипләрнең әдәби эзләнүләре турында язамы—ул һәрвакыт әсәрнең төп асылын тирәннән аңлап анализлый, һәр әһле каләмнең үзенчәлеген тоя белә иде. Мәсәлән, Равил Фәйзуллин шигъриятенә багышланган «Күзләрем һаман шулмы?..» мәкалә-эссесы—әнә шундый саллы хезмәтләренең берсе. «Өлешенә тигән көмешең», «Милли гамь ярында уйланулар» исә—эссе жанрының асыл үрнәкләре. Әдәби тәнкыйтьне Көнбатыш үрнәгендә эссе жанрына тарту, шул рәвешле нәфис әдәбият төренә әвереледерү омтылышын бездә иң әүвәле Фәиз Зөлкарнәй ясады. Тора-бара бу юнәлешкә Салих Маннапов (Мөдәррис Вәлиев), Наис Гамбәр һәм Марсель Галиләр дә ныклап торып юл салдылар.

Менә Фәиз Зөлкарнәйнен «Мәңгелек учак» эссесыннан бер генә җөмлә-гыйбарә: «Мон—гүя үтә нәзек ефәк җеп, һәм шагыйрь шул җепкә сәйлән-сәйлән сүзләр тезә...» Янә бер мисал: «Сүзләрнең гаҗәеп табигый янәшәлеге белән хисләрнең көтелмәгәнчә тансык янәшәлеге бергә туры килүне шигърият диләр!»—кыска, төгәл бәяләмә...

«Әверелеш: шигырь парадокслары» инде менә чирек гасырга якын шигырь, әдәбият теориясе белән шөгыльләнүчеләргә, студентларга файдалы вә игелекле китап буларак хезмәт итә.

Игелек дигәннән... Фәиз Зөлкарнәй төзегән «Татарча борынгы хәрби терминнар сүзлеге»ннән тарихи әсәрләр язучы әдипләребез һәрдаим файдалана дип беләм. Аның «Заманча иҗтимагый-мәдәни мәгънәләр сүзлеге» исә «Идел» журналында 1995 елда дөнья күргән иде. Ни кызганыч, бу сүзлекләрнең берсе дә аерым китап рәвешендә чыгып өлгермәде...

***

Алтыннары булмаса да, Дәрдемәндкә охшатам мин аны. Аз сандагы фәлсәфи-сагышлы шигырьләре белән. Милләт мәнфәгатьләренә багланган тугры максаты белән. Зыялы зәвыгы белән. Фани дөньяда бик аз яшәп тә, татарга китергән игелеге белән...

*—Миңа мизгел кирәк!—*
*Бар дөньяны яктыртырга—*

ди Фәиз Зөлкарнәй соңгы шигырьләренең берсендә. Ни аяныч, гомере дә мизгел сыман гына булды. Әмма шул мизгелдә дә ул рухи халәтебезне савыктыруга үз өлешен кертеп өлгерде. Игелек иясе иде ул.

**Марат ЗАКИР**

# 2012 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

(МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1433-1434 ҺИҖРИ ЕЛЛАР)

**20 гыйнвар**—һиҗрәт кичәсе көне. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

**4 февраль**—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**21 май**—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**22 май**—мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хаҗы кылына.

**24 май**—Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич—Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**16 июнь**—Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**21 июнь**—дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбан ае башлану көне.

**4 июль**—Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**20 июль**—чират изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе—14 август.

**19 август**—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**24 октябрь**—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**25 октябрь**—Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**26, 27, 28 октябрь**—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**15 ноябрь**—1434 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**24 ноябрь**—Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

*Төзүче-мөхәррир*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

**Рабит БАТУЛЛА:**

—12-14 октябрь көннәрендә Төньяк Кыбрызда (Кипр) «Төрки Дөньядагы әдәби журналлар конгрессы» (Turk Dunyasi Edebiyat Dergileri Kongresi) булып узды. Бу инде Дүртенче конгресс. Ул кырым татарларының классик язучысы Чыңгыз Дагчының якты хатирәсенә багышланган иде. Мәрхүмнең ватанына кайта алмыйча жирсүе һәм чит-ят жирдә вафат булуы, васыяте буенча җәсәден Кырымга, туган туфрагына алып кайтып жирләүләре турында монсу фильм күрсәтелде.

Җыенга утыздан артык төрки телле журналларның вәкилләре килгән иде. Анда Төркия, Казакъстан, Кырым, Иран, Гыйрак, Әзәрбайжан, Үзбәкстан, Башкортстан, Косово, Голландия, Кыргызстан, Румыния, Македония, Карачәй-Балкар, Татарстан вәкилләре катнашты. Мин җыенга «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы һәм актив авторы буларак бардым. Аны ТӨРЕКСОЙ, Ауразия Язучылары Берлеге һәм Кыбрыз Төрек Якын Көнчыгыш университеты бергәләшеп оештырган иде.

Иң мөһиме шулдыр ки, төрки телле халыкларның вәкилләре бер-берсен сагынган, юксынган һәм һәркайсының бер-берсе турында беләсе, үзара аралашасы килә. Төрки телле милләтләрнең журналлары бу эшне үз өстенә алырга, бер-берсенең әсәрләрен бастырырга тиеш.

Шушы өч көн аралашу гына да безне якынайтты, һәр милләт вәкиле үз ана телендә сөйләде, кайбер очраклардан башка, тәржемәсез аралаштык. Ачык итеп татарча сөйләсән, сине төрекләр, балкарлар, карачәйләр, каракалпаклар, кумыклар, казакълар, үзбәкләр, кырым татарлары, кыргызлар, гагаузлар яхшы ук аңлаячак. Дәрдемәнднең, Тукайның, Заһир Бигиевнең иҗатын яхшы белгән (гомумән, ана телен яхшы белгән) һәр татар төрекчәне һәм башка төрки телләрне яхшы төшенәчәк.

Һәр халык вәкиле үрнәккә үзенең әдәби журналын алып килгән иде. Мин дә үзем белән берничә журнал алдым. Шулар өстенә «Казан утлары»ның 1000нче санына багышлап чыгарылган энциклопедик китапны—«Сүнмәс утлар балкышы»н ике данә алып бардым. Университетның фойесына журналларны күргәзмәгә куйдылар. Тәнәфескә чыккач, күрдек: «Казан утлары» журналларын һәм «Сүнмәс утлар балкыш»ын кемдер чәлдергән иде. Ихтимал, университет студентларыдыр. Ярый әле «Сүнмәс утлар балкыш»ының бер данәсен ТӨРЕКСОЙга тапшырып өлгергән идем. Бу сөенеч, әлбәттә, чөнки «Казан утлары»быз башка утыз журнал арасында әллә каян күренеп, балкып тора, тышлык татар милләтенә кагылышлы рәсемнәр белән бизәлгән: берсендә Кол Шәриф мәчетенең мәһабәт рәсеме, икенчесендә «Акмулла» сурәте, өченчесендә Сөембикәбез хан сараенда дивани мәҗлестә катнаша. Күләме ягыннан да безнең журнал иң калыны һәм 1000 санына җитүе белән дә иң абруйлысы булып чыкты.

Алган тәэсирләрнең нәтиҗәсе: безгә—кардәш халыкларга еш аралашу зарури; төрки дөньядагы иң яхшы әсәрләрне һәр журнал һәрдаим тәржемә итеп бастырырга тиеш; уртак әлифбага мохтаҗлык хәттин ашкан; Гаяз Исхакый, Акдәс Курат, Садри Максуди, Баттал Таймас, Сәгадәт Чыгытай, Йосыф Акчура, Муса Акъегетзадә, Зәки Вәлиди һәм башка мәшһүрләребез турында Төркиядә тупланган мәгълүматны үзебезгә, мондагысын аларга тапшырырга кирәк; алар турында чыккан китапларыбызны һич тоткарлыксыз төрекчәгә тәржемә итеп, Төркия нәшриятларына тәкъдим итәргә вакыт; уртак шәхесләребез турында һәм документаль, һәм нәфис фильмнарны Төркия киночылары белән Татарстаннықылар уртак эш итеп башкарсын иде.

Бишенче конгресс киләсе елда Казакъстанда, Астана каласында узачак.

## НИК ЕЛЫЙСЫҢ, ТАКТАШ?

Редакциябезнең бер бүлмәсендә Такташ портреты бар. Биналарында ремонт үткәреләсе дип Язучылар берлеге аппараты вакытлыча (?) башка җиргә, кысан урынга күчереләсе булгач, безнең егетләр Берлектән алып кайткан иске рәсемнәрнең берсе ул. Шул Такташны күргән саен үзенә күрә бер тетрәнү кичерә идем. Чөнки, яшь түкмәсә дә, Такташыбыз елый. Авыр бер елау белән елый. Газаплана. (Төсле рәсемне журнал өчен ак-карага күчергәч, бу халәт җуела төшкән.) 12нче санны әзерләшеп йөргән бер мәлдә аңа баккач, бигрәкләр дә авыр булып китте. Нигә елаганын белми торып тынычлана алмаячагымны тойдым. Бу—күңелемә индерелгән бер хәбәр-фәлән дә булды, ахрысы. 8 декабрьдә бөек шагыйребезнең вафатына 80 ел тула икән бит.

Шагыйрьне нигә шундый итеп күргәнен рәссам үзе сөйли алыр иде. Ләкин аның исеме язылмаган шул. Рәссамнарга, белгечләргә, шагыйрьне бик тә үз итүчеләргә шалтыраттым. Тик «Еглаучы Такташ»ны (минем башка килгән исем, укучыларыбыз, бәлкем, шәбрәген дә табар?) белүче булмады.

—Такташны күргән-белгән кеше генә иҗат итә ала моны, Җәгъфәр Булат түгел микән?—Гүзәл Сөләйманова шулай диде. Гүзәл—сәнгать белгече, Алтын Урданы үз иткәнгә кыерсытылган хәлдә дөнья куйган (1984) сәнгать белгече Фуад Вәлиевнең кызы. Ләкин Җәгъфәр ага (1903-81), автор булган хәлдә дә, берни дә сөйләмәс шул инде.

Шулай да, мондый газаплы хәлне кайчан кичерә алган соң Такташ?

«Үзе усал, үзе болай бер дә усал түгел кебек шикелле» Алсуны, ягъни Гөлчирәсен җуйгач түгел микән? Уллары Рафаил язуынча, рабфакта укыган, әле 17нче яше белән генә барган Гөлчирә Хәмзина тулай торактагы бүлмәдәшләренә «Такташ миңа тәкъдим ясады» дигәч, тегеләре көләләр генә. Шуннан кызый ярсып чыгып китә дә, күпмедер вакыттан бүлмәгә Такташның үзен җилтерәтеп алып керә!.. Ләкин гаилә ныклы булмый шул. «Шөһрәт сөючән, боерырга яратучан, үсәргә теләүче» (Такташның сеңлесе Хәнифә сүзе бу) Гөлчирә укырга Мәскәү университетына китеп бара һәм юрист (прокурор) буларак шәп кенә карьера ясый. Кияүгә чыга, аерыла. Һәм гомере буе (48 яшьтә үлә) үкенеп яши. Такташның туганнарын онытмый, ул үлгәч, аларга ярдәм дә иткәли. Такташ та аны онытa алмый. Гөлчирәнең хатларын укыганда үтә нечкә күңелле шагыйрь, шәт, еламый калмагандыр.

Уллары Рафаил Гөлчирә укыган елларда Такташ белән яши. «1930 елда әни Казанга кайтып, мине алдап-юмалап Уралга алып китә. Ни өчен алдап-юмалап дигәндә, мин әтине бик ярата торган булганмын»,—дип яза Р. Такташ. Дүрт яшьлек улыннан аерылганда да шагыйрьнең үзәккәе өзелгән, әлбәттә.

Гомере нигә утыз яшендә очланган соң бөегебезнең? Мунчадан кайтышлый салкын сыра эчкәч, кайтып урынга егылды, бер ел элек башына суык тиюдән дә бик каты авырган иде, дип сөйләгән икенче хатыны, икенче Гөлчирәсе. (Ни дисең инде моны: нәкъ шул чакны аны дәваларга тиешле профессор үлә!) Агулаганнар дигән шик тә була. Такташка багышланган фәнни конференциядә «Бу дөресме?» дигән сорау бирелгәч, шагыйрьнең тормышын энәсеннән җебенә хәтле белгән галимә Лена Гайнанова: «Әйе, агулап үтергәннәр»,—ди. Аннары өсти: «Аның тәнен түгел, җанын, тормышын агулаганнар». Лена ханымнан җавапны шәрехләвен үтенгәч, ул миңа болай дип сөйләде:

—Бөтен хәл-халәте шуңа китергән аны. Бик авыр, үтә киеренке тормыш кичергән Такташ. Редакцияләрдә ал-ял белми эшләгән ул. (Нужа да эшләтә инде. Ач йөргән чаклары да була хәтта.) Әдәби иҗатка вакыты да калмаган. Олуг талант иясе буларак, көнчеләр чолганышында яшәгән. Шулар тырышлыгы белән аны, «Азат хатын»ны журнал иткән кешене, редакциядән кысрыклап чыгаралар. Җиде ай буе эшсез яшәгән ул! Квартирга түләмәгән өчен андагы бөтен мөлкәтен (өстәл,

шкаф, кәнәфи!) аздан гына аукционнан сатмый калалар. Матбугатта чыккан төрле пасквильләр белән (күбесе аноним) аннан сәяси дошман ясарга теләүчеләр дә күп була. Фәүзия Бәйрәмованың «Атылган йолдыз» пьесасы буенча Яшьләр театрында куелган спектакльдә олуг язучыбызның «Такташизм» дигән мәкаләсен укыганнан соң Такташ күз яшьләре түгеп елый. Тормышта еламагандыр дисезме? (Елагандыр, әйе. Чөнки язучысы кем бит! Хатыны (үзе дә әдибә) «Аның үз гомерендә беркайчан да Һадидан да якын дусты булмады» дигән бит әнә.—Р. Ю.). «Кулак элементлар» дип Сыркыдыда әтисе белән әнисе тавыш бирү хокукыннан мәхрүм ителә, Казанда энесе Габидулла белән сеңлесе Хәнифә уку йортларыннан куыла. Бу кадәр дә оятсызлыкны жинеп чыгар өчен нык кына йөрәк бозарга туры килә Такташка...



Бик күпләр, шул җөмләдән Галимҗан Ибраһимов тарафыннан да ясалган көчле «кызыл басым» тәэсирендә «Такташ үлде» дигән шигырь язу, ягъни элекке, хөп-хөр, ип-ихлас, «гыйсьянчы» Такташны «гүргә индерергә» мәҗбүр булуы да кайта-кайта газапка салгандыр аны.

Гүр дигәннән, әнисе Шәмсениса апа Һадие үлгәннән соң чыгарган бәет искә төште.

*Кай җирләрдә, балам, синең кабереӊ?*
*Каен бармы кабереӊ янында?..*

Бу портреттан Такташның рухы да карап тора сыман. Безгә шагыйрьнең вафатыннан соңгы хәлләр өчен дә газап чигеп, рәнҗеп багадыр кебек ул. Такташ нигә Тукай, Әмирханнар янында түгел, Ял паркындагы «туганнар каберлегендә», кызыл түрәләргә кардәш булып күмелгән соң? Житмәсә, тирән коры елга да елдан-ел якыная бара әнә. Үлчәдем, Такташ каберен аннан хәзер нибары—биш, күршесе Галиәсгар Камал каберен өч кенә адым аерып тора. Алар бергә өчәү җирләнгән—янәшәдә тагын актер Камал I дә бар. Шөкер, аларны Яңа бистә зиратына күчермәкчеләр бугай.

—Бер еллап элек моңа минем ризалыгымны сорадылар, гариза яздырдылар,— диде Рәмзия Такташ. Рәмзия ханым шагыйрьнең икенче хатынынннан туган улы Аванның (мәрхүм инде) хатыны, озак еллар Опера-балет театрының әдәбият бүлеге мөдире булып эшләгән кеше.

Пушкин урамындагы Такташ яшәгән йорттан истәлек тактасының фотокүчермәсе генә торып калды. Шәһәр башкарма комитеты аны йоткан бинада—университет «Уникс»ында Такташ музее өчен ике бүлмә бирергә дип карар чыгарган булса да.

—Шуннан соң бары бер генә төрле җавап ишеттем,—диде миңа Рәмзия ханым: Университет бирми. Ректор риза түгел.—Күп зуррак мәйданны теш клиникасына арендага бирергә бик риза булганнар югыйсә!..

Музей да юк, һәйкәл-фәлән дә юк... Казан халкы бөек шагыйребезне котсыз Такташ урамы яисә телдән төшмәс «Такташ группировкасы» аша күзалларга тиеш микәнни?

Такташның рәсми-ялтыравык түгел, тормышчанрак образын тудыру омтылышы да вафатына ярты гасыр тулганда гына ясала. «Хәнифә Такташева бүгенге көндә Казанда яши икән». «Гөлчирә Такташева-Мансурованың Казанда яшәгәнлеген белеп, аны эзләп таптык». 1980 елда чыккан «Такташ турындагы истәлекләр» дигән китаптан алынды болар. Бу «эзләү» Такташның өч томлык «Сайланма әсәрләр»ен әзерләү уңаеннан (1980-1983 елларда дөнья күрде) житмешенче еллар азагында башкарыла. (Бик күп башка туган-тумачалары да табыла, бай гына мәгълүмат туплана). Югыйсә әлеге шәхесләрнең беренчесе, Такташның бертуган сеңлесе, Казанда 1926 елдан, икенчесе, Такташның икенче хатыны, 1929 елдан бирле яшәп ятканнар бит инде! (1983 һәм 1984 елларда дөнья куялар).

*Миннән соң туачак җырчыларның*
*Даны күмәр минем атымны...*

Юк, Такташ, сине беркем дә артка чигерә алмады. Кадереңне генә белеп житкермәдек менә...

**Рәфикъ ЮНЫС**

# 2011 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ**

Татарстан Республикасында 2011 елны Габдулла Тукай елы дип игълан итү турында. № 3

2011 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында. № 6

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның композитор Нәҗип Җиһановның тууына 100 ел тулу уңаеннан мөрәҗәгате. № 2

***

Польшада татарга һәйкәл куелды. Польша президенты Бронислав Коморовскийның һәйкәл ачу тантанасындагы чыгышы. № 1

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил Фәйзуллин. Сыналабыз, әмма сынмабыз. № 1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әдһәм Г. Әтнәби. *Хикәя*. № 9

Әмирханов М. Әлвидаг. *Тарихи бәян*. № 11

Баттал Ф. Альтернатива. *Хикәя*. № 10

Галиуллин Р. Өч хикәя. № 1

Галиуллин Р. Номерың кем? *Хикәя*. № 8

Галиуллин Т. Китек көзге. *Бәян*. № 9

Камалов Х. Сугыш зигзаглары. *Бер солдат хатирәләре*. № 5

Кәрами Р. Сөеп туймас чакларың. *Роман*. №№ 7-9

Лашманчы С. Алман күчтәнәче. *Роман-элегия*. № 12

Мир-Хәйдәров Р. Җәяүле татар. *Бәян*. № 10

Мушинский Ә. Һаваларда—ак күгәрчен. *Роман*. № № 1-6

Мөдәррисова Х. Соңгы сер. *Бәян*. № 2

Мөхәммәдиев Р. Прәннекле төшләрем... *Хикәя*. № 7

Салах Ә. Үрләргә менгән чаклар. *Бораулаучы истәлекләре*. № 1

Хәсәнов А. Данәгөл. *Роман*. № № 7, 8

Хәсәнов Н. Золым. *Роман*. №№ 3,5, 6

Шәфигуллин Р. Тауиле гарасаты. *Кыйсса*. № 8

**ШИГЪРИЯТ**

Арсланова Р. Бик сагынып искә төшерермен. *Шигырьләр*. № 12

Әминева Н. Догам. *Шигырьләр*. № 2

Әхмәтҗан Р. «Ачлык мәйданы» циклыннан. № 8

Әхмәдиев Н. Бәгырьдә бар—ташлар. *Шигырьләр*. № 10

Бәдигый Х. И татарлар! *Шигырьләр*. № 1

Бәшәр Р. Бер җыр йөри күңелем түрендә. *Шигырьләр*. № 12

Булатова К. Фани дөнья—миңа үзе җәннәт. *Шигырьләр*. № 3

Вафин М. Дөньялар серле, серле!.. *Шигырьләр*. № 2

Галиев М. Тәхет җуйган халык—бәхет җуя... *Шигырьләр*. № 11

Гәрәева С. Якты хәтер яшәр... *Шигырьләр*. № 2

Гыйззәтуллина Ф. Яңу дәверләрендә. *Роман-поэмадан өзекләр*. № 9

Гаташ Р. Ихлас сүзем. *Шигырьләр*. № 3

Гыйләҗев И. Онытмасагыз иде. *Шигырьләр*. № 1

Диндаров И. Ә гасаби уйлар бөтереп ала. *Шигырьләр*. № 6

Җамал Р. Үткәннәрдән кайтып киләм... *Шигырьләр*. № 9

Җиһангирова Ш. Ачам һаман бер үк фал. *Шигырьләр*. № 5

Ибраһим Б. Өй артына... Яңа заман килгән. *Шигырьләр*. № 8

Идиятуллин Р. Кайту. *Шигырьләр*. № 2

Корбанова Г. Тургай җаны, Тукай моңы бездә. *Шигырьләр*. № 7

М а й о р о в а  Р. Шуны тели йөрәк. *Шигырьләр.* № 11

М а н с у р о в  З. Тамыр буйлап ага хәтер... *Шигырьләр.* № 1

М и ң н у л л и н  Р. Ике тамчы каен яше. *Шигырьләр.* № 6

М и р з а  М. Адәм баласы. *Яңа бишьюллыклар.* № 3

М ө х ә м м ә т ш и н  Г. Безнең гомер. *Шигырьләр.* № 10

М ө х и я р  Р. Кем биргән соң безгә очар канат? *Шигырьләр.* № 8

Н и з а м и  Р. Яшәүгә гимн. *Поэма-рапсодия.* № 7

Н у р и  З. Ышану. *Шигырьләр.* №12

Р ә ш и т  Ә. Яшәү диңгезендә. *Шигырьләр.* № 3

С а ф и н а  Н. Яңа җыр алып киләм. *Шигырьләр.* № 11

С ә г ы й д у л л и н а  Л. Чиксезлек чикләрендә. *Шигырьләр.* № 11

С у ф и я р о в  Ф. Юлаучыга юлдаш булам. *Шигырьләр.* № 6

Ф а з л е т д и н о в  И. Төнге күктән бага... ат күзләре. *Шигырьләр.* № 8

Ф ә й з у л л и н  Р. Яңа шигырьләр. № 12

Х а р и с  Р. *Сонетлар.* № 5

Ш ә е х  Л. Әйтелә сүзләр, әйтелә. *Шигырьләр.* № 5

Ш ә р и ф у л л и н а  Э. Тәрәзәм саен гөлләр. *Шигырьләр.* № 6

Ш ә р и п о в  Ә. Күкрәгемдә көн дә бер яңара... *Шигырьләр.* № 10

Я н с у а р  Л. Риваятьләрдә без—яңа исем... *Шигырьләр.* № 8

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

З ә й д у л л а  Р. Шул булды эш... *Драма.* № 12

**ПУБЛИЦИСТИКА**

З а к и р  Л. Сәяси парчалар. № 2

С а б и р о в  И. Татулык та, горурлык та кирәк! № 10

Ш ә р и ф у л л и н  Н. Яңа мөгез, яки зиһен йокысы һәм албастылар турында. № 4

«Шомалыкны, шомаларны сөймим!» *(Р. Юнысның Адлер Тимергалин белән әңгәмәсе).* № 2

Ю н ы с  Р. Берләшик! № 6

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Г а л и у л л и н  Т. Акыл һәм хис берлеге шагыйре. *(Р. Хариска 70 яшь)* № 5

Игътибар үзәгендә—балалар әдәбияты *(И.Ибраһимов, Г.Гыйльманов, Р.Зәйдулла, Р.Рахман, Л.Минһаҗева, Р.Корбан чыгышлары).* № 8

Х а н н а н о в  Р. Төрек-татар әдәби бәйләнешләре. № 2

Х ә с ә н о в а  Ф. «Мәхәббәт шагыйрен таный белегез!» *(Р. Гаташка 70 яшь).* № 3

Н ә җ и п о в а - З и н н ә т у л л и н а  Ә. Гомер балкышлары *(Ф. Галимуллинга 70 яшь).* № 3

Ю н ы с  М. Тормыш сәхнәсендә. № 3

Ш ә м с у т о в а  А. «Алдымда—чикле чиксезлек.» *(Р.Аймәтнең иҗат портретына штрихлар).* № 11

Ш ә я х м ә т о в а  М. Ил мәшәкате, халык моңы *(Г.Рәхимгә 70 яшь).* № 7

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

А х и р. Колак. *Сатирик кыйсса.* № 7

Ә б л и е в а  Л. Кырмыскалар йорт салалар... *Шигырьләр.* № 12

Ә х м ә д и е в  Н. Алтын балык турында заманча әкият. *Шигырь.* № 4

Ә х м ә т г а л и е в а  А. Җырлап яши Мөхәммәтҗан. *Сатирик кыйсса.* № 12

Б а т т а л  Ф. Баттализмнар. № 11

Б а т у л л а  Р. Батуллизмнар. № 12

Б ә д р и  Р. Нитәләр! *Шигырь.* № 4

Г а л и у л л и н  Р. Дан. *Хикәя.* № 11

Г ы й л ә җ е в  Ф. Денсезләр авылы. *Шигырьләр.* № 4

Җ а м а л е т д и н о в а  Ф. Карак һәм ашказаны. *Хикәя.* № 9

З а р и п о в  Р. Яңартылган мәкальләр, әйтемнәр. № 1

Л е р о н  Л. Шадра юморкалар яки нормальный робагыйлар. № 3

М и ң н у л л и н  Т. Минһаҗ маҗаралары. № 5

М о р а т  С. Ил белән... *Шигырь.* № 6

М ә җ и т о в  Ф. Замана чибәркәенә. *Шигырь.* № 12

М ө х т ә с и п о в  М. Юкны бушка аудару. *Мәсәл.* № 6

М ө х ә м м ә т ш и н  Р. Яңа тормыш. *Шигырь.* № 10

С а ф и у л л и н  Ә. Тормыш җае. *Хикәя.* № 10

С а ф и н а  М. Теге дөньяга хат. № 3

С ә й л ә н. Авыл мәктәбен япкач,

мөгаллимнәре ни диләр? № 2

Рәсем бездән—җавап сездән. №№ 3, 6

Хәким З. Бармы ришвәткә дәва?.. *Сатирик комедия.* № 8

Хәмзин А. Имгәк. *Хикәя.* № 9

Хөснияр З. Инструктор. *Эстрада монологы.* № 7

Чулпан. Хөкем. *Хикәя.* № 6

Юныс Р. Эш күп әле. *Шигырь.* № 9

**ФӘН**

Галләм Р., Нәккаш—Исмәгыйль. Беренче татар басмасы. № 10

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №№ 1-12

«Манифест»ның хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе. № 10

Мәрдәнов Р. Мансур Хәлляҗ кыйссасы. № 1

Мөхәммәтҗанова Л. Казан татарлары иҗатында китаби дастан. № 11

**ТАРИХ**

Мостафин Р. Җамал Вәлиди фаҗигасе. № 5

Насыйров Т. Татар матбугатының авыр хәле. № 2

Самат Ш. Матбугат йорты. № 4

Таһиров И. Татар ничек барлыкка килгән? № 5

Фәткуллин Ф. Мохтар Әүэзов һәм Муса Җәлил: әдәби бәйләнешләр тарихы. № 2

**СӘНГАТЬ**

Алмазова А. Нәҗип Җиһанов һәм татар музыка сәнгате. № 9

Газиев И. Граммофон тәлинкәләре ни сөйли? № 10

Сәгъди Р. Аның тормышы—театр... № 4

Хәйри Ә. Габдулла Кариев феномены. № 5

Шакиров Ә. Татар сәхнәсе даһие. №7

Шаһиева Р. Бөдрә таллар симфониясе. № 3

**ХӘТЕР**

Акъегет Р. Су йоткан авыл өстендә ялгыз көймә. № 3

Баттал Ф. Юксыну. № 5

Баттал Ф. Кадерлеләр һәм кадерсезләр. № 7

Галимуллин Ф. Якты шәхес, олы иҗат (*Кави Нәҗминең туууына 110 ел*). №12

Галиуллин Т. Шигърияткә багышланган гомер *(Нил Юзиевның туууына 80 ел).* № 1

Гыйлаҗев Т., Закирҗанов Ә. Музыкаль драма жанрына нигез салучы *(М.Фәйзинең туууына 120 ел).* № 11

Зыятдинов А. Такташ иленә ике сәяхәт *(Һади Такташның туууына 110 ел).* № 1

Курамшин Р. Онытырга хакыбыз юк *(Фәхри Насретдиновның туууына 100 ел).* № 10

Минһаҗева Л. Иманнең дә имане иде... *(Ибраһим Салаховның туууына 100 ел).* № 8

Мир-Хәйдәров Р. Чон-Таш—Чыңгыз Айтматовның соңгы сыеныр урыны. № 7

Нарбекова Һ. Кырык дүртнең июлендә. № 5

Рәхим Г. «Туры карап күзегезгә» *(Зәки Нуриның туууына 90ел).* № 12

Хәким Р. «Төшләргә кереп гел йөдәтә...» *(Сибгат Хәкимнең туууына 100 ел).* № 12

Сибгат Хәким турында замандашлары. № 12

Хәмзина А. Атаклы разведчик Ибраһим Аганин. № 5

Яруллин Ф. Хәтер төпләрендә утлы күмер. № 1-11

**Г.ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ**

Бөеклек баскычлары. №№ 1-4

Хәмидуллин Л. «Китап» ширкәте һәм Тукай. № 3

Әхмәтҗанов Р. Тукайның соңгы рәсеме. *Шигырь.* № 4

Батулла Р. Апуш-Тукай. *Кыйсса.* №№ 4-6

Батулла Р. Бер рәсем тарихы. № 4

Бер сорауга—бер җавап. № 4

Бөекләр сүзе. № 4

Дәминова Ф. Тукай, Казан һәм Тукайның Казан төбәгендәге туганнары. № 4

Зыятов Ф. Тукай Өчиледә. № 4

Миңнуллин Т. Ялгыш төзәтелергә тиеш. № 4

Миңнегулов Х. «Татар бәхете өчен мин җан атармын?» № 4

Рәмиев З. Тукай энциклопедиясе булырмы? № 4

Тукайга шигъри чәчәкләр *(М.Гафури, Ш.Бабич, Н.Исәнбәт, Х.Туфан,*

*Ә Фәйзи, Ф.Кәрим, С.Хәким, Г.Афзал шигырьләре.)* № 4
Хәмзин А. Оялтасың, энекәш. № 4

ЮБИЛЕЙЛАР

ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРИНСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ. № 3
ГАФУР КОЛӘХМӘТЕВНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ. № 5
МӘХМҮТ ГАЛӘУНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ. № 9
СОЛТАН ГАБӘШИНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ. № 5
ХӘЙРЕТДИН МӨҖӘЙНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ. № 3
СӘРВӘР ӘДҺӘМОВАНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ. № 4
ШИРИЯЗДАН САРЫМСАКОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 5
ГАРӘФИ ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ
Аяз Хәсәнов. НКВД күзе астындагы гомер. № 6
ӘДИП МАЛИКОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ. № 8
ЮНЫС ӘМИНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ № 12
РӘШИТ ГӘРӘЙНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 4
ХӘНИФ ХӘЙРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 9
РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ
Бәйрәмова Г. Рәхәт сагыну, татлы сагыш. № 4
ТӘУФИКЪ ӘЙДИНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ
Галиуллин Р. Әйдаман. № 5
ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ
Закир М. Игелек иясе. № 12

КОТЛЫЙБЫЗ!

БАСЫЙР РӘФИКОВКА 90 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 2
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВКА 80 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 10
СОФИЯ ГОБӘЙДУЛЛИНАГА 80 ЯШЬ
Юсупова Р. Бөеклек һәм көнделдәге яралар. № 11
ФАТИХ УРМАНЧЕГА 75 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 5
ИЛДАР НИЗАМОВКА 75 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 9
ӘХӘТ САФИУЛЛИНГА 75 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 12
СӘЙДӘ ЗЫЯЛЫГА 70 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 3
РИЗВАН ХӘМИДКӘ 70 ЯШЬ
Леров Л. Зыялы матурлык. № 10
ФОАТ САДРИЕВКА 70 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 3
ФАЯЗ ХУҖИНГА 60 ЯШЬ
«Алга—гасыр тирәнлекләренә!» *(Р.Галиуллинның Ф.Хуҗин белән әңгәмәсе).* № 8
МАНСУР ШАҺИМӘРДӘНОВКА 60 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 10
РАВИЛ БОХАРАЙГА 60 ЯШЬ
«Мин Казаннан китмәдем» *(Р.Галиуллинның Р.Бохарай белән әңгәмәсе).* № 11
МАНСУР ГЫЙЛӘҖЕВКА 50 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 1
ФӘРИТ ЯХИНГА 50 ЯШЬ
Редакция котлавы. № 1
МИҢНАЗЫЙМ СӘФӘРОВКА 50 ЯШЬ
«Чын журналистика—иманга тугрылык ул *(Р.Галиуллинның М.Сәфәров белән әңгәмәсе).* № 5
ЛӘБИБ ЛЕРОНГА 50 ЯШЬ
Закир М. Канатлы Ләбиб. № 11

КИТАП КҮЗӘТҮ

Вәли-Баржылы М. Шигъри җан бәяны. № 6
Миңнегулов Х. «Татар кызы»—«Хәят юлында». № 1

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Әпсәләмов Г. Онытырлык түгел. № 11
Сабитов Г. Хәвефле җәй. № 6

БЕЗНЕҢ МУЗЕЙЛАР

Низамиев Р. Гасырлар белән күзгә-күз. № 1
Низамиев Р. Җәлил белән очрашу. № 2
Низамиев Р. Тукай белән очрашулар. № 4
Тарих калка гасыр түреннән. № 1

ЮМОР-САТИРА

Гобәй Р. Мамадыш мәзәкләре. № 2
Сафина М. Әгәр син баем булсаң. *Шигырьләр.* № 7

АК ҖИЛКӘН

Балык Бистәсе районының Ямаш мәктәбе укучылары иҗаты *(Р. Сафин, Т. Мостафин, Р. Гаязова).* № 8
Бәләкәчләр Тукайны олылый. *(И. Ситдиков, Г. Галимова, А. Габидуллина, Н. Ситдиков).* № 7
Габделмәннанова Д. Менә шундый укытучы. № 6
Галиев Ф. Мәхәббәт хатирәсе. *Хикәя.* № 10
Гарәфиева-Шәрипова. Жеффи һәм Йомшакбикә. № 9

Гыйләҗев Ф. Мин ышанам, халкым, кайтыр язлар. *Шигырьләр.* № 2

Гыйззәтуллина-Хәмидуллина Р. Ишек шыгырдавы. *Хикәя.* № 8

Зур Сәрдектән «Ак җилкән»гә иҗат сәламе. (И. Горохова, Э. Хәбибрахманова, Н. Фәтхетдинова, Д. Габделманнапова) № 6

Зарипова А. Ике канәфер. № 10

Ибраһимова С. «Агым уңаена йөз!» № 10

Мамадыш районы Кече Кирмән мәктәбе укучылары иҗаты *(Д. Гыйззәтуллина, А. Исрафилова, З. Хаҗиева).* № 9

Мансуров А. Сине сайладым. *Шигырьләр.* № 10

Мостафин Ф. Якындагы ерак яктылык. *Шигырь.* № 4

Нәгыймуллина Д. Гөнаһлы җиһан. *Шигырьләр.* № 6

Нәҗмиева Ф. Әниләрдә—әниләр дә. *Шигырьләр.* № 11

Низами Р. Төсле карандашлар. *Хикәя.* № 9

Нургатина А. Туган авыл. *Шигырьләр.* № 9

Сабиров И. Икенче мәхәббәт. *Хикәя.* № 5

Сафина Л. Тәүге сөю. *Шигырьләр.* № 7

Фәтхетдинова Н. Мин ялкау түгел. *Шигырь.* № 6

Хәбибрахманова Э. Кар күрәүнең тәме. № 6

Хикәя яза аласызмы? №№ 3, 4, 5, 7, 9, 11

Хисамов З. Рәсемле кроссворд. № 2; Ребус. № 4; Чайнворд №6; Сканворд. № 10

Шакиров К. Шаян физик. № 1; Профессор мәсьәлә чишә алмаган. № 3; «Әһә!» дип башта кем әйткән? № 4; Табигать үзе шәбрәк белә. №5; «Ишәкләр белән очрашмыйм!» №6; Кеше исемендәге чәчәк. № 8; Ул үсмер чагында ук академик булган! № 9; Орбиталь станциядәге «куян». № 10; Бер планета—ике кояш. № 11; Томшыклы күршеләребез. № 1

#### БӘЛӘКәЙЛӘР

Батулла Р. Бәләкәй Батулла. № 1

Баттал Ф. Бәләкәй Баттал. № 2

Бәләкәй Тукай. № 4

Гаташ Р. Бәләкәй Гаташ. № 8

Зәйнуллин З. Бәләкәй Зәки. № 3

Кәримов К. Бәләкәй Камил. № 6

Лерон Л. Бәләкәй Ләбиб (Лемон, Ленарис). № 7

Мингалим Р. Бәләкәй Рөстәм. № 11

Мостафин Р. Бәләкәй Рафаэль. № 5

#### ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Фәизов Р. Инрәп ауды манара. №4; Чаналар китте. №5; «Күңелле поезд». №6

#### ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

Гомәр Г. Тотып ярырлык итмәдек. № 1; Дөрес әйттем, гой! № 7; Органга—өрделәр. № 9

#### ФИКЕР

Закиров З. Динебез турында уйланулар. № 9

#### ТАТАР ГАЛӘМЕ

Батулла Р. Язучы сәфәрдән кайтты. № 12

Гаратуев М. Йоклады дип бирмиләр ошбу җиһанда мәртәбә. № 4

Тимербулатов Х. Ул Ялтада, ләкин ял итми. № 2

#### РӘСЕМ ҺӘМ ИСЕМ

Юныс Р. Ник елыйсың, Такташ? № 12

#### УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Сиражи Р. *Шигырь.* № 9

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№ 2-11

Укучы сүзе № 1, 7, 10

2012 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. № 12

«Казан утлары»—интернетта № 2, 5

«Матбугат. ру»дан безне укыгыз. № 5

«Казан утлары» архивыннан. №№ 1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№ 1-12

Хушлашу сүзе (Рафаэль Мостафин. № 5; Шәүкәт Галиев. № 6; Гали Акыш. № 9)

### БОЛГАР ФОРУМЫНА ӘЗЕРЛЕК

ТР Дәүләт Киңәшчесе, Республика тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне торгызу фондының Химаячеләр советы рәисе Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә 2012 елда халыкара Болгар форумына әзерләнү һәм аны үткәрү мәсьәләләре буенча киңәшмә уздырды.

Әлеге форум тәүге тапкыр 2010 елның 19-21 июнендә борынгы Болгар шәһәрендә үткәрелгән иде. Аның максаты—Болгар цивилизациясе белән шөгыльләнүче белгечләрне берләштерү, мәдәният һәм туристлык үзәге буларак, Болгар музейтыюлыгын үстерү, Болгар цивилизациясе чыганакларын тирәнтен өйрәнү. Икенче форум исә 2011 елның 21-23 маенда Казанда уздырылып, Идел-Урал төбәге генә түгел, бәлки, Алтай, шулай ук Көнчыгыш Европаның бай тарихына бәйле проблемалар буенча фикер алышу мәйданчыгына әйләнде. Шуңа күрә өченче, дүртенче халыкара Болгар форумын Алтай Республикасында һәм Болгариядә үткәрергә тәкъдим ителде.

### «ВАТАН» ЯШЬЛӘРНЕ ТӘРБИЯЛИ

Республикада ике елга бер мәртәбә уза торган яшьләрнең «Ватан» халык иҗаты фестивале үтте. Анда 7 яшьтән алып 30га хәтле балалар һәм яшьләр катнашты. Фестивальдә төрле халыкларның фольклор коллективлары үз йолаларын күрсәтте. Әтнәдән Әлфис Кыямов Гран-prига лаек булды. Аны тапшырганда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Мондый фестивальләрдә катнашу балаларны дөрес тәрбияләргә, республикада яшәүче халыкларның мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен сакларга ярдәм итә»,—дип белдерде.

### «ЕВРОПА-АЗИЯ»ГӘ 10 ЯШЬ

21-23 октябрьдә башкалабызда X халыкара «Европа-Азия» заманча музыка фестивале булып узды. Анда Германия, Бельгия, Болгария, Черногория, Израиль, Япония, Вьетнам, Казакъстан, Әрмәнстаннан, Россиянең төрле шәһәрләреннән музыкантлар катнашты.

«Европа-Азия» заманча музыка фестиваленә 1992 елда халыкара татар һәм япон музыкасы фестивале үткәрелгәннән соң нигез салына. Аны Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Композиторлар берлеге гамәлгә куя. 10 ел эчендә фестивальдә 25 илдән композиторлар, музыкантлар катнашты.

Фестиваль башланыр алдыннан булып узган матбугат очрашуында Израильдән килгән композитор һәм дирижер Б.Юсупов бу чараның мөһимлеген ассызыклап, аның музыка ярдәмендә илләр, халыклар арасында дуслык урнаштыруда зур роль уйнавын искәртеп узды. Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган, бүгенге көндә Германиядә яшәүче композитор И.Харисов әйтүенчә, «Европа-Азия» фестивале Татарстан Республикасының йөзен билгели һәм Европада безнең җөмһүриятебезне шактый дәрәҗәдә әнә шул фестиваль аша беләләр.

Фестиваль электән килгән гадәт буенча «La Primavera» дәүләт камера оркестры, Яңа музыка оркестры һәм композитор, дирижер Б.Юсупов катнашында симфоник концерт белән башланып китте. Камера концертлары «Казан Кремле» музей-тыюлыгындагы «Эрмитаж-Казан» үзәгендә, Татарстан Милли музеенда һәм С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залының камера залында узды. Фестиваль Зур концерт залында гала-концерт белән тәмамланды

### ТАТАР ВИКИПЕДИЯСЕ

Быел җәй Татар Википедиясе 10 000 мәкалә чиген узды. Бу Википедиянең татар бүлеген башка Википедияләр рәтендә чираттагы югары дәрәҗәгә куя. 10 мең мәкалә чигенә Википедия махсус программа (бот) ярдәмендә Татарстан торак пунктлары турында мәкаләләр язу нәтиҗәсендә иреште.

Википедия проекты 2001 елның 15 гыйнварыннан ирекле универсаль интернет-энциклопедия буларак эшли башлады. Монда автор һәркем була ала. 2002 елда «Вики» технологиясен куллана башлагач, Википедия киң тарала башлады. Төрле телләрдә бу энциклопедия бүлекләре ачыла башлады. Телләр бүлекләре арасында иң зуры—инглиз Википедиясе (3 миллионнан артык мәкалә). Рус Википедиясендә мәкаләләр саны 700 дән арта.

Википедиянең татар бүлеге 2003 елның 15 сентябрендә ачылды. Башта ул тулысынча латин әлифбалы булды. 2009 елның язынннан башлап, Татар Википедиясе актив рәвештә кириллица әлифбасын куллана һәм зур популярлык яулый башлый.

2009 һәм 2010 елларның «Татнет йолдызлары» бәйгесендә Татар Википедиясе «Туган тел» номинациясендә беренче урын яулады.

Татар Википедиясе катнашучылары бу юбилей белән барлык татар җәмәгатьчелеген тәбрикли һәм актив рәвештә Татар Википедиясе эшчәнлегенә кушылырга чакыра. Татар Википедиясе адресы: tt.wiki pedia.org.

## ГЫЙЛЕМ ИЯЛӘРЕН БАРЛАУ ТАРИХЫ

«Татар галимнәренең беренче бөтендөнья форумы» (Казан, 2010, 230 бит, 1000 данә) китабы 2007 елның 19-21 сентябрендә узган гыйльми җыенны искә төшерә. 2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын үтәү максатында нәшер ителгән әлеге тупланма пленар утырышта һем гуманитар, табигать, техник фәннәр секцияләрендә яңгыраган чыгышлар белән таныштыра. Төзүче Булат Хәмидуллин шулай ук ТР Фәннәр академиясе каршындагы татар галимнәре координация советының эш кагыйдәләренә дә урын биргән. Советның 21 әгъзасы турында кыскача мәгълүмат та урнаштырган.

## ТӨРКИЯДӘГЕ ТАТАРЛЫК

Татарлар һәм Татарстан турындагы яңа басмалар зур кызыксыну уята. Бу уңайдан шушы арада Төркия Республикасында нәшер ителгән берничә басма игътибарга лаек.

Шуларның берсе—«Евразия тюркологларының биобиблиографик сүзлеге» (I том, XX гасырның Россия тюркологлары) дип атала. Ул төрек һәм рус телләрендә дөнья күргән. Фундаменталь энциклопедик характердагы әлеге китапта төрки халыкларны өйрәнүгә багышланган фәннәр һәм галимнәр турында төпле мәгълүмат бар. Сүзлек ТЮРКСОЙ төрки мәдәниятләре халыкара оешмасы һәм аның генераль директоры, профессор Д.К. Кассинов тырышлыгы белән дөнья күрде. Аерым алганда китапта күренекле галимнәребез—милләттәшләребез Һади Атласи, Гайнетдин Әхмәров, Хуҗа Бәдигый, Габделбарый Баттал, Җамал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Шамил Мөхәммәдьяров, Әдһәм Тенишев, Миркасыйм Госманов һәм шулай ук Осман Акчаокраклы (Кырым), Николай Ашмарин, Василий Бартольд, Александр Баскаков, Василий Богородицкий, Василий Радлов, Дмитрий Васильев, Владимир Вильяминов-Зернов, Лев Гумилев, Николай Катанов, Сергей Кляшторный һәм башкалар турында мәгълүматлар бар.

Икенче зур басма төрек телендә нәшер ителгән һәм «Yirmi Birinci Yuzyilda Idil Ural» (XXI гасырда Идел-Урал регионы) дип исемләнгән. Тышлыгы Казан Кремле һәм Кол Шәриф мәчете сурәте белән бизәлгән 433 битле бу китапта күренекле галимнәрдән Хәлил Инәлҗик, Хәдичә Ширин Үсәр, Әминә Горсой-Наскали, Мостафа Үнәр, Азаде Гайшә Рорлих, Надир Дәүләт, Ләйсән Шаһин, Али Акыш Әйшән, Услул Бәйрәмлиләр белән бергә Мирфатыйх Зәкиев, Ильяс Камаловларның да фәнни хезмәтләре урын алган.

## ТАЛАНТЛАРГА ИГЪТИБАР

Әлмәттә «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте һәм Татарстан Язучылар берлегенең Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләрен тапшыру тантанасы булды. Башта С.Сөләйманова исемен йөрткән урамда, шагыйрәнең бюсты янында шигъри митинг үткәрелде. Кичен тантананың дәвамы Әлмәт Татар дәүләт драма театры бинасына күчте. Быел бу чара шунысы белән үзенчәлекле булды, ул танылган шагыйрь, прозаик, байтак еллар Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы сәркәтибе булып эшләгән, С.Сөләймановaның ире Әдип Маликовны 90 еллыгы уңаеннан искә алу кичәсе дә иде.

Быел Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә «Газзәбану» китабы өчен—Гөлчәчәк Галиева, «Мөнирстан» китабы өчен Нур Әхмәдиев, «Авыл кызы» китабы өчен Ләйсән Кәшфи лаек булды. Кызыксындыру премияләре татар прозаиклары хикәяләр җыентыгының төрек телендә бастырып чыгарганы өчен—Фатих Котлыга, «Из века в век» дип аталган татар поэзиясе антологиясенә кергән шигырьләрне тәрҗемә иткән өчен—Наил Ишмөхәммәтовка, «Болытта җиләк үсә» дигән китабы өчен Айгөл Әхмәтгалиевага тапшырылды.

Болардан тыш, ун яшь каләм иясе (алар төрле югары уку йортларындагы студентлар) бер ел дәвамында С.Сөләйманова исемендәге стипендия алып торачак.

Бүләкләрне «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары, «Рухият» рухи янарыш фонды директоры Рөстәм Мөхәммәдиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Гарифҗан Мөхәммәтшин, тәрҗемәче, галимә Гәүһәр Хәсәнова (соңгы икесе С.Сөләйманова бүләге ияләре) тапшырды.

Тантанада катнашучыларны Әлмәт шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Ирек Фәррахов сәламләде. Кичәдә Сажидә Сөләйманова һәм Әдип Маликовның улы Әнвәр Маликов та катнашты.

## ШӘЛЕДӘ—ПРЕМЬЕРА

Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт Яшь тамашачы театры үзенең сезонын Питрәч районының Шәле авылында ачып җибәрде. Андагы мәктәпкә Г.Тукайның сөйгән кызы Зәйтүнә Мәүледовага (күренекле язучы Атилла Расихның әнисе) ис-

тәлек тактасы куелды. Заманында ул әлеге мәктәптә эшләгән булган. Зәйтүнәне шушы авылда яшәүче Мөслимә Зарипова әле дә хәтерли. Тантанадан соң узган сезонда уңышларга ирешкән артистлар бүләкләнде. «Иң яхшы ир-ат роле» төренә «Тискәрегә—авызлык» спектаклендә Петруччоны уйнаган Илфат Камалиев, «Иң яхшы хатын-кыз»га шул ук әсәрдәге Катарина өчен Лилия Низамиева һәм «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз»дагы Зөлфия ролен башкарган Гөлнур Шиһапова лаек булды.

Соңыннан тамашачы кариевлылар уйнавында Рабит Батулла әсәре буенча куелган «Зәйтүнәкәй» дигән премьера карады.

### ЧИЛӘБЕДӘ ҖӘЛИЛ УРАМЫ

Чиләбенең яна микрорайонында төзелә башлаган урамга Муса Җәлил исемен бирәчәкләр. Бу хактагы карар шәһәр хакимиятенең урамнарга исем бирү комиссиясе утырышында кабул ителде. Соңгы 2 елда Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемнәре шагыйрьләрнең 125 һәм 105 еллык юбилейлары уңаеннан Уралда еш искә алынды. Шуңа күрә җирле хакимият яңа урамны татар халкының горурлыгы булган шагыйрь исеме белән атауга каршы килмәгән. Быел язын Чиләбедә Тукай урамы да барлыкка килгән иде.

### УРАМ БӘЙРӘМЕ

Исеме борынгы «Идегәй» халык дастанында «Урмандагы Саба» дип телгә алынган Байлар Сабасындагы дүрт чакрымга сузылган төп урамнарның берсе Габдулла Тукай исемен йөртә. Бөек шагыйребезнең 125 еллыгы уңаеннан шушы урамның бәйрәме уздырылып, ул бик күп кызыклы чаралар белән үрелеп барылды. Мәсәлән, ике йөзгә якын шәхси хуҗалыгы булган Тукай урамының 35нче йорты танылган язучы, хикәяләр остасы Мәгъсум Хуҗин белән бәйле. Ул биредән олы иҗатка һәм тормышка юл алган. Шул уңайдан истәлек тактасы ачу тантанасы булды. Саба муниципаль районы башлыгы Рәис Миңнеханов, әдипнең каләмдәше Тәлгат Нәҗмиев Мәгъсум Хәмит улының иҗаты белән таныштырып, хатирәләре белән уртаклашканнан соң, мемориаль такта өстендәге ак япманы төшерделәр.

Әлеге чарада әдипнең кызы Ләйлә, бертуган сеңлесе Нурания ханым катнашып, әтиләренең һәм абыйларының исемен мәңгеләштергән өчен олы рәхмәт сүзләре җиткерделәр.

### ЮБИЛЕЙЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

***

«Г.Исхакый һәм М.Җәлил премияләре лауреаты Зиннур Хөснияргә дә 50 яшь тулды». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында язучының юбилей кичәсен алып баручылар Алсу Каюмова белән Эмиль Талипов әнә шулай дип башлап җибәрде. Юбилярны Мәдәният министрлыгының идарә эшләрен башкаручысы Кадрия Идрисова, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов тәбрикләде. «Салават күпере» журналы баш мөхәррире буларак та аның тырышлыгын билгеләп үттеләр. З.Хөснияр әсәрләреннән өзекләрне Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләлов, артистлар Раил Шәмсуаров, Алмаз Гәрәев укыса, аның туган ягына багышлап язылган җырларын Илназ Миңвәлиев, Булат Нигъмәтуллин башкарды. Кичәдә шулай ук Г.Тукайның 125 еллыгы уңаеннан укучылар арасында «Салават күпере» оештырган конкурста җиңүчеләр дә бүләкләнде.

***

С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче һәм драматург Равил Бохараевка 60 яшь, иҗат эшчәнлегенә 40 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. Бәйрәмдәрны республика җитәкчелеге исеменнән Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева тәбрикләде һәм Равил Бохараевның Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә танылган шагыйрьләрнең берсе булуын билгеләп үтте. Вице-премьер юбилярга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Рәхмәт хатын укып ирештерде. Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең Рәхмәт хатын тапшырды. Тантана хуҗасын шулай ук Мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис һәм республиканың башка мәдәният-сәнгать әһелләре котлады.

Бүгенге көндә Равил Бохараевның 40 проза һәм поэзия китабы бар, ул татар мәдәниятен якын һәм ерак чит илләрдә танытуга зур хезмәт куя. Кичәдә Казан яшь тамашачылар театры артистлары Р.Бохараев тәрҗемәләре буенча эшләнгән «Алтын Урда шигърияте» әдәби композициясен башкарды, аның «Әкият» Татар дәүләт курчак театрында «Апушның тылсымлы төшләре» пьесасы буенча куелган спектакльдән өзекләр күрсәтелде. ТР Дәүләт кыллы квартеты Равил Бохараевның хәзерге көндә иҗат ителә торган әсәре—«Мәхәббәткә шәрехләр» музыкаль драмасыннан өзек белән таныштырды.

***

Арча балалар сәнгать мәктәбендә шагыйрь һәм галим (ветеринария фәннәре докторы), фән һәм техника буенча Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Рифат Корбановның (Җамал) 60 яшьлегенә багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

Кичәне Арча муниципаль районы

башкарма комитеты житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Надия Мифтахетдинова ачып җибәрде һәм ул бәйрәмдарга район башлыгы Алмас Назировның котлавын ирештерде.

Аннары сәхнәгә юбилярның авылдашы, Социалистик Хезмәт герое Галимулла Әсхәдуллин күтәрелде.

- Син безнең өч герой үстергән Миржәм авылының дәрәҗәсен тагын да күтәрдең. Мин синең белән чын күңелдән горурланам.

Рифат Җамалны шулай ук каләмдәшләре Ринат Мөхәммәдиев, Шаһинур Мостафин, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Рифә Рахман, галим һәм рәссам Нәжип Нәккаш, танылган җырчы Мирсәет Сөнгатуллин, хезмәттәшләре—«Вамин-Татарстан» ширкәте җитәкчеләре тәбрикләде.

***

Танылган прозаик Нурислам Хәсәновның 70 яшьлеген язучының туган ягы Теләче районында зурлап билгеләп үттеләр. Юбилярны, аның белән бергә кайткан каләмдәшләрен район чигендә милли киемнәр кигән кызлар ипи-тоз, чәкчәк белән каршы алды. Кунаклар башта район үзәгендәге туган як тарихы музеен карады, китапханәдә булды

Юбилей тантаналары район үзәгендәге һәм язучының туган авылы Шәдкедәге Мәдәният йортларында үтте. Н.Хәсәновны Теләче муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Марсель Әсәдуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, каләмдәшләре Фәнзаман Баттал, Камил Кәримов, Рәфкать Кәрами, Тәлгат Нәжмиев, жирле житәкчеләр, туганнары котлады һәм изге теләкләрен ирештерде.

***

Арча районында якташлары шагыйрь, галим, әдәби тәнкыйтьче Хәнәфи Бәдигыйны 70 яшьлек юбилее белән котлады. Башта район үзәгендәге сәнгать мәктәбендә әдәби-музыкаль кичә булды. Бәйрәмдарны Арча муниципаль районы башкарма комитеты житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Надия Мифтахетдинова, Арчадагы әдәбият һәм сәнгать музее директоры Ринат Фазлыйәхмәтов, каләмдәше Минһаж Кашапов, авылдашы Расип хәзрәт Нәбиуллин, Казаннан кайткан кунаклар—Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, шагыйрәләр Сания Әхмәтжанова, Йолдыз Шәрәпова тәбрик итте. Аннары Х.Бәдигыйны үзе укыган Сеже мәктәбендә, кичен Арча педагогика көллиятендә зурладылар.

Котлаулар Хәнәфи Бәдигый язган, укучылар һәм студентлар укыган шигырьләр һәм башкарган җырлар белән үрелеп барды.

***

Октябрь ахырында күренекле шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе Әхмәт Рәшит Буа районында якташлары хозурында булды. Аны туган ягына 75 яшьлек юбилее уңаеннан чакырдылар.

Шагыйрь белән очрашу иң башта аның туган авылы Яңа Чәчкап авылында үтте.

Юбилей унае белән үткәрелгән төп чара Буа шәһәре Мәдәният йортында булды. Бәйрәмдарны Буа муниципаль районы башлыгы Рафаэль Әбүзәров котлады. Казаннан кайткан кунаклар—Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, «Мәдәни жомга» атналык газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров, шагыйрьнең җәмәгате, прозаик Мәдинә Маликова, якташ шагыйрьләр Йолдыз Шәрәпова белән Рифат Сәлах та үзләренең изге теләкләрен ирештерделәр.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «Кыш».

*Дүртенче биттә:* язучы һәм тәрҗемәче **Наил Ишмөхәммәтов**.

# «Казан утлары» 2012 елда

Иң әүвәл шуны белдереп узыйк: киләсе елның май аенда журналыбызның чыга башлавына 90 ел тула. (Башлангычын революциягә кадәр нәшер ителгән «Аң», «Шура» кебек әдәби журналлардан санасак, яшебез йөздән дә ашар иде). Әдәбиятыбыз тарихы, язучыларыбыз һәм укучыларыбыз өчен олы дата бу. Шуңа күрә журналның алдагы сәхифәләрендә басмабызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында гамьле чыгышлар, тарихи документлар, истәлекләр зур урын алачак. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп узыйк, хөрмәтле укучылар, сездә дә журналга мөнәсәбәтле материаллар, документлар, теге яки бу әсәр турында кызыклы мәгълүматлар булырга мөмкин. Безгә юлласагыз, без аларны журнал битләрендә файдаланыр идек.

Редакция портфелендә шактый әсәрләр тупланды. Шуларның бер өлеше белән сезне дә таныштырып китәбез. Аларның күбесе киләсе елда дөнья күрәчәк.

**Чәчмә әсәрләр**

**Т.Галиуллин.** Мәһдиев йолдызлыгы. Роман-эссе; **М.Кәбиров.** Бердәнбер һәм кабатланмас. Роман; **А.Хәлим.** Яңа хикәяләр; **С.Юзеев.** Мәрхүмнәргә сүз катмыйлар. Роман; **Ә.Зарипов.** Галиябану. Бәян; **Р.Габделхакова.** Кояшлы мизгел. Бәян; **Р.Галиуллин.** Кафе. Бәян. **М.Миншин.** Кызыл диплом. Бәян.

**Шигърият**

Әйдәп баручы шагыйрьләребезнең яңа шигырьләре һәм поэмалары **(Ф.Яруллин, Ә.Баян, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Миңнуллин, Г.Рәхим, Р.Гаташ, Л.Шагыйрьҗан, З.Мансуров, Р.Вәлиев, М.Мирза, М.Галиев, Ф.Гыйззәтуллина, И.Гыйлаҗев, Р.Зәйдулла, Г.Морат, Ә.Рәшитов, Р.Низами, С.Гәрәева** һ.б.)

**Публицистика**

**Т.Миңнуллин.** Үзгәрү (Үзем турында үзем); **Р.Шәрәфиев.** Кем белән берләшик?; **Н.Петров.** Крандагы су—эчемлекме, халыкны киметү коралымы?; **К.Йосыпов.** Гыйлем эстәгәндә; **Х.Шәриф.** Кая омтылабыз?

**Фән, әдәби тәнкыйть һәм сәнгать**

**Ф.Ислаев.** Яңа керәшен конторы: җитәкчеләре һәм кылган гамәлләре; **Р.Вәлиев-Карашәмле.** Иң соңгы «халык дошманы»; **Ә.Шакиров.** Х.Әбҗәлилов иҗаты; **Г.Тарханова.** Бәгырьләрдә Вакыт... Хәтер бәрелешә. **Ә.Закирҗанов.** «Яңа татар пьесасы»: нәтиҗәләр һәм бурычлар. **Р.Сверигин.** Хәзерге татар прозасы; **А.Әпсәләмова.** Г.Әпсәләмов иҗаты.

«Печән базары» конкурсының йомгагы 4нче санда биреләчәк. Ләкин «базар» ябылмый: сатирик әсәрләр киләчәктә дә шул сәхифәдә басылачак. «Ак җилкән»дә «Бәләкәйләр» сериясе һәм «Хикәя яза аласызмы?» конкурсы, шулай ук традицион «Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан», «Казан утлары» архивыннан» рубрикалары дәвам итәчәк.



Наил Ишмөхәммәтов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)